

# КАЗАН УТЛАРЫ

11
НОЯБРЬ
1981

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

11
НОЯБРЬ
1981

## Бу санда

**М. МӘҺДИЕВ.** Торналар төшкән җирдә. Лирик-документаль повесть . . . 3
**Р. ГАТАШ.** Бабич. Шигырь . . . 79
**Ә. ЕНИКИ.** Соңгы китап. Истәлекләр . . . 81
**Ф. САФИН.** Сандугач җыры. Шигырьләр . . . 101
**Л. ХӘЙДӘРОВА.** Кырым хикәясе. Хикәя . . . 105
**Г. МОРАТОВ.** Бер йотым су җитми кала. Шигырьләр . . . 124
**Р. ЗӘЙДУЛЛИН.** Сезнекеме! Шигырьләр . . . 126

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: ЭШЛӘР ҺӘМ КЕШЕЛӘР

**М. ӘМИРХАНОВ, Р. КИЛЬМАТОВ.** Яңа күпер . . . 129
**С. ШАКИР.** Ил һәм халык рәхмәте . . . 136

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**М. ВӘЛИЕВ.** Шагыйрь уты . . . 145
**Н. ЮЗИЕВ.** Уйлы туйра . . . 151

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Х. МӘХМҮТОВ.** Җыр хәзинәбез . . . 160

МИФТАХЕТДИН АКМУЛЛАНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

**М. ГОСМАНОВ.** Шагыйрьнең иҗаты һәм мирасы . 163
**Д. ГАРИФУЛЛИН.** Телдән телгә, кулдан кулга . 179

Кечкенә рецензияләр . . . 183
Безнең календарь . . . 186
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . 191

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

Баш редактор: **ЗӘКИ НУРИ**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** *(баш редактор урынбасары)*, **РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** *(җаваплы секретарь)*, **СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

---

**Редакциянең адресы:** Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.
**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

---

Производствога бирелде 23/VII-1981 ел. Басарга кул куелды 19/X-1981 ел. ПФ 09056. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,2). Тираж 102.944 экз
Заказ Д-282. Бәясе 50 тиен.

---

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

Мөхәммәт Мәһдиев

# ТОРНАЛАР ТӨШКӘН ҖИРДӘ

ЛИРИК-ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

## Әя, агач, яшең күпме?

Туган авылым шәһәрдән һәм район үзәгеннән ерак урнашкан, мин бала вакытларда анда юллар бик начар, көзге пычракларда, кышкы бураннарда авыл бөтенләе белән шәһәрдән, район үзәгеннән аерылып бетә иде. Ни сиңа телефон, ни радио! Ә авыл халкы эшкә каты куллы, колхоз, урман эшен сытып, җимереп эшли иде, безнең авыл күбрәк урман белән яшәгәнлектән, ирләр халкы урман кисү, агач әзерләү, визирь юлы ачу, ботак яндыру кебек эшләр башкара иде — ничә карасаң, колхоз идарәсе урнашкан йорт янына әле лесничий, әле лесхоз директорының аты килеп туктый иде. Авыр эш, авыр хезмәт, шунда кулы-аягы тайган, бармагы, кулбашы каймыккан кешеләр һәр атна саен булып тора иде. Ул вакытта Казанның Горький урамындагы ортопедия институты булгандырмы-юктырмы, әмма сөяк төзәтү, тайган буыннарны урынына утырту тулысы белән авыл карчыгы Маһиҗамал түти (авылда аны Майҗамал тәтә дип йөртәләр) кулында иде. Без — мәктәптә, пионер дружинасында им-томга, дини гореф-гадәтләргә каршы сугыш ачкан еллар иде ул. Урман эшендә без дә катнаша идек, бер көнне ниндидер бер үҗәт ботакка сөртенеп аягым каймыкты. Биш-ун минут эчендә аяк гөбе кебек шешеп тә чыкты. Мине арбага утыртып авылга алып кайттылар. Аннан Майҗамалтти янына алып чыктылар. Арбага утыртып. Үз гомеремдә беренче тапкыр «врачта приемда булдым». Хәзер аның дәвалау-савыктыру методикасы турында еш уйлыйм. Майҗамалттә иң беренче эш итеп су җылытты, суны эмальле зур чиста табакка салды да, шунда минем шешкән аягымны озаклап юды. Аннан суны алыштырды да, кулына гап-гади кер сабыны алып, шул су эчендә аякка озаклап массаж ясады. Аякның сызлавы кимегәннән-кими бара иде.

— Таймаган бу, балам, тайса мин аны тартып урынына утыртыр идем, — диде ул аякны сабын белән уа-уа. — Таймаган бу...

Икенче көнне мин яңадан урман эшендә идем. Безнең авылның әнә шулай тайган-сынганны урынына утырта, ялгый торган авыл «докто-

---

Ахыры. Башы журналыбызның унынчы санында.

ры» бар иде. Майҗамалттә, агачтан шиналар ясатып, көзгеме-язгымы сарык йоны белән урап, тайган-сынган сөякләрне урынына утыртып бәйләп куя иде. Сугыш алды елларында ул үлде һәм үзе белән халыкның зур тәҗрибәсен дә алып китте. Әмма традицияләр яши икән: вактөяк каймыгу, тамыр сузылулар булганда әле дә Майҗамалттә тәҗрибәсен кулланучы хатыннардан берәү бар икән. Халык медицинасы бу очракта фәнни медицинага каршы килмидер дип уйлыйм мин...

Майҗамалттә «ортопед» булса, безнең күршенең Бибинур түти (аны да «Бибинурттә» дип кенә йөртәләр иде) «киң профильле белгеч» иде. Моның һөнәре: сыер бозаулату, кайчы-пычак белән эш итү, үлән, чәчәк, бал, яфрак белән дәвалау иде.

Сыеры бозаулый алмый яткан крестьян төн урталарында зур хафа белән Бибинурттәнең ишеген кага, аны гозер белән чакыра иде. Әмма Бибинурттәнең бу мәшәкатьтән зарланганын, авырыксынганын авыл халкы хәтерләми. Андый «вызов» булганда ул аеруча дәртләнеп, башына бүрек, өстенә сырма киеп, чакыручы кешенең үзеннән дә узып ярдәм күрсәтергә ашыга һәм абзарга килеп керүгә җылы су, комган, тастымал сорап ала да, газап эчендә яткан бичара сыерга ярдәм күрсәтергә тотына иде. Безнең авылда «бозаудан үлгән», «үле бозау тапкан» дигән сүз, гомумән, телгә алынмый иде. «Бибинур килгәние... Шуннан соң...» дип кенә сөйлиләр иде авылда. Бибинур түти малай-шалайның аягын дәвалау буенча авылда беренче белгеч иде. Хәзер без еш кына авылда яланаяк йөргән вакытны сагынабыз. Уйлап куям: әгәр хәзерге кебек юньле аяк киемнәре булса, ялан аяк йөрелгән булыр идеме икән? Чөнки яланаяк йөрү — ике башлы таяк ул. Яланаяк тавык үләненә басып рәхәтләнеп уйнап йөреп була. Ләкин авыл табигате гел тавык үләненнән генә тормый. Каткак, камыл, үткер ташлы урыннар була: күгәргән кадак, пыяла кисәге, очлы тимер чыбык тырпаеп торган урыннар була. Тыраклап йөреп, аяк. җәрәхәтеннән җәфа чигеп җаен уздырган малайлар да була иде. Башка авылларда. Ә бездә... Әниең җитәкләп Бибинур апага бер тапкыр алып бара иде. Нибары бер тапкыр. Миңа да булырга туры килде анда. Шул ук методика: табак, җылы су. Аннан үткен пәке. Стерильный булмагандыр инде ул. Пәке белән ярып, юып, җәрәхәткә яфраклар салып бәйләп җибәрә иде Бибинур тәтә. Берсен хәтерлим: бака үләне яфрагын яба иде ул пәке тиерерлек булмаганда.

«Күзгә чүп керү» дигән афәтнең нәрсә икәнен бары тик авыл халкы гына белә. Шәһәр халкының күзенә чүп керми. Шәһәр халкының күзенә тузан, тополь мамыгы, корым керергә мөмкин. Әмма күзгә чүп керү... Бу инде — авылда гына була. Авылда «фәлән кешенең күзенә чүп кергән» дигән хәбәр көне буе йөри. «Әле ни хәлдә икән ул? Чүбен алдыLармы икән?» Алдылармы икән... Ә аны алу өчен Наһар түти кирәк. Аргыякта, Пуник очында яшәүче Наһар кирәк. (Безнең авыл ике урамнан булып, шул урамнар икешәр «оч»тан тора. «Аргыяк», «Биргеяк». Теге як өчен — без «аргыяк», безнең өчен — теге як «аргыяк»). Җыр да бар иде:

Аргыякка таш атам,
Биргеякка таш атам.
Аргыякның кызларына
Үлгән бака ашатам.

Моны алты-җиде яшьлек кызлар, язын тау башына чыгып, теге як кызларын күргәч, тамакларын ерта-ерта җырлыйлар иде һәм аргыяк— биргеякка, биргеяк — аргыякка карата күпмедер дәрәҗәдә «оппозиция» саклап яши, уйнаша, сугыша, җырлаша, аралаша бара иде. Ә, әйе, күзгә чүп керү... Наһар түти Пуник очында яши. Майҗамалттәдән арырак, урманга табарак, «Починок Поник» дигән керәшен авылына безгә караганда боларның очы ярты чакрымга якынрак. «Починок Поник» ун

чакрым булса, боларга нибары тугыз ярым чакрым... Күзенә чүп кергән кешене җитәкләп әнә шул очка — Пуник очына алып китәләр. Анда үзенең бер дә бетмәс талкы, тәрәш, каба кебек «җитештерү коралларыннан» арына алмыйча мәңге йөгереп йөрүче Наһар түти бар.

Капкадан кергәндә үк белә иде ул: бу кеше бәлагә тарыган. Арпа, арыш кылчыгы эләккән булуы мөмкин. Наһар түти, йөзенә җитди кыяфәт чыгарып, күлмәк итәкләрен як-яктан күтәреп кыстырып куя, тиз генә кулын юа башлый. Ә теге бичараның инде күзен кан баскан, ул инде сәкегә ауган. Күздән чүп алуның күп төрле ысуллары арасында берсе хәтердә калган: Наһар түтинең китап эчендә саклый торган ефәк җепләре була иде. Һәм төрле юанлыктагы шул җепләрнең берсен сайлап алып, чүпне шуның белән тартып чыгара иде. Ул безнең авылга утызынчы елларның башында килен булып төшкән иде. Бәлагә юлыкканнарга кырык еллар чамасы шулай ярдәм күрсәтеп яшәде.

...Мәрфугатти беренче бөтендөнья сугышы вакытында тол калып өч малай үстергән. 1941 ел июленең беренче атнасында Мәрфугаттинең өйләнгән өч улы да сугышка чыгып китте. Өчесе өч көнне. Мәрфугатти аларның һәрберсен басу капкасында озатып калды. Һәр улының малайлары бар иде, берсе — ике яшьлеге, этисе арбага утырып хушлашканда «Әт-ти! Әт-ти!» дип кычкырып калды. Мәрфугатти әнә шул улын тотып торды, ләкин күз яшен кешегә күрсәтмәде.

1941—42 еллар эчендә Мәрфугаттинең өч улы турында бер-бер артлы өч кәгазь килде: Ватан азатлыгы өчен көрәштә үлгәннәр. Мәрфугатти һәр хәбәр килгәч халык алдына чыгып елап йөрмәде, хәлен сорашкан кешеләргә:

— Шөкер, хәсрәтне күп күрдем,— дип кенә әйтә иде.

Кара кайгылы ул көннәрдән соң әле Мәрфугатти утыз еллар чамасы яшәде. Яшен кешегә әйтмәде. Халык арасында «аңа йөз яшь инде, тик ул күз тимәсен дип яшен яшерә» дип сөйлиләр иде. Ничек алай озак яшәгән ул?

...Мәрфугатти — урман карчыгы иде. Ул җәй буе урманда була иде. Кешеләр җиләккә кояш чыгып көянтә буе күтәрелгәч китәләр. Мәрфугатти исә кояш чыкканчы кызу-кызу атлап китеп бара һәм төш җиткәнче зур су чиләген мөлдерәтеп кура җиләге алып кайта иде. Ата-аналар балаларын аңа ияртеп җибәрергә тырышалар һәм кичтән белешеп тә куялар иде.

— Мәрфугатти... Иртәгә минем Миңнисламымны ияртмәссеңме икән?...

Бервакыт әни мине аңа ияртеп җибәрде. Кояш чыкмаган иде әле, мин гадәттән тыш ризасызлык белән йокыдан тордым, аны-моны капкаладым, йокы аралаш нәрсә капканымны белмәдем дә. Менә бервакыт әни дулкынланып:

— Мәрфугатти! — дип пышылдады.

Ындыр арты киртәләре буеннан, еш-еш атлап, бераз бөкрәя төшкән карчык урманга таба чаба иде. Мин дә йөгереп чыгып аңа иярдем. Мәрфугатти урманга барып җиткәнче бер сүз дәшмәде. Урман буена килеп җиткәч, чиләген агач төбенә куйды да, аның эченнән бер төргәк алды. Озын, туры, капчыксыман киндер күлмәк икән. Күз ачып йомганчы шул күлмәген өстән киеп куйды да, баш яулыгын алмаштырды. Нәрсәдер укыгандай итте, тәвәккәллек белән:

— Я, олан, башлыйк,— диде.

Башка көннәрдә без урманга кояш кыздырганда гына килеп җитә идек һәм куак арасыннан, сыдырыла-сыдырыла бер-беребез янына килеп, җыйган җиләкләребезне тикшерә идек.

Мәрфугатти исә алай сөйләшеп тормады. Капчык күлмәге белән ку-

раларны чожылдатып эчкә кереп китте һәм ике-өч сәгать буена миңа тамак кыргалап кына йөрде. Кояш кыздыра башлагач кына куралар арасыннан чыкты да, мөлдерәп тулган чиләген салкын күләгәгә куеп, өстенә әрекмән япты.

— Инде кышлыкка җыйыйк,— диде. Мин аңламадым. Аннан ул капчык күлмәген салды һәм гадәти чуар бала итәкле күлмәгенең тирән кесәләренә үләндер, ташборчактыр, кура яфрагыдыр, тагын әллә ниләр өзеп, сыдырып тутырды. Аннан карт юкә янындагы ашъяулык кадәр бер урындагы сары чәчәкләрне җыеп алды.

— Болары — суык тигәндә,— диде.

Аннан озынча сабаклы, сары чәчәкле үләнне йолкып ук җыйды.

— Менә шушыңа мәченең исе китә инде,— дип сөйләде ул.— Шушының тамырын иснәр өчен келәткә кереп әллә кайларга менә, төреп куйган капчыкларымны ертып бетерә.

...Аннан кыш буе авыл халкы Мәрфугаттигә дәвага йөри. Мәрфугаттинең келәт матчасына элгән капчыкларында кипкән кура җиләге, гөләп, кура яфрагы, бөтнек, тагын әллә ниләр була иде. Ә теге «мәче ярата торган» үләннең нәрсә икәнен мин 30—40 еллардан соң гына белдем. Мәрфугатти валериан үләнен җыйган икән.

Заманында Мәрфугатти турында мин район газетасында зур бер мәкалә бастырган идем. Ул мәкаләне Мәрфугаттигә укыганнар, ишетүемә караганда, карчык аннан бик риза калган. Авылга бер генә сәгатькә тукталган арада әни миңа бер төргәк бирде һәм шыпырт кына әйтте:

— Мәрфугатти бирде моны, суык тигәндә генә тотсын дип әйтте:

Төргәк эчендә яфрагы-ние белән сыдырып җыеп киптерелгән кура җиләге иде. Хәтерлим, шул кышны Мәрфугаттинең әлеге дәвасы белән дәваланырга берәр сылтау чыкмасмы дип гел көтеп йөрдем.

Дөнья мәшәкате белән Мәрфугатти инде онытылып та бара иде. Көтелмәгән бер хәл хатирәләремне кузгатып, яңартып җибәрде.

— Беләсеңме, мндә нәрсә бар? Киттек безгә,— дип бер көнне мине Мәскәүдәге гостиницадан Миргазиян Юныс үзләренә алып китте. Миргазиян чит илләрдә йөрүче кеше, бәлки диңгез артыннан килгән берәр хикмәтле шәрабы бардыр дип өметләнеп, шактый тиз киенә башладым. Килсәм, Миргазиян кухня шкафыннан чажылдатып өстерәп бер кечкенә капчык чыгарды. Мәгънәле елмаеп:

— Менә... Уфадан Мостай Кәрим биреп җибәрде. Мәтрүшкә,— диде. Кулында бер кочак мәтрүшкә иде.

Шул мизгелдә Мостай Кәрим белән рәттән минем күз алдыма Мәрфугатти килеп басты.

...Мәрфугатти үләр алдыннан аның туу турында таныклыгы белән кызыксынганнар: 99 яшь булган. Соңгы сүзе итеп болай диган:

— Шөкер, хәсрәтне күп күрдем...

Тагын күршедә Хәдичәттәй дигән карчык бар иде. Бала вакытта урамда малайлар белән бәхәсләшеп утырганымны хәтерлим.

— Шәймулла абзый хатынының исеме ничек? — дип сорый арабыздан берәү.

— Камәрттә.

— Ә Вәли хатынының?

— Мәйсүфәттә...

Шулай бөтен урамдагы кешеләрнең исемен барлап чыга идек. Ни өчен хатын-кыз исемен? Чөнки авылдагы хатыннарны «Йосып хатыны», «Гыйният хатыны» дип кенә атап йөртәләр, ә без, малайларга, бу хатыннарның исемен ачыклау кызыклы бер уен, хәзергечә әйтсәк, «проблемалы мәсьәлә» була иде. Менә шунда арадан беребез:

— Ә Хәдичәттинең исеме ничек? — дип сорап куйды.

Ни гаҗәп, бу сорауга беребез дә җавап бирә алмады. Беренчедән, Хәдичәтти «фәлән кеше хатыны» түгел, аның ире гражданнар сугышында үлеп калган, исемен без белми идек. Икенчедән, без — малайлар өчен — ул карчык шулкадәр якын, үз кеше иде, ул әллә кайчаннан бирле Хәдичәтти иде һәм аның исеме башкача булырга тиеш түгел кебек иде.

Хәдичәтти әнә шулай «исемсез» калды. Бу сүз — Хәдичәтти сүзе — башка хатыннарның исеменнән зуррак, киңрәк мәгънәдә иде. Ни өчен дисәң, ул безнең тирә малайлары өчен рухи бер ана булды. Ул хикмәтле итеп сөйләшергә ярата, авыл халкы аны «сайландыра» дип әйтә иде. Хәдичәтти һәрвакыт рольгә кереп сөйләшә. Мәсәлән, син яңа күлмәк киеп чыккач, шатлыгыңа чыдый алмыйча, сәгатенә сиксән чакрым тизлек белән элдертеп урамны узасың. Икенче көнне исә, йомыш белән кергән җирдән, Хәдичәттинең хәтфә ишегалдында катык ашыйсың. Ә ул болай сөйләштерә:

— Карале, кем, олан... Кичә карап торам, ярабби бер матур малай, матур күлмәк кигән, ярабби каты да чабып узды... И-и-и... Кем генә булды икән шул, беләсем килеп калды.

Синең катыклы кашыгың чирәмгә төшеп китә, кисәк бәргән бу шатлыктан синең тамагың буыла һәм син шәрран ярасың:

— Хәдичәтти, минием ул, минием!

— Ә-ә, шулаймени... — дигән була Хәдичәтти-артистка,— шулаймыни... Әйтәм җирле бик каты йөгерәдериең... Яңа күлмәк тектеләрмени?

Хәдичәтти балаларны әнә шулай шатландыра белә иде. Хәер, балаларны гына түгел: үзеннән он, бәрәңге, ипи, кәчин алып торган кешеләрнең әҗәтләрен, әгәр мохтаҗлык аркасында вакытында түли алмасалар, Хәдичәтти гел кичереп (списать итеп) бара иде. Сугыш вакытында ул баласыз калды. Ике улы фронтта хәбәрсез югалды. Хәдичәтти дүрт кыш буе, үз өен бикләп, ятим калган фронтовик балаларына ана булып яшәде. Ул балалар Хәдичәтти аркасында әнисезлекне белми үстеләр. Хәзер алар республикабызда бик ихтирамлы кешеләр: кайсы мәктәп директоры, кайсы алдынгы төзүче-депутат, кайсы автохуҗалыкта зур эштә. Боларның икесе дәүләт орденнары алды. Ул орденнарның һәрберсендә, әлбәттә, Хәдичәттинең дә өлеше бар. Хәдичәтти бөтен урамга шулай икенче ана булып яшәде. Ике малае эзсез югалгач та, кешегә күз яше күрсәтмәде. Гадәттән тыш сабыр иде, кайгысын колхоз эшендә баса иде. Ләкин язмыш Хәдичәттигә карата шәфкать күрсәтте: сугыш беткәндә аның уллары табылды. Бераздан алар кайтып төштеләр. Берсе еракка — Норильскига китеп урнашты, икенчесе йортта калып, 15—20 еллар буе колхозда бригадир булып эшләде. Үз гомерендә Арчадан ары узмаган Хәдичәтти самолетка утырып Мәскәү, Красноярскийлар аркылы Норильскига барды. Шунда поляр төнне уздырып кайтты. Яз көне, ул кайткач, авылга ике яз килгәндәй булды.

— Анда гел төн генә икән,— диде ул елмаеп.

— Аэропланда курыкмадыңмы? — дип сораштылар аннан замандаш карчыклары.

— Ю-ук. Бернәрсәсе дә юк аның. Зур балык шикелле бер нәрсәнең эченә кереп утырасың, утырган җирең әз генә дерелдәп тора. Ике-өч тапкыр һәйбәт чәй бирделәр. Юк, курыкмадым.

Хәдичәтти сиксәннәргә җиткәч йорт эшеннән азат булды. Сәламәтлеге дә шәптән түгел иде, оныклар да үсеп җитте, малай белән килен ул гомер кичергән теге йортны сүтеп, яңа «дворец» салдылар. Хәдичәтти урамга чыгып сөйләшеп утырыр өчен замандашларын эзли, йөренә иде. Әмма замандашлар юк иде инде.

...Мин аспирантурада укыган вакыт иде, Хәдичәтти мине бик «зур кеше» дип чын күңеленнән ышана иде һәм узган заманнарны сөйләшер-

гә дип без капка күләгәсендәге эскәмиядә утыргалый идек. Бервакыт, ни җуләрлек килгәндер, мин Хәдичәттидән сорый куйдым:

— Хәдичәтти, син яшь вакытыңда җырлый идеңме?

— Ник җырламаска? Би-ик, би-ик җырлый торганыем...

— Хәдичәтти, шул җырларның берсен генә булса да хәтерләмисеңме? — Мин блокнотымны, карандашымны алдым.

— Ник хәтерләмәскә? Бик хәтерлим...

— Хәдичәтти, берсен генә җырлап күрсәт...

Һәм мин үз гомеремдә беренче тапкыр Хәдичәттинең — сиксәнгә җиткән карчыкның — яшьләрчә көр тавышын, хикмәтле сүзләрен ишетеп таң калдым. Ул болай җырлады:

Әя, агач, яшең күпме?
Түгелгән яфрагың күпме?
Минем күк хәсрәтең күпме? —
Диеп сорыйм агачлардин...

Минем кинәт кенә күңелем тулды. Ике малаен югалткан елда Хәдичәтти белән без урманда утын әзерләгән идек һәм ул бик еш кына карт имән янына килеп, сүзсез калып, имән башына карап тора иде. Агачлар белән серләшкән икән ул. Бу юлларның Кандалый шигыре икәнен ул вакытта мин әле белми идем. Китапханәдә шул шигырьгә юлыккач, минем авылга кайтасым һәм Хәдичәтти белән тагын бер сөйләшәсем килде.

Кайтуга, аларның капка төбендәге бүрәнә өстенә барып утырдым. Хәдичәтти тыкрыкта эшсез, бер шөгыльсез арлы-бирле йөренә иде. Килеп утырды, хәл-әхвәл белештек. Шунда мин аннан сорап куйдым:

— Хәдичәтти, сезнең иске йортны сүткәндә чормадан китаплар чыкмадымы?

— Ник чыкмасын, чыкты,— диде ул тыныч кына.

— Аларны нишләттегез?

— Нишләтик, берни эшләтмәдек. Әнә әрҗәдә, лапастагы утын әрдәнәсе өстендә торалар.

...Йомарланып, яңгырда җебеп, ниндидер җан ияләре тарафыннан кимерелеп беткән кульязмалар арасыннан мин берсен сайлап алдым. «Йосыф-Зөләйха» поэмасының яңа бер язмасы иде ул. Бу кульязма хәзер Казан университетының китапханәсендә сирәк кульязмалар бүлегендә саклана һәм поэманы тикшерүче, өйрәнүче галим Ф. Фасеев үзенең гыйльми хезмәтендә безнең Хәдичәтти биргән вариантны да телгә ала. Мин моңа бик шат — Хәдичәттинең исеме тарихка кереп калырга бик тә, бик тә лаек иде.

...Хәдичәттинең кабере безнең авыл зиратының иң матур урыны — кояшлы, җиләкле тау кырында. Аның кабере очында бик көяз каен агачы бар. Җәйнең тын, эссе көннәрендә дә вак, затлы-пөхтә яфракларын дерелдәтеп, һава дулкыны белән серләшеп утыра ул каен. Мин шул каберлеккә киләм дә (Хәдичәтти янында үз әнием дә ята), каен башына текәлеп торам. Җир астыннан, әйтерсең лә, Хәдичәтти каенга дәшә:

Әя, агач, яшең күпме?
Түгелгән яфрагың күпме?

## Исәнме, яшьлек!

Мине гомер буе көньяк тартты. Төньякта Чепья, Малмыж, Балтач, Борбаш, Лиза, Карлыган дигән авыллар бар иде, алар, нигәдер, еланлы, караңгы сазлык авыллар булып күз алдына килә иде. Тәпи йөри башлау белән мин гел үзебезнең авылдан көньякка — кояшка таба чы-

гып китәргә кызыксындым. Хыял гел шул якка тарта иде. Моның сәбәбен илле яшемә җиткәндә генә белдем. Мине бабайлар туфрагы тарткан икән. Чөнки әти ягыннан бабай бездән көньяк-көнчыгышта урнашкан Тәкәнеш ягыннан. Әни — көньяктагы Симет авылыннан.

1948 елның июль аенда РОНОда миңа приказ тоттырдылар: фәлән иптәш фәләневне Чүриле районы Керәнле җидееллык мәктәбенә тарих, конституция, география фәннәре укытучысы итеп билгеләргә...

Минем хәл! Керәнле! Өчиле! Чикләвекле таулар! Бәхет дигәннәре шулдыр инде ул!

Һәм кырык сигезенче елның унбишенче августында мин Керәнле дигән хикмәтле бер авылга таба юлга чыктым. Мәһабәт көяз чикләвек агачы каплап алган тау буенда мылтык аскан бер абзый юл өстенә чыгып мине каршы алды.

— Керәнле — ә-ә-ә-нә тегендә, болын буйлап барасы да, барасы,— диде.— Шәп авыл, энем, бәхетле икәнсең, юньле җиргә эләккәнсең,— диде.— Фатир төшәргә, тәгаен генә урының булмаса, я безнең кода Рамазан абзыйларга, я минем баҗай Хәсәннәргә сугыл. Керәнлеләр — юньле халык.

Тау башындагы куе чикләвек урманын күргәч, безнең авыл килене— Өчиле Зөлкамал сүзе искә төште:

— Безнең урман,— дип сагынып сөйли иде ул,— баш өстендә егылам-егылам дип тора.

Мин ул вакытта күз алдына китерә алмый идем. Урман тау башында буламыни? Урман бит ул, бездәгечә, басу түрендә генә булырга тиеш! «Егылам-егылам» дип торган чикләвек урманының каравылчысы мине Керәнлегә таба озатып калды.

Өчилене чыгып бераз баруга, мин яшел тугайга — борыла-сарыла киерелеп яткан елганың киң болынына килеп чыктым. Бу — хәтфә тугайлы Керәнле болыны иде. Таллыкка тезеп салынган буа куенында тегермән утыра. Дамба шактый таза, ул тотып калган су бөтен болынны бүрттереп, зур куәтен кыса төшеп, тын җәелгән. Суының итәге ике чакрымнарга килеп җиткән. Тегермән дамбасы өстендә киң кара фуражка кигән мәһабәт бер ир күренде. Күкрәгендә юл-юл тельняшка.

Керәнле буасында, районда беренче буларак, динамо куелган һәм кичләрен авыл гөлт итә икән. Фуражкалы кеше — Хәби Тын океан флотында тугыз ел хезмәт итеп кайткан алтын куллы диңгезче. Шушы авыл егете, электростанция начальнигы икән.

Мәктәптән мине туп-туры квартирага озаттылар. Гаҗәп бер дөнья башланды.

Еллар әле авыр иде, ипи карточкасы беткәнгә әле тугыз ай чамасы гына, магазиннар әлегә юка, бик юка... Әмма Керәнледә тормыш икенчерәк иде.

Бу — республикага мәшһүр «Кызыл партизан» колхозы икән. Председателе Шәех абзый — мәһабәт гәүдәле, өлкән яшьтәге кеше республика Верховный Советының депутаты икән.

Минем, квартирага урнашып, әби белән чәйгә утыруым булды, ишекне кактылар. Әби җәһәт кенә чыгып китте һәм зур бер түгәрәк ипи, бер йомарлам май тотып керде.

— Моны сиңа мәктәптән җибәргәннәр,— диде.

1948 ел җәендә бер бөтен ипи һәм бер йомарлам май! Мәктәп сыер асрый, иген чәчә, сыерның бозавын үстерә икән...

Малайлыктан чыгып егет булу чорын мин шул авылда уздым...

Сугыш елларына туры килгән балачакта без кино карамыйча, радио тыңламыйча үстек. Безнең нәрсәбездер җитмидер, ниндидер сәләтләребез үсеп китә алмыйча һәлак булгандыр. Керәнле мәктәбенә килеп

эшли башлауга мин ике юньле кеше белән дуслашып алдым. Болар — математика укытучысы, фронтовик, Берлинны алган, 1945 елның Җиңү парадында катнашкан өлкән лейтенант Тәлгать Ибраһимов һәм тугыз ел чамасы Тын Океан флотында хезмәт иткән, Керәнле «электростанциясе» начальнигы Хәби Фазуллин иде. Яшь аермасы безнең дуслыкка комачау итмәде. Мин дәрескә әзерләнеп төннәр буе мәктәптә, укытучылар бүлмәсендә утырам, шунда Тәлгать Ибраһимов белән Хәби дә килә иде. Миңа китә сүз, җыр. Хәби миңа тарих, география буенча ярдәм итә, идәнгә картаны җәеп салабыз да, сузылып ятып, иртәгесен минем дәрескә кирәк булачак вулкан, тау, күлләрне эзлибез.

Тәлгать Закирович сугыш хәлләрен сөйли — информациягә, аң-белемгә сусаган минем баш мием рәхәтләнә. Көннән-көн үсәм. Ул арада, директорны күндереп (директор Сара — Хәбинең хатыны), «Родина — 47» маркалы радиоалгыч кайтарабыз, мин коры элементлар, антенна, заземлениеләр белән мәш киләм, ә тегеләр — икесе дә инженер! Мине өйрәтәләр дә өйрәтәләр. Безнең компаниягә бервакыт рус теле укытучысы Галина Марковна катнашып китте. Һәм озын көзге төннәрдә без дүртәүләп зур дөньяга чыгабыз. Хәрби Тын Океан, Порт-Артур, Кытай җире турында бөтен мәшһүр киноартистлар турында әллә ниләр сөйли. Сергеев-Ценский, Степанов, Станюкович һәм Леонид Соболев әсәрләрен күңелдән белә. Кыскасы, минем күңел тәмам урыныннан купты, мин хәзер диңгез флотына алынсам, кеше булырмын, башка частька эләксәм, дөньяда яшәүнең бер мәгънәсе дә калмаганлыктан, яшәп маташмаска дигән фикергә килдем. Галяның исә үз дөньясы: аның балачагы Армавир шәһәрендә, сәхнә артында узган, аның этисе дә, энисе дә актерлар булган. Алар үлгәч, Галя детдомнан детдомга йөргән дә, менә бу авылга килеп чыккан. Ул берөзлексез французча өйрәнә, стенография курсында читтән торып укый һәм төннәр буе безгә Качалов, Москвин, Шаляпин, Щепкин, Якушенко, Провоторов, Загорскийлар турында сөйли, спектакльләрдән монологлар укый иде. Минем алда рус драматургиясе, сәнгать дөньясы ачылып китте. Галя, ике-өч көн узган саен, район үзәге Чүриле китапханәсенә торып чаба, үзенә һәм миңа китап ташый иде. Диңгезче язучыларны укып бетергәч, әлеге компания мине Гюго, Бальзак, Флобер, Гейне дөньясына этеп кертте. Мин ял көннәрендә, Казанга махсус килеп, рус театрының спектакльләрен карый башладым. Островский, Гоголь, Горький, Чехов... Болар Галяның дүрт алласы иде. Казанга барып театрга кермичә кайтсаң, Галя рәнҗеп, чын күз яшьләре белән елый иде. Диңгез дәресе, сәнгать дәресе хәрби җыр белән алышына: Тәлгать Закирович сугыш чоры җырларын бик яратып, моңланып та, яшьлеген сагынып та җырлый иде. Мин инде җырчы булырга, артист булырга хыялланам. Миңа хәзер рус, европа җырлары дөньясы ачылып китте. «Родина-47» бик әйбәт, юньле радиоалгыч булып чыкты. Укытучылар бүлмәсенең бер почмагында радиоалгыч тора. Менә аның яшел индикаторы яна башлый. Бу могҗизалы аппарат мине планета белән тоташтыра. Мин үз гомеремдә беренче тапкыр французча, гарәпчә, немецчә, кытайча сүз ишетәм, җырлар тыңлыйм. Каһирәдәнме, Димәшкътәнме коръән укыйлар. Кыска-кыска сигналлар, морзе әлифбасы арасына кайвакыт метеостанцияләрнең үзара сөйләшкәне килеп керә. Мин төннәр буе шулай Зур дөньяда сәяхәт итәм һәм, әлбәттә, үземне бик бәхетле сизәм. Дәрестән соңгы сәгатьләрдә, гаиләле укытучылар өйләренә кайтып киткәч, мин аеруча зур бәхет кичерәм. — «Маяк» тыңлыйм. Музыка бервакыт мине тәмам кешелектән чыгарды. Күңелне җилкетә торган, акылдан шашарлык дәрәҗәдә ашкындыра торган берничә җыр бар иде. Боларның нинди хасияте булгандыр, аны мин әле дә әйтә алмыйм, әмма бу җырлар минем яшьлек хатирәләрем булып мәңгегә күңелдә яшиләр.

Боларның беренчесе — «Пути-дороги» дигән җыр иде. Моны ул вакытта хатын-кызлар хоры башкара иде. Ул җырны Сергей Алымов сүзләренә Исак Осипович Дунаевский язган икән.

Бегут, бегут пути-дороги...

— дип, хатын-кызлар әллә нинди үзәк өзгеч тавыш белән мине әллә кая еракка чакыралар иде. Үземне сихерле сиреналар тавышына әсәренеп, үзен бәйләп куйган мачтадан ычкынырга газапланган Одиссей кебек хис итә идем, бу хордагы кызлар мине гел еракка чакыралар иде. Авылда яшәвемнең, укытып йөрүемнең, шулай итеп, бер мәгънәсе калмады. Икенче җыр... Хәер, ул җыр тәэсиренә бирелгәнче, мин әле бу авылда беренче мәхәббәт хисенә дучар булып, иләс-миләс килеп йөрдем. Бу дөньяда бер эшем дә кешечә рәтле булмады... Ул вакытта мин мәктәп балаларының хор җитәкчесе, драма түгәрәге җитәкчесе, тагын әллә нинди җитәкчеләр идем. Тарих, география, конституция укытудан тыш, авырган, декретка чыккан кешеләр урынына рус теле, ботаника, зоология, физкультура, тагын әллә нәрсәләр укытам. Өлкән пионервожатый, агитколлектив җитәкчесе, күрше авыллардагы башлангыч мәктәпләрдә штаттан тыш инспектор, колхоз фермасында газета чыгаручы, уку йорты советы, район китапханә советы, колхоз комсомол комитетының бюро әгъзасы, тагын әллә нәрсәләр идем.

Шуның өстенә әле туганнан бирле хыялланган бер эшем бар: газета корреспонденты. Минем хыялымча, ул инде дөньядагы бөтен гаделлекнең патшасы. Район газетасында инде әллә ничә мәкаләм басылып чыкты һәм мин горур кыяфәттә инде зур блокнот тотып, колхозның яшелчә бакчасына, ат абзарларына, фермасына барам, сорашам, язган булам. Бераздан мине район газетасы гына канәгатьләндерми. «Яшь Сталинчы» («Татарстан яшьләре»)га үрелеп карыйм. Бәхет! Гали Хуҗи имзасы белән хат килә, киңәшләр бирәләр һәм минем мәкаләләрне баса башлыйлар. Ләкин мине бу газета гына канәгатьләндерми. Мин «Кызыл Татарстан»га үрмәлим. Күпмедер язмаларымны «газетада урын җитмәү сәбәпле» кайтарып җибәргәч, ниһаять, газета ихтыяҗына туры килә торган материал җибәрәм һәм «Кызыл Татарстан»да басылам! Ну инде, ул көннәрдә мин кешеләр белән әллә исәнләштем, әллә юк... Шулай мин үзем өчен район газетасы «Сталинчы», өлкә газеталары «Яшь Сталинчы», «Кызыл Татарстан»ның «штаттан тыш корреспонденты» дигән горур исем уйлап таптым. Мәкаләне мин төннәр утырып, йокы хисабына яза идем... Кыскасы, мин эшсезләрдән, эшлексезләрдән саналмый идем...

Әмма боларның берсе дә миңа көннәрдән бер көнне гашыйк булырга комачау итмәде. Минем кызлар белән танышкалаганым бар, озатып куйгалаган бар, әмма гыйшык утында янганым юк иде. Гыйшыкка мин ышанмыйм, гомер юлын аннан башка гына узарга, үземне фәнгә, әдәбиятка, сәнгатькәме, әллә диңгез флоты офицеры булып хәрби тормышкамы багышларга дип баш ватып йөри идем. Хәби әйтә: әнә, ди, адмирал Нахимов өйләнмәгән, ди, Чайковский өйләнмәгән, ди. ...Мин дә ул мәсьәләне инде хәл итеп куйдым: хатын-кыз белән буталып гомер әрәм итәргә монда... Ни чуртыма кирәк ул! Шулай да бала вакытта әнидән ишеткән бер хикәят хәтердә калган. Шул борчый. Гыйльменисаттн белән бергә озын кышкы кичләрдә лампа янында алар китап укыйлар, дөресрәге, бер-берсенә «китап сөйлиләр» иде. Шул китапларның берсе «Тутыйнамә» дип атала иде. Анда шундый хикәят бар. Бер адәм каяндыр каядыр барганда ишәгеn казыкка бәйләп куя да, ялга туктый. Йоклап китә. Уянса, ишәген алып киткәннәр. Әлеге адәм хәсрәткә төшә. Гаделлек эзләп, мәчеткә таба китә. Җомга намазы алды икән.

Хәзрәтне күреп үзенең кайгысын сөйли һәм ярдәм күрсәтүен үтенә. Хәзрәт аңа намазга кереп утырырга куша. Намаз-нияз тәмамлангач, хәзрәт чираттагы вәгазь өчен сүз ала. Сүз арасында сорап куя:

— Җәмәгать — ди,— сезнең арагызда үз гомерендә хатын-кызга күтәрелеп карамаган, гыйшык утында янмаган берәр кеше бармы?

Арткы рәттән шома битле, чапанлы бер ир күтәрелә.

— Хәзрәт,— ди,— сезне алдарга җыенмыйм: яшем иллегә җитеп килә, әмма хатын-кызга күз салганым юк, алар турында уйлаганым да юк, бөтен уем — ахирәт көне турында...

— Һмм-м-м,— ди хәзрәт, авыр сулап. Һәм урта рәттәге мөсафиргә эндәшә:

— Син, кем... Ишәгем югалды дип зарланасың. Әнә ул — алып чык...

... Кышкы каникул тәмамланып берәр атна укыткач, колхоз клубында ата-аналар җыелышы уздырдык. Клуб шыгрым иде. «Бала тәрбиясе» циклыннан алты-җиде бала үстерүче өлкәннәргә мин лекция укыдым, балаларны ничек үстерергә икәнен өйрәтеп бетердем. Хәтерлим: гел елмаеп тыңладылар. Аннан спектакль куйдык. Таҗи Гыйззәтнең «Фәрхиназ» драмасын. Мин — Каһарман, Мадагаскар атауларын күргән, диңгезләрдә йөзгән, дөнья күргән егет, имеш. Мин шәп, мин, мин... Хәбинең өр-яңа тельняшкасын киеп, сәхнә артындагы кызлардан битне-башны бизәтеп, сәхнәләргә чыгыплар киттем. Әйтерсең, мине бөтен дөнья тамашачысы карый. Дөньяда иң шәп егет мин, төкергән мин дөньяга... Менә сез мин булып карагыз әле...

Киерелеп шулай сәхнәдә йөргәндә, минем шәплекне барысы да күрәләрме икән дип аска — залга күз салуым булды — әйтәсе сүзне оныттым. Өметсезләнеп суфлер утырган почмакка таба чигендем. Әмма күзне залдан алып булмый иде: залда, сәхнәгә якын гына, беренче рәттә, моңарчы мин күрмәгән бер кыз утыра икән. Шәһәрчә бизәнгән, шәһәрчә киенгән, керфекләрен буяган, моңарчы мин күрмәгәнчә чибәрлеккә ия булган бер кыз утыра икән. Каушый калдым. Исереп киттем. Рольне чак-чак кына уйнап бетердем, мин чыккан саен теге кыз урынында селкенеп, кулларын-тезләрен рәтләп алгансыман иде. Хуш...

Спектакль тәмамлангач, авылның бик матур гадәте буенча, «бичер уйнау» башланды. Мин дә, горурлыктан рәхәт чигеп, егетләр-кызлар арасына төштем. Очраклы рәвештә теге кыз янына барып утырдым. Әлегә эндәшү-сөйләшү юк. Гармунчы дыңгыр-дыңгыр татарчага әйләндереп бер вальсны вата иде. Ирле-хатынлы укытучылардан бер-ике пар әйләнә башлады, бераздан Галя да бер кыз белән уртага кереп китте. Минем йөрәк дөп-дөп тибә, нәрсәдер эшләргә кирәк иде, әмма мин вальс (татарчага тәрҗемә ителгән булса да) әйләнә белмим һәм шуңа газапланып идәнгә, олтанлы итекләремә карап утыра бирдем.

Алга таба йөгереп шуны әйтим: танцы белмәү аркасында егетлек чорында мин бик күп нәрсә югалттым. Флотта, увольнениегә чыккач, бу кимчелек минем өчен трагедиягә әйләнә иде. Өч-биш класс белемле матросларга (сугыш еллары афәте — оккупациядә калып, белем ала алмаган малайлар байтак иде) мин Соболев әсәрләрен сөйлим, Горькийның «На дне» әсәреннән Сатин монологын укыйм һ. б. Болар мине әллә кем дип беләләр. Ә менә матросский клуб яки паркка барып кергәч, шул малайлар ленталарын җилфердәтеп фокстрот, танго, вальс биеп җибәрсәләр, мин бәхетсез, боларга кызыгып бер читтә ятим торам. Болар сары озын толымлы латыш кызлары белән шундый чикылдашалар, ә мин — кеше түгел. «Комплекс неполноценности» дигән төшенчә ул вакытта әле популяр түгел иде, әмма мин инде шуның корбаны идем. Хәзер дә мәҗлесләрдә тәнәфес ясап бию оештырылганда мин

читкә таям. Нишлим соң? Биергә һәм биек тау башыннан чаңгыда төшәргә гомер буе тәвәккәллек җитмәде, өйрәнә алмадым.

•

— Сез нигә биемисез?

Мин айнып киттем. Зур кара күзләр, буяулы керфекләрен селкетеп, миңа карап елмаялар иде. Йомшак, дусларча елмаю. Минем борын очы тирләп алды. Секунд эчендә.

— Әә-э... Мин, көн салкын булгач, менә мондый итекләр белән килгән идем шул.

Кычкыртып ялганладым. Авыл җирендә кышын ботинка кию гомумән юк нәрсә иде ул, минем ботинкаларым да юк иде. Булса да кимәгән булыр идем, чөнки 1948 елда ботинка киеп кышын клубка килгән булсам, мине, юләргә санап, иртәгесен ата-аналар балаларын укырга җибәрмәячәк иде.

— Ие, итек киеп килгәнием шул...

Кызый үзе сукномы-ниме, ниндидер резин аслы итек кигән иде. Бу инде — ботинкалы дигән сүз, һәм «мин — шәһәр кызы, син — авыл мокыты» дигән хөкем иде.

Әмма кызый андый хөкемнәрен телдән әйтмәде һәм авыр озын керфекләреннән нурлар сибеп:

— Бәлки сез мине биергә чакырырсыз? — диде.

•

Тагын бер чигенеш: Латвиянең диңгез буендагы бер паркында мин бер кызны танцыга чакырып харап булдым: авыр ботинкалы озын аякларымны чатый-ботый китереп буталып «Старинный вальс»ка әйләнгәндә мин ул кызның капрон оеклы балтырына ботинка дагасы белән кагылып алганмын. Оркестр туктап, кызның сыңар кулыннан һәм биленнән Болконскийча гына тотып кырыйга чыгарып куйгач, теге кыз, бичара, мөлдерәтеп бер карап алды.

— Менә,— диде,— бер күзәнәге китте.

Шайтан сөягеннән өстәрәк, чыннан да, бер ак тап бар иде. Капрон оекның чыккан елы — 1954 ел иде.

— Капронның шул инде аның,— диде бәхетсез кыз күз яше аша елмаеп,— ярты сәгатьтән бу күзәнәк тез башына кадәр менеп җитәчәк.

Мин авыр суладым, нишлим? Күзәнәк булсам, мин дә шул юнәлештә хәрәкәт итәр идем. Әмма мокытлык көчле, мин авылча елмаеп, авызга папирос каптым.

— Нәкъ илле тәңкәгә кичә генә алган идем,— диде бәхетсез кыз. Шуннан соң мин үз гомеремдә бер генә хатын-кызны да үз теләгем белән биергә чакырмадым. Хәзер мин боларны иркенләп язам: мин инде алтынчы дистәгә чыктым һәм биергә чакырылу куркынычы инде — шөкер! — бетте.

•

— Бәлки сез мине биергә чакырырсыз?

... Керәнле авылының клубында бик күп мәхәббәтләр чәчәк аткандыр, бик күп матур сүзләр сөйләнгәндер, әмма шул вакыт вальста мин кичергән бәхетне берәү дә кичермәгәндер. Кызый, кайнар сулышын миңа бәреп, мине тәмам кешелектән чыгарып, беткәч бетсен инде дигәндәй, мондый сүзләр әйтте:

— Сез сәхнәдә искиткеч матур егет... Нигә сез студент түгел? Нигә югары белем алмыйсыз?

Мин бу моментларны хәзер бик иркенләп язар идем... Әмма башта берни калмаган. Чөнки мин ул минутларда икенче бер сихри дөньяга

күчкән идем, дүресрәге — моңа кадәр яшәгән елларым гомеремнең беренче яртысы, монысы — икенче яртысы, әле башланып килә иде.

Аннан нәрсә? Буранлы төн иде. Мин, кызыйны култыклап, урамнан атладым. Юл буе ул, бичара, аягын дөресләде, минем өч адымга ул җиде атлый иде, шул кечтән соң мин ант иттем: үз гомеремдә хатын-кызны култыклап йөртмәм дидем һәм шул үҗәт вәгъдәмне гомер буе тоттым. Мине «культурасыз син» дип сүгүчеләр аз булмады. Кызый университетның рус филологиясе бүлегендә укый икән һәм бик ерак чыбык очы туганнарына кышкы каникулга кайткан икән. Үзенең әти-әнисе Уралдамы, кайда, бу каникулны монда гына уздырмакчы икән. Алай-и-и...

Кайттык, буран сырган урыс капка астына кереп баганага сөялдек. Мин гел тирлим. Леонид Соболевның «Морская душа» әсәреннән цитаталар китерәм:

— Один матрос — матрос, два матроса — взвод. Сколько нас? Трое? Ро-о-та. Смир-р-рно!

Шундый байтак өзек китерелде. Кытай, Порт-Артур турында, Качалов, адмирал Нахимов, 1945 елгы җиңү Парадында булган нюанслар турында сөйләп бетердем. Төн шактый карлы, җилле һәм соң иде.

Шуннан әллә ни булды...

— И-и-и-х, син, нинди саф, нинди матур күңелле егет син,— диде дә, озын керфекле кыз, «чуп» итеп мине үбеп алды һәм урыс капкасының келәсенә басты. Капка, физика законнарына нигезләнеп эшләнгән корылма, шыңгырдап ачылды да теге төн кызын эчкә йотты. Ә мин баганага тотынып калдым. Тотындым, чөнки бөтен дөнья әйләнә — буран туктаган, кар беткән, аның урынына тропиктагы җылы тыгыз яңгыр ява. Шул яңгыр астында зонтик тотып, мыеклы Сергеев-Ценский, бантиклы Станюкович, фин кепкасы киеп сөяк таяк тоткан Леонид Соболев, төлке толып кигән Шаляпин һәм озын кара бәрхет күлмәк кигән Ермолова — бөтенесе бергә урам уртасыннан баралар һәм миңа карап елмаеп кул болгыйлар иде.

Аннан... Мин кайтып кергәнмен, ул заманда әле исерү өчен аракы кирәкми иде, хуҗа әби мине каршы алганны хәтерлим. Пальто ачык (ике ай элек кенә җиде йөз илле тәңкәгә Чүриле кибетендә сатып алган сукно «пәлтә», якасы — кара сарык тиресе, йомшак, җылы), ак сарык йонынннан бәйләнгән шарф бер якка салынып төшкән, бүрек ямьшәйгән, хәер, боларны мин белмим, иртәгесен әби генә сөйләде:

— Син,— диде,— әлләкем әйтмешли, салып кайтканыеңмы суң? Кара аны, малай, безнең нигездә булган хәл түгел бу. Юктыр бит? Исерегиеңме суң?

— Юк,— дидем мин түбән карап, әмма ялганладым. Чөнки, үз гомеремдә башка беркайчан да, бер җирдә дә минем бу дәрәҗәдә бәхетле исергәнем булмады. Аракыдан исерү — нәрсә ул!

Икенче көнне мин иләс-миләс килеш дүрт дәрес укыттым. Географиядән, ничектер, Австралия кыйтгасында сарыклар үрчетү проблемасы турында сөйләдем, тарих дәресендә Кызылкашлар белән Сары Чалмалылар восстаниесе турында сүз куерттым. Әмма болар төштә генә! Күз алдымда буран сырган капка баганасы һәм шул баганага сөялеп торган йомшак билле кыз бала гәүдәсе һәм аның кар арасыннан ялтыраган кара күзләре иде. Кая монда сиңа Сары Чалмалылар һәм Кызылкашлар!

Саташулы берничә дәрес шулай узды. Дәрестән соң ул көнне без күршедәге Курсабаш башлангыч мәктәбенә ачык дәрескә барырга тиеш идек. Дәресләр тәмамлангач, ашап тормадык — киттек. Буран себерә башлавы бераз гына борчыды безне, әмма буранда алты чакрым юл

чыгу ул заманнарда проблема идеме соң? Бардык, өч-дүрт дәрестә утырдык, озаклап анализлар ясадык. Безнең як буранының гадәте шул: кичкә таба холыксызлану. Беренче класс укытучысының арифметика дәресенә анализ ясаганда, мин сизеп утырдым: минем беренче мәхәббәтем яна! Яна, яна... Чөнки болай сөйлиләр:

— Юк, иптәшләр, бу мәсьәлә, минемчә, укучылар өчен бик авыр иде. Я инде, үзегез уйлап карагыз: менә сезгә шундый авыр мәсьәләне чишәргә нибары 25 минут — мин кабатлап әйтәм — 25 минут бирелсен әле. Менә мине голаслауныйлыкта гаепләмәсеннәр өчен, мин мәсьәләне, дәреслектә бирелгәнчә, сүзгә сүз укыйм: «Вәдүтнең әбисенең ике үрдәк баласы бар иде. Аларга бер көнне Нәбинең әнисе бер үрдәк баласы кертеп кушты. Вәдүт әбисенең барлыгы ничә үрдәк баласы булды?» Бу бит, иптәшләр, бу бит, иптәшләр... Бу бит...

Буран котырды, бер катлы мәктәп тәрәзәсеннән башланган кар диңгезе кояшның газаплы чырай ташлаган хәлсез нурларын сендерде дә, караңгылыкка биреште... Минем йөрәктә исә давыл, чын мәгънәсендә давыл иде. Ә буран котырды... Бераздан мәктәп түбәләре шыгырдый башлады, классның унлы лампа яктысында саран елтырап утырган бүрәнәләре, мүкле бүрәнә җекләреннән бәреп кергән кыр җиле, кичәге кара күзләр, кайнар үбү һәм Вәдүтләрнең өч үрдәк бәбкәсе — барысы бергә буталды. Ә методистлар, авыз тутырып, әле Нәби әбисенең, әле Вәдүт әнисенең бәбкәләрен санадылар.

Аннан ниндидер рәхмәт әйтүләр булды, шыгыр-шагыр китереп парталарны кузгаттылар, безне, җидееллык башкаладан килгәннәрне, фатирга чакырулар булды. Уникеләп кешене берәүләргә кертеп кайнар аш ашату, кемдәдер куну һәм иртәгесен ат, чана, толыпларга төреп илтеп куюлар турында байтак сүз булды. Әмма кешелек җәмгыяте һәм кырык сигезенче елларның матур, эшлекле халкы мине гафу итсен, берничек тә ул авылда, мәгънәле, ишарәле, ымлы ашлар янында утыра алмыйм, дөресрәге, яшьлек законнары буенча, минем монда утырырга хакым юк иде. Юк — вәссәләм!

Шуннан... Беркем дә берәүгә дә кермәде. Яшьлек җиңде. Мин җиңдем. Саран-кызгылт лампа утларын буранда тоныкландырып, Курсабаш авылы калды, ә без — электрлы Кереәнле авылына таба, кар ярып, тирән карда сукмак салып алга атладык. И сүгенделәр, и каргадылар мине арттан атлаучылар. Ә мин ун адымнар чамасы алдан көрт ярып бардым. Миңа бары тик кайтып җитәргә генә кирәк, бу бәхетле кышның бер кичен мин ниндидер Курсабаш авылында уздыра алмый идем.

Үз гомеремдә читтә иң күбе алты кич кунган мин, малай, ул кышның февралендә өч атна чит авылда, үз өемә кайтмыйча яшәдем. Моңа газаплана, борчыла идем, ничек инде ул үз ояң, үз әниең, үз йортың моннан унбиш-уналты чакрымнарда гына, урман артында гына була торып, шунда кайтмыйча, тирләп-пешеп токмачлы аш ашамыйча, аннан иртәнге мичтә чыжылдаган ял көне ризыгының исенә рәхәтләнеп, киерелеп үз караватыңда аунамыйча, читтә — кеше өендә, ярым кадерсез бер хәлдә яшәргә мөмкин? Ярамый бит болай, ярамый! Аек акыл шулай ди. Әмма, теге кичтән бирле миндә тагын бер акыл барлыкка килде. Монысы көчлерәк, дуамалрак булып чыкты. Анысы әйтә: шту син, ди, дурак, әни кеше янында унсигез ел гомер иттең, әни — әни инде ул, ә менә мондый кызны ташлап ничек итеп үз авылыңа кайтмакчы буласың син? Әни ул гел синең янда инде, ә менә мондый кызны очрата алырсыңмы тагын?

Акылның монысы — яшьрәге, көчлерәк иде.

Студентларның кышкы каникулы тәмамланган көн — минем бәхетем өстенә кара болыт килгән көн иде. Ул китте, дөньяны февраль аеның тәртипсез, мәгънәсез бураннары басты, аннан март аеның иләмсез,

холыксыз җилләре исте, кар эреде бугай. Аннан ниндидер апрель, май айлары узды, ахрысы. Бу язның минем өчен сукыр бер тиенгә дә кирәге юк, чөнки бу дөньяда мин ялгыз, ә теге кызый зур калада, әллә ниткән шәп егетләр белән ил-умач килеп, аудиторияләрдә бергә утыра, чыркылдаша, уйнаша, көлешә иде. Ә мин монда Керәнле балаларына папа Бонифаций фәләненченең ниндидер бер чиркәүдә сөйләгән сүзләрен хәтерләмәгән өчен икеле куеп утырам...

Җәй житте, мин зур дәрт белән калага юл алдым, әлеге кызның теге кышкы кичләрдә сөйләгәннәре буенча аны эзләп университет аудиториясендә, коридорларда йөрдем. Көннәр буе йөрдем. Кызлар затлы, егетләр шәп, күбесе күзлекле иде. (Шул көннәрдә канга сеңеп калган: күзлекле егет — һичшиксез, галим кеше... Менә бит! Күзлексез галимнәргә әле дә булса шикләнеп карыйм, бу, дим, фәнгә очраклы гына килеп кермәдеме икән?) Әмма теге кыз күренмәде. Без аның тәкъдиме буенча шулай килешкән идек: кыш буе хат алышмыйбыз, янәсе, җәй көне мин аны үзем эзләп табам...

Ике-өч көн университет вестибюлен таптагач, мин үземнең төп бурычымны үтәргә — Сулъяк Болак урамындагы институтка «заочниклык»ның бәхетсез язмышын татырга китеп бардым.

Аннан ямьсез, ятим җәй дә узды, көз житте. Мин шул ук мәктәптә, әмма инде.шактый басылган. Минем йөрәк җәрәхәтле, теге газаплы, татлы мәхәббәттән мин әле һаман арынмаган. Ул көзнең ничек газаплы узганын хәтерләсәм, әле дә кызганыч. Әрәм үткән бер көз. Ә бит көзләр, язлар кебек үк, санаулы гына. Кызганыч. Ул көз коры иде, кичләрен томан төшә дә, авылда томанлы тынлык урнаша. Хәби кабызган утлардан салкын туфраклы коры каткак урамнарга саргылт ут яктылары сибелә иде. Ә мин — элеккечә укытучылар бүлмәсендә. Ул елны компания бераз таркалды: Хәбинең дә, Тәлгать Закировичның да беренче малайлары туды, алар инде сугыш, флот темаларын беразга онытып, бәхетле ата булдылар. Галя исә бөтенләе белән француз теленә чумды. Ялгышмасам, ул инде Бальзакның «Евгения Гранде» әсәрен француз телендә укый иде һәм Керәнле авылы кибетенә кайткан конфетны бөтенләе белән сатып алып, көн-төн шуны суыра һәм иртән дәрескә килгәч, теше сызлаганнан, битләре, күз кырыйлары кызарудан зарланып, моржа артындагы юынгычта кер сабыны белән озаклап битен-күзен юа иде.

Көз... Тын, салмак, ярым караңгы. Коры көз. Аяк астында салкын тузан, агачлар бриллиант булып утыра. Укытучылар бүлмәсендә ут бар. Мин шунда юнәләм. Бер почмакта конфет суырып, «французча» «наң-наң» килеп, Галя утыра. Мин радиоалгычны кабызам. Маякта миңа таныш моңнар:

> Снова замерло все до рассвета —
> Дверь не скрипнет, не вспыхнет огонь.
> Только слышно — на улице где-то
> Одинокая бродит гармонь.

Бу җыр минем яшьлек газапларым турында. Моның мәгънәсен бу дөньяда бары тик мин генә аңлыйм. Радионы сүндереп, авыл читенә, бушап калган бәрәңге басуларына чыгып китәм, табигать белән ялгыз калам. Шулай газаплы төннәр үтә. Ә бер көнне мине тарих укытучыларының семинарына шәһәргә җибәрәләр. Мин тагын аяк астында җирне югалтам. Йөрәкләнеп китеп, теге югалган сихри экият кызының тору адресын туганнарыннан сорап алам. Һәм Казанга килеп төшүгә, Качалов театрына ике билет алам да (әле дә хәтерлим: Афиногеновның «Мать своих детей» әсәрен куялар иде), теге адрес буенча оча-куна бер

йортның ишегенә барып житәм. Шәһәр йорты, ике катлы, биек баскычлы. Кыңгырау төймәсенә басам. Хужа хатын чыга. Сездә шундый кыз яшиме? Ул өйдәме? Тамак ярыла, күзне яшь баса. Сүзләр өзелә.

— Әйдә кер. Син кайсы авылдан? Кызым! Әнә сиңа бер авыл малае килгән! Ике елдан бирле фатир тора инде, иялэнеп беттек. Кызым урынына күрәм. Аның ай саен түли торган йөз тәңкәсе миңа нәрсә?

Моржа артындагы обойлы кечкенә бүлмәгә ничек кергәнемне белмим. Ниләр сөйләшкәнне белмим. Дөнья әйләнде. Кызый артык гажәпләнмичә генә, йомшак киез җәйгән сандык өстеннән төште, өстәлдәге китап-кәгазьләрен рәтләде; шул арада күзлекле бер егетнең пыяла рам эчендәге портретын арты белән әйләндереп куйды. Утырырга кушты. Яңа гына кар яуган көннәр иде һәм мин астына олтан салган бик һәйбәт киез итекләр киеп килгән идем. Каһәр! Шәһәр урамы лычма су иткән аларны. Мин тагын итек башларыма карап утырам. Ул арада ишектә тагын кыңгырау чылтырады. Монысына кызый үзе чыгып йөгерде. Кем беләндер кызу-кызу сөйләшеп алдылар, борын аша чыккан авазлардан мин бу сөйләшүнең ярым-яшерен булырга тиеш икәнлеген аңладым. Бераздан зур пыяла күзлекле, озын чәчле кара чибәр егет түргә узды. Аның артыннан, бераз гына кызарынып, каушагансыман кызыкай да керде. Авыр тынлык урнашасы иде — егет сүзчән булып чыкты.

— О! Гарс дю кампаң? [1] — дип елмайды чибәр егет, ак тешләрен күрсәтеп.

Бу сүзләр минем йөрәкне телгәләде. Боларны мин аваз янгырашы буенча (Галя гел «наң-наң» килеп утыра иде) французча икәнен чамалап алдым һәм бу яңгырашны гомер буе хәтердә сакладым. Нәрсә әйтте икән бу галим егет минем турыда? Моны мин чама белән хәтердә саклап егерме елдан соң үзем тәрҗемә иттем. Яман сүз әйтмәгән икән, әмма инде мине үтереп чыгып китте ул. Шәһәр урамында мин моңарчы үземнең русча белмәгәнемнән оялып, башны түбән иеп кенә йөри идем, болай булгач, инде шуышып кына йөрисе калды.

Минем француженкам күзлекле белән нииндидер мәгънәле афоризмнар, жаргоннар аша фикер алышты, елмаештылар, көлештеләр. Аннан француженка, миңа яхшылык эшләп савабы булсын дигәнсыман бер кыяфәттә, театрга әзерләнә башлады. Урамнан барганда юл буе сөйләшмәдек, театрда сөйләшмәдек, өенә кайтарып куйдым — сөйләшмәдек. Хәтерлим, мин шул вакытта бик нык ябыктым. Чөнки эчтән гел ут, һәр сулыш саен энергия чыга иде. Нииндидер дежур сүзләр сөйләнеп алдык та, аерылыштык. Мәңгегә! Кар ява иде, ул кар бөртекләре минем француженкамның озын керфекләренә куна иде, ә ул юка перчаткалары белән чәченә, керфегенә кунган кар яфракларын сыпыра, үзе елмая. Безнең арада гүя мин мәңге кичеп чыга алмаслык тирән елга, без икебез ике ярда тора идек...

Шул көннән соң мин авылда калмаска, ничек кенә булса да дөнья күрергә, укырга, кеше булырга һәм күзлек киеп, чит сүзләр кыстырып сөйләрлек дәрәҗәгә ирешергә, аннан соң гына бу кызыйны эзләп табарга булдым. Кабул ителгән программаның байтак өлеше үтәлгәндә, минем инде чәчкә ак бөртекләр йөгергән иде. Кешеләрдән сорашып белдем: кызыкай күзлекле бер егеткә кияүгә чыккан, бер мәктәптә эшлиләр, берсе рус әдәбияты, икенчесе чит тел укыта, инде олы уллары алтынчы класста укый икән...

Иртәгесен иртүк торып, тимер юл вокзалына киттем. Коры, салкын иртә, урамнарда салкын тынлык иде. Шул вакыт диңгез шавыдай га-

[1] Ә ...Авыл егетемени? (Французча).

зәмәтле бер тавыш ишетелде һәм иртәнге салкынлыкта тын гына сузылган Профсоюз урамына Куйбышев мәйданы аша бер колонна солдат килеп керде. Тыгыз колонна, ялтыраткан күнитекләр белән, урам карын чыкырт-чыкырт таптый, колоннаның аяк тавышы соры стеналарга барып бәрелә һәм кабатлана иде. Тротуардан аерым атлаган лейтенант та ялан өс иде һәм колонна үрне менеп тигезләнгәч, ул барган җиреннән туктап борылды да, бакыр тавыш белән:

— Запевай! — дип команда бирде.

Нәкъ шул секундта ачы тавышлы берәү җыр башлады:

> **Где ж вы, где ж вы, где ж вы, очи карие,**
> **Где ж ты, мой родимый кра-а-а-й?**

Шунда могҗиза булды. Йөзләгән таза күкрәктән берьюлы, бер сулыш белән җыр бәреп чыкты һәм шәһәрне тетрәтте.

Җыр чын мәгънәсендә шартлау ясады, бозлы түбә кыекларыннан күче-күче белән чәүкәләр күтәрелеп, университет гөмбәзләре тирәсенә очты, иртәнге тын урам уянды, җыр тактына бөтен шәһәр селкенгәнсыман булды.

Кып-кызыл битле, киң күкрәкле таза бу сыннардан торган колонна асфальтның каты карын чакырт-чокырт сытып барганда, мин тротуарда каттым да калдым: болар — кеше, болар — егетлек, батырлыкның үзе иде. Мин хәзер уйлыйм: бу — бер рота. Ул ротаның йөгереп, упражнениеләр эшләп, иртәнге гимнастикадан казармаларга кайтуы. Ул колоннадагы егетләрнең гимнастерка күкрәгендә орден, медаль колодкалары бар иде. Димәк, болар сугыш узган егетләр. Болар хәрби хезмәттә бик озак, бик озак еллар инде. Аларны алыштырырга кирәк иде. Җиде-сигез ел хезмәт иткән, сугыш узган бу егетләрне алыштыру өчен миндәй мокытларга сафка басарга кирәк иде...

Бу егетләрнең шәһәрне селкетерлек әлеге тавышыннан мин йөрәк өзгеч авазлар ишетеп, шуларны аралап алдым: безнең егет вакытыбыз шулай казармада, стройда уза. Солдат булу — яшьлек эше. Без унҗиде яшьтән ут астына кердек. Сугыш туктаганга инде ничә ел. Безгә алмаш кирәк. Безнең дә үз авылларыбызга, туган якларыбызга кайтасыбыз килә, кызлар белән яратышасыбыз, үпкәләшәсебез килә, өйләнеп гаилә корасыбыз килә. Ватан алдында безнең йөзебез пакь, әмма безгә инде егерме биш яшь! Алмаштыр безне, салып ташла да шул олтанлы соры киез итегеңне, бас безнең сафка, буып куй биленә солдат каешы — умач ашап капчыкка әйләнгән корсагыңны җыйсын, сиңа да бер кеше рәвеше керсен...

...Ул җәй — күңелем сиздe — яшьлегемнең соңгы җәе иде. Ул җәйне гел көньяктан җылы җил исте, бөтен дөнья зәңгәр — күк тә, ерак басулар да, рәшә дә зәңгәр иде, җәйге җил аша минем колакка теге сихерле сиреналар тавышы ишетелеп торды:

> **Бегут, бегут пути-дороги...**

Тормыш мине еракка чакыра иде. Бу халәттән чыгарга, дөнья күрүгә сусаган күзәнәкләрне тутырырга, киң колач белән йөрергә, яшәргә кирәк иде.

Август ахырында басулар саргайды, зәп-зәңгәр күк гөмбәзе астындагы кырлар, ындырлар алтын сары көлтә, салам чүмәләсе, эскертләр, кибәннәр белән тулды. Менә бер көнне ачык зәңгәр салкынча күк гөмбәзеннән сихри авазлар ишетелде:

— Торыл-лыйк! Торыл-лыйк! Торыл-лыйк!

Болар — китеп баручы торналар икән. Аларның чакырулы моңлы авазына минем саташулы төшемдәге сиреналарның җыры кушылды:

Аннан... Октябрьның беренче көнендә, мин, Керәнле авылы белән саубуллашып, беренче башлап кылгән юлымнан чыгып киттем. Минем өстемдә инде әйбәт кенә плащ, аякларымда яхшы күнитекләр иде. Өчилегә җиткәндә, теге, бала вакытта, миңа шом салган бәет искә төште. Аягында күнитек... Үз баласы күк итеп...

Торналар хушлашуын ишетеп инрәп калган бу авыл мине үз баласы күк итеп ямансылап озатып калды. Сау бул, яшьлек!

## «Акрын искел, сәба җиле!»

Безнең авылда алты тегүче булып, болар ак һәм кара тегүчеләргә бүленәләр иде. «Аклар» — пальто, бүрек, костюм, мундир, тужурка, «каралар» — толып, тун, тире чалбар, бишмәт тегәләр иде. Гади тегүчеләр һәм «культурныйлар»... Гади тегүчеләр кышын чаңага тегү машиналарын салып, ерак юлга чыгып китәләр, моны әле кырыгынчы елларда да «өязгә чыгу» дип атыйлар иде. Болар язын, март башларында, баеп кына кайталар һәм кайткан көнне кибеткә килеп теләгән кадәр чәй, конфет, шикәр, ситса товарлары алып, гади халыкны бер шаккаттырып китәләр иде. Арадан берсе аеруча хәтердә калган — Шәмсетдин Бәдрие дигән кырык яшьләрендәге бер ир иде. Бәдри җәен-көзен колхозда эшли, карусыз гына йөри, әмма колхозда эш бетүгә, беркем дә белми торган әллә кай якларга чыгып китә һәм май бәйрәме алдыннан гына кап-кара шевиот костюм, сары штиблетлар киеп, авылга кайтып төшә һәм кәефләнеп кенә авыл кибетенә килә иде.

Аңа ияреп, әлбәттә, сеңелесе, апасы килә. Бәдри вакарь белән генә товар карый, ашыкмый. Бер әйбер ала, исәп-хисап ясыйлар. Кибетче агач ящик — кассадан алып аңа вак акча «ыздача» бирә. Әмма Бәдри вак акчаны алмый. Аның өчен иң тантаналы момент шул иде, ул вак акчаны эчкә, кибетче аяк астына терсәге белән сыпырып төшерә һәм мыскыллы караш белән әйтә иде:

— Миңа ыздача нәрсәгә?

Бу моментта ул гадәттән тыш бәхетле горурлык белән әйләнә-тирәсенә карап ала иде. Бераздан Бәдри карап-әйләндереп тагын берәр нәрсә сатып ала, кибетче дә аңа нәкъ баягыча вак акча кайтарып бирә һәм Бәдри монысында тагын да куәтлерәк хәрәкәт белән акчаны сыпырып төшерә иде.

— Вак акча җыеп маташырга син мине кем дип белдең?

Шулай дип ул үзенең калын, кечерәк кенә китап кадәр кара бумажнигын, мәгънәле хәрәкәт белән, куен кесәсенә салып куя иде. Бәдринең тегүгә йөрүе, ахырысы, әнә шул — авыл кибетенә килеп, бер-ике көн горурлык күрсәтү өчен генә иде. Сугыш башланырга бер-ике ел кала Бәдри, кай яккадыр, язылып китеп барды. Ул елларда безнең авыл халкы «язылып» бик күп өлкәләрне юньле, һөнәрле кешеләр белән баетты: бездән Нижний Тагил, Кизил, Кәттә-Курган, Кемерово, Магнитогорск, Тайшет, Красноярск, Сыктывкар кебек шәһәрләргә, эшчеләр поселокларына кеше күп китте. Бәдри дә киткәч, авыл, кемнедер югалткансыман, ятим калды. Аны гел көттеләр. «Бәдри, кайчан кайтасың инде?» дип, күрәсең, сорап язучылар да булган. Утыз тугызынчы-кырыгынчы Бәдрисез елларда авылда шундый шыксыз хәбәр йөри иде, имеш, Шәмсетдин Бәдрие хат язган: крәчин мае кайчан катса, шул чакны без дә кайтабыз, дигән... Бәдри шуннан сугышка киткән һәм, бер дә шикләнмичә әйтергә мөмкин, аның үлеме дә шулай үзенчә, бәдричәрәк булгандыр.

Мондый горурлык, күрәсең, һөнәрчеләрнең барысы өчен дә хас булган. Итекче Җиһанша абзый бар иде. Акыллы, тәртипле, кыска холыклы кеше. Ул Дөбъяз ягына дүрт-биш айга итек басарга чыга иде. Арча станциясенә килеп төшкән — кораллар авыр. Кайтасы юл — егерме чакрым. Базар көн туры килгән, Җиһанша абзый базарда кул чанасы эзли башлаган. Пошалым авылы Арча базарына чана торгыза иде, арадан берсе Җиһанша абзыйга бәйләнгән.

— Ал минекен, гомерлек бу, — дигән.

Шунда горур һөнәрче, кыска холыклы Җиһанша абзый «ычкынган».

— Син, — дигән, — фәләненңне фәлән иткән нәрсә, миңа гомер буе чана тарттырмакчымыни? Миңа бит ул коралларны төяп кайту өчен генә кирәк. Аннары мичкә ягам бит мин аны.

Шулай дулаган да, икенче, телсезрәк чаначыдан тегенең күз алдында кыйммәтрәк бәягә чана сатып алган. Әле киткәндә дулаган:

— Кара әле син аны! Гомер буе мине чана тарттырмакчы! Бирермен мин...

Тегүче Хөснетдин абзый да шундый сыйфатлары белән аерылып тора иде. Анысы, тегүдән кайткач, яз башында — колхоз эшләре башланганчы — берәр атна типтереп алырга ярата иде. Типтерүе дә, эчәргә яратудан түгел, бары тик кеше арасында «менә без болай да итә алабыз» дигән кыяфәт өчен генә иде. Хөснетдин абзыйның СССР Дәүләт банкысы алдында җинаяте бар: ел саен, әнә шул типтереп йөргән көннәрдә, урамда, агай-эне, ирләр җыелган урында, ул кесәсеннән өчлекме, бишлекме чыгарып (тәмәке кәгазенә кытлык еллар), кешене шаккаттырып, шул акчага төреп тарта иде. Әмма бу инде «типтерү» атнасының соңгы көннәрендә «йомгаклау концерты» була иде һәм аның таза, саллы гәүдәле хатыны Гыйльменисатти (Хөснетдин абзый үзе бик җыйнак гәүдәле, җиңел сөякле кеше, әлеге атнада бик җиңел холыклы да була белә иде), гастрольгә чик куеп, өенә кайткач, картын дүрт шарлы агач караватка сузып сала да өстенә менеп атланып утыра һәм тегәрҗепле күзлеген киеп «Йосыф китабын» укый иде.

Бичаралар... Алар дөньяда юк инде. Сугыштан соң малайлары өйләнеп тормыш корган якка — Иделнең теге ягына — Тәмте ягына китеп тордылар алар. Хөснетдин абзый Тәмте ягына сыер җигеп, үзенең тегү машинасын салып барды. Озак еллардан соң туган авылга кунакка кайтканнар. Илле җиденче елның июнь ае булса кирәк. Хөснетдин абзыйның «гастрольләре» туктаганга егерме еллар чамасы вакыт узган икән. Очрашуга теге елларны искә алды.

— Һи-и, яшь чакта, бәйрәм көнне, дуслар белән очрашканда бер «пруштук»ны җибәрә торган идек инде аны, иптәш... Ат ите ашап шаярганда берние дә юк аның. Любей суыкта атны бияләй белән җикмәдек инде аны, иптәш...

...Без сөйләшеп утырабыз. Мин — аспирант, Хөснетдин абзый мине бу дөньядагы иң зур галим дип белә (ялгыша, бичара!). Аның грамотасы юк, ул әле әдәбият дөньясында зур галимнәр барын башына да китерми.

Туган авылда безнең йортта шулай утырабыз. Миңа шайтан керде.

— Хөснетдин абзый, ничек соң, синең яшь чакны бер искә төшереп алыйкмы? — дим. Өстәл астыннан «Вишневая» дип кәгазь сугылган кара авыр зур бер шешә алам. Литр дигәннәр, авырлыгы өч килога гына бетмәс.

Хөснетдин абзый дерелдәп куя:

— Юк, иптәш, шту син, ураза вакыт,— ди.— Минем, —ди,— утыз алтынчы елдан бирле авызга алганым юк. Әле менә сагынуга чыдый алмыйча кайттык. Гыйльмениса әйтә, туган нигезгә, зиратка дога укып

китик, ди. Уразага кердек. Шәригатьтә мөсафир кешегә рөхсәт итела дип әйткәннәр әйтүен.— Ул ниндидер өмет белән Гыйльменисаттига карап алды.

Гыйльменисатти исә, өстәл өстенә япкан ашъяулык почмагын бөтерә-бөтерә, әнигә сөйли иде:

— Шуннан суңы... нитеп-е... Йосыфның күлмәген алып-ы... Кыр кәжәсен тотып суеп-ы... Шуның канына Йосыфның күлмәген буяп-ы... Хәзрәти Якупның каршына китереп-е куеп-ы...

«Йосыф-Зөлайха» кыйссасы турында мин күпме генә фәнни хезмәт укымадым! Бу турыда ничә генә лекция тыңламадым! Әмма алсу эре чәчәкле шәлъяулыгы белән бөтен аркасын-җилкәсен, маңгаен төргән Гыйльменисаттинең «ы-ы» килеп Йосыф кыйссасын укыгандагы кебек көчле тәэсирне бер җирдә дә алмадым.

Монда да шулай иде. Гыйльменисатти, өстәл астыннан менеп утырган теге явыз шешәгә күзе төшеп, кинәт тынсыз калды.

— Син, дим, син! Җүләрләнмә!

Хөснетдин абзый бер аңа, бер миңа карады.

Мәсьәләнең җеп очы һәм ахыры минем кулда иде. Мин үзем булдыра алырлык фәлсәфәгә керештем. Болай сөйләдем:

— Гыйльменисатти! Сез гомер буе юньле кешеләр булдыгыз. Сез күчеп китkәч авылда ямь кимеде. Сез яшәгән урам ятим калды. Сез миңа — атасыз балага — авыр елларда күпме ризык бирдегез. Мин сезнең аркада исән калдым. Инде сез олаеп, туган җирегезне сагынып монда кайткансыз. Шәригать юл кешесенә ураза тотуны мәҗбүри түгел дип әйтә — моны мин беләм. Инде Хөснетдин абзыйның да мондый зәмзәм суы капмаганына ничә еллар икән. Тагын кайчан күрешәбез? Үз гомерендә беркемгә начарлык эшләмәгән, гомере буе җир сөргән, кешеләргә матур киемнәр тегеп, аларны матур иткән, колхозда теләсә нинди авыр хезмәтне сытып башкарып килгән бер гөнаһсыз Хөснетдин абзыйдан бер стакан шушы зәмзәм суын алла кызганырмыни?

Күрәм — Гыйльменисатти каушады. Чөнки үз коралы — шәригатьне эшкә җиктем. Шулай да тиз генә бирешмәде:

— Җитмешкә якынлашып килгәндә... Ураза аенда...

Мин кыюландым, Хөснетдин абзый да күзләрен мөлдерәтеп миңа карап тора иде. Бу караштан мин шуны аңладым: әйдә, әйдә, иптәш, тагын бер-ике сүз...

Һәм сүзгә ул да катнашты.

— Шушы басу исләрен бер иснәргә... Үз чишмәбезнең суын бер эчәргә... Шушы агачларның яфрак кыштырдавын бер тыңларга... әллә ниләр бирерлек булам. — Ул чалбар кесәсеннән таушалган кулъяулыгы чыгарды. Гыйльменисатти биреште.

— Я алла, үзең ярлыка,— дип авыр сулады да әнигә таба борылды...

...Чия суы тамырларга йөгерде. Әни белән Гыйльменисатти стенадагы герле сәгатькә карый-карый (авыз ачарга әле 5 сәгатьләр чамасы вакыт бар) сөйләшәләр, мин исә Хөснетдин абзыйны тыңлыйм. Ул бер дә сөйли белми, ләкин мин аны аңлыйм. Әйтелмәгән сүзләрен дә аңлыйм.

— Шуннан, шул, иптәш. Күрше-күлән бик ярата. Баштарак кием тектем. Хәзер текмим, кибеткә кайта. Аннан алма бакчасына эшкә кердем.

Анда һәр колхозның үз алма бакчасы бар, иптәш. Мине яраталар. Тик, иптәш, йөрәк үз урынында түгел. Бабай дип эндәшәләр. Хөснетдин абзый дигән кеше юк. Исемемне дә белмиләр. Аннан... «Зингер» машинасын чормага меңгереп куйдым. Бик жәлькә, иптәш. Ул, мин сиңа әйтим, андагы алма бакчаларын күрсәң... Алар чәчәк атканда, оҗмах шушымы икән әллә дип уйлыйм мин. Тик, иптәш... Менә әле, килешли Масра юлыннан килдек. Һи-и-и... Бездәге баллы куәт, күк чәчәк, билчән

чәчәге исе! Күзен торналар төшә торган Масра түре! Андагы рәшәләр! Алары юк инде аның... Һи-и-и, иптәш... Ә торна елгасы?

Миңа авыр. Түр якта, инде күчеп карават кырына яртылаш утырган Гыйльменисатти, шуа-шуа, «китап сөйли».

Гәүһәр таштыр вәләкин гади таш улмас,
Тикмә кеше гәүһәр кадрен кыяс кылмас,
Бу назымның кадрене ахмак белмәс,
Гакыйль кеше дыңлар, аңлар, белер имди...

...Икенче көнне алар таң белән Масра юлыннан чыгып киттеләр. Масра юлы — гомернең гомер буена безнең авыл кешеләрен читкә озаткан, читтәгеләрне кайтарган юл. Хөснетдин абзый үр артына күмелгәнче, ике-өч тапкыр туктап, борылып авылга карап алды. Гыйльменисатти борылмады. Июньнең йомшак, тыгыз таң җилендә аның кәбестә яфрагы кадәр ал чәчәкләрдән бизәлгән шәлъяулыгы җилферди иде. Әни белән без моңаеп карап калдык. Бу — Хөснетдин тегүченең соңгы китүе, соңгы борылып каравы иде.

Таң җиле исә иде, шул вакыт Гыйльменисаттинең көйле, ипле ритмына кушылып хикәят әйтәсе килде:

Акрын искел, сәбах җиле, нә үтәрсән,
Хакыйкать Йосыфымнан ис тотарсаң,
Җәрәхәтем уңалмага сән ийтәрсәң,
Сән искәли, шат-хөррәм улдым имди...

Шул җәй беткәндә Хөснетдин абзый гүр иясе булган. Хәер, кайтуы кайчан булса, шул елны үләсе булган ул. Ә ул сузган. Белеп сузган.

Аның «Зингер» машинасы кайда икән хәзер? Алма ашап үскән Тәмте ягы малайлары, ихтимал, аны инде металл җыю атналыгында чормадан табып алганнардыр...

Һай, бу дөнья! Акрын искел, сәба җиле!

## Егетлеккә юл, имеш...

Безнең авылда егет булуның, егетлек чорына күчүнең бер киртәсе бар иде. Ул — кызлар янында кунып чыгу. Монда бернинди гөнаһ, бозыклык юк, әмма шуны узмаган көе сине әлҗгә егетлекнең серле дөньясына кабул итмиләр, синең белән әле юньләп сөйләшмиләр. Егетнең иң шәбе төн уртасы узгач, таң алдыннан, урамнан ялгыз җырлап кайта. Моңа каршы тагын берәү җырлап килә. Тыкрыктан тагын берәү. Бәхетле йөз белән очрашалар. Тәмәке кабызалар. Сөйләшү, мактанышу.

— Ә мине шундый итеп төртеп уятты Гөлбәдәр. «Бар, ди, адәм хурына калабыз, кояш чыгар вакыт җитә», ди. Сикереп торып сәгатьләрен карасам — нибары ике тулып чирек. Йокыдан һич айныр хәл юк. Чак чыгып киттем...

— Ә мин! Ә мин! Утны сүндергәч, сәкегә ятуым булды, Гәскирәне кочагыма алуым булды, ишетәм — теге як идәндә берәү гырлый. Фәрхетдин икән. Без бит кичә көне буе урманнан агач тарттырдык. Визирь юлыннан, кәнүшнигә хәтле дүрт юл бардык. Арылган. Әле Фәрхетдин калды. Тәзкирә анысын уятып та тормады. Майбәдәргә «Даваегыз, кеше-кара күргәнче, яктырганчы егетләрегезне аттыравәләй, — ди. — Минем йөзгә кызыллык китермәгез», дип Минсараны да торгызды.

Бу — бик ирләрчә, бик бәхетле сөйләшү.

Мин бу киртәне узарга бер-ике ел хыялланып йөрдем. Кыюлык җитмәде.

Шул киртәне узмаган егет-малай явыз, кешегә каныгучан, үчлекле була. Хәер, гыйшык-мәхәббәтнең тәмен татымаган, ул хистән мәхрүм

булган кешедән нинди юньлелек көтәсең? Без егет-малай чорын кичергәндә авылда байтак шуклык эшләдек. Берсе аеруча хәтердә калган. Көзге каткак кич. Ай яктысы. Бөтен дөнья яшькелт-зәңгәр салкын нурда коена. Безнең инешле су буенда анда-санда боз ялтырап күренә. Урамнар коры, чиста. Бу — көз дисәң көз түгел, кыш дисәң — иртә. Урамга киез итек, каеры тун киеп чыккан кешеләр бар. Җылыга рәхәтләнәләр. Юкача киенеп, кепка-фәләннән генә йөрүчеләр бар. Бераз туңалар. Әмма безне туңу да, җылыну да кызыксындырмый. Авыл башындагы иң кырый өйгә — тол карчык Шәмсеҗиһан түтинең бердәнбер кызы Хәйриҗиһан янына егет кергән. Өйләрендә ут юк. Егет — күрше Мөрәле авылыннан. Моны безнең «братва» төп-төгәл белә. Без каткак урамда йөрибез, төн салкын, ә күрше авыл егете, пнимаешь, Хәйриҗиһанның кайнар кочагында рәхәтләнеп (без инде, бер дә шикләнмичә, анда рәхәттер дип уйлыйбыз) ята. Бу ни эш бу? Абзарга бүре кергән — аны куып чыгарырга кирәк.

Шунда фантазия эшли. Шәмсеҗиһан түтинең йорты киртә-курасыз, тәрәзәләр урамга чыккан. Күрше малайлары яхшы белә — Шәмсеҗиһан түти почмак якта йоклый. Анда бер тәрәзә. Өй бүлмә тактасы белән урталай бүленгән. Олы якта сәке. Анда ике тәрәзә урам ягында, икесе — ишегалдына карый. Ишегалды да урам белән тоташа, кыскасы, йорт уч төбендә кебек. Оператив план төзелә. Шәмсеҗиһан түти йоклый торган якның тәрәзәсенә килеп шырпы сызабыз. Караңгы йортның эче ялтырап ала. Бер шырпы, ике шырпы, өч... ыңгырашкан тавыш:

— Кайсы юньсезләрс ул, башы беткерләре?
— Абзарыңда бүре бар!
— Нинди бүре?
— Хәйриҗиһан яныннан Касыймны чыгар!
— Нинди Касыйм? Һай, башыгыз беткере! Нинди...
— Хәйриҗиһан яныннан Касыймны чыгар!
— Нинди Хәйриҗиһан? Һай, башыгыз...
— Үз Хәйриҗиһаның. Олы якка чыгып кара!

Тагын шырпы сызу. Бу юлы олы як тәрәзәсенең өч-дүрте берьюлы яктыртыла. Күрәбез — «дошман» хәрәкәткә килде. Ә сугышчан разведчиклар почмак як тәрәзәсендә һаман әле эш куерталар.

— Хәйриҗиһан яныннан Мөрәле Касыймны чыгар!

Ыңгырашкан тавышлар чыгарып, Шәмсеҗиһан түти сукыр лампасын кабыза, ул арада өй ишеге «дың» итеп ачыла һәм, мәчедән куркып он бурасыннан атылып чыккан күсе шикелле, чоланнан Касыйм килеп чыга һәм шундук бакча яктан түбән элдертә. Без аның артыннан йөгереп тә тормыйбыз, без шат, чөнки программа үтәлде, Хәйриҗиһан белән Касыймны без рәхәтлектән мәхрүм иттек.

Җиңү шатлыгы җырласыны китерде. Югары оч малайларының исә теләсә кем өчен репертуар әзер. Ертык ай яктысында ялтыравык бозларны чытырдатып, Мөрәлегә таба астан Касыйм йөгерә. Ә без тау башыннан хор белән такмак әйтәбез:

> **Хәери — балта, пычак кайрый,**
> **Кайраса да утми,**
> **Касыйм гына житми...**

Бәндә үзе белмәгән нәрсәгә дошман булыр, дигән китап. Без дә мондый хәлләргә дошман идек.

Әмма... Шул, үзең дошман булган халәткә бер төшеп карыйсы иде...

Менә көннәрдән бер көнне — җәйге җылы, чикерткәле кич — чык төшкән, су буенда түгәрәк уен уйнаганда минем белән янәшә баскан кызга игътибар иттем. Кунак кыз! Каян?

— Масрадан.
— Кемгә килдең?
— Сәрияләргә.
— Озаккамы?
— Бер кичкә.
— Синең белән якыннанрак танышырга мөмкинме? — Кыз кулын минем учтан ычкындырып читкә борылды, чәчен рәтләгәндәй итте. Аннан, су буе һавасы кебек дымлы салкын тавыш белән болай диде:
— Анысын үзегез карыйсыз инде. Мин монда ярминкәгә килмәдем, товар күрсәтәсем юк...
Аны озата кайткач, мин урынның келәткә җәелгәнен белдем. Төн иде инде. Башта келәт баскычында тегене-моны сөйләшеп утырдык. Хуҗа кызы «Я, ярар, калганын үзегез карагыз», дигән сыман бер җөмлә әйтте дә өенә кереп китте. Ә мин кунак кызга сөйләдем дә сөйләдем. Менә болай сөйләдем кебек:
— Бүген сәгать дүрттә әни уятты. Ашап-эчкәнче биш булды. Ә миңа лесхозга барырга кирәк. Печән өсте җитеп килә бит, сыер асрыйбыз, тана бар, бозау бар. Печән чабарга участок алмыйча булмый. Участоклар быел бик кысылган. Билетсыз бер җиргә дә кертмиләр. Менә егерме чакрым иртән бардым, җил каршы. Кайтырга чыксам — җил борылган. Җилгә каршы барганың бармы синең, ә? Бармы? Менә була ул барлыгы кырык чакрым. Аяклар әле дә сызлый. Белдеңме шуны?
Бу сөйләшүнең ахырында икебезнең дә авыз ачылгалый башлаган иде, моны аңлап, келәткә кереп киттек. Мин болай гына, аны озата гына кердем, ул да болай гына... Түшәккә баш тиюгә, мин әллә ниткән ак болытлар арасыннан очып киттем. Рәхәт, бик рәхәт иде. Күпмедер шулай йөзеп йөргәч, кемдер мине ак болытлар арасыннан очып барышлый кулымнан тотты.
— Тор, юньсез, кояш чыга, көтү куар вакыт җитә,— диде. Күземне ачсам — хуҗа кыз.
Тиз генә бакча яктан су буена таба элдерттем. Гомер буе үкенгәнем — теге кызның исемен сорарга онытканмын һәм яткач-яткач, инде бер тапкыр булса да, кочаклап карыйсы булган икән. Су буенда чишмәдә битне юып маташканда кемдер эндәште. Сискәнеп күтәрелеп карасам — яшьтәш Юрис. Аның исеменең тарихы бар: утызынчы еллар башында, нинди дер бер җинаятьтә катнашы булуда гаепләнеп, анын әтисе кулга алына. Шул эш буенча колхозга килеп төшкән бер укымышлы егет бу эшне тикшереп, күп кешене азат итә. Мондый гаделлек, яхшылык эшләгән егетнең исемен дә белмиләр, тик аны бөтен кеше «юрис», «пыркарун» дип атый. Шул көннәрдә генә авылда борын өстендә аркылы зәңгәр тамырлы бер малай туа. Әтисе өч көн КПЗда нахакка утырып кайткан көнне була бу. Малайга нинди исем кушарга? Дөньяда иң юньле кеше исемен. Ә иң юньле кеше кем? Юрис, пыркарун. Әнә шулай безнең авылда Юрис барлыкка килә. Икенче берсенең дә күпмедер вакыттан соң малае туа. Аңа «Пыркарун» кушмакчы булалар, әмма «Прокурор» сүзенә бик ошаган ул дип, ана кеше ирек бирми.
Юрис инде егет булган, төнге йөрүләрдә тәҗрибә туплаган, колхозның төп эшчеләреннән берсе, минем кебек ярым крестьян, ярым интеллигент түгел. Юрисның кәеф шәп иде, ул чишмә өстендәге чирәмлеккә рәхәтләнеп утырып тәмәке кабызды. Йөз процентлы крестьян яшьтәш сөйләп китте:
— Минем,— диде,— Исламгали абзаңның келәтеннән кайтып барыс Зәмилә яныннан. Уеннан таралганда гына — сап! — мин Зәмиләне борып алдым. Яздан бирле борынын күтәреп йөри. Ә күңел гел сунда гына минем. Тоттым, кайттык. Мин әйтәм: или келәтеңә апкерәсең, или, минәйтәм, бу дөньяларда ясәмим.

Юрис «ш», «ч» авазларын яратып бетерми иде. Күрәсең, әти-әнисе аның бу дефектына ярдәм итәргә теләптер инде, аннан соң туган малайга җайлы исем кушканнар: Зәмзәметдин. Юрис энесен бик ярата һәм аны мактый иде. Тегесе ташбаш булып чыкты, сугыш башланганда аңа алты яшь иде, ул 1941 елның салкын кышында төнге сменага ындыр табагына йөрде, ат белән эшләде. Сугыш беткәнче колхозда Зәмзәметдин дигән бер карусыз кеше бар иде, колхоз, әйтерсең лә, шуңа гына тотынып тора иде. Юрис энесенең яңгыр-карда яланаяк, күлмәкчән, яланбаш йөри, эш башкара алуына горурланып:

— Минем Зәмзәметдин энем заңгырда сыныгып үсә,— дип мактанырга ярата иде.

Әә, Юрис сөйли бит әле...

— Күнде, риза булды, ыслусай. Әйттем: бир кулыңны, Зәмилә, гомерлеккә, мәңгегә,— дидем. Хатын-кызны беләсең... Аларга беркайсан да ысанып бетәргә ярамый. Кердек, түсәк-мендәр. Яттык кына, анасын корт саккыры... Исламгали абзаңның өй түбәсенә тас ыргыталар. Вактөяк малай. Дөбер дә сатыр килә. Күпкә киткәс — сизәм, Исламгали абзый өеннән сыкты. Капкага килде. Исетеп ятабыз. Зәмилә дер-дер килә. И суннан нәрсә булды дип уйлыйсың?

— Нибар, нисләп хулиганить итәсез? — ди Исламгали абзый урамдагы малайларга.

— Келәттән Юрисны сыгар, Зәмилә янында Юрис бар,— дип сау киләләр бит тегеләр, малай заным. Суннан нәрсә булды дип уйлыйсың? Исламгали абзый кыстыр-кыстыр атлап келәткә таба килә баслады. Без дә сикереп тордык. Киңәсергә вакыт зук — мин капкында. Исеккә килде, тамагын кырды. Исек, кәнисне, инде асылган. Килеп керүе булды, карсына бастым да...

— Нәрсә, әллә суктыңмы? — дип куркынып сорап куйдым мин.

— Зук, зук... Нисләп сугыйм. Син мине әллә зүләр дип белдеңме? Заратып зөргән бер кызның этисенә сугарга. Зук... Исламгали абый, мә, берне тарт,— дидем дә кулына папируз тоттырдым.

— Шуннан? — Минем, түземсезлектән, йөрәк кызу-кызу тибә башлаган иде.— Шуннан?

— Суннан — сул. — Ә, ярый сез икәнсез әле,— диде. — Тульке тәртипле булыгыз, зәме,— диде дә папирузын кабызып өенә таба китте.- Ут кына сыгара күрмәгез, ди. И суннан соң, малай, сундый тынысланып йоклап киткәнмен...

...Көтү куа башлаганчы, бакча башларыннан тиз-тиз генә элдертеп, кайтып җиттем дә, өйалдындагы караңгы бүлмәгә кереп, яшь егетләрдә генә була торган тирән, татлы йокыга талдым. Хәзер, олайгач, егет үстерүче ата-аналарга әйтәсе бер сүзем бар: тәмле итеп йоклаган өчен улларыгызга ачулана күрмәгез! Йоклап калсыннар! Тәмле йокы — яшь вакытныкы. Олайгач, андый йокыны меңнәр, миллионнарга да сатып алып булмый...

Иртәгесен, гадәт буенча, әни уятты. Җитмәсә, апалар да җыелган көн иде. Әни:

— Бу нәрсә? Бу нәрсә? — ди. Кулында — минем кара сатин күлмәк. Кыек якалы, егермеләп ак сәдәпле. Ул вакытта шундый мода бар иде. Кара сатин күлмәгем түшәк-ястык мамыгына буялып, ала-тилә булган! Күрәсең, хуҗа кыз келәттәге түшәк-ястыкка җәймә җәяргә оныткан...

Мин әни каршында басып башны иеп тордым. Апалар бик мәгънәле итеп миннән көлделәр. Әни дә булганыннан артыгы белән аңлый иде. Әмма мин читенсенмәдем: минем Масра кызы янында кунып чыкканга ике шаһит — хуҗа кызы һәм Юрис бар иде. Димәк, мин... Димәк, мин— инде егет! Егет!

Ул көнне су буена кечке уенга төшкәч, мин дус-иш егетләр белән

кул очын биреп кенә, авызымны бераз күтәребрәк, гамьсез кыяфәттә читкә карабрак кына күрешкән булдым. Нәрсә, сезнең белән авыз чайкап торырга мин әллә малай-шалаймы? Әле күбегезнең кыз янында куныл чыкканы юктыр... Кулыңа су салырга ярамаган малайлар белән вакланып ятканга рәхмәт диегез...

Бу — хәрби хезмәткә китәсе ел иде бугай.

Шул көннән башлап, авылга килгән кунак кызлар — минеке. Егетнең иң шәбенә генә эләгә ул кунак кыз. Шулай бер кызның клубтан чыгышлый гына янына килдем. Мин бит инде тәҗрибәле: шулай, дидем, мин бу авылда шәп егетләрнең берсе, әгәр танышып китсәк, үкенмәссең, дидем. Кызый — кыю, күрше колхоздан туганнарына килгән. Ул вакытта әле «доярка» дигән мактаулы исем юк, әмма кыз — фермада эшли. Кулларын тоттым — бармаклар нык, беләк көче дә сизелеп тора. Кайттык капкага, кердек эчкә. Каз суйган көзге матур вакыт. Кыш әле килмәгән, аяк асты каткак, кар катыш боз, каты балчык. Айлы төн. Кердек төз лапас астына. Сөялдек саламлы киштәләргә. Мин, тәҗрибәле кеше буларак, сайрыйм. Шулай, шулай, дим, мин, дим, төшеп калганнардан түгел, шулай, шулай, мин шәп егетләрнең берсе, дим. Шул вакыт — өй ишеге ачылганны ишетәм һәм өйалдындагы керосин лампасының тоныкнуры безгә таба юнәлгәнен күрәм. Төнге салкында каткак өйалды сайгаклары шаңгырдап ала һәм баскычны шыгырдатып берәү безнең янга төшеп килә. Ай нурында күреп калам, без үзебез күләгәле лапас астында саламлы киштәләргә сыенып беткән, күреп алам... Хуҗа хатын, комган тотып, нәкъ безнең өскә килә. Килә... Кунак кызның таза йөрәге дөп-дөп килә, лапас киштәләре дерелди. Мин дә белдермәскә тырышып кына дерелдим. Кыймылдарга ярамый. Ләкин моны — без уйлыйбыз. Ә хуҗа хатынның моны уйларга исәбе юк, ул туп-туры безгә таба килә... Куркудан мин артка чигенәм һәм... шул чак салам кыштырдый. Һәм мин үземнең кочагымдагы кунак кызны язмышка тапшырып, гөрселдәп атлап, лапас астыннан ай нурына коенган капкага таба торып йөгерәм. Менә сиңа рыцарь! Һәм ишетәм:

— Ах, чукынчык, жулик тәре, әле син монда лапаска кереп сарык урларга йөрисеңме?

Дөңгер-дөңгер итеп, каткак ишегалдында минем арттан комган тәгәри...

Мине исә ай күрде — кояш алды.

Хәер, «кызлар белән танышу, дуслашу өлкәсендә» мин гомер буе беркатлы мокыт булып калдым. Минем кызык — ничә кыз белән танышсам, шулкадәр мәзәк! Я инде, шунысын гына алыйк: апам эшләгән кечкенә авылга «кунак егет» булып барам. Кызлар — гөж! Кунак егет килгән! Безнең Казан артында шулай. Кунак кыз белән кунак егет аеруча ихтирамга, игътибарга лаек кешеләр. Җиңелчә сыйланып, кыюланып, көтү кайтыр алдыннан урамга чыксам, ни күрим?! Нәзек тал чыбыгы тоткан бер гүзәл кыз тыкрыкта тора. Миңа нәрсә? Бардым, таныштым. Шулай, шулай, дидем, кич чыгасыңмы? Мин, дидем, әлегә беркемне дә тапмаган, үз тиңемне, үземне яратырлык бер кызны эзләп гомер уздыручы, картаючы (миңа бу елда 19 яшь!) бер бәхетсезмен... Кич уенга чыгасыңмы? Чыгам, диде бу. Мин моңа игътибар иттем: бу инде кич чыгар өчен киенеп куйган, ак кофта, үтүкләнгән юбка, аягында ап-ак брезент тапочкалар. Ап-ак. Алай... Ярар, дидем, мин сине кичке уенда табармын. Шуннан мине яраткан җизни белән бик шәп утырулар булып алды, караңгы төште, кызлар-егетләр болынга уенга агылдылар. Йөрәгем типкәнне ишетеп, болынга мин дә киттем. Кичке куе караңгылык болынны төреп алган иде.

Тукай әйткәнчә булды: мин дә бардым болынга, дегет чиләге дә барды. Карасам, түгәрәк уендагы кызлар барысы да ак тапочкадан

иде. Мин уен тирәсендә озак йөрдем, теге кыз үзе мине тапмадыэзләмәде. Ду кубып, шаулашып болыннан авылга кайтканда да мин ялгыз идем: төн караңгылыгында бер күч ак тапочкалар гына бутала, куе чыклы кара чирәмнән авылга таба ак ялкын ургыла иде.

## Киленнәр

Түбән һәм Югары Симеттән безнең авылда алар нәкъ биш килен иде. Болар кадәр бер коллектив булып яшәгән киленнәрне башкача белмим мин. Август ахыры. Кыр эшләре инде беткән, бәрәңге алганчы берара вакыт бар. Шул көннәрдә әни активлашып китә: аеруча бер дәрт белән «авылдаш киленнәр»гә йөри башлый. Күрешәләр, план коралар, көнен билгелиләр. Берәр көн кала сәгатен үк билгелиләр. Әни пешеренә-төшеренә. Күчтәнәчкә ул төш пешерергә ярата иде. Күлмәк, яулык, аяк киемнәрен карый. Сандык төбеннән бик күп тишекле, бик күп вак тимер колаклы кара ботинкаларын ала. Ул ботинкалар бары тик Симеткә барганда гына киелә. Менә алар, баш очларына төенчек утыртып, кыр казларыдай тезелешеп, Симет ягына таба юл алалар. Алардагы шатлык, алардагы күңел күтәренкелеге. Юлга чыгуга Симетчә сөйләшә башлыйлар. Әйтергә кирәк, безнең авылның теле әдәби тел нормаларына бик якын. Бездә нормадан чыккан бер генә диалект бар: «дагын-дәген». Ә Симет теле бай: алар: «кыдыл бодау» диләр, бодайны — «бозай», сәкене «сике» диләр. Әнинең яшьтәше — Симет килене Шәмсеруй түти сүзләрне юри дә бозып сөйләшә, шуннан тәм таба: җиңел машинаны «туфли» (легковая) ди, шуны әйткәч, хәйләкәр елмаю белән кешеләргә карап ала, янәсе, шәп әйттемме?! Бригадирны — каян алыптыр — «пертизар» ди һ. б. һ. б.

Ничә яшемдәдер, болар белән бергә Симеткә мин дә бардым. Юлда баш түбәсенә акробатларча утыртылган төенчеген селкетмичә, аяк атлавы җаена Шәмсеруй түти сөйләде. Калганнары тыңладылар. Симеткә якынайган саен Шәмсеруй түтинең теле симетләшә бара иде. Бичара, безнең авылның төрки-гарәп-угро-фин катыш каты сөйләменә каһәрләнеп, тилмереп яшиме икән әллә ул? Шәмсеруй түти һәрвакытта үз нәселендәге (Симеттәге) төрле һөнәр ияләре булган кешеләр турында сөйли. Ул гел әйтергә тели: мин менә каян чыккан, ә сез менә кем генә.

— Безнең Ишнияз,— ди,— калада зур эштә эшли. Атбәкәтлектә. Гозере төшкән кеше шуңа килә. Судтан өенә гел чыбык белән хәбәр итеп торалар. Фәлән кешегә атбәкәт кирәк, диләр. Әле үзебезнең Симетнең дәү апа кызы харап була язды. Ачык авыз булсаң шулай ул. Өстеннән чыкты. Чүриледә культимәгтә эшләп алганые. Ай ярым эшләп калды. Ишнияз кайтмаса, башлары беткәние инде. Минәйтәм, бу теге ни инде, тиле хатын әйтмешли, җырдагы кебек була:

> Култимәккә кергән булып,
> Дәптәр-мәптәр саткан булып,
> Ай җарымга — мен җарым,
> Мең җарымга — җыл җарым.

Шулай булды инде ул, минәйтәм. Алдаганнарын белә торып, шунда эшләп җөри бит. Белә торып. Шуннан и судка кайтып төште Ишнияз туфлигә утырып, и суд башланганчы Чүриле халкын җыеп җыен уздырдылар, и минсиңайтим, кызына җиңелләр бәйләп (юри: җиңенә кызыл бәйләп дигәние әйтә) йөри бер-ике егет. И мин сиңайтим, судка тикле бөтен кәпрәтиф халкын авыллардан җыелышка җыеп сөйләшеп җибәрделәр. Кәпрәтифнең иң галауның пертизары әйтә:

— Заваегыз, иптәшләр, сикегә алгарак килеп утырыгыз, закладны сөйли башларга вакыт,— дигән була.

Шуннан безнең Ишнияз торып... Ә-ә, анысы әле судта икән, шул көнне өйләдән соң...

Югары Симеттә өч килен бездән аерылып калды. Түбән Симеткә килеп керүгә тагын берәү төп нигезендә тукталды. Минем бабайларның нигезе авыл уртасындарак икән, әни белән икәү генә барабыз. Чит авылга кияүгә чыккан кызлар! Үз авылыгызга кунак булып килгәндә, һичшиксез, малаегызны җитәкләп алып барыгыз! Машина белән түгел, мотоциклда түгел, авыл урамыннан җәяүләп керегез! Малаегыз гомере буена шул көнне хәтерләп, бәхетле сагыш эчендә яшәр...

Урамнан барабыз — капка төбендәге хатыннар кузгалып каршыга киләләр. Кочаклашалар, ике кул биреп, әни белән күрешәләр, шул арада елап алалар.

— И, Рабига, Рабига... Син дә картайгансың,— диләр. Авыл халкы тәкәллефләнеп тормый: ни бар — шуны әйтә.

— Әйдә, чәйгә керик!

— Әйдә, самавыр яңартам!— дип бөтен Симет урамы гөж килде. Миңа шулчак бик рәхәт булды — әни яшәреп китте, гәүдәсе төзәйде, күзләрендә балаларча беркатлылык, шатлык очкыннары күренде. Урам буйлап без шулай бардык. Авылның нәкъ уртасында олы зират. Әни мине шунда алып керде. Нигә башта туган нигезенә бармаган ул, нигә зиратка керергә ашыккан, әле дә аңламыйм. Кердек, куе караңгы агачлар арасында ниндидер калкулыклар, иңкүлекләр, черегән такталы чардуганнар, дымлы мүкләнгән яшькелт ташлар бар иде. Бер калкулык янына утырып әни дога укыды.

— Менә монда әбиең-бабаң сөякләре булыр, улым,— диде. — Әбибабаңның каберен онытма! Әби-бабасының туфрагын онытмаган кеше игелекле була.

Ә минем Түбән Симет зиратына шуннан соң бөтенләй аяк атлаганым юк...

## Җиде аршынлы бүрәнә белән...

Гатият абзый, бер дә арттырмыйча әйткәндә, Уральск шәһәрендә Тукайның үзенә тужурка тегеп биргән «ак тегүче». Тукайның Уральск шәһәрендә кулына газета тотып төшкән рәсеме булырга тиеш, ди Гатият абзый — укый-яза белми торган, мәһабәт гәүдәле, мыеклы карт.— Бармы шул? Бармы? (Өйләрендә бер китап юк! Малайлары сугышта үлеп бетканнәр, бер генә онык та юк!) Бармы шул?

Тукайның Уральск шәһәрендәге тормышын сөйләгәндә Гатият абзыйның күзләре очкынланып китә. Сизәм — барысын да булганча, язылганча сөйли. Габдулла Кариевны, Мортаза байны, Камил Мөтыгыйны, Мөтыйгулла хәзрәтне белеп-күреп сөйли. Шиккә калам. Әмма, шунысын да беләм: Гатият абзый — бер әлифбадан бер хәреф тә танымый. Хәтер генә эшли.

— Иске Кишетнең Хәкимҗан белән мине Тукай бик яратты. Якташлар дип йөртә иде. Без — байда хезмәт итәбез. Бер кичәдә Тукай шигырен укыды. Сайлче турында. Шунда саилче итеп Хәкимҗанны чыгарып бастырды. Шуңа карап шигырь укыды. Шуннан соң Хәкимҗанны урамда очраткан бер кеше «Хәерче! Хәерче!» дип кычкырып көлә иде.

Гатият абзыйның сөйләгәннәре — дөп-дөрес. Бу истәлекләр Тукай томнарының артында бар. Чагыштырып карыйм — бер генә хилафлык та юк.

Гатият абзый «ак тегүче» — ягъни, авылдагы укытучыларга, фельдшерларга, агрономнарга, шәһәрдән ялга кайткан кешеләргә затлы киемнәр тегә иде.

Аның тегәргә яраткан киемнәре — «тулстуфка» (Лев Толстой исеме белән аталган кием: вельветтан тегелә, тезгә житәрлек озынлыкта, күкрәктә ике кесә, путалы, янда ике кесә); «зимнәчтүркә-чалбар»; тужурка; җәйге яки кышкы пальто. Сугыш башланыр алдыннан авылда тегү артеле ачылды. Солдат киеме, бияләй, бүрек тегә башладылар. «Ак тегүчеләр» шунда керде. Әмма Гатият абзый колхозда калды. Аның мәһабәт саллы гәүдәсенә күрә эш бар иде: өч җәплекәле агач сәнәк белән ул барабаннан тарттырылган саламны күтәреп өскә бирә — эскерт очлап тора иде. Кырда кибән очлау да (көлтә чүмәләләрен бер урынга ташып кибән куела) Гатият абзый карамагында булды.

Гатият абзый авылның җәй көнен, аның да көтү кайткан вакытын бик ярата, шул сәгатьтә ул тау буендагы чирәмлекләрдә йөри, кулын каш өстенә куеп, аргыяктан биргеякка карап торырга ярата иде. Һәм сүзнең тәмен белеп, сюжет корып сөйли иде.

Кич... Әле кояш батмаган. Гатият абзый яшел чирәмлеккә салынган бүрәнәдә утыра. Өстендә үзе текән юл-юл күлмәк, үзе теккән «постау» жилет, башында эшләпә. Урамда сарык бәтиләре авазы. Аңгыра бәтиләр әниләрен югалтып, адашып, капка саен кычкырып йөриләр. Әниләрен дә танырлык түгел: иләмсез итеп кыркып йоннарын алганнар да, бер уч йоннарын калдырып, зәңгәр яки кызыл лента бәйләгәннәр. Ямьсезләнеп, сырлы бәләк булганнар да калганнар. Үз ямьсезлекләреннән үзләре оялгандай, ахмакларча кычкыралар. Гатият абзый исә ип белән гәп кора:

— Беркөн шулай көтү алдыннан гына Низамилар күпереннән чыгып киләм. Кәефем яхшы, йомшак кына җил исә. Бөтен әйләнә-тирәгә май үләне, кычыткан исе таралган. Үпкәнә бәреп керә инде, минсиңайтим. Күпердән чыгып киләм. И ул аста бакалар кычкыра, ул, минсиңайтим, вак балык үрли, и ул, минсиңайтим, тал песиендә кортлар гөжли. Әле кояш — көтү әллә нәстәсенә иртәрәк кайта. Шулай хозурланып күпердән атлап чыгып киләм. Бер вакыт, ярабби, тез астына китереп тондырдылар. Жиде аршынлы бүрәнә белән китереп төрттеләрмени. Алты-жиде адым алга сөрлегеп барып төштем: күтәрелеп карасам, теге, нәсел тәкәсе «меринос» икән. Танавын җыерып, күзләрен тондырып, ямьсезләнеп тора, чуртумайтери. Ике көн буе ылыс суында, кычыткан төнәтмәсендә утырдым мунча яктырып...

Арада әле генә солдаттан кайткан күрше егете Гарифулла да утыра иде. Ул сорый куйды:

— Алайса, быел сабантуй көрәшен башлаган инде син, Гатият абзый,— дип көлде.

Гатият абзый рәнҗеп аңа таба борылды һәм калын саргылт мыекларын сыпырып куйды.

— Авызыңны бик җырма, күрше. Әл-ле мин... Әл-ле мин...

— Нәрсә, әллә бил алышабызмы?

Гатият абзыйның күзләре очкынланып китте. Истәлекләргә бирелде.

— Һи-и, егетләр. Уральскида вакытта Кари Габдулласы (Габдулла Кариевны ул шулай дип кенә искә ала иде) белән көрәшә идек без. Тукай Габдулласы елмаеп карап торыр иде. Ул — ябык, җыйнак. Теге — таза, миңа торырлык (Гатият абзыйның бу сөйләгәннәре «Казан утлары»нда һәм Г. Кариев турындагы истәлекләр китабында басылып чыкты.— Автор.).

Истәлекләр таза яшь солдат Гарифулланың яшел чирәмлектә нык кына бил алышып Гатият абзыйны тәгәрәтеп салуы белән тәмамланды.

Гатият абзый торды, эшләпәсен каккалап киде, чалбар-күлмәкләрен рәтләде һәм сагышлы елмаеп авыр сулады:

— Булмый икән инде, энекәш,— диде. Бу минутта ул кызганыч иде. Бераз хәл алгач тагын истәлекләргә бирелде.

— Хәзер ашавым кысылды, әпитит начар,— диде.— Ашау хуты иркен булгандамы? Һи-и... Кари Габдулласы белән бервакыт Казанда хәрчәүнеккә кердек. Китертте бу кыздырган ике үрдәк. «Аша, туган,—ди,— сезнең солдат халкына бу сирәк эләгәдер». Вәт ашау, вәт яшьлек. Кари Габдулласы бик задур егет, ә минем солдаттан кайтыш, Казанда, Болак буенда очраштык. Ашасаң — ашыйсың, ашамасаң — авызыңа җыгып сала. Һи-и... Ул вакыттагы куәт булса иде.

Гатият абзый шул елны эшләпә астыннан гына Сабантуй көрәшен карап торган, уртага кереп элеккеге гадәт буенча кысылып-катышып йөрмәгән. Ә июнь ахырында урынга егылган. Авырып ятканда күрше кызы кереп, аңа «Казан утлары»нда басылган мәкаләне укыган. Гатият абзый шунда бик борчылган.

— Һәй алла,— дип урыныннан торып утырган ул.— Аның китапта чыгасын белсәм, мин моны гына сөйлидериеммени? Әле бит безнең Тукай Габдулласы белән... Әле бит безнең Камил мәхдүм белән... Ә Мортаза бай өендә! Әле теге казаклар безне куып тараткан көнне... Тукайга камчы чүт кенә эләкмәде, һәй алла...

Мин аның белән яңадан күрешергә барганда Гатият абзыйның ак кәфенгә төрелгән озын, искиткеч сузынкы гәүдәсе янына утырып картлар тәһлил[1] әйтәләр иде. Мин килеп кергәч, аптырап калдылар. Янәсе, укыган кеше — моны ошатырмы, юкмы. Картлар янына барып утырдым. Тынычландылар, Гатият абзыйның гәүдәсе өстендә тәһлил әйтүнең кирәге юк иде, Тукайга тужурка теккән, гомере буе кеше матурлаган, авыр сугыш елларында берөзлексез кибән салган, эскерт өйгән кешедә нинди гөнаһ булсын ди?

Гатият абзыйны, сугышта ятып калган өч малае белән күрешергә дип, әнә шулай «чистартып» җир куйнына салдылар.

Җир шары шулай тагын бер юньле кешене үзенә алды.

## Берәү улдан, берәү кыздан

Авылда акушерлык хезмәтен башкаручы ике әби бар иде: Газзәти һәм Гайшәтти. Алар дөньяга бик күп юньле бәндәләр тудырып, авылларда медпунктлар ачылгач, дөньядан китеп бардылар. Үзләре аякка бастырган кешеләр өчен, җир өсте бераз бушасын дигәндәй, тын гына, шыпырт кына китеп бардылар.

Газзәти — минем әби. Кендек әбисе. Мин аңа үз гомеремдә бер бүләк тә бирә алмадым. Әгәр хәзер ул исән булса, авылга кайткан саен аңа күчтәнәч, кием-салымнан бүләк алып кайтыр идем. Әмма ул минем зур үскәнне көтеп тора алмады.

...Камыт аяклары белән авыш-тәвеш килеп урамнан бер юантык карчык барса — ул Газзәти. Ул һәркем белән исәнләшә, һәр бала янында туктый. Инде урамда мине очратса, башымнан бисмилла әйтеп сыпыра да елап җибәрә:

— Тәүфыйклы булып үс, балам, анаң сине бик авырлык белән тапты,— дип яшь коя.

Гомумән, үз гомерендә мин Газзәтинең еламаган чагын күрмәдем.

---

[1] Мәет янына кара-каршы утырып, йөз тапкыр «ля илаһә иллә аллаһы» дип әйтү белән аның бу дөньядагы гөнаһлары кими дип ышану.

Мине очраткан саен ул күз яше койды. Үзе таптырган балаларны аның ярату рәвеше шул булган икән. Башка малайлар белән сөйләшеп аңлашкач ачыкланды: һәрберсен — үзе таптырган баланы — очраткач башыннан сыйпый да елап җибәрә икән:

— Тәүфыйклы булып үс, балам, анаң сине бик авырлык белән тапты,— ди икән.

Әни янына килгәндә дә алар шулай бала тәүфыйгы турында сөйләшәләр иде. Бер хикәят тә истә калган. Имеш, бер егет карт авыру әнисен арка кочтырып өч мең чакрым ераклыктагы изге суга алып барып кайткан. Кайткач бер акыл иясеннән сораган:

— Мин, дигән, әниемне савыктыру өчен өч мең чакрым ераклыкка аны арка кочтырып алып барып кайттым. Анам алдында минем бурычым үтәлдеме инде?

— Һи-и-и,— дигән акыл иясе.— Бу — беләсеңме нәрсә? Бу хезмәтең синең анаңның бер минутлык тулгагына да тормый.

Адәм баласы дөньяга әнә шулай авырлык белән килә икән. Газзәтинең «Анаң сине бик авырлык белән тапты» дигән сүзе миңа карата аеруча туры килә иде. Әнинең тулгагы нәкъ бер тәүлек дәвам иткән. Хәле бик авырлангач, Газзәти әтигә әйткән:

— Бар,— дигән,— духтырга ат җибәр, аллага тапшырдык, хәле шәптән түгел, үзең янында утыр,— дигән.

Ун чакрымдагы Чүриле марҗасын алырга төнлә ат җибәргәннәр. Буранда, ниһаять, безнең авылның уты күренгән. Безнең өйнең тәрәзәләре бик зур, әти ике якка да гөлт итеп унлы, егермеле лампалар кабызып куйган, доктор көтәләр икән.

Доктор килгәч, Газзәти әти бүлмәсенә чыгып, елый-елый дога укып утырган.

— Анаң бер тәүлек җәфаланды сине таба алмыйча, зинһар анаңа игелекле бул!— Газзәти гомер буе миңа шуны теләде. Әнигә күпмедер игелек күрсәттем, әмма дөньядагы иң якын кешеләремнән булган Газзәтигә дә, Чүриле акушеркасына да, дөньяга килүемне утлар яндырып көткән әтигә дә файда күрсәтә алмадым, рәхмәт әйтә алмадым. Бу дөньяда минем, шулай итеп, үзем белгән өч бурычым калды...

Гайшәтти. Анысы — дөньяда бер генә. Дөньяда икенче андый карчык була алмый. Ни өчен? Беренчедән, Гайшәтти гомере буе үзе дөньяга китергән балаларның хәлен белеп йөрде. Аның ниндидер графигы бар иде, ахрысы. Икенчедән, дөньяда Гайшәтти кебек ике бүрек киеп йөргән бүтән карчыкның булуы мөмкин түгел. Мин, тамакларын урам җиленнән, ишек, тәрәзә җиленнән саклап төренеп йөргән атказанган, халык артистларын күргәнем бар. Син авызыңны күтәреп клуб ишеге янында тәмәке тартып торганда, бугазын әллә ниткән шарфлар белән урап (май ае!), сәхнәгә таба җырчы кереп китә. Вәли карт үзенең чалгысын ничеп карап тотса, Гатият абзый үзенең «Зингер» машинасын ничек кадерләсә, теге җырчы үзенең бугазын шулай кадерли. Иң кыйммәтле урын! Иң кыйммәтле хезмәт коралы!

Гайшәтти исә башын саклый иде. Күз алдына китерегез: кыш көне өегезгә әкрен генә бер чүмәлчек килеп керә. Бөтен йорт аякка баса, дučат килә:

— Әби килгән! Гайшә әби килгән!

— Үземнең әби килгән! Кендек әбием килгән!

Ләкин «әби» үзе юк әле: әлегә чүмәлчек кенә бар.

Һәм бала-чага теге чүмәлчекне сүтәргә керешә. Чүмәлчек эчендә Гайшәтти барын бөтен кеше белә. Әмма, сүтәргә, шуны табарга кирәк.

Гайшәттине тапканчы, әлбәттә, байтак эш бар әле. Башта яшел шакмаклы, юрган хәтле зур шәлне чүмәлчек өстеннән аласы. Әлеге шәл астында колакчынлы бүрек. Бүрекне аласы. Шуннан аста кәҗә мамыгын-

нан бик яхшы шәл. Нафталин исе килеп тора. Аны да алгач, бәрән тиресеннән тегелгән бер түгәрәк бүрек чыга. Гайшәттигә хәтле әле ерак! Бәрән бүректән соң зур алсу чәчәкле шәльяулык. Аны сүтеп аласың. Зур чәчәкле шәльяулыктан соң гына гадәти баш яулыгы күренә һәм җыерчыклы мөлаем йөз хәрәкәткә килә:

— Хәерле бәрәкәт бирсен йортка, исән-сау торамсыз?— дип Гайшәтти елмая. Андый елмаю! Андый самимилек! Андый якынлык!

Аннан Гайшәтти балаларны сөя.

— Син ни атлы әле? (Безнең авылда карт-карчык беркайчан да «ни исемле» дип сорамады). Ә-ә, шулай шул, мин әле онытканыем. Сиңа, бәбекәем, арыш урагы җитсә ун тула инде... Ә менә монысының исемен беләм. Зәйнагытдин. Сөннәткә утырттыгызмы әле? Бик яхшы, бик яхшы, улым. Каз суйганда сиңа да җиде тула бит инде.

Гайшәтти безнең гаиләдә дә кадерле әби.

Әни сөйли иде: имеш, берәү ерак юлга чыкканда йөкле хатыны янында Гайшәттине калдырган.

— Гайшәтти, ишетсен колагың, мин кайтканда өйдә малай булсын,— дигән.— Шаярып болай дигән:

— Малай булмаса, күземә дә күренәсе булма...

Беркатлы, саф күңелле Гайшәтти, бичара, моны чын йөрәктән кабул иткән. Бичараның бәхетсезлегенә каршы, теге хатын кыз бала тапкан. Ул арада, төш авышканда, Теләче базарыннан ире дә кайтып төшкән. Олы урыс капканы дөбердәтеп ачып ат белән ишегалдына килеп кергән, лапас астында толыплар кагып, ат туарып матавыкланганда җылы, парлы өйдән башына бер генә кат шәл бөркәнеп, бер генә бүрек кигән Гайшәтти килеп чыккан. Ул гаепле кеше сыман башын түбән игән дә, әти кешегә карамыйча гына:

— Анысы инде ходай эше... Әһ-һемм... Ие, анысы ходай эше. Берәү улдан, берәү кыздан. Ие. Берәү улдан, ие, берәү кыздан. Ие. Ходай эше ул...

Әти кеше шул вакытта Гайшәттине мәңгегә онытмаслык итеп шатландырган.

— Гайшәтти! Бала сәламәт тудымы? Әнисе сәламәтме? Әйдә, өйгә керик, сөенеч бүләге бирәм!— дип, сабыйларча шатланган карчыкны өйгә алып кереп киткән.

«Берәү улдан, берәү кыздан» дигәненең мәгънәсе болай икән: бер төрле ата-ана улдан игелек күрә, икенче бер төрлесе — кыздан. Тормыш моны раслады: Гайшәтти дөньяга китергән улларның бик күбесе илгә игелек күрсәтеп сугыш кырларында ятып калдылар. Гайшәтти дөньяга китергән бик күп кызлар, егетләре сугышта яшьли шәһит китү аркасында, карт кызлар булып, туган нигезләрендә утырып калдылар һәм ата-анага игелек күрсәтеп картайдылар.

Ил — уллардан, ата-ана — кызлардан игелек күрде. Хәер, моны аерып билгеләве кыен. Тик бер нәрсә генә бәхәссез: безнең авылда Гайшәтти белән Газзәтти якты дөньяга чыгарышкан малайлар да, кызлар да илгә, йортка, ата-анага игелекле булдылар.

## Председатель Хайф

Хәлил абзый революциягә кадәр Казанда Суворовское подворье янында (хәзер Яңа театр салынып яткан урын) Иске Масрадан күчеп килгән Әсәт байда тегүче булып эшләгән. Юл аркылы гына — Болгар номерлары. Анда Тукай яши. Тукай ара-тирә Суворовское подворьега пилмән ашарга керә. Тегүче Хәлил дә шунда. Тукай берничә мәртәбә

аннан үзенә чалбар, күлмәк тектерә. Карт кеше боларны оештырып сөйләмиме дияр идең, Хәлил абзый бик зур төгәллек белән Тукайның бүлмә номерын, аның янына килеп йөргән кешеләрне атый. Гайнан ишан мөритләренең кием формасын, Мөхәммәтҗан Хафизның кәфер почмагындагы шкафын — барысын да төп-төгәл сөйли. Хәлил абзый солдат буларак беренче бөтендөнья сугышында катнашкан. Сугыштан өенә кайтып барганда Казандагы дуслары янына керсә — Казанда кыямәт — урам сугышлары икән, хәрби киемле Хәлил солдатны аклар үз сафларына бастырып кулына корал бирәләр. Әле ярасы төзәлеп тә бетмәгән Хәлил солдат кемнәр өчен, нәрсә өчен сугышасын белмичә йөргәндә, кемнәрдер болар отрядын чорнап та ала, коралсызландырып тезеп тә куя. Тегеләрнең командиры әйтә:

— Сез,— ди,— үз халкыгызга каршы корал күтәрдегез, сезгә трибунал үлем җәзасы бирде,— дип кәгазь укый да, ул арада строй кырында беренче булып басып торганны шартлатып атып та ега.

— Дер-дер киләм,— дип искә ала Хәлил агай, нәрсә әйтергә белмим, бер тиешлек гаебем юк бит. Революция булган икән, э мин белмим. Шунда карыйм — командир янында берәү тора — таныш. Иванов фамилияле рус солдаты. Резервта бергә торган идек. Көчкә хәл алып:

— Товарищ Иванов!— дип кычкырдым.

Иванов та мине танып алды да, командирына әйтте:

— Бу, — диде, — әйбәт солдат, татар. Ул, — диде, — начар юлга басмас, үзенең неграмотный булуы аркасында гына болар арасына эләккән.

Стройдан чыгардылар. Иванов кул бирде.

— Син нәрсә, Хәйбин,— ди,— башыңа ат типтеме әллә? Халык дошманнары белән бер рәттә торасың? Революция булды, революция!— дип минем аркадан какты. Шулай исән калдым.

Хәлил абзый шуннан соң гомер буе авылда кием текте. Әмма заказны ул читтән ала иде. Чөнки Хәлил абзый — «ак тегүче». Ул елларда авылда әле костюм киюче юк, халык күбрәк «кара» тегүчеләр белән эш итә. Гомер буе Хәлил абзыйның капка төбендә тарантаслы ат торды. Аның клиентлары, гадәттә, Арчадан, зур начальниклар арасыннан була иде. Хәтта военкомга да мундир, галифе кебек әйберләрне ул тегә иде.

· Хәлил абзый үзе бик культуралы киенә, борын астында нәкъ рафинад шикәр шакмагы зурлыгында мыек йөртә, башында һәрвакыт кызыл плюш өсле тупый бүрек, чалбары үтүкләнгән була, кыска пальтосының кыек кесәләренә кулларын тыгып кызу-кызу узып китә иде. Сөйләшкәндә дә, эшләгәндә дә темпны ярата иде. Аның турында халык болай сөйли иде: имеш, гомере буе, кысыр аш ашаганы юк, көн саен итле аш! Булса булыр, аларның өй алдында һәрвакыт тәмле ис борынга бәрелә иде. Тагын сөйлиләр иде: хатын-кыз, бала-чагага бик коры икән дип. Хатыны — сүзне озын итеп сөйли торган Бибинисаның исемен тутырып әйтеп торырга аның вакыты булмый һәм ул аңа гомер буе «Биса» дип кенә дәште.

— Быелгы бәрәнге өястына сыймас, базга салыйк,— ди икән Бибиниса түти.

— Шту син, шту син,— ди икән Хәлил абзый,— базның стеналары начар, өшеп бетәр ул.

— Юк,— ди Бибиниса түти,— әнә узган ел Һәдиятуллалар салды бит, безнеке төсле базлары, аларныкы өшемәде.

— Шту син, шту син,— дип каршы тора Хәлил абзый, үзе кызу-кызу зәңгәр габардин галифе үтүкли. Район милиция начальнигы бүген килеп алырга тиеш.— Шту син,— ди-ди Хәлил абзый җиңелә.— Ну, кара аны, өшсә —башың сары май,— дип хатынын кисәтеп тә куя.

Март уртасында базны ачалар. Хәлил абзый йөгерә-йөгерә сәнәк

белән салам ташый, бәрәңгенең өстен чситарта. Әлегә Бибиниса түти өйдә. Чистартып бетерсәләр, күрәләр, йөз чиләк бәрәңге өшегән. Рәвеше, кыяфәте беткән. Хәлил абзый сәнәкне карга кадый да, уч төбен төкрекләп өйгә торып йөгерә.

— Ну бирәм, ну бирәм, ну бирәм,— ди-ди йөгерә. Әмма нәкъ шул вакыт капкага кошевкалы ат килеп туктый һәм парлы кунак ишегалдына килеп тә керә. Карасалар — күрше авылдан бажай белән балдыз икән. Хәлил абзыйның ачу урталай өзелеп кала. Кунакларны өйгә кертеп чишендерәләр, Бибиниса апа аш салып җибәрә, ыгы-зыгы. Әмма шул көнне Хәлил абзый кунаклар янында артын төртеп өч минут та утыра алмый. Сөйләүләренә караганда, ул көне буе баз белән өй арасында йөгереп, бөтерелеп йөргән:

— Ну, көне туры килмәде, көне туры килмәде...

Көне буе ул башка бер сүз дә әйтмәгән.

Сугыш башланган атнада ук аны колхозның председателе итеп куйдылар. Менә шунда йөгереп тә күрсәтте инде Хәлил абзый. Урамнан тупый бүрекле кыска пальто йәлт кенә узып китсә — аның эчендә, һичшиксез. Хәлил абзый. Ни арада узадыр, әле амбарда, әле сушилкада, әле идарәдә — Хәлил абзый берьюлы бөтен җирдә була иде. Ләкин, грамотасы бик түбән булганлыктан, кәгазь, печать белән эш итү аңа бик авыр иде. Кырык беренче елның көзендә кинәт кенә кар явып, бөтен чүмәләләр, кибәннәр, бәрәңге күчләре кар астында калды. Бераздан җебетте. Кыш буе ындыр сугылды, икмәкнең иге-чиге булмады. Халык председательдән гел аванс сорап торды. Хәлил абзый исә эшләгән кешедән берни дә кызганмады. Аны урамнан йөгереп узганда гына тотып туктаталар да, аванс сорыйлар иде. Хәлил абзый исә хут белән барганда туктатуларына бераз рәнҗүле чырай чыгара да, кесәсеннән гәзит кәгазе алып, капка баганасына куеп карандаш белән яза иде. Бу инде амбарга алып бару өчен бер документ була, кладовщик ул язуны очлы тимер чыбыкка кадап җыеп бара. Гәзит кәгазе нәкъ хәзерге трамвай талоны зурлыгында була. Анда исә капка баганасының сырлары беленеп торган карандаш эзе. Нибары өч сүз: «12 кг Хайф». Ул инде, бәлки, «ф» хәрефе үк булмагандыр, аның инде Хәйбин дип язасы килгәндер, ләкин грамота аз булганлыктан шулай килеп чыга иде. Колхозчылар аны инде «Хайф» дип кенә йөртә башладылар. Явызрак яшьүсмерләр гәзит кәгазеннән үзләре дә байтак «Хайф» ясаганнар. Тик берсе, арттырып җибәреп, «32 кг Хайф» дип язылган кәгазь белән килеп тотылгач кына бу системаны туктаттылар.

Фронтовик бер егет яраланып кайтканчы, Хәлил абзый колхоз белән җитәкчелек итте. Үз эшен яратып, янып-көеп эшләде, кешеләрне рәнҗетмәде.

Сугыштан соңгы елларда Хәлил абзый кибеттә эшләп алды. Анда да шулай җиңел сөякле булды. Кибеткә чәй-шикәр, кием-салымның яңа гына кайта башлаган вакыты. Прилавка артында Хәлил абзый берөзлексез йөгеренә-кабалана.

— Теге чалбар олыларга ярыймы ул?— дип әдәп белән бер хатын эндәшә.

Хәлил абзый чалбарны прилавкага китереп тә сала, ни арада кабып өлгергәндер, авызыннан су бөркеп җибәрә дә, әллә каян гына кайнар үтүк тартып чыгарып, чыжылдатып үтүкли дә башлый. Әлбәттә, чалбар алына.

— Хәлил абый, теге пычак ничә тиен тора?

Ялт! Хәлил абзыеңның кулында инде кайрак, пычак Гали пәкесенә әверелә (безнең авылда үткен пычакны — Гали пәкесе дип йөртәләр, ихтимал, дини мифологиядәндер).

Кыскасы, Хәлил абзый эшләгәндә халык кирәккә дә, кирәкмәскә дә

гел кибеткә йөри торган булды. Чөнки Хәлил абзый кибеткә кеше килеп керүгә хәрәкәткә килә, кыбырсып йөгеренә башлый иде.

— Иптәш! Иптәш! Менә бу чалгы бераү генә. Менә кара, менә кара! Тавышы нинди! Бераү генә бу, бераү генә...

— Иптәш! Иптәш! Менә җәяле пычкы полотносы кайтты. Нибары икәү. Әйдәле, әйдәле.

Ул полотноны тотып йөгереп урамга чыга. Полотноны бөгеп түгәрәк ясый да, кисәк ычкындыра. Кинәт турайган пычкы чыжылдап өскә кибет биеклеге күтәрелә һәм тураеп, чыжылдап аяк астына килеп төшә. Хәлил абзыйның күзләре яна, шатлана:

— Күрдеңме, иптәш? Ишеттеңме? Әллә икесен дә үземә алыргамы икән, иптәш? Корыч бит, чын корыч, иптәш!

Хәлил абзый минем әтине бик яратып искә ала иде һәм мин, атасыз үскән малай, иртәгә армиягә китәсе көнне аның янына кибеткә саубуллашырга дип кердем.

— Иртәгә китәм, исәнлектә күрешик, Хәлил абзый,— дидем.

Ул гадәтенчә йөгеренде, кибетнең эчен тутырып бөтерелде, стенадагы сәгатькә күз ташлады да:

— Һи-и, иптәш! Эш сәгате чыккан бит!— дип, кибетнең тәрәзә капкачларын япты, ишекне эчтән бикләде дә, керосин лампасын кабызды.

— Илле генә грамм, илле генә грамм,— дип ду-чат килде, һәм башта илле грамм портвейнны үзе авыз итте. Аны үз гомерендә шуннан да ары эчми дип әйтәләр иде. Аннан хәерле юл теләп миңа сузды.

— Илле генә грамм, илле генә грамм,— дип ашыктырды.— Юл аягы, исән-сау кайт, иптәш, исән-сау кайт...

Кибеттән чыгар алдыннан күңеле нечкәрепме, тавышын тыеп кына бер җыр җырлады.

Әйдә, дуслар, җыелышып
Чыгыйк әле сәйранга.
Аш-шыйк, эч-чик, уйныйк, көлик,
Калсын дошман хәйранга...

## Зөлфия

Безнең авыл ата-аналарының традицион бер-ике гадәте бар. Бала яхшы укыса — ата-ана үзенең эш нәтиҗәсе дип билгели. Начар укыса — укытучыдан. Тагын: бала начар укыса, ата-аналар җыелышына әни кеше йөри. Яхшы укыса — бары тик әти генә.

Безнең күрше Зөлфиягә дүрт класстан ары укырга туры килмәде. Менә ул укып күрсәткән булыр иде! Бу кызда, белмим, нинди генә талантлар ачыла алмыйча сүнеп, күмелеп калды икән?

Әгәр безнең авылда безнең буын балалары әдәбиятны, фольклорны яратып үскәннәр икән — моның белән без беренче чиратта Зөлфиягә бурычлы. Һәр кичне (ул бигрәк тә көзге яктагы караңгы кичләрне ярата иде) Зөлфияләр капка төбенә җыелабыз. Шунда, караңгыда, безнең өчен дөньяның иң серле, иң куркыныч, иң кызыксындыргыч капкалары ачыла. Зөлфия авылның әллә кай якларын белә. Удмуртлардан килгән борынгы традицияләр авылда әле дә яши иде, күп семьяның үзенә генә хас берәр хикмәтле әйберсе, тылсымлы көче бар иде. Зөлфия боларның барысын да белә.

Ул елларда безнең өчен ашаудан кала иң кадерле нәрсә дәфтәр белән китап иде. Китап дигәннән, Зөлфия каян тапкандыр, шул елларда ук ул (38 еллар тирәсе) «Совет әдәбияты» журналын укып барган икән. Без исә дөньяда андый журналның барын ишеткәнебез дә юк, бөтен укыганыбыз «Яшь ленинчы» да басылган «Гали баба һәм кырык карак» һәм «Пионер каләме»ндә басылган бер-ике поэма иде.

Яфракларын селки-селки,
Шаулый кара урман.
Бер кечкенә малай бара
Урман юлыннан,

— дип башланып киткән бер поэмада Алик исемле малай ике-өч аңгыра япон разведчикларын тотып (бер коралсыз!), безнең заставага китереп тапшыра. Икенче бер поэмада кечкенә генә малай урмандагы бөтен бер банданы тоттыра. Зөлфия исә беркөнне безгә караңгы кичтә «Гашыйк гариб» дигән әкият сөйләде. Безнең йөрәкләр дөп-дөп типте. Хикмәтле Гашыйк гариб, Маһел-миһри, Хөршидбәк дигән кеше исемнәрен, Эрзерум, Карс кебек шәһәр исемнәрен беренче тапкыр без шунда ишеттек. Ул әкияттән Зөлфиянең бер җөмләсе (безнеңчә әйтелмәгән бер фигыль) истә калган:

— Нишләмәк кирәк, — диде Хөршидбәк...

Шул сихри бер кичтә мин дөньяда Кавказ дигән серле бер ил барын, ул якларда исемнәре безгә охшаш халыклар барын белдем һәм Эрзерум, Карс исемнәренә мәңге гашыйк булдым. Шул кичтән соң утыз биш еллар узгач, китапханәдә «Совет әдәбияты» журналы санналарын актарып утырганда, мин бервакыт сискәнеп киттем, анда М. Ю. Лермонтовның бу әкиятен татарчага тәрҗемә итеп бастырганнар икән. Һәм мин ашыга-ашыга теге җөмләне эзләдем. Бар! Нәкъ шулай!

— Нишләмәк кирәк,— диде Хөршидбәк...

Актара торгач ачыкланды: Зөлфия караңгы кичләрдә безгә сөйләгән «Кара ясаучы малай» (Шолом Алейхем), «Яктыга таба» (Иван Франко) һәм башка хикәяләр шул елларда «Совет әдәбияты» журналында басылганнар икән. Мондый реалистик әдәбият дәресләре көзге караңгы кичләрдә еш кына коточкыч фольклор әсәрләре белән чиратлаштырылып алып барыла иде. Зөлфия сөйләгән әкиятләрдә әллә ниткән куркыныч урыннар була иде һәм һәр кичне берничә бала шул куркынычны сөйләгәндә дерелдәп урыныннан сикереп тора да, йомылып өенә йөгерә иде. Әмма шул ук бала икенче кичне тагын Зөлфияләр капка төбендәге эскәмиягә килеп утыра һәм әкият көтә иде. Ә Зөлфиянең куркыныч җөмләләре менә мондыйрак була иде:

— Шуннан соң... Иртә белән, яктыргач чыгып карасалар... Теге егетне, бичара, үтереп, мәчет манарасына алып менеп, эчәгеләрен буйбуй элеп куйганнар, ди...

Яки:

— Шуннан соң... Бу карчык нишләп бик озак торды икән дип, күпер астына төшеп карасалар, теге шатыр-шотыр нәрсәдер ашап утыра, ди. Карасалар — шунда яткан бер мәетнең колагын кимерә икән...

Бу җөмләләр, әлбәттә, бик күп баланы «өенә йөгертә» торган җөмләләр иде.

Инде дәфтәргә килсәк... Без беренчедә, Зөлфия исә үз гомерендә алачак белеменең соңгы классында — дүртенчедә иде. Дәфтәр юк, дәфтәр җитми. Ул еллардагы матур тышлы дәфтәрләр... Хәзер дә шулай матурмы икән ул? Ал тышлы, ап-ак юка кәгазьгә сыек зәңгәр сызыклар уздырылган юллы дәфтәрләр. Ал тышлысы язу, матур язу өчен, зәңгәр тышлысы арифметика өчен әйбәт була. Яңа дәфтәрнең исе! Баш әйләнә, күзгә яшь килә. Дәфтәр тышындагы хикмәтле рәсемнәр! Әнә Пушкин — аның үлеменә 100 елны билгеләгән чакта без беренчедә идек. Дәфтәр тышында көдрә Пушкин — ни гаҗәп!— бармагында йөзек! Ирләр йөзек киямени? Ирләр чәчен кырдырып алдырырга тиеш, ә бу? Дәфтәр тышында аның шигыре:

Я памятник себе воздвиг...

Икенче бер дәфтәр тышында рәсем: князь Олег хазарларга поход чыгарга әзерләнә. Аста шигырь.

Ал тышлы дәфтәрнең бер ягында күзен кысып, бераз хәйләкәррәк елмайган кадерле Ленин рәсеме. Нихәл, агайне, укырга-язарга өйрәнәсеңме?— дип якын итеп сорый сыман. Шунда ук аның сүзләре: «Если я знаю то, что знаю мало, то добьюсь того, чтобы знать больше». 1960 елның көзендә мин аспирантурага кердем. Шуңа әзерләнгәндә миңа бу җөмлә очрагач, шатланулар! Балачак, Ленинга карап, шул сүзләрне ятлаган кадерле балачак!

Безнең өебез урамнан эчкәрәк кереп салынган һәм кышларын без мәһабәт кар дәрьясы эчендә ялгыз утырып калабыз. Март ае җитсә бөтен кояш безнеке. Тәрәзә белән тигезләп салынган кар дәрьясы Масра юлына ук җәелеп тоташкан, ул җем-җем итә; өйдә әллә бүрәнәләрдән, әллә тәрәзә пәрдәләреннән алсу нур тулган, әни мич томалап йөри, ә өстәлдә алсу тышлы дәфтәр. Мин аңа язып утырам:

> Һич сине куркытмасыннар
> Шүрәле, җен һәм убыр...

Алсу тышлы дәфтәр миңа әле дә март аеның кояшта җемелдәгән кар диңгезен, мич алдында ризык әзерләп йөргән әниенең нурлы йөзен, безгә мәңгелек идеал булган бөек Ленинның акыллы сүзләрен, киң маңгаен хәтерләтә. Тагын март аеның кичләре. Тулы айлы көмеш кичләр. Ул кичне җир өстенә чыккан бөтен ай нуры безнең өйдә, өй түрендәге кар дәрьясында. «Энә табарлык якты» — ай яктысына безнең авылда чагыштыру бер генә. Ай нуры өйгә тулгач, мин яткан җирдән шыпырт кына торып утырам һәм өстәлдәге дәфтәрне алам. Яшькелт тышлысын. Миңа, нигәдер, шул яшькелт тышлы дәфтәр белән дөньядагы ай нуры икесе бер булып тоела. Мин шул дәфтәремне күкрәгемә кысам да, хыялым белән ай нурында, еракта очам, еракта-еракта калын тун кигән Папанинны, хикмәтле шлем кигән Чкаловны, бозау тикле эт җитәкләгән, хәрби фуражкалы Карацюпаны күрәм. Шулай озак-озак хыялланам. Ә ай үзенең яшькелт нурларын безнең кар диңгезендә ялгыз утырган өебезнең зур тәрәзәләреннән көчләп тутыра сыман.

Җиләк җыю буенча балалар арасында Мәрфуга карчыктан кала иң зур абруй Зөлфиядә иде. Кичтән, җиләк вакытында Зөлфияләр капка төбендә «оперативка» була.

— Иртәгә нишлибез? Барабызмы?

Зөлфиянең бу вакытта телеграф стилендә кыска җөмләләре була.

— Биргән булса.

— Кая?

— Кимпласага.

— Ничәдә?

— Көтү куганда.

— Савытны — ниндине?

— Пласкатң житеп торыр. Артса — күлмәк итәгенә.

— Кемнәр, кемнәр?

— Шәйхулланы ияртмибез. Зөләйха белән Рәшидә дә калып торыр. Гел ашыйлар, җыю турында уйламыйлар да.

Зыңгырт! — Тимер келәле авыр капка ябылды, Зөлфия юк булды.

...Зыңгырт!— тимер келәле авыр капка ачылды, Зөлфияне ай күрде, кояш алды, көтү куалар икән. Артыннан торып йөгерәсең, авылны чыкканчы Зөлфия берәүгә дә бер сүз дәшми, урман юлына чыккач, туктап, барлау үткәрә. Әлбәттә, кичен исемлектән сызылган берәр бала булмый калмый. Зөлфия аңа авыр караш ташлый, теге бичара башын иеп басып тора. Әмма, Зөлфия бик гуманлы, яхшы холыклы кеше иде.

Урман буена килеп җиткәч, Зөлфия мендәр тышы кадәр зурлыкта-

гы эрекмәннәрне зелпе, куак төпләреннән чаж-чож китереп умырып ала. Урман буенда ташланган иске чабата булмый калмый. Зөлфия эрекмән белән аягын урый да, кешедән калган иске чабатаны киеп чажолдатып куак арасына кереп китә. Кура җиләге җыйганда чиләге тулмыйча кешегә эндәшми. Ә чиләк тиз тула! Аннан ул иптәшләренә җыеша. Безнең авыл балаларының бик матур бер гадәте бар иде, савыт тулгач, өстенә сабагы-тәлгәше белән өзеп сабаклы җиләк утырта идек. Анысы кайтып кергәч тә әнигә. Әни җиләге. Бу — изге. Бу — һәр балада бар. Моны Зөлфия бик каты күзәтә иде.

— Әйдәгез, әниләргә берәр сабак кадыйк та, кузгалыйк...

Безнең арада әниләре үлгән Тайфә, Мансур, Мәгъсүм исемле өч бала бар иде. Алар нишләде икән шул чакта? Алар хәзер өчесе дә бик абруйлы кешеләр, очрашкач шуны сорарга кирәк әле.

Без бәләкәй чакларда җиләккә бик күп йөрдек. Урман буена чыгабыз. Зөлфия эрекмәнле чабатасын салып ташлый. Чабатаны ташлау — аны питомник киртәсенә элеп кую дигән сүз. Димәк, кирәк кеше файдалансын. Аннан питомник киртәсенең юан баганасы башына бер-ике җиләк куясың. Монысы — урман иясенә. Шулай итсәң, ул иртәгә дә җиләкне күп таптыра. Шатланышып кайтып китәбез.

Сугыш вакытында Зөлфия ундүрт, унбиш, уналты яшьләрне кичерде. Кырык беренче — кырык икенче елның рәхимсез кышында салкыннар 40 белән 48 градус тирәсендә уйнады. Колхозның икмәген кырдан ташырга, әвеслектә сугарга, амбарга, сушилкага ташырга, заготзерногә илтергә кирәк иде. Боларның барысы да Зөлфиягә эләкте. Колхоз эшенең иң авыр урынында әрсез Зөлфия була иде. Шомырт кара чәчләрен яулык астыннан чыгарып, телән тешләп бер эшкә тотынса—аңа эш чыдамады. Төнге смена гел Зөлфиянеке булды. Очар кошлар егылып төшәрлек салкында көлтә керткән, капчык күтәргән Зөлфиянең кызарган ялангач тез башы, алсу үкчәсе күренеп йөрү берәүне дә гаҗәпләндерми иде. Ул үзе һәрвакыт оптимист булды.

Ара-тирә Зөлфия яшүсмерләрнең аулак өен оештыручы, шунда иптәш кызларыннан берәр уч он, унар бәрәңге җыеп аулак аш пешерүче, аулак өйдә уеннар оештыручы, Мөхәммәтша карт булып чабата көен уйнап күрсәтүче, чуар Нигаҗ булып чабата көенә биюче, әтисе булып җырлаучы һ. б. бик күп рольләрдә чыгыш ясаучы була иде. Шул ук вакытта «мирдән җыелып» пешерелгән аулак өй боткасының бер өлешен алып, аулак өйгә керергә хокукы булмаган, яше житмәгән әллә кемнәргә ашата, ботканың кимүенә тавыш чыгарган иптәш кызларын адаштырып, ыгыштырып та ала иде. Үз йортларында да ул шулайрак булды. Йортта булган малны, байлыкны Зөлфия мохтаҗларга, ятимнәргә өләшергә бик ярата иде.

Беренче кызыбыз тугач, мин аңа Зөлфия дип исем кушмакчы булган идем. Уйлана торгач, бу фикеремнән кире кайттым: әгәр минем кызым Зөлфия кебек гуманлы, аның кебек елдам, өлгер, кешеләргә ярдәмчел булмаса? Ул бит таш калада, асфальт-бетонда үсәчәк? Каты авырып дөньядан вакытсыз киткән бичара Зөлфиянең рухын кимсетмимме, рәнҗетмимме мин?

Бу исемне мин үз хәтеремдәге Зөлфия белән генә бәйле рәвештә сакларга булдым.

## Шәл бәйләдем, шәл бәйләдем...

Безнең авыл халкының төп чыгышы — удмуртлардан булса кирәк. Һәрхәлдә, авыл — интернациональ. Түбән оч арлары — бу инде авылның дүрттән бер өлеше дигән сүз. Поник очы — крәшеннәрдән дип әле дә

ышанып сөйлиләр. Анысы тагын дүрттән бер өлеш. Күрше авыллар да шулай. Г. Камалның этисе авылы — Сикертән — бер дә ялгышсыз, марилардан татарга әйләнгән авыл. Ике кешенең берсе сары кашлы, кызгылт-сары эре сипкелле, зәңгәр күзле. Бу турыда Г. Камал да әйтеп калдырган. Арча юлына таба ике Масра — Югары һәм Түбән Масра. Г. Камалның язуынча, гарәпләрдән, Г. Камал белми язмас, ул Түбән Масрада мәдрәсәдә укыган, аның әнисе шул авылныкы. Масраны ул «Мисыр» сүзеннән килеп чыккан дип аңлата һәм, ихтимал, хаклыдыр. Анда ирләр озын буйлы, эре тешле, кап-кара кашлары килеп кушылган—үзенә бер аерым кешеләр. Алар, имеш, Казан ханлыгы чорында миссионерлар ролендә бу̂ якка — мари, удмурт тулы урманлы авыллар чигенә килеп урнашканнар. Миссионерлыкның конкрет программасы да булган; мөселманлыкка чыккан халыкның ир балаларын сөннәткә утыртырга кирәк икән...

Безнең авыл егетләре ара-тирә Масрадан кыз алып кайталар иде. Масра килене, гадәттә, төп ике сыйфатка ия. Болар — йорт тотучылар, исрафчыллыкның төп дошманнары, ә безнең авыл, бу сыйфатны бик гади итеп, «саран» дип кенә аңлата иде. Масралар — сараннар, икенче сыйфат — Масра киленнәре килеп кергән йортта, һичшиксез, кәҗә барлыкка килә. Бу — котылгысыз. Нигә кәҗә? Ул бит алмагачны кимерә, урамга утыртылган яшь агачны каһәрли, ул бит яшелчә бакчасының дошманы! Әмма, Масра киленнәре кәҗәне мамыгы өчен тоталар. Масра киленнәре — шәлчеләр! Ә безнең авыл алмагач, яшелчә үстерми. Безнең авыл шул Масра киленнәре аркасында гомер буена Арча, Теләче, Чүриле, Апаз, Әтнә базарларына, Казанга кәҗә мамык шәл торгызды. Куян мамык шәл безнең авылда иң дәрәҗәсез, иң чүп бер нәрсә иде. Куян мамыгыннан шәл бөркәнеп килгән кунак кыз — безнең авылда үзе белмәгән, үзе аңламаган бер трагик халәткә тап була иде.

— Һи-и! Йөргән була, эчемне поштырып! Куян мамык шәл бөркәнгән булып! Әҗәткана! Ыстырам!

Хөкем шулай гына иде.

Масралар, кичен вакытны әрәм итмичә, ут янына җыелып шәл бәйлиләр. Киленнәр бу хезмәткә каенсеңелләрен, кайнаналарын, нәсел-нәсәпне өйрәтәләр.

Кич... Җиделе лампа яна. Масра килене шәл бәйли Дүрт кич бәйләсә — шәл уртасы. Һәр кич саен — бер чите. Төрле үрнәк, төрле челтәр белән. Тугызынчы кич — шәлнең читләрен уртага тегү. Шул кич — иң тантаналысы — шәлне чылатып киергегә тарттыру. Сугыш елларында тол калган Масра киленнәренә мин өч-дүрт шәл киергесе ясап бирдем. Үземнең апалар да күп шәл бәйләделәр, кәҗә асрадык. Әтидән калган бик күп агачлар бетсә бетте — без шәл бәйләдек. Төн узуга киергедәге шәл кибә. Иртән аны кадаклардан алалар. Матур бер сәнгать әсәре. Шәлнең сыйфатын, бәясен ачыкларга безнең авылны Масралар өйрәтте. Күпереп торган кәҗә мамык шәлнең сыйфаты, бәясе болай билгеләнә: зур ашъяулык кадәр авыр шәлнең нәкъ урта бер җиреннән ике бармак белән генә тотен кебек мамыгыннан эләктерәләр дә, асып карыйлар. Шарты бер: җептән тотасы түгел. Шул сынауда мамык өзелмәсә, шәл үзен-үзе күтәреп торса, мал — затлы. Моның бәясе бар. Затлы шәл бәйләү өчен сыйфатлы мамык кирәк. Ә аны бөтен кәҗә дә бирми. Агач кимергәндә алар барысы да бер дәрәҗәдә, әмма мамык биргәндә аерылалар. Бөтен авылга данлыклы шәлче — Масра килене Мәстүрәне чакыралар.

— Мәстүрә, бу мамык әйбәт булырмы?

Мәстүрә — аз сүзле, эшчән, житди күзле, бер чеметем мамык ала да, теленә тиереп карый. Аннан чәп-чөп китереп авыз алдында гына чәйни.

Аннан ишек янындагы чиләккә барып түкерә, иреннәрен сөртә. Кеше хөкем көтә.

— Бу,— ди Мәстүрә,— шәп булмас. Алданырсыз. Мамыгы тозлы. Әнә Ногманнар кәҗәсенең нәселен булдырыгыз. Ул нәселнең мамыгы коры, тозсыз. Бу — шәп түгел...

Шәл бәйләү һәрвакытта да җыр белән бара иде. Безнең авыл кызлары кадәр кичләрен җырлаган кешеләр бүтән җирдә булмагандыр дип уйлыйм мин. Яраткан җырлары — «Шәл бәйләдем» була иде. Бигрәк тә шәлнең соңгы чите тәмамланганда. Күңелләр күтәренке, эш тәмамланган, алдагы базарда кулга акча керәчәк...

Радиодан «Шәл бәйләдем» җырын тапшырганда, мин әле дә тырыш, хезмәтчән Масра киленнәрен искә алам. Хәер, ул киленнәрнең авылда инде үз киленнәре байтак, шәл бәйләү традициясе авылда мәңгегә беркеп калды.

«Шәл бәйләдем, шәл бәйләдем» җыры — безнең авыл кызларының, сугыш вакытында тол калган киленнәрнең тормыш юлдашы, сердәше булды.

Шәл бәйләү өчен иң уңай урын — аулак өй. Заманында аулак өйләрне бозыклык эшли торган урын дип каршы чыгучылар, тәнкыйть итүчеләр булды. Моны яшьлекләрен оныткан кешеләр язды. Яшь кеше кичен кая барсын? Клубта концерт яки «бичер» булган көнне аулак өй булмый. Теләсәң дә оештыра алмыйсың. Ә клубың көн саен ачылмаса? Аулак өй халыкның әнә шул клубсызлыгыннан туган борынгы бер гадәте иде.

Монда бик күп мәсьәләләр хәл ителә иде. Монда кызлар бер-берсеннән хезмәткә өйрәнәләр, монда егет сайлыйлар, танышалар, аңлашалар, җыр-көй өйрәнәләр, уеннар уйныйлар. Сөю-мәхәббәт җырларының бик күп тексты аулак өйләрдә туган. Ә бозыклык ягына килсәк... Бозыклыкны эшлим дигән кешегә кайда, нәрсә комачаулый ала соң?

Шәл бәйләүче кызлар, Масра киленнәре белән утырган бер аулак өйне хәтерлим мин. Нигә анысы гына хәтердә нык калган? Монда гадәттән тыш бер хәл булганмы? Анда авылның иң һавалы кызы — Зәкәрҗан сеңлесе Зөлхәбирә киявен алып килгән иде.

Зөлхәбирә... Тицианнар, Рафаэльләр, Боровиковский яки Серовлар безнең авылга килеп чыксалар, һичшиксез, Зөлхәбирәнең портретын ясар өчен бездә торып калырлар иде. Зөлхәбирәнең фарсы миниатюраларындагы кебек сызылып киткән кашлары, аксыл-алсу бит-иякләре, узышлый гына, пәке очы ялгыш тиеп киткәннән генә ясалгансыман уймак авызы һәм юка иреннәре... Аның үҗәтләнеп үскән куе кара чәчләре һәм авыр ике толымы... Крестьянның утызынчы-кырыгынчы авыр еллардагы ризыгын ашап үскән булуына карамастан сакланган зифа буе... Һәм әнә шуларның барысы өстенә табигать, нәсел тарафыннан бирелгән һавалылык. Була шундый матур кызлар авылларда, була. Әмма, егетләр игътибарыннан башы әйләнеп, титарайлыкка чыкканнары, кияүгә барганчы ук әллә ниткән хаталар эшләп бетереп дан чыгарганнары да була. Була. Тик Зөлхәбирә алай эшләмәде. Аның матурлыгын, зифалыгын, яшьлеген аңа нәсел һәм табигать тарафыннан бирелгән һавалылыгы саклады. Теләсә кем аның янына килеп сүз ката алмады.

— Һи-и, сезнең белән авыз чайкап ятарга монда,— дип Зөлхәбирә сагызын гына бер чартлатып ала иде.— Сез сабакыларга тел әрәм итеп торырга монда...

Ярыйсы гына, әйбәт кенә егетләр башка кызларга яраган «подход»ны Зөлхәбирәгә карата да кулланып, әнә шулай «сабакы»га әйләнгәләп калдылар. Зөлхәбирә бәхетле — үзенең чибәрлеге, зифа буе һәм беркемгә дә иелмәс башы, горур характеры белән бәхетле иде. Авыл-

ның байтак әйбәт егетләре аның янынннан, утлы күмергә кунып тәпиен яндырган бал корты кебек, очып киткәләделәр.

Инде, көннәрнең берендә, Зөлхәбирә күрше Масра егетенә кияүгә чыккан дигән хәбәр таралды. Ничек булган? Зөлхәбирә авылдан гел урман эшенә йөрде. Авыр эш, гел кеше өсте, гел авыр хезмәт. Күрше авылда торып урман чыгарганда бер егет моңа «ачкыч» тапкан. Ачкыч — нәкъ Зөлхәбирәчә икән. Нәрсәдер, сүз чыккач, теге егет:

— Һи-и, сезнең авыл кызлары белән авыз чайкап ятарга!— дип ташлаган.— Урман караклары бит соң сез! Шунда туып, шунда катасыз инде сез,— дип атына бер чөңгергән дә, выжылдап Зөлхәбирә янынннан узып та киткән...

Ә урман заданиесен үтәп, расчетлар алып авылларга таралышкан кичне теге егет, нәкъ шулай выжылдап узганда, карга кереп юл сабып торган Зөлхәбирәне чанасына төртеп еккан да авылларына алып киткән. Бер кич кунгач булган хәлне беркетер өчен Зөлхәбирәнең әти-әнисенә килеп хәбәр биргән. Алар бәхетле икән, имеш.

Менә теге аулак өй бит әле. Имеш, Зөлхәбирә кияве белән беренче тапкыр кунак булып килгән. Ә аулак өй — күршедә генә. Аулак өйгә җыелган кызларның тын ала алмаудан күкрәкләре селкенә, тавышлары ватыла. Кияү? Нинди була ул? Бу бит кырык жиденче еллар... Кияүгә чыгу бәхетенә ирешкән кеше нинди була? Ул кияүнең тагын да шундый яхшы күңелле дус-ишләре юкмы, калмадымы икән? Аулак өй сулый алмаудан селкенә, түшәмнәр бер күтәрелә, бер төшә иде. Бары тик киленнәр генә күпмедер дәрәҗәдә тыныч.

— Зөлхи кияү күрсәтергә керә!

Вәссәлам. Дөньяда, «данный моментта» шуннан да әһәмиятлерәк бер эш тә юк иде. Әле беркем дә өч көннән соң акча реформасы буласын, ипи карточкасы бетәсен, кибеткә ситсы, пулсукна, галош кайтасын, конфет-шикәрнең иркен сатылачагын белми иде. Зөлхи кияvеннән дә әһәмиятлерәк шәхес, вакыйга булуны берәү дә башына да китерми иде. Шәлләр бәйләнә алмады, телләр бәйләнде... Инде лампа филтәләрен кайчы белән тигезләп кистеләр, инде эссе лампа куыкларын өрә-өрә кабат чистарттылар, тәрәзә пәрдәләрен чыж да выж китереп тегеләй тартып карадылар, болай тарттылар. Инде идәнне ике кат кына себереп, сөртеп алдылар.

— Зөлхи кияү күрсәтергә керә!

Аулак өй шулай тигезсез сулады. Кызлар, хәтта, дулкынланудан, бер-берсенә бераз гына авыр сүзләр дә әйтеп алдылар.

Ниһаять, артына тимгел чыккан, пыяла белән такта арасында байтак таракан күкәе җыелган зур көзге янына килделәр. Кашлар, чәчләр, битләр тагын бер кат рәтләнде, чыж да быж чәчләр таралды.

Бервакыт чолан баскычы шартлады. (Чатнама суыкта аны дөбердәтеп юып кергәннәр иде.) Менә бервакыт йортта булган бөтен кыз — гөрес!— сәкегә утырды һәм бәйләү эшенә тотынды. Безгә нәрсә? Без әле болай гына җыелдык, без әле сезнең керәсен түгел, кунакка килгәнегезне дә белмәдек, безгә нәрсә? Кемдер сагызын чартлатып алды, берсе, хәтта, тыныч кына җырламакчы булды.

Ул арада «дыңкъ» итеп өй ишеге ачылды һәм тыштан һаваның түшәк-түшәк салкын зәңгәр болыты бәреп кереп, сәке астына, көзге артына юнәлде, уңлы лампаның якты нурын бутап, тоныкландырып алды.

Зөлхи. Билле драп пальтодан, пальто якасы җыйнак кына мех, кәҗә мамык шәл бөркәнгән. Битләр вазелиннан бераз ялтырый, кашлар элеккечә кыйгач, йөз нурлы. Әмма күзләрдәге элеккеге наз бераз гына кимегән, күзләр тоныкланып киткән, карашларда ниндидер серләлек, яшерен сагыш бар. Күз төпләре дә бераз батып калган... Кияү. Сукно

кара пальто. Кып-кызыл таза бит, кышкы җил ашаган борын, ияк. Күзләре мут елтырый. Сукно тышлы кара мех бүрек, киез итекне сыдырыпката ясап бетергән дә, чалбар балакларын лыпырдатып рәхәтләнгән. Сукно пальто чишелгән һәм сарык йонынннан бәйләнгән ак шарф арасыннан таза кызыл муены күренеп тора. Йөз — бәхетле.

— Исәммесес?

— Исәммесес?

— Нихәлләрегес бар?

— Ничек яшисес?

— Әйбәт килеп җиттегесме?

— Сау-сәламәт кенә торасызмы?

Әнә шундый сүзләрнең иге-чиге булмады. Сәке кырыенда шуышулар, каушаулар, кияү утырасы урынга бер киезне куйгач, хуҗа кызның выжылдатып аны тартып алып, чуар корамалы икенче киезне куюлары, аны да ошатмыйча, шундук ике киезне бер итеп калынайтып куюлары кебек ыгы-зыгы булды. Утырыштылар. Теләсә нинди белемле, культуралы кешеләр компаниясендә дә булып ала торган авыр бер мизгел: әллә ниләр сөйләшәсе бар, сүзләр тамак төбенә тыгылган, ә тынлык... Монда да шулай булды. Аңышмыйча гына бармак битләренә шәл энәсен уйнаттылар, чартлатып сагыз чәйнәделәр. Әмма һәрбер баш миендә бер генә сорау бар иде: «Кияү» — ул кем? Ул — нинди? Безнең авылның сугыштан соңгы беренче кияве ул — кем?

Кияү пальтосын чишеп җибәрде, бүреген салып тез башына киертте. Як-ягына карады. Тирә-якта яшь тол хатыннар, яшь кызлар иде. Тәк... Кияү булып йөрү рәхәт, дәрәҗәле. Аннан барысы да акыллы сүз көттеләр. Ул арада Зөлхәбирә белән пышын-шашын сүз китте:

— Нихәлләр соң, малай җаным?

— Ияләнеп буламы?

— Кайнишләрең кемнәр?— һ. б. һ. б.

Зөлхәбирә горур утырды, әллә ни күп сөйләшмәде, күз кыры белән генә кияүне күзәтте. Шәл астыннан ургылып чыккан матур чәчләрен рәтләде.

Ә кияү! Авыл өе эссе иде, бабай кеше, күрәсең, кияүне яхшы гына сыйлап ташлаган, ә эссе өй ул сыйны кияүнең тиешле урынына (баш миенә дип әйтүем) меңгереп җиткереп, канга таратып та өлгергән. Кияү — шап! — бер кызның ботына үзенең зур кулын! Һәм кыю елмаеп:

— Нихәлләр соң, апасы?

Кызлар уңайсызланып алдылар, җиңелчә көлештеләр. Бу — программада каралмаган иде, моңа беркем әзер түгел иде. Ул арада кияү икенче кырыйда утырган, таза яшь кызның ботына дәү кулын — шап!

— Эшләр барамы соң, апасы?

Уңайсызланып көлү, шуышып утыру һәм авыр сулау йортны тутырды. Аулак өй эчтән хәрәкәткә килде. Зөлхәбирә дә, күзләрен кыса төшеп, кияү ягына караш ташлады. Ә кияү инде кыза киткән иде. Шул арада кияү дәү таза кулы белән бер кызның шәл энәсен тартып чыгарды да, эффектына алдан ук сокланып, авыз тутырып елмайды. Теге кыз ә дип тә, җә дип тә әйтергә өлгермәде, аның күршесендә шәл чите тәмамлап утырган чибәр солдатка чырыйлап кычкырып җибәрде: кияү, авызын ерган килеш, шәл энәсен аның утырган урынына төртеп алган икән. Кычкыру өйдә ыгы-зыгы тудырды. Ә кияү һаман шат, бәхетле иде.

Ыгы-зыгы Зөлхәбирәнең сикереп торуы белән тәмамланды. Зөлхәбирә шәлен рәтләде, пальтосын төймәләде дә, кияү янына килеп, киерелеп аның яңагына бирде. Тез башыннан бүреген алып киертте дә, сагызын бер чартлатып, авызыннан ут чәчте:

— Һи-и, әҗәткана, сине кешегә санап, дус кызларым янына алып килгән мин юләр. Синең белән авыз чайкап торырга монда, сабакы

һи-и, әҗәткана, кем дип белерсең... Безнең авылда синең ишеләр белән... белдеңме шуны. Әйдә, кайтыйк әле. Әле мин синең белән кайткач сөйләшәм, кайткач. Әле мин сине... һи-и... Әле мин сине. Ярый, кызлар, гаеп итеп калмагыз. Сугыш булмаса, юньле егетләр тегендә ятып калмаса, мондыйларга эләгә торган кыз идемме мин? Әйдә әле, әйдә әле...

Кияү бер сүз дәшмичә аның артыннан атлады. Безнең авылның сугыштан соңгы беренче кияве шәл бәйләү кичәсендә әнә шундый номер күрсәтте...

## Алмазлар белән кисәләр

Шәйхи — зур күзле, ябык гәүдәле, озынча буйлы бер ир иде. Авылда тәрәзә рамнары ясау, пыяла кую буенча бердәнбер оста. Аз сүзле, әдәпле. Шәйхи эчкән, Шәйхи сүгенгән, гаиләдә тавыш чыгарган дигәнне авылда беркемнең дә ишеткәне булмагандыр.

Аның кесәсендә кулъяулыкка төргән алмазы була иде. Шәйхи аны «алмас» дип кенә йөртә иде. Ул алмаз без малайлар өчен сихри бер корал иде. Әле дә күз алдында: «алмас» дигәне сап-сары сөякне ялпаклатып шомарткан бер әйбер иде. Шуның белән пыялага бер сыза — пыяла тавыш та бирмичә икегә аерыла иде. Без — малайлар гаҗиз: ничек инде сары сөяк пыяла кисә?

— Аның башында тары бөртеге кадәр генә алмас ташы бар— дип аңлата ул безгә сары сөякне кесәсенә яшереп.— Ә сабы — фил сөяге. Мәкәрҗәдән алып кайткан иде эти.

Без, табигый инде, борын тарта-тарта шул тирәдә кайнашабыз, могҗизалы тары бөртеген күрәсебез килә. Әмма Шәйхи абзый бу мәсьәләдә каты.

— Алмасны кояшка күрсәтергә ярамый,— ди ул.— Күрсәттең — бетте, диген. Сразы үтмәсләнә. Аннары мин нишлим? Ә?!

— Менә,— ди ул,— гомер буена моны миннән башка беркем дә тотып карамады.

Шәйхи куйган тәрәзә рамнары, ул кискән пыялалар авылда хәзер дә исән әле. Ул тәрәзә куйган мәктәп, клуб исән әле. Клуб дигәннән... 1941 елның җәй башында авылда клуб төзергә керештеләр. Тиз эшләделәр — иллеләп балта остасы бар иде. Алар арасында үзенең беркемгә дә тоттырмый саклаган җыйнак үткен балтасы, кулъяулыгына төргән кадерле алмазы белән Шәйхи дә бар иде.

Менә беркөнне авыл Советы урнашкан Сикертән авылыннан чапкын килде: сугыш... Ирләр балталарын бүрәнәгә кададылар да, дәшмитынмый тәмәке төрделәр. һәркемнең эченнән ут чыккан сыман булды.

Клуб бурасы өстендә эшләгән осталарга Сикертән юлы күренеп тора, һәр көнне алар төштән соң, ара-тирә бүрәнә өстенә утырып, Сикертән юлын күзәтәләр иде. Ә аннан һәр көнне сәгать икеләрдә канатлы ак алъяпкычын җилфердәтеп хат ташучы Габидә атлый. Габидә клуб янына килеп җиткәнче эш туктап тора, балталар борыннары белән сагызлы ак бүрәнәләргә кунып калалар — ирләр янына бер уч повестка тоткан яшь килен якынлаша.

— Тагын кайсыларыбыз?— дип авыр сорыйлар һәм кош теледәй озынча кәгазьне тотып, балталарын җилкәгә салып өйгә таба атлыйлар. Бер атна эчендә Габидә клуб янын кешеләрдән тәмам чистартты. Иң соңгы повестка Шәйхигә килде. Ул тәрәзә борысларын көйләп йөри иде. Янында йомычка җыючы карчык-корчык һәм без — малайлар идек. Габидә килеп туктагач, Шәйхи сизеп аңа карады һәм барысын да аңлады. Җиңел, үткен балтасын жонглерларча бүрәнә өстенә очыртты, балта, су эчәргә туктаган яшь каз кебек, борыны белән дык итеп

сагызлы бүрәнәгә кадалды. Шәйхи түбән төшеп, каезланган агачка утырды һәм тәмәке төрде. Аннан, авыр сулап, теге кош телен алды һәм күкрәк кесәсендәге алмаз янына икегә бөкләп тыкты. Каядыр еракка күз ташлады. Күрәсең, иртәгә ятим каласы балаларын уйлагандыр, ә аның балалары — кыздан-малайдан нәкъ алты баш иде. Безнең авыл хатыннары, гомумән, баланы мул табарга яраталар иде.

...Клуб тәрәзәләрен 1943 елда гына, Шәйхи авыр яраланып фронттан кайткач кына куйдылар. Шәйхинең ашказанына пуля кереп чыккан, ул авыр операция кичергән һәм бик нык саргайган иде. Кырык беренче елда бүленеп калган эшен ул зур газап белән тәмамлады. Ул ялгыз иде: аның белән бергә бу клубны салган осталарның кайсы сугыш кырында ятып калган, кайсы әле дә сугыш кырыннан сәлам хатлары җибәрә иде.

Шәйхинең ашказаны бары тик сөттә пешкән бәрәңге боламыгын кабул итәрлек кенә калган иде. Хатыны аңа гел шуны пешерде. Кем белә, бәлки, ул ашказанына цейлонда үскән ананас, Кампучиядә өлгергән банан, яки Урта диңгездән тотылган мидея дә килешәсе булгандыр, әмма без — авылда, сугыш чоры авылында, андый нәрсәләрнең барын әле берәү дә белми, аларны табуы да кыен иде әле. Шуңа күрә ул гел сөттә пешерелгән бәрәңге боламыгы ашады.

Колак артына карандаш кыстырып, клуб өстәлендә Шәйхинең пыяла кискәне хәтердә калган. Ул авыру йөзенә чиксез сагыш чыгарып, киселәсе эздән бармак бите белән сызып, пыяланың тузанын алды да, акрын гына җырлады:

Алмаслар белән кисәләр
Тәрәзә пыяласын.
Сабыр итеп карыйк, дуслар,
Сабыр диләр дәвасын.

...Шәйхинең алмазы хәзер кайда икән? Алмаз череми бит, кай туфракларда гына вәйран булып «сабыр итеп» ята икән ул могҗизалы таш?

## Төнбоеклар үскән болында

Безнең авылның элеккеге тормышы «Пауал тегермәне» дигән хикмәтле бер урынга бәйле иде.

...Арасында сап-сары зонтик булып кабы күренгән ужым басуыннан барасың-барасың да, кинәт кенә тау битенә килеп чыгасың. Аста болын. Сузылып ялтырап бормалы Кесмәс ята. Борынга баллы куәт исе бәрә. Дымлы тугайда шөлдерле сары чәчәкләр, суга якынрак урыннарда давыл чәчәге, су эчендә төнбоеклар. Болын юлына килеп кергәч, синең «уф алла» арбасы да, аңа салган иңе пот арышың да бу дөньяның бик кечкенә, бик әһәмиятсез бер кисәкчәләре булып кала. Кояш нурына коенган сары чәчәкле болынның, тын, серле елганың үз дөньясы, үз сере бар. Тегермәнгә якынлашасың. Төнбоеклар өстенә шапшап итеп бакалар сикерә. Сулыш каба — дөньяда бал, су, балык исе. Лепердәп утырган ике катлы тегермән йортына киләсең, арбаңны агач күпердән деңгердәтеп тартып өскә алып менәсең. Үлчисең, кәрәк оны бирәсең, капчыгыңны чишеп мөшкә авызына шудырып куясың да аска төшәсең. Аста — җылы он исе! Моны безнең як кешесеннән башка тагын кем генә анлый ала икн? Америка ковбоемы? Италиядә йөзем үстерүчеме? Һиндстанда дөге җыючымы? Тегермән стеналарына ак пудра кунган, моны безнең авылда «поракъ оны» дип йөртәләр. Агай-эне

тын гына капчык тутыра, ара-тирә таш астындагы улактан аккан жылы онны учына салып уып карый. Эре тартмыймы? Ә тегермән йорты легер-легер килеп селкенә, тирбәлә, шул арада синең йокың да килә башлый.

Менә ишектә ак чәчле, ак мыеклы, кып-кызыл битле карсак бер абзый күренә. Авызында — сүнгән трубка. Елмаеп кына улак янына килә, аккан онны учына ала, уып карый да, мөшкәдән коелу тизлеген үзгәртә. Ак тузанлы сүс бау, шомарып сөяккә әйләнгән боргычлар...

Бу — Пауал абзый, Яңа Чүриле русы. Русча бер авыз сүз әйтми, «к» белән «г» авазларын гына русчалаштырып матур итеп саф татарча сөйләшә. Әрекмән, ат кузгалагы арасына чумган абзар артында сыеры арканлап куелган. Безнең тирәдә «урыс сыеры» дигән төшенчә бар иде. Урыс сыеры — димәк, күп сөтле, куе сөтле уңган мал, дигән сүз. «Пауал сыеры» дигәнгә тагын «бура тикле» дип тә өстиләр иде. Дуңгызны яратып бетермәгән авыл халкы Пауалның дуңгызына әйбер әйтми иде. Шунда, тегермән белән абзар арасында мыркылдап, өч тиен акча зурлыгындагы түгәрәк танауларын жиргә төртеп йөргән ак керфекле йомры дуңгыз балаларына да Пауалныкы булган өчен генә бөтен кеше яратып карый иде. Авыллардан шактый ерак утырган бу хуторга җәй көне иң матур вакытларда гына Пауал картның читтә-миттәге балалары кайта иде. Без аңлый алмый гаҗиз: шушы матурлыкны ташлап, ничек инде кайдадыр, ташкүмер, шпал исе килә торган Арчада яки Шәмәрдәндә эшләп йөрергә кирәк? Әмма «Пауалның Зинасы кайткан икән» дигән хәбәр якын тирәдәге дүрт авыл өчен матур бер яңалык була иде. Чәчен ясаткан, ак кофта, озын кара юбка кигән. Озын буйлы дастуен (безнең авылда озын мәһабәт кешене әле дә «дастуен» дип атыйлар, бу инде «достоин» дигән сүздән алынгандыр) Зинаның тегермән артындагы тугайлыкта чәчәк җыеп йөргәнен карап торганда агай-эне мөшкәдән аккан ашлыкның нинди эрелектә тартылуын онытып тора иде. Кайвакытта кыз янында костюм, штиблетлар кигән егетләр була иде, алары, имеш, аның абыйсы һәм булачак кияве икән. Алар кайвакытта мылтык алып болын буйлап еракка китәләр һәм җәйге тын кичләрдә томан баскан уйсулыклар артында гөрселдәгән дәһшәтле ату тавышлары ишетелеп куя. Пауал абзый, сүнгән трубкасын төйгечләп, буа өстендәге басмада шул якка карап тора.

— Аттылар. Кыр үрдәгедерме инде, әллә йорт үрдәгеме. Карарбыз,— дип елмая карт.

Пауалның сеңлесе (исеме, шаять Харитина булгандыр) безнең авылда Хәтирә исеме белән йөри иде һәм хатын-кызлар мәҗлесе җыйганда аны бер дә чакырмыйча калдырмыйлар иде.

— Пауал Хәтирәсе килгәнме?

— Килгән, килмәгән кая! Яулыгын татарча бәйләгән, и ходаем, безнең белән бергә кулларын күтәреп догалар кылып җибәрде...

Ихтимал, Пауал абзый булгангадыр, Кесмәс суына балык тотарга Чүриле руслары төшә иде. Бер вакыйганы хәтерлим: миңа нибары 4—5 яшь булгандыр, тегермән чираты көтеп ятканда, әти мине капчык өстендәге тәмле йокыдан уятып, буа янына алып чыкты. Ак штаннан гына калган ярым-ялангач озын руслар ятьмә белән буаны сөзәләр һәм ятьмәгә эләккән кыслаларны ялангач кул белән шау-шу килеп җыялар һәм чиләккә тутыралар иде. «Суда аягыңны кысла кисмәсен» дигәнне мең кат ишетеп үскәнгә, бу хәл гомерлеккә онытылмас бер истәлек булып калды.

Тагын хәтерлим: кышның шартлаган суык көннәрендә — һәр кышны — әни, чишмәдән чиләкләренә боз асылындырып су алып кайткач, бер хәбәр әйтә иде.

— Бүген Чүриле урысларының хач мана торган көне.

Аннан сөйли иде: ат җигеп, чанага төялеп Пауал тегерменәнә Чүриле руслары төшә икән. Чүриленең үзендә инеш кенә, анда су керерлек урын юк. Пауал абзый бәке тишеген киңәйтеп куя да, шуннан, арадан берсе бөтенләй чишенеп, бәкегә чума икән. Иптәшләре аңа карап торалар һәм ул чыгышка аңа сөлге бирәләр, толыпка төрәләр дә Пауал абзыйның суган пирогы исе килеп торган җылы өенә алып керәләр.

— Ничек суык тиеп үлми ул? — Ел саен әнидән мин шуны сорыйм. Әни бу сорауга иялэнгән.

— Аңа Пауал өендә зәмзәм суы бирәләр,— ди ул.

Чүриле руслары хач манган көн кышның иң суык вакыты, йорт бүрәнәләре чартлаган, чишмәләр бозга каткан, иртә туган сарык бәрәннәре абзарда өшегән вакытлар була иде. Һәм моны бөтен авыл дерт итеп сөйли иде.

— Бүген Чүриле урыслары хач маналар...

Монда ниндидер серлелек, без аңламаган шигърият бар сыман. Чүриле белән безнең авыл халкы бер-берсенең диннәренә тимиләр, ихтирам саклыйлар иде.

Язгы сулар ярларны җимереп, тегермән буасын ашап бетергәч, май ахырларында дүрт авылның халкы Пауал тегермәнен буарга җыела иде. Көрәк, сәнәк, ат, носилка (бездә: лачинкә), тачка, балта. Ирләр, яшь хатыннар, егетләр-кызлар. Төш вакытында кызлар тегермән артындагы тугайга чыгалар да карт каен төбенә чирәмгә тәгәрәшеп яталар. Таза гәүдә, кояшта ашалган бит-куллар. Каршыларына тезелешеп егетләр ята. Җиңелчә генә уен-көлке, артык үткен булмаган юмордан да рәхәтләнеп көлү. Әмма монда зур әхлакый бер эш эшләнә: бу авылның фәлән егете, фәлән кызы эшкә ничек? Кулыннан эш киләме? Сөйләшүе, үз-үзен тотуы ничек? Моның белән тормыш корып булырмы? Бу каен төбендә юк-барны сөйләшеп ятканда әнә шундый бөек әхлакый мәсьәләләр хәл ителә, сүзсез генә шул турыда зур дискуссия бара иде. Әмма, юкка гына! Юкка гына булган икән... Бичаралар! Аларның күбесе йон оек, яңа чабата, канатлы алъяпкыч, бала итәкле озын күлмәк кигән иде, аларга хәзерге затлы колготки, кофталар, йон күлмәкләр, туфли кидертсәң, матурлык, гүзәллек буенча алар дөньяда беренче урынга чыгарлар иде! Әмма булмады! Барысын да кырык беренче ел хәл итте. Ул кызлар каршында тегене-моны сөйләшеп яткан егетләрнең өч-дүрт елдан заты да калмады — алар әнә шул кызлар өчен, әнә шул карт каен үсеп утырган тугай, мыекларына порак оны кунган Пауал абзый, аның көяз, гүзәл Зинасы, гомумән, Пауал тегермәне янындагы сары чәчәкле, дымлы болын өчен көрәшеп, ерак туфракларда башларын салдылар.

...Күпмедер еллар узгач мин — Пауал картның бөтен хуҗалыгына, бала-чагасына, тегермән буасына һәм чәчәкләре бүртенеп утырган болынга гашыйк малай — хәрби хезмәттән ялга кайткач, шул болынга төштем. Русчаны белүемә горурланып:

— Здравствуйте, дорогой Павел Васильевич!— дидем мин, уң кулымны безкозырканың кырыена тидереп.

Ап-ак чәчле, ап-ак мыеклы Пауал абзый әкрен генә атлап каршыма килде, кулы белән күз өстен каплап бераз карап торды да, елмайгансыман чырай белән татарча сөйләп китте:

— Ә-ә... Син әле теге Сөнгать улы мыни? Службаданмы?— диде.— Минем улым да — Вася — Черноморскийда веть. Кайтып китте. Тагын өч ел хезмәт итәсе калды. (Ул вакытта без флотта 5 ел хезмәт итә идек). Пауал абзый трубкасын чыгармады.

— Тегермәндә эш бетеп килә хәзер,— диде ул, русчага күчеп тормастан.— Хәзер — электричество. Әле болай гына тотабыз буаны. Күселәр үрчеде. Стенадагы порак онын ялыйлар...

Аның карашында мин авыр сагыш, үткәнне сагыну кебек моңсу хисләр тоеп алдым.

— Син теге Сөнгать малае мыни әле? Хәтерлим, хәтерлим. Бывший солдат иде. Минем белән гел солдат тормышы турында сөйләшә иде. Без веть бер елларда служить иткән кешеләр. Мин — уланский полкта, ул — маршевая ротада. Ә син, значит, минем Вася кебек — флотта. Безнең заманда әйтәләр иде: лодырь — в артиллерии, щеголь — в кавалерии, пьяница — во флоте, дурак — в пехоте...

Пауал абзыйның, мин сизеп алдым, җаны тыныч түгел иде.

— Менә, эшсез калдык,— диде ул.— Буаны быелга будылар, болай гына. Минем кирәк бетте. Инде Чүриле зиратына карап-карап алабыз. Карчык белән бергә утырабыз да елыйбыз, утырабыз да елыйбыз. Безне инде Чүриле зиратына күмәрләр.— Ул авыр йөткереп алды.— Үлгәнне белсәләр, конечно. Хәзер веть кеше килми монда. Безнең эш бетте, сезнең татарда ничек диләр әле? — Азраилны гына көтәсе калды...

Миңа авыр, бик авыр иде. Абзар җимерелгән, аның янында сыер күренми, ерактa — Масра тавы буендагы кое бурасы да күренми, өч тиенлек акча зурлыгындагы танаулары белән җир сөреп ак керфекле дуңгыз балалары да аяк арасында йөрми иде. Без кыен аерылыштык. Пауал абзый минем исемемне дә сорамады, кайчан кайтасымны да, әниең исәнме-түгелме дип тә сорамады. Икебез дә белеп тордык — бу соңгы күрешү, соңгы сөйләшү иде.

...Мин узган елда ул болынга велосипедка утырып төштем. Болын беткән, тегермән йорты сүтелгән, аның урынын әрекмән баскан, буа убылган, сары чәчәкле болын кипкән, ул болынны сөреп, анда нәрсәдер утыртканнар. Тулы суыннан киерелеп, акрын искән җилгә чупылдап утырган яр буйларында тузан өермәсе йөри. Кесмәс елгасы өзгәләнеп кипкән, яр буенда культуралы көтүлек өчен су алырга дип механизаторлар торбаларын кая каптырырга белмичә йөриләр. Пауал тегермәне торган әрекмәнлек артында теге елларның җансыз шаһиты булып карт каен гына тора. Каен төбендә техника ремонтлаганнар, анда мазут, керосин түгелгән һәм үлән беткән. Тимер-томыр, резина кисәкләре майлы җиргә кереп баткан. Мин авыр уйларга чумдым. Шулчак, кырылган кәефемне җиңеләйтер өчендер инде, мәзәк бер җыр хәтеремә килде.

Хәер, һич тә очраклы түгел, мин шул вакытта үзебезнең як житәкчелеге турында уйладым. Башта табигать биргән суны бетереп, аннары су киләсе торбаны кая каптырырга белмичә йөрүне ничек аңлатырга? Җаваплы иптәшләргә чын йөрәктән үпкәләдем, һәм шуңа бәйле рәвештә теге җыр хәтеремә килде.

...Безнең күршедә башына килгән фикерне шундук җырга салырга сәләтле Галимулла абзый яши иде. Сугыш вакытында аны хезмәт армиясенә алдылар. Баҗасы — авыру Заһри безнең өстәге урманда урманчы иде. Сугыш вакыты биргән мөмкинлекләрдән иркен файдаланып, ул авыл кешеләренең «уф алла» арбаларын, бауларын, балтасын алып кала иде. Кыза китеп беркөнне баҗасы Галимулла абзыйның кызы Зөлфияне дә каһәрләгән: арбасын кордонга чыгартып биклəп куйган да, бер атнасыз бирмәгән.

Сугыш беткән айда Галимулла абзый бөтенләйгә азат ителеп өенә кайтты. Гадәт буенча кунак җыйды, өстәл янына утыруга, тәрәзәләрен ачтырды да гыжлавык тальянын алып җырлап җибәрде. Мәҗлеснең түрендә хатыны белән Заһри иде. Теге җыр хәтердә калган:

Безнең Пауал тегермәне
Бик вак тарта ярманы;

Бажай, сиңа үпкәм бик зур,
Ник апкалдың арбаңны?

Авыл халкына бу җыр шул көнне үк таралды һәм канатлы фразага әйләнде. Шул көннән башлап бер кыз артыннан йөргән ике егетнең («бажайларның») сөйләшеп торганын күрсәләр, болай дип кенә әйтә торган булдылар:

— Пауал тегермәнендә ярма тарттыралар...

Пауал абзыйның исеме әнә шулай фольклорга кереп калды. Халык мәхәббәтен казанып кереп калды.

...Элек төнбоеклар үскән елга буена килгәч, мин гел Пауал абзый һәм аның су тулы тегермән буасын сагынып искә алам.

## Зәкәрҗан, алга!

Туган нигездә, карт тополь төбендә укып утырам. Җиләс, яфрак шаулавы башны рәхәт әйләндерә. Нигәдер укып булмый, уйланып та булмый. Нәрсә комачаулый икән? Як-якка каранам. Күрәм, тополь төбендәге өстәл астында иске радиоалгыч! Бичара! «Родина-47». Моны кичә минчән рөхсәт сорап бетермәстән, улым сүтә башлаган иде. Ничә еллар миңа турылыклы хезмәт иткән радиоалгыч хәзер беркемгә дә кирәкми, кирәкми генә түгел, ул инде артык, ул инде чыгарып ташланган. Әйе, ул баз артындагы тимер-томырлар өстендә бер кыш чыкты инде. Заманында күпме моң, күпме шатлык, күпме җан рәхәтлеге агызды ул безнең бакчага... Җәйге кичләрне мин аны тәрәзә төбенә күчерә идем дә, тәрәзәләрне төбенә кадәр ачып, үзем бакчаның әллә кайсы почмакларына китеп тыңлый идем. Хәзер мин шәһәрдә авыру картлар шикелле мырлап йөрим: проигрывательләрен бөтен көченә акыртып, форточкага эләләр яки балконга куялар. Янәсе, менә мин тыңлыйм, шулай булгач, сез дә тыңларга тиешсез... Бәлки мин дә теге елларда шундый мәгънәсезлек эшләгәнмендер? Юктыр, дип юатам үземне, чөнки, беренчедән, безнең өй бакча эчендә түргә үк урнашкан һәм урам рәтеннән ул бик ерак тора. Икенчедән, ул музыка безнең агачларга бәрелеп бакча эчендә генә йөри; өченчедән, безнең авылда ул вакытта әле радио юк; радиоалгыч бер бездә генә. Дүртенчедән, кеше ишетсә дә зыян юк — чөнки мин теләсә-нәрсә акыртмыйм. Ә концертларны гына җибәрәм. Казан станциясенең позывное ул вакытта «Нәфисә» көенең бер өлеше иде. Мандолинадан уйналган шул көй белән Казан безнең күңелләрне әсир итеп үзенә бәйләп куя иде. Ул еллардагы концертларда Мөнирә Булатова, Галия Кайбицкая, Мәрьям Рахманкулова, Зифа Басыйрова, Шәфыйка Котдусова, Рокыя Бәхтиева, әлбәттә, ике генә туз — Фәхри Насретдинов белән Усман Әлмиев җырлый иде. Еш кына Фәйзулла Туишев концертлары тапшырыла иде.

Инде шул радиоалгыч — өстәл астында чирәмлектә аунап ята... Ә бит «Родина-47»се булган кеше ул заманда колач җитмәслек байлыкка ия булып исәпләнә иде. Мин бит аны ике-өч айлык хезмәт хакына, өстемә пальтом булмаган килеш алдым, ә хәзер?

Иске радиоалгыч минем күңелне әллә кайларга алып китте. Әллә кемнәр искә төште. Авылда икенче булып моны кем алды икән? Әйе, хәтерлим, моны район үзәгендә балавыз җыю конторасында эшләүче фронтовик Зәкәрҗан алды. Дөресрәге, район үзәгендәге квартирасыннан үзенең туган нигезенә — карт әтисе белән әнисенә кайтарып бирде. Зәкәрҗан үзе авылда еш була, узышлый да, барышлый да туктый, чөнки бөтен районда бер аның гына мотоциклы бар иде. Дөбер-шатыр килеп урамнан Зәкәрҗан уза — авыл урамында тузан болыты гына ка-

ла, берничә минуттан аларның түр тәрәзәсе ачыла һәм актык хутына кадәр куелган тавыш белән аннан я Казан, я Мәскәү, бер дә булмаса Киров, я Саратов сөйли иде. Зәкәрҗан эти-әнисе янында ашыгып кына тамак ялгап ала да, дөнья җимереп, урам куптарып тагын юкка чыга иде...

Зәкәрҗан сугыштан 1945 елның сентябрендә кайтты. Тегеләй-болай гына түгел, бер орден, дүртләп медальне бик яхшы офицерский френчкә тагып, билне яссы, ике эләктермәле офицер каешы белән буып, ул каешны портупея белән күтәртеп, бик яхшы хром итекләр, кызыл кантлы зәңгәр галифеләр, Союзниклар армиясе офицерлары кия торган яшькелт-соры кыйммәтле шинель киеп кайтты. Кайткан көнне Зәкәрҗан авылдагы туганнарын җыйды. Әнисе аның өчен саклаган узган елгы каз түшкәсен турап аш пешерде, табада итле бәрәңге кыздырды. Каклаган каз янына Зәкәрҗан солдат флягасын яткырып куйды. Туган-тумача гел аның авызына гына карап утырды, гел фронт хәлләрен сөйләттеләр. Орденны нәрсә өчен бирүләре турында сөйләгәндә Зәкәрҗан бераз кызып китте һәм хикәянең иң кульминацион ноктасында калай кружка төбендәге спиртны су кушмый гына йотты да, кул аркасы белән иреннәрен сөртеп, кинәт кенә урыныннан торды һәм...

— Эфпирют, Зәкәрҗан!— дип кычкырды. Кычкырды... һәм ике якка ачылмалы түр тәрәзәне рамы-ние белән бәреп үзенең таза гәүдәсен бакчага ыргытты...

Сугыш күрмәгән халык шунда гына сугышның нинди хәтәр, хәвефле икәнен аңлады... Әйдә, белсеннәр, авылга бит Зәкәрҗан кайтты. Кайтты — ул вакыттагыча, җәяү түгел, ә үз хутына, мотоциклга утырып. Авыл халкы ике көн рәттән юньләп эшләмәде. Бөтен халык Зәкәрҗаннар ишегалдында булды. Әлегә көтү кермәгән иде һәм Зәкәрҗан көтү каршына мотоцикл белән бара башлады... Беренче көннәрдә сыерлар бик куркынды: авыл башына кайтып җиткәч кая ул элеккеге кебек мутлыкка качулар! Күзләрен алартып, коерык чәнчеп, авыл урамыннан сырт сикертә-сикертә алдырып, һәр сыер үз капкасыннан керәп бу гыйфриттән котылу ягын карады. Зәкәрҗаннарның болай да әйбәт холыклы сыеры, бичара, бер атна буе мотоцикл озатуында куркып-чабып кайтты да, бозау салды.

Урамда көзен тәкә хәтле казлар гына була. Көз байлыгыннан алар симергән, йокымсырап тәнгә май салып кына ялкау утыралар. Зәкәрҗанның әнисе Шәмсениса карчык ул казлар өчен борчылды. Зәкәрҗан инде район үзәгенә эшкә урнашкан иде һәм авылга кичләрен генә кайта иде. Шәмсениса карчык кичке якта урам буйлап бер уза:

— Безнең Зәкәрҗан кайтыр вакыт җитә, каз-үрдәкләрегезне ябыгыз...

Ләкин Зәкәрҗан бер казны да таптатмады.

Каз-үрдәкне таптатмады, әмма малай-шалайның кирәген бирде. Зәкәрҗан урамда күренгәндә (ул бик ерактан күренә иде, буй — 1 м 90 см, башта полковниклар кия торган папаха, өстә я затлы шинель, я хром пальто, алары ике-өч төсле), малайлар качу ягын карыйлар иде. Чөнки Зәкәрҗан күпер өстеннән узганда малайлар очраса, берничә дә карамыйча аларны суга ыргыта иде. Сентябрь суының температурасын ул елны бик күп малай үлчәде. Мондый вакытта Зәкәрҗанның әйтә торган сүзе бер генә була иде:

— Батыр, чыныккан кеше генә ил сакчысы була ала. Ну-ка!

Һәм аның белән күпердә очрашкан малай киеме-ние белән аска суга оча иде...

Аның эш шәп, рәвеш-шәп, йөреш-кыяфәт шәп иде. Шәп булыр өчен Зәкәрҗан үләргә дә риза иде. Фронтта бер тапкыр яралангач, аны әйбер складының мөдире булган диләр. Моңа кимсетеп карарга ярамый, фронт — фронт инде ул. Солдатның сабын, подметка, сөлге склады да

үзенең хәвефе, ярасы, үлеме янында, ерак булмый. Зәкәрҗан анда шәп, батыр солдатлар, офицерлар белән аралашкан, сөйләүләренә караганда, генераллар һәм маршаллар белән ике тапкыр өстәлдәш булган. Шул кешеләрне күрү аны — әзерлексез, белемсез авыл егетен, үзгәрткән дә бетергән.

Һәм, чыннан да, батырлык эшләгән: фашистларның зур азык складын алган вакытта Зәкәрҗан беренче булган һәм охрана торган объектка граната күтәреп үзе ыргылган.

— Миңа,— диде Зәкәрҗан,— герой бирәселәре булган. Ниндидер показатель — балл җитеп бетмәгән.

Зәкәрҗан язга шәп чыкты: көннәр җылынуга урамда бөтен авыл халкы карап торганда мотоциклын сүтте, чистартты, юды, майлады. Ул арада юл да кипте. Зәкәрҗан мотоциклына шәп көзге куйды, сөйләшмәс булды, гел дулкынланды. Җәйге формага күчте: яхшы йон гимнастерка, теге каеш, теге чалбар һәм итекләр. Яшәү-формалары буенча әти-әнисе белән бер конфликт та булып алды. Чөнки яз житү белән Зәкәрҗанның күзе төз лапас астындагы «уф алла» арбасына төште һәм ул аны ишегалдына өстерәп чыкты да кулына балта алды. Сугыштан кайткан малайның мондый хуҗалыкчыл инициативасына куанып бетә алмаган әти карт, рәхәтлектән тамагын кыра-кыра, улы янына килде.

— Нәрсә, улым, көйләп куймакчы...

Карт җөмләсен төгәлли алмады. Яшел йон гимнастеркалы калын күкрәк иркенләп киерелде дә, югарыдан селтәп, балта белән «уф алла» тәгәрмәченә берне бирде. Коргаксыган тәгәрмәч дүрт булды. Карт авызын ачып икенче җөмлә әйтергә җыенганда, утын яра торган бүкән янында тәгәрмәч, тәртәләрдән учаклык утын гына калган иде.

— Моның белән алга барып булмый,— диде Зәкәрҗан, галифе кесәсеннән «Казбек» чыгарып.— Бу — дошман, ә дошманны без юк итәбез. Бу — кешелек җәмгыятен алга алып бара алмый. Пока ат көчен, аннан, карарбыз — механизация! Баста!

Карт ә дип тә, җә дип тә әйтә алмады, ул көнне аның теше сызлый иде. Зәкәрҗан сәгатенә карады, фосфор йөгертелгән кара циферблатлы швейцарский зур сәгатен ул кул аркасына төшереп үк йөртә һәм сөйләшкәндә, число, ай, ел, гомумән, саннарга кагылышлы предметлар, күренешләрне телгә алганда, сәгатькә карап алуны гадәт иткән иде.

— Әйдә докторга алып барыйм,— диде ул әтисенә. Әтисе әле дә булса арбаны кызганып сүзсез басып тора иде, яңагын тотты.

— Балам, төш узды бит инде. Иртәнге як хәерле булыр. Бер кичкә — кер мичкә, диләр. Түзәрмен...

Төн узды. Гадәттән тыш аяз, җылы май көне иде, иртәнге чәйдән соң Зәкәрҗан мотоциклын кабызды.

Карт та юлга чыгар алдыннан карчыгына карап сәке кырында утырып алды, аннан ниндидер дога кыймылдатты.

— Я хода, үзеңә тапшырдык,— дип, карчыгына кызганыч бер караш ташлады да, урыныннан торды. Зәкәрҗан инде тыпыр-патыр китереп ишегалдын төтенгә тутырган иде.

Терсәк күмелерлек зур кара перчаткалар, танкист шлемы, зур кара күзлек кигән, затлы гимнастерка өстеннән офицерлар кия торган плащ-накидка элгән Зәкәрҗан мәһабәт һәм коточарлык дәрәҗәдә матур иде.

— Яхшы тотынып утыр,— диде ул әтисенә, үзенең билен җайлап.

Авыл урамында сузылып тузан гына калды. Авылдан Арчага кадәр — унсигез-егерме чакрымнар юл. Басу капкасын чыгуга Зәкәрҗан газ өстәде. Чүт кенә борылып:

— Әти, утызны бирәм,— диде.

Двигатель искиткеч көйле, юл яхшы, тигез иде. Бераздан Зәкәрҗан:

— Әти, кырык!— дип җилгә кычкырды.

Казиле үрен төшкәндә җил тагын бер кисәк тавышны йолкып, умырып алды:

— Әти, илле! Ныграк тотын!

Арчага җитәрәк юл тагы да әйбәтләнде, юлга вак таш сипкәннәр иде, коточкыч тизлектә таш бөртекләре Зәкәрҗанның кара күзлегенә бәрелделәр.

— Әти! Аркага ятыбрак бар! Алтмыш!

— С-с-сик-сән!— дигәндә Арча урамына килеп керделәр. Инде тизлекне киметергә кирәк иде, Зәкәрҗан тизлекне кырыкка калдырып чышт итеп поликлиника каршына килеп туктады. Нәлт кенә сикереп төшеп, зур перчаткаларын салганда игътибар итсә — әтисе юк. Кинәт кенә ул куркуга калды. Әмма паникага бирелмәде. Димәк, Арчага кергәндә әтисе очып төшеп калган. Юлдан читкә тәгәрәгән булса берни дә юк, ике як та йомшак уҗым басуы иде. Фронтовик кеше, салкын кан сакларга тырышып, кире борылды. Арча басуында әти-карт юк иде. Әһә, Казиле үрен төшкәндә очкандыр, дип уйлады егет һәм газ бирде. Карт, ни хикмәттер, анда да юк иде. Зәкәрҗан куркуга калды. Шулай йөри торгач, авылга кайтты. Юлда төшеп калгач, берәрсе утыртып авылга кайтармадымы икән дигән бик сыек өмет белән капка төпләренә кайтып туктады һәм хәвефле чырай белән өйгә керде. Керсә... гаҗәп! Әтисе белән әнисе тыныч кына чәй эчеп утыралар. Карт кәефле иде.

— Әйдә, улым, утыр, кайтып бик әйбәт эшләдең әле,— диде. Үзенең битенә, маңгаена әллә ничә җирдән гәзит ябыштырылган иде.— Ходаның хикмәте, син басу капкасына борылганда ук очып барып төштем мин. Шунысы ярады инде — теге мәлгунь теш төбе белән сынып чыкты бит — авыз белән юл каткагына барып төшкәч. Менә аналардан яңадан туган күк булдым. Әйдә, улым, утыр. Ниме, каян борылдың? Әллә ике-өч чакрым ук киткәнсеңме? Масрага хәтле үк түгелдер ич! Эштү син, аны тиз генә туктатып та булмый торгандыр? Әйдә...

...Туктале, мин нигә соң өстәл астындагы иске радиоалгычка карап ятканда боларны хәтерләдем? Әйе, берничә еллар узып, егет булгач, мин Зәкәрҗан белән сөйләшеп утырдым.

— Ничек инде син, шундый шәп егет, фронтовик, без — яшүсмерләр сокланып йөргән кеше, төрмәгә эләктең? Сиңа бер дә туры килми бит бу... Сине бит бөтен авыл халкы бик намуслы кеше дип белә.

Инде олая төшкән Зәкәрҗан авыр сулап куйды. Аның элеккеге шәплеге күзләрендә генә калган сыман иде.

— Ничек бы сиңа әйтергә? (как бы тебе сказать? димәкче була). Эш бит менә ничек тора иде (гел тәрҗемә итеп сөйли, шайтан), кырык җиденче елның коры җәе. Засуха. Халык нервный — бөтен җир көя. Минем дә план яна. Балавыз тапшыру планы яна. Мин бит ничә районга бер кеше. Миндә — Яңа Чүриле, Саба, Кукмара, Тәкәнеш, Мамадыш районнары. Ә план юк. Ничек бы сиңа әйтергә? Кайттым әти карт белән әни карчык янына, мунча кердем, әни ясаган квасны эчтем. Ә син беләсеңме, мин үз гомеремдә йөз граммнан ары акны эчмәдем? Белмисең? Ә беләсеңме, күпме кеше әнә шул границаны белмичә харап була? Миңа фронтта вакытта начальник снабжения дивизии әйтте: ир кешегә, диде, сугышта гына түгел, егетлек, диде в каждую минуту кирәк. Син, диде Фәхригалләмов, дөньяда матур итеп яшисең килсә, беркайчан да, бернинди обстановкада да үзеңнең маркаңны төшермә. Икенче йөз грамм, диде,— безгә ул вакытта фронтовой паек бирәләр иде — сине кешелектән чыгаручы иң коварный көч. Менә шулай. Шкафтан алып йөз грамм да эчтем. Рәхәт, җиләс көн, әмма яңгыр әле дә юк, болытлар күренә генә. Эч поша. Фронтта андый состояниене белмәдем мин. Ә монда — ужас! Ятам. Үрелеп кенә приемникны кабы-

зам. Минем бит «Родина-47» бар иде, авылда беренче булып мин алдым! (Мин аның бу хатасын төзәтеп тормадым, миңа нәрсәгә ул?). Кабыздым, тыңлыйм, әйтә бит бу: «Саратов сөйли», ди. Хуш, сөйләсен, безнең планета өстендә дуслар, туганнар өчен эфир иркен. Ие, Саратов сөйли. Белдерүләр тапшырабыз, ди. Ну, анда, кайда утюг ремонтлыйлар, Волга аркылы паромда эшләргә кешеләр кирәк, кайсы ательеда үз сукноңнан пальтолар тегәләр и так далее... Шуннан тыңлыйм: балавыз буенча Саратов әзерләү конторасы хәбәр итә, ди. Фәлән-фәлән сумнан балавыз алабыз, ди. Минем колаклар үрә торды. «Родина-47»нең тавышын көчәйттем. Болар безгә караганда әллә никадәр арзан түли икән населениегә. Тәк, тәк, дип уйлыйм мин. Без кем? Совет гражданины. Саратов өлкәсе умартачысы кем? Тоже. Балавызны мин кем өчен җыям? Дәүләт өчен. Саратов конторасы кем өчен? Тоже. Теге умартачыга Саратов күпме түли? Фәлән сум да фәлән тиен. Ә мин күпме түлим? Почти ике тапкыр артык. Саратов өлкәсе умартачысы кем? Үзебезнең совет гражданины, утны-суны кичкән, сугышта җиңеп кайткан, Ватан өчен канын койган... Ә мин шул туганыма яхшылык эшли аламмы? Шуңа хакым бармы? Уйлап ятам — бар. Бар — и все. Бар... Тә-әк. Шуннан? Шуннан өченче көннең кичендә мин — Саратовта. Шуннан? Шуннан — шул (ул авыр сулады), кәкре хочешь — бөкре делаеш... Тагын бер айдан мин — өтермәдә. Мотоциклны саттык. Орден, медальләрне әти картка бирдем. Сакла, дидем... Мин — и вдруг! — өтермәдә. Минем начслужбы — фронттагысын әйтәм — моны ишетсә! Туп-туры бомбардировщикка утырып Казанга кайтып төшәр иде...

Зәкәрҗан авыр сулады. Бу тарихны хәтерләү аның рухын имгәтә, җанын каһәрли иде. Без дәшмичә генә урамга карап утырдык, Зәкәрҗанның да, минем дә ялга, авылга кайткан көннәр иде.

Калганын мин хәтерлим. Боларына Зәкәрҗан үзе кирәк тә түгел...

1948 елның язы. Авыл язгы чәчүне төгәлләде, заемны түләде. Әмма, ел авыр. Бакча китмәнләсе, бәрәңге утыртасы бар. Колхозда атлар җитми. Зәкәрҗаннар гаиләсендә дә бер зур мәсьәлә бу. Үзе ат җиккән кешеләрнең бу турыда борчыласы юк. Зәкәрҗанның үзеннән байтак яшь бер сеңелесе бар, ул кыз исә я урман эшендә, я юл эшендә, аны гел «разнарядка» буенча шулай читтә йөртәләр. Бакча китмәнләргә Зәкәрҗанның әтисе дә, әнисе дә карт инде. Ат җигүчеләр дә әрсезләнде: бер яртысыз яннарына да килеп булмый. Нишләргә? Авылга шул көннәрдә генә төрмәдән ачык хат (открытка) килеп төшә. Анда исә болай язылган (авылда открытканы укымыйча бирмиләр; капкасыннан керешли булса да, и ходаем, мине гөнаһлы санама, дип эчтән укынып булса да, открыткага күз төшерелә).

«Кадерле әти һәм әни, сеңелем Зөлхәбирә, сезгә ерак җирләрдә нахак бәла аркасында ятучы, но дә ләкин прораб булып акча эшләп ятучы улыгыз Зәкәрҗан күп сәлам җибәрә.

Әти, әни, конкрет эшкә күчик: инде яз житте, сезнең бакчаны эшкәртәсегез бардыр. Әти, син чуар йөрәкле кеше, мин сине беләм, син тагын, мин моны булдырам әле, дип көрәк белән бакчага чыга күрмә. Бүсерең кузгалыр. Инде күрше-күләндә ат җигеп, колхозда эшләүче егетләр, бакчагызны сөреп бирик, дип бик алҗытсалар, минем бер үтенечем булыр: бакчада иләнгән кәҗә тиресенең хромына төреп (Кукмара районы Ядгәрдә иләтеп кайткан тире) сигез мең акча күмелгән иде. Плуг белән эләктереп шуны харап итмәсәләр ярар иде. Бакчаны эшкәрткән малайга, акчаны таба калса, берәр йөзен җәлләмәгез. Исән булсак, безгә дә озак калмады инде, нахак бәлаләр аркасында прораб булып әллә никадәр акча эшләп йөрергә чит җирләрдә...»

Зәкәрҗаннарның бакчасын ул елны өч тапкыр сөрделәр.

Алдагы язга Свердловск ягыннан «М-72» мотоциклына утырып Зәкәрҗан кайтты. Рәвеш-кыяфәт нәкъ элеккечә иде. Киемнәр — шул ук,

хәтта бераз затлырак та. Кайтты, яз көне иде, авылда әлеге дә баягы мәшәкать — бәрәңге бакчасын казу мәшәкате бар иде. Нишләргә? Әтиәнисе тап-таза Зәкәрҗанга көрәк тоттырмакчы булып карадылар. Әмма егет каршы торды:

— Бу юл белән алга барып булмый,— дип ул кырт кисте. Артык сөйләшеп тормыйча, нидер планлаштыра, уйлана иде.— Европа,— диде,— Россия көрәк белән җир эшкәртми.

Шул көннәрдә генә авылга Райфо агенты килеп төшә. Гадәт буенча атын туарып, янгын сараендагы бүлмәгә ябалар, солы, башак бирәләр. Ат таза. Агент бер көн ята авылда, ике көн ята. Атны исә гел сыйлыйлар. Финагент та бал белән майда гына йөзә. Авылда итек басып, шуннан подоходный налог түләүчеләр күп, подоходный налогның күләмен билгеләү тулысынча финагент карамагында.

Колхозның бөтен аты тиргә батып кырда эшли: сөрәләр, тырмалыйлар. Язгы чәчү бик авырлык белән бара. Зәкәрҗан бер әйләнә янгын сараен, ике әйләнә. Эче поша. Үзенә дә инде эшкә урнашырга вакыт. Менә икенче көнне кич соң гына ул янгын сараена килә. Шау итеп килеп керә, каравылчы картны уята.

— Кая,— ди,— кунагың атын алып кайтырга кушты.

...Төнге караңгыда Зәкәрҗан арслан кебек таза ат белән бәрәңге бакчасын гөл бакчасына әйләндерә. Атка да бер аяк язарлык кына эш була бу. Моны берәү дә белми кала, тик иртәгесен өенә чәйгә кайтып барган каравылчы карт кына, Зәкәрҗаннарның күпереп яткан бакчасын күреп, эшнең нәрсәдә икәнен аңлый. Каравылчы карт аңа дәгъва белдереп караган икән дә, Зәкәрҗан аны кырт кискән:

— Безнең карт әти белән әни,— дигән,— ул бакчада кырык пот бәрәңгене көзен дәүләткә тапшыра. Мин үземне генә кайгыртмыйм, мин зурдан уйлыйм. Шәһәрдәге рабочий класска бәрәңге кирәк...

— Соң бит караклык була бу, энекәш,— дигән каравылчы карт.

Зәкәрҗан анысына да җавап тапкан:

— Каракныкын, — дигән, — бур урлаган: аны ходай турылаган. Ауфвидерзеен, Зиятдин абзый...

Зәкәрҗан шул көнне үк районга китеп барды.

Межрайбазаны житәкләрлек инициативалы кешене районда күптән эзлиләр иде. Зәкәрҗанны бер көн эчендә директор иттеләр дә куйдылар. Штат буенча тиешле ике тәгәрмәчле дәүләт мотоциклыннан ул баш тартты.

— Малай-шалай дип белдегезмени мине, мин үз машинам белән йөрим. Минеке, ичмаса, кая барып туктасаң да йөз кызартырлык түгел,— дип сөйләнде.

Зәкәрҗан район үзәкләре, шәһәр, тимер юл станцияләре арасында бу «машинасы» белән ду кучереп йөрде. Ул беркайчан да «мотоцикл» дип сөйләмәде, аныкы гел «машина» булды.

Авылга машина сүзе «Зәкәрҗан мотоциклы» мәгънәсендә кереп урнашты.

Бервакыт ул Казанга барганда шул машинаның бишегенә мине дә утыртты. Зәкәрҗан хәзер сак йөри иде, курыкмыйча утырдым. Эссе көн иде, Арча ашханәсенә туктадык. Кердек. Ул кара күзлеген һәм иләмсез зур перчаткаларын гына салды да, куеныннан китап зурлыгы бумажник чыгарып, тастымал кадәр йөзлекне буфетчицага сузды.

— Ике шешә лимонад,— диде ул, читкә караган килеш кенә.

Зур йөзлектән бирелгән сдачаны санамыйча гына куенына тыкты. Казанга килеп житкәнче шулай ике ашханәгә һәм бер-ике авыл кибетенә туктап, Зәкәрҗан йөзлекләр чыгарды. Кайда ике стакан квас, кайда компот эчтек. Минем фәкыйрь берлекләрне чыгарырга ул бөтенләй мөмкинлек бирмәде.

— Кешене кесәсеннән нинди акча чыгаруына карап бәялиләр,— диде

ул.— Син бервакытта да эре акчаны саклап йөртмә. Ул гел күренергә тиеш. Мин бит сдачаны теләсә кайсы кибеттә яңадан эреләндерәм. Кибетчеләр бик шатланып эшли аны. Чөнки көне буе акча ваклаулары үтенеп, аларның үзәкләренә үтәләр. Ә мин — на тебе!—эреләндерәм.

Шәп йөрүнең кайбер атрибутларын Зәкәрҗан миңа әнә шул сәяхәттә сөйләде.

— Менә синең әле яшь вакытың,— диде ул.— Әле синең барысы да алда. Егет кешегә әйбәт яшәргә, яхшы йөрергә кирәк. Бөтен мөмкинлекләр бар аңа. Менә мин тегеннән егерме биш мең акча белән кайттым. Урламадым, таламадым. Көн эшләдем, төн эшләдем. Юләр! Андый җирдән егерме биш меңсез дә кайтырга ярыймыни? Анда бит аракы юк, хатын-кыз юк. Кесәңдә акча булу — егетлекнең бер показателе. Аннары? Менә син, үскәч, бәлки берәр начальник булырсың. Әйтик, район үзәгендә. Килеп төшәсең авылга. Сиңа мөнәсәбәт каян башлана? Колхоз идарәсе янына син килеп җиткән моменттан. Җәяүләп, әлсерәп килеп кер. Велосипедта кил. Атка утырып кил. Машинада кил. Шуның һәрберсенә аерым бер мөнәсәбәт. Җәяүләп килеп кергән кешене бар дип тә белмиләр аны, белдеңме шуны?

Аннан, кызлар мәсьәләсе. Мин үзем байтак күрдем бу өлкәдә. Әмма шунысын әйтә алам: минем өчен елап йөргән кызлар күп булды, ну дә ләкин рәнҗеп елаучы булмады. Һи-и... Без йөреп тә карадык инде. Егет шундый булырга тиеш: урамнан барасың — каршыңа килгән кыз аягын саташтырып сөртенә. Без сөртендердек иңде яшь чакта. Хәзер олая барабыз... Менә син бик юк нәрсәгә гаҗәпләнәсең: имеш, өч төстә хром пальто алырлык акча каян? Имеш, өч пальто берьюлы нәрсәгә? Ә мин сиңа әйтә алам: хром пальтом өчәү түгел, берәү генә иде. Һәм мин аны ике-өч ай кигәч, Казанга барып химчисткада буятып ала идем. Аларга барыбер ич: бер барганда күзеннең явын алырлык итеп карага буятам, икенчесендә — кызылга. Сарыга да буяттым әле бер тапкыр. Халыкка нәрсә аңа? Халык ул химчистка белән эш итми, ә сөйли бирә: Зәкәрҗан тагын бер пәлтә алган...

— Һи-и,— дип көрсенеп куйды Зәкәрҗан.— Без йөреп тә карадык инде. Утыз дүртенче, утыз бишенче елларда Мәскәүдә «Метрополитен» төзүдә эшләдем мин. Колхоз җибәргән иде. Кайтам авылга, кич гармунга җырлап узам... Беләсеңме, нинди кушымталар бар иде безнең ул чакта?

Ах, метрополитен!
Яратам, ни хәл итим?

Шулай урамнан җырлап узасың... Аннары...

Ах, метро юллары —
Йомшак иде куллары.

Монысын күз атып йөргән кызыңның өй түреннән җырлап узасың. Син учти: күзең төшкән кыз сиңа пока отказ бирә. Но отказ бирәбирә синеке була бара инде ул. Йокламый ул. Син нәрсә әйтеп узарсың дип көтеп ята ул. Син шунда гордый гына җырлап узасың. Кемнең кулы ул — «йомшак иде»? Может ул, минем Мәскәүдәге кызымныкыдыр?

Крепостьне әнә шулай, Суворов әйткәнчә, чигенеп аласың. Но — чигенә белергә кирәк. Ераккарак киткәч тагын берне сибәсең:

Ах, метро, метро —
Бер күрешү ни тора...

Һи-и, без йөрдек инде, энекәш. Кызлар безне күргәч, күз карашларын түбән төшереп, бер генә җөмлә әйтәләр иде:

— Сез бик якын бер кешемне хәтерләтәсез...— Ә без моны аңлыйбыз: сине ошатам, дигән сүз ул. Сиңа ошаган бер кешесе дә, бер якыны да булмаган аның. Безгә ул сүзләрне күп ишетергә туры килде... Ә без чыннан да, хәтерләтә идек. Кое-кого...

«Машина»га капиталь ремонт кирәк икән, Зәкәрҗан аны кайтышлый Биектауда авторемонт мастерскоенда калдырды. Биектау станциясендә билетлар алып поездга кереп утырдык. Билет алганда Зәкәрҗан тагын бер йөзлекне ваклатты. Капчык күтәргән кешеләр ихтирам белән аның артыннан карап калдылар. Вагонга кереп утыруга Зәкәрҗан гимнастерка кесәсеннән күзлек алып киде дә газит укый башлады. Каршында фырт кына киенгән ике кыз бара иде. Шунда мин бер нәрсәгә игътибар иттем: Зәкәрҗан газитне бөтенләй укымый, укыган сыман гына бара. (Ахырдан тагын бер нәрсә ачыкланды: күзлек гади тәрәзә пыяласыннан икән.)

Ул елларда ревизорлар бик еш һәм күп йөри иде. Монда да шулай булды. Вагонның ике ягыннан планшеткалар аскан, кительле, кокардалы мәһабәт чибәр ревизорлар билет тикшереп килә башладылар. Вагонда һәммә кеше бер кат каушап ала. Билетың да бар, әмма нигәдер каушыйсың. Монда да шулай булды. Теге кызлар борчылды, мин дә билетымны суздым. Бары тик Зәкәрҗан гына газит каравын дәвам итте. Ревизор аның янына килеп басты да эндәште:

— Ваш билет, гражданин?

Зәкәрҗан шунда сискәнеп китте һәм күзлеген салып, күкрәк кесәсеннән кызыл каты тышлы кечкенә удостоверение сузды. Билет тикшерүче «извините» дип әдәпле елмайды да китеп барды. Кызлар алдында Зәкәрҗанның дәрәҗә кинәт кенә күтәрелеп китте, аңа кыеклап та, туры да карадылар, күз аттылар. Зәкәрҗан шуның белән бәхетле иде. Бу уенның мәгънәсен мин аңладым: поезд билетын ул Биектау станциясендә үк «удостоверение» дип алтын хәрефләр белән язылган буш катыргы эченә тыккан иде. Бу — теләсә нинди очракта да оттырышсыз уен икән. Ревизор удостоверениене алып ачып караса, аның эченнән билет килеп чыгачак иде. Ә тегенә, билетың булгач, шул җиткән. Зәкәрҗанга ярты вагон халкына күренерлек эффект ясагач шулай ук җиткән.

Шулай да Зәкәрҗанның өйләнү мәсьәләсендә «осечка» булган дип сөйләделәр. Чындырмы, ялгандырмы, аның кебек кешеләр турында, гадәттә, булмаганны да сөйлиләр. Ләкин чынга охшый: өйләнү мәсьәләсендә «осечка» бирү Зәкәрҗан кебек егетләр өчен гадәти бер хәл инде ул. Әнә нәкъ шул мәсьәләгә иң аз игътибар бирәләр алар... Ә Зәкәрҗанның эш болайрак булган: ул үз системаларындагы зур бер начальникның кызы белән танышкан. Кыз шәһәрдән, Зәкәрҗан авылдан. Кыз — шәп, укымышлы, чибәр, буйлы-сынлы; Зәкәрҗан — шәп, укымыш әлләкем булмаса да, шәп — вәссәлам. Әмма кызның авылга кайтасы килми, Зәкәрҗанның әти-әнисен ташлап китәсе килми. Анысын ул булдыра алмый. Шулай булгач? Шулай булгач, кала бер вариант:

— Бабай,— ди Зәкәрҗан әлеге начальникка (ул инде үзен кияү дип исәпләп, «бабай» дип эндәшә).— Менә без болай итик: безгә рөхсәт бир. Без язылышыйк. Кыз сездә яшәсен. Мин бит гел килеп-китеп йөрим. Аңа да рәхәт үз әти-әнисе янында, миңа да неплохо килеп-китеп йөрү...

Теге начальник, имеш, бик нык дулап Зәкәрҗанны өеннән куып чыгарган, ди. Ләкин арттырып сөйлиләрдер: еллар узды, Зәкәрҗан һаман шәһәр юлында командировкада йөрде, авылда хатыны күренмәде, булмады... Соңгы елларда ул «Доротдел»да начальник иде һәм сөйләшкәндә кешеләргә болай әйтергә ярата иде:

— Дөньяда юньле өч профессия бар: икмәк үстерү, умарта корты

асрау һәм юл төзү. Мин сугышка кадәр колхозда ат белән эшләдем, җир сөрдем, иген үстердем. Сугыштан соң балавыз җыйдым. Олайгач хәзер менә юл төзим. Монысы особо әйбәт эш: балчык дөньяда күп, ул «өстән чыкмый», аның белән эш иткәндә растрата булмый. Ә мин балавыз вакыйгасыннан соң андый эшләрдән бик куркам. Ну инде, мин бераз гына иртәрәк туганмын. Яшь вакытта укып, белем алып булмады. Ну дә ләкин, әгәр бүгенге яшьләргә бирелгән мөмкинлек миңа бирелгән булса, билләһи дип әйтәм, мин инде бүген я Антарктидада фәнни бер станция начальнигы булып эшлим һәм бөтен авылга посылка белән кит мае җибәреп яшим, или, на худой кәнис, мин бүгенгесе көндә БАМда балавыз, бал җитештерү комиссиясенең председателе булам. Белемсез калып харап булдым. Ну да ләкин, эшләдек, сугыштык, җиндек, яшәдек. Шәп яшәдек...

..Ул заманнардан бирле инде утыз елдан артык вакыт узган. Казан — Арча поездында әле дә кеше күп йөри. Арча ашханәсенең каршына мотоцикл белән әле дә килеп туктыйлар, вагоннарда әле дә гәзит укып йөрүче кешеләр бар. Колхоз идарәләренә әле дә булса районнан кешеләр килеп тора. Әмма Зәкәрҗан пенсиядә инде. Ул этисен-әнисен җирләгәч, ниһаять, шәһәргә күчеп килде, теге хатында аның ике баласы үскән икән, хәзер алар бөтен бер гаилә.

Зәкәрҗан мине танымый, шәһәр урамында мин аны күргәлим. Һәм аның яшьлеген сагынып карап калам. Ул олайган, әмма кыяфәт һаман шәп. Өстендә чия-кызгылт каккан тун, суык көннәрдә аягында эт тиресеннән эшләнгән унты, башыда полковниклар кия торган бүрек. Гомумән, аның картлыгы әйбәткә охшый. Мине аның картлыгы борчымый. Мине... үзебезнең якта шундый шифырт егетләр бармы икән, «Зәкәрҗан мәктәбе» әле дә яшиме икән диган фикер борчый. Зәкәрҗан бит «буш шәп кенә түгел, эшлекле шәп» иде. Ара-тирә мин авыл егетләре арасында мәһабәтлекне, горурлыкны күреп куанам. Нигә мәһабәт, горур булмаска? Син бит комбайнер, нефтяник, шофер, син — директор, зоотехник, председатель, агроном, ветеринар! Син яшь, таза, бәхетле! Син эш кешесе!

Ара-тирә Казан — Арча поездының вагоннарында мин Зәкәрҗансыман берәр егет күреп алам. Һәм шатланам: аның мәктәбе яши. Егет кеше мәһабәт булырга тиеш. Эре, эшлекле булырга тиеш. Тормышны эшлекле кешеләр алып бара. Имеш, Зәкәрҗанның бердәнбер сеңлесе Зөлхәбирә, абыйсы сугыштан кайткан елны мәктәпкә колхоз җыелышына килгән. (Клубның ремонтта вакыты.) Килсә — җыелыш башланган, президиумга моның абыйсын сайлаганнар, орден-медальләрен чыңгылдатып мәһабәт утыра икән теге. Зөлхәбирә өенә кайтышлый әтисенең бертуган сеңелесе — тәтәсенә кергән дә:

— Барып кердем мәктәпкә, карадым як-якка. И, тәтә җаным, безнең абыйдан да матур кеше юк,— дигән.

Абыйсы турында һәр сеңел шулай уйларга тиеш дип беләм мин.

Аннары, бераз тын алгач, Зөлхәбирә болай дип тә куйган:

— И тәтә җаным! Кызлар арасында — мин матур, егетләр арасында — абый матур.

...Иске радиоалгычка карап утырганда мин шуларны хәтергә төшердем.

## Герман җире яшел үлән

«Герман көе» безнең авылга кинәт килеп керде. 1941 елның көзендә аулак өйләрдә бер мәлне гел шушы көйне җырлый башладылар. Моның нибары өч җыры бар иде сыман. Тын гына шәл бәйләп утыручы

килен яки кыз бервакыт, күкрәк тутырып бер сулыш ала да, борын астыннан гына көйли башлый. Шуны гына көткән гармунчы да, гармун төймәләрен шапы-шопы китереп, бармак шудырып ала да эргәгә керә. Чын йөрәктән, күкрәк тавышы белән җырлыйлар.

Атландым атның биленә,
Киттем герман җиренәләй;
Герман җире яшел үлән,
Әллә кайтам, аллә үләм.

Җырның беренчесе тәмамланганда күп кешенең күзендә яшь була, чөнки «герман» сүзе ата-бабадан килгән зур бәхетсезлек, ятимлек, толлыкны аңлата иде. «Герман» диюгә авылның дүрт карты искә төште, болар — метр да егерме сантиметр биеклегендәге Әптел карт, ул гомер буе үзенең «Ярманда плин булып» ятканын сөйли иде, икенчесе — аз сүзле, чиста йөзле Хәнәфи карт — әсирлектә газап чигеп ятканда укымышлы егетләрдән танцыга өйрәнеп кайткан кеше һәм өченчесе — кызыл сипкелле, җирән сакаллы Хәйрулла абзый иде, анысы немец сүзләрен кыстырып сөйләп җанны өшетә иде. Хәер, дүртенче карт Насибулла абзый бар, ул исә география, тарих буенча гадәттән тыш тәгәл мәгълүматлы кеше — безнең күз алдында, элеккеге әсирдән бигрәк, зур укымышлы бер кеше буларак тора иде.

Теге җырны җырлаганда күз алдыннан бер-бер артлы әлеге картлар үтә. Берсе, кечкенә буйлысы, әсирлек газабыннан сытылган, изелгән; икенчесе герман көенә бии-бии әйләнә кебек; өченчесе — җирән сакаллысы — немецчә сүгенә, «доннер вайтер, доннер вайтер» дип ачулана сыман; дүртенчесе кулына күрсәткеч таягы белән тотып картадан Франкфурт, Магдебург, Гамбург дигән җан өшеткеч куркыныч исемле шәһәрләрне күрсәтә сыман иде. Җыр тагын күтәрелә.

Инде тол калган киленнәр күз яшьләрен яшереп тормыйлар, алъяпкыч итәге, яулык почмагы белән сөртеп алалар. Җырга гармунчы да кушыла:

Герман көен, герман көен,
Герман көен яратамлай,
Герман көйләренә җырлап,
Хәсрәтемне таратам.

Җырлаучыларның карашларында «герман»га карата нәфрәт белән бергә аңлашылмаган сорауга җавап көтү дә сизелә иде. Нинди халык бу герман? Ник гел безгә тия ул? Нәрсә кирәк соң аңа? Әнә бит Әптел абзый сөйли, аларның өйләрендә кеше санынча «бисәпилке» бар иде. Ә безнең авылда нибары бер кешедә. Нәрсә җитми бу явызларга? Ник безнең авылның ирләрен кыралар болар, торып-торып?

Герман көе бу сорауларга җавап бирми иде.

Авылда сугыш вакыты дип торылмады, җырлы-биюле бәйрәмнәр уздырып барылды. Шуларның берсе һәр җәйне — язгы кыр эшләре беткәч сабантуй итәсе көннәрдә клубта уздырыла иде. Моның тәртибе болай: клубта җыелыш ясала. Халыкара хәлләрдән соң һәр колхозчының быелгы компаниядә ничек катнашканлыгына бәя бирелә. Аннан — алдынгыларны бүләкләү. Бу — бер дә уен түгел, беренче ведомость белән яңа арыштан аванс таратканда, хезмәт көненә йөз граммнан гына бирсеннәр — бер кило, яки кило ярым он дигән сүз ул. Хәер, беренче авансны ун, егерме граммнан бирәләр иде. Җыелыш бетүгә клуб ишеге алдына өстәлләр куелган, аш китерелгән була. Колхоз хисапчысы, табельщигы, тагын берәр активист исемлек буенча аш бүләләр.

— Зиннәтова Мәрфуга! Өч җан.

Табельщик Мәрфуганың агач табагына өч чүмеч өйрә сала, хисап-

чы яшел эмальле зур табактан өч кисәк ит алып, «чап» итеп Мәрфуга табагына ыргыта.

— Хисмәтова Зәйтүнә! Алты җан...

Әмма ирләргә монысы кызык түгел. Ирләр сугышка яраксыз, аксак-туксак, чукрак-чулак һәм сугыштан яраланып кайткан кешеләр. Болар — төшереп алганнар, чөнки бер читтә исемлек буенча чи аракы сатыла.

Ирләр сүгенә-сүгенә эчәләр, дүрттән өч өлеше кое суы, диләр. Ирләр кәефле. Авыр эштән соң шулай бер көн мамык коеп, ачлык җәфасын, сугыш хәсрәтен онытып торалар. Авылга сугыш афәте белән бергә аракы керде.

Иң кызганы — Хөрмәтша. Яшьтән чукрак. Колагы да, файдага ярамагач, баш сөягенә таба ятып беткән. Ул бик кычкырып эндәшсәң генә ишетә. Ә болай — дөнья белән алыш-биреше юк. Үз көенә яши бирә. Колхоз эшендә — карусыз. Борчак чапканда иң күп эшләгән шул. Ничек ирешәдер ул аңа — берәү дә белми. Югыйсә, чалгы муенына чорналган эт эчәгесе катыш борчак саламын алып ташламый, чалгысын күтәреп шуның борчагын ашап бетергәч кенә эшкә тотына. Ял итәргә утырганда сөйләргә ярата. Гомер буе кеше авазын начар ишеткәнгә, кайбер авазларны гел үзенчә чыгара.

— Минем колак ишетми пит,— ди.— Вак корт пар анда. Каты тәмәке тартсаң, коела да петә. Перазга ачылып тора. — Каты тәмәке нинди була ул, дип мең бәла белән сорыйсың.

— Каты тәмәкеме? Самосадны чапканда пераз чия потагы, имән яфрагы кушып җибәрәсең. Шуны тартканда төтенен йоткач, пераз күзләрне йомып, порынны кысып торасың. Шуннан колак эче кымырҗый пашлый. Шуннан коела тегә. Кәзит кагәзенә коям мин аны...—Ә бүген ул кызган башын кыйгайтып алган да, сигез телле тальянкада сиптерә. Ул бер генә бию көен белә. Ул көй «чабата» көе дип атала. Ул көйне дөньяда бары тик Хөрмәтша абзый гына уйный белгәндер. Музыка фольклоры фондларында бу көй сакланмаган булса, безнең культура мирасыбызның зур югалтуы була бу. «Чабата» көе бик экспрессив иде һәм Хөрмәтша абзый моны уйнаганда бии белмәгән кеше дә үзеннәнүзе селкенә башлый иде. Бик кызганыч — әмма нишлисең? Сүз белән көйне биреп булмый. Һәрхәлдә, Хөрмәтша абзый бөтен сугыш афәтен, хәсрәтен онытырлык итеп дер селкетеп шул көйне уйный һәм яшен-картын биетә иде. Бу көйдә урман шавы да, удмурт ритмы да, тагын әлләниләр бар иде. Шунысын гына әйтә алам: бала вакытта миңа бу көй — иләк өстенә куеп, ду кучереп кайгы-хәсрәт иләү булып күз алдына килә иде.

Хөрмәтша абзый уйный, бу көйгә өч кеше берьюлы бии: болар — авылның иң оста биючесе, сугыштан кулы яраланып кайткан агротехник чуар Нигаж, үпкәсе авыру сәбәпле сугыштан калган, дөньяга мәҗлес өчен туган алтын куллы тимерче Нотфый; ике сүзнең берендә русча сүгенү сүзе катыштырып, алланы искә ала торган шахтер Баязит. Ул да гармунчы, гомер буе күмер чапкан, бөтен семьясы оккупация зонасында калган да, үзе монда җанына урын таба алмыйча йөри. Күз начар күргәнлектән сугышка җибәрмиләр. Баязит гел сүгенә иде. Ә бүген тиләләрчә бии, клуб алдындагы чирәмне авыр дагалы күн итеге белән таптый.

Бераздан чабата көе туктый, гармунны Баязит ала. Аныкы әлләнигән чит-ят көй уйнап җибәрә. Менә уртага җирән сакаллы, кызыл сиптелле Хәйрулла карт чыга. Хәйрулла карт гомер буе фермада каравылчы, авылда бер аның гына йорты — землянка. Аның бабалары мари булган диләр, хатыны — мөселманлыкка чыккан керәшен. Хәйрулла карт, җирән сакалын селкеп, уртага кереп бөтерелде, кулларын җәеп иңбашларына сукты да кычкырып җибәрде:

— Кикри-ку-ү-ү-к!
Аннан, бугазыннан каты тавыш чыгарып, нәкъ әтәч төсле уылдап алды.
— Мин,— диде,— ярманда пленда вакытта иптәшләрне гел шулай көлдерә идем. Әле конвойлар да көлә иде.
Шулай диде дә, әйләнә эчендә биеп китте — бармакларын шартлатып, чүгәләп, бөтерелеп алгач, җырлап та җибәрде.

Сербиянка, сербиянка,
Сербиянка модная.
Бери ложку, ешь картошку,
Не сиди голодная.

Аннан бармак шартлатып, аягын аякка бәргәләп йөренде, тагын уртага тукталды.

Сербиянка, сербиянка,
Сербияночка моя...
Кәбестә шулпасы эчеп
Симергәнечкә моя.

Халык ду килеп көлде, шаулашты. Бөтен кешенең йөзеннән хәсрәт китеп торды. Тик бер читтә генә югары оч Шиһабетдин хатыны кайгылы йөз белән карап торды. Аның ире — каты күңелле, миһырбансыз, тәмсез телле ире Шиһабетдин — Ижевск шәһәрендә корал заводында эшли иде. Ул аннан качкан, Можга урманында тотылган. Хәрби трибуналның хөкеме каты һәм бер төрлерәк була иде, моның нәтиҗәсен әлегә белүче булмаса да, чамалыйлар иде. Бәлки хөкем инде җиренә житкерелгәндер.
Көтү кайтыр алдыннан гына халык җитдиләнде. Бәйрәм тәмам. Шул вакыт гармун яңадан Хөрмәтша кулына керде һәм ул башын кыйшайтып герман көен сыздырып җибәрде. Бу җырны картлар, ирләр һәм яшүсмерләр тавышы күтәреп алды.
Герман көе авылда 1946 елга кадәр яшәде. 1946 елның май-июнь айларында авылга әллә каян гына «Шомыртым» көе килеп керде. Әле беркемдә дә радиоалгыч юк иде. Атна саен бер-бер артлы кайткан фронтовик егетләр су буйларында, урманнарда, болында печән чапканда күкрәк киереп гел шул көйне генә җырладылар. Өлкән яшьтәге хатыннар болай диделәр:
— Без яшь чакта, ярман сугышы беткәч, бу көй бер тапкыр җырланып алган иде инде. Тагын чыкты бит. Менә гаеш-тамаша,— дип сөйләнделәр.
Әмма герман көе дә аваз биргәләп куя иде. Бер вакыйга истә калган: Баязитның энесе Рамазан (халыкта аны Рамый дип йөртәләр иде) шул көннәрдә генә Берлиннан кайтып төшкән иде. Гармунчы дисәң гармунчы шул, сугыш беткән көннәрдә генә кулына бер гармун төшергән. Аны тегеләй дә, болай да тартып карадылар, әмма ни чабата көен, ни герман көен уйнарга ярамады — бакалары бик күп, тавышы тартканда бер төрле, эткәндә икенче төрле чыга: шуңа күрә бу үги гармунны, гел кызгылт сөяктән гоҗа коелган булса да, кадерләп тотучы булмады. Җәйнең яңгырлы, пычрак бер төнендә Хөрмәтша, Баязит, Рамый кәефләнеп утырганнар. Энекәш сугыштан исән кайткач, ансыз гына ярамый бит инде. Тимерче Нотфый боларның җырлап утырганын ишетеп, чолан ишеген каккан. Нотфый — алтын куллы мастер, әмма инде берәр җирдә келт иткән җыр, бию, гармун авазы ишетелдеме — аны тапмый калмый һәм һәрвакыт көләч йөз белән керә:
— Юк, юк, егетләр, узмыйм, әле сезне алмага гына килдем. Ганди (Гандәлиб исемле хатынын яратып ул шулай әйтә иде) апагыз итле аш салып калды, сезне алып кайтмасам, минем буранны очыртачак ул,— дип сүз башлый иде.

Нотфый гел шулай кунакчыл булганга, Гандәлиб апаны борчымыйлар, хәер моны ул белми дә кала иде. Кузгалып мәшәкатьләнгәнче, Нотфыйның үзен генә түргә утырталар иде.

Бу төнне дә шулай булган. Нотфый килеп кергән, шактый утырганнар һәм немец гармунын алып караңгы тайгак урамга чыкканнар. Чыкканнар да, урам уртасыннан герман көенә җырлап узмакчы булганнар. Ул кичне аргы якта гел ишетелгәләп торды.

Атландым атның биленә...

Әмма, күпме генә башламасыннар, очына чыга алмадылар. Караңгы урам уртасында былчырак изеп йөри торгач, ахрысы, үги гармунны Нотфый алган. Ул да бераз гармунчы, ләкин гомер буе тимерчелектә авыр чүкеч тотып, тимер әвәләп, аның куллары бирчәеп, мунча ташыдай катып, ярылгалап беткән иде, шуңадыр күрәсең, ул да уйный алмаган. Лыгыр-лыгыр тартылган үги гармунның тавышы бервакыт тынды, караңгы урам уртасында Баязитның сүгенгәне генә ишетелде. Һаман русчалап алланы телгә ала иде.

— Нәрсә пар? Нәрсә пулды?— дип Хөрмәтша агай да кызыксынып карады, әмма җавап тавышы ишетелмәде. Тик бераздан гына (ахрысы, былчырактан тора алмый ята) Нотфый тавышы ишетелде:

— Рамый! Бояз! Гармунның яртысы кемдә? Кемдә дим?! Ярты ягы — Нофида. (Кәефе гадәттән тыш яхшы булганда Нотфый абзый үзен өченче затка куеп сөйли башлый һәм исемендәге «т» авазын төшереп калдыра, бәхетле авызның аны әйтеп мәшәкатьләнәсе килми иде).

Үги гармун әнә шулай герман көен чыгара алмыйча дөньядан китте. Кызганыч! Безнең моңны чыгартып карарга иде аңа бер.

## Яшьтәш! Бер сөйләшеп куныйк...

Яшькә ул миннән бер-ике елга өлкәнрәк иде, әмма беренче тапкыр авыл урамына мөстәкыйль рәвештә чыккан көнне мин аны очраттым да, шундук дуслаштык та. Бу дуслык без мәңгегә аерылганчы — кырык ел буена дәвам итте. Мин җырларга яратам, ә ул — гармунчы иде. Биш яшеннән тальянкада уйнарга өйрәнде, ә сигез-тугыз яшьтә без, күзге коры, караңгы кичләрдә, олы егетләргә охшарга тырышып, тыныч урамнардан җырлап уза идек. Мәктәп оештырган концертларда мин декламация сөйлим, ә ул, артистларча чыгып утырып, көмеш телле тальянда «Алмагачлары» көен уйный иде. Аның ул гармуны егерменче елларда, ат чабышында аты беренче урынны алган өчен, сабантуйда әтисенә бирелгән бүләк иде. Ул гармунны карт гармунчылар әле дә таба алмыйлар: сөйләүләренә караганда, бу гармунны минем яшьтәшнең хатыны аерылышкан вакытта үзенең нинди зур байлык алып калганын белмәгәндер, биш-ун тәңкәгә Сорочига алып чыгып саткандыр дип уйлыйм.

Ә яшьтәш — табигать баласы — артист иде. Җиде класстан ары укымады, әмма аның табигатендә эстрада артисты, драма артисты, язучы таланты — тагын әллә ниләр бар иде.

Утыз-кырык еллар узгач кына мин аның җанында, рухында язучы таланты булганын аңладым. Соңгы заман әдәбиятында минем иң яраткан әсәрем В. Шукшинның «Срезал» дигән хикәясе. Анда авылның бер демагогы Глеб дигән кешенең шәһәрдән кайткан укымышлыларны кәкре каенга терәтеп баруы турында языла. Бу хикәяне укыганда минем күз алдында гел яшьтәш тора. Аның исемен кыскартып Рәкыйб

дип йөртәләр иде, әмма минем өчен ул гел Габдерәкыйб булды, мин аның исемен беркайчан да кыскартмадым. Безнең авылда утыз дүртенче еллар тирәсендә ниндидер йомыш белән Арчага барган яшь егетләр, төнлә буранга очрап, Казыйле эскертендә кунып чирләп кайтканнар иде. Арадан берсе — Шәмгәрәй дигән егет — шул чирләүдән озак кына ятып култык таягына калды. Утыз җиденче еллар тирәсендә алар гаиләләре белән язылып читкә киттеләр. Сугыш башланган елның декабрь аенда әниләре кайтып төште дә такта сугылган тәрәзәле йортларын ачты, кырык икенче елның язында култык таяклы Шәмгәрәй дә кайтып житте. Без малай-шалайга Шәмгәрәй үзен фронтта яраландым, лейтенант идем, дип сөйләп ташлады. Без ышанган сыман кебек иттек, әмма Габдерәкыйб монда бер алдау сизде. Бездән башка гына Шәмгәрәй янына барып, ул аннан сугыш хәлләрен сорашкан. Шәмгәрәй, табигый инде, бернәрсә дә сөйли алмый икән. Яшьтәш исә аның саен нечкәртә, сораша икән.

— Шәмгәрәй абый, чүтеки, ничек яраландың соң? — дип үзәгенә үтә икән. Шәмгәрәйгә нәрсә кала?

— Мин,— ди — бернәрсә хәтерләмим. Без атакага кергәндә чурный туча булып фашист аэропланнары килде дә бомба ташладылар. Шуннан соң мин — без память.

Кырык икенче елның җәендә, яшьтәш кичләрен безне җыя да, Шәмгәрәйләр капка төбенә алып китә торган булды. Барабыз. Шәмгәрәй, бичара, култык таякларын коймага сөяп куйган да, бүрәнә өстендә тәмәке тартып утыра. Барабыз, янына утырабыз, яшьтәш исә безгә күз кысып ала да, сүз башлый.

— Шәмгәрәй абый, ул сугышта да инде... Ничек исән калырга кирәк... Баш өстеңә эсңәрәт төшсен дә. Әле дә исән кайткансың, ә!

Шәмгәрәй тамак кыра, тирән итеп тәмәкесен суыра, без исә тын да алмыйча тыңларга әзерләнәбез. Яшьтәш активлаша:

— Шәмгәрәй абый, ничек булды? Курыктыңмы? Монда кайтып бу капка төпләрендә утырырмын дип уйладыңмы фронтта вакытта (безгә күз кысып ала)?

Шәмгәрәй түзә алмый, төпчегенә төкереп таптый да, авыр сулап куя.

— Мин үзем мало что хәтерлим. Без атакага күтәрелдек, мин взвод командиры — алда. Шуннан карыйм — чурный туча булып аэропланнар! Бервакыт — бух! И мин — биз память. Уянганда — госпитальдә. Аякны вич чорнап бетергәннәр.

Ул елны яшьтәш безне җәй буе Шәмгәрәйләр капка төбенә шуны тыңларга алып йөрде. Шукшин бу турыда менә дигән бер хикәя язар иде.

1950 елның көзендә без армиягә китәргә җыендык. Гадәт буенча, китәсе егетләр Октябрь бәйрәме көннәрендә «сөрән сугалар», ягъни бер-берсенә җыелышып кунакка йөриләр. Сый — бер табак кабартма, коймак, сумса, сирәк кенә бәлеш һәм ике-өч чирек ачы бал. Аракыны әле өйгә кертү юк, хәер, без аны эчә дә белмибез. Хәтерлим, башта бездә утырдык. Аннан яшьтәш алып китте. Утырган җирдә берәр стакан тәмле ачы бал эчәбез, ярты кабартма яки сумса ашыйбыз да, рәхмәт әйтеп чыгып китәбез. Әле тәмәке тартмыйбыз, безгә эчү дә кирәк түгел, әмма кергән җирдә без — никрутларга игътибар һәм өстәл өстендәге ризык-нигъмәт кирәк. Йөри торгач төн җитте, инде таралышсак та була иде, шунда гына бик нык ашыйсы килгәнне сиздек. Их, күсәбәсе белән ит ашарга иде хәзер — мал суйган көннәр бит. Шунда яшьтәшнең фантазиясенә юл ачылды. Безнең яшьтәшләрнең берсе әллә хаталык белән, әллә явыз ният белән, колхоз ашлыгын урлауда гаепләнеп ерак җирләргә озатылган иде.

— Әйдә,— ди яшьтәш,— Бибиҗамал апайлар бүген генә тана суйдылар. Кереп хәлен белик. Чуҗтәки яшьтәшнең әнисе бит...

Караңгы төз лапастан, гармунны кысып, ярым караңгы өйгә барып керәбез. Безне теге ерактагы яшьтәшебезнең абыйсы каршы ала:

— Һай, егетләр, сезмени бу? Әле җырлап узган сезмени? Әрмиягә китәсезмени? Һай, минем энекәш кайларда ята бит! Ул сезнең белән шулай йөрер иде бит, бәхете булса...

Ул шулай йомшады да, почмак якка чыгып китте. Мыдыр-мыдыр әнисе белән сөйләшә башлады. Мич башындагы ниндидер бер савытны чайпалдырып карады, табак-савыт тавышы чыгарды. Ләкин әнисе мыдырдады. Бүлмә тактасы аша бу безгә дә ишетелде.

— Кит аннан!.. Җөрәгемне бозма. Нишләп мин урамнан кергән саяк-сындыракны сыйлыйм! Каян чыккан гадәт ул?

Миңа бик кыен булып китте. Тиз-тиз җыенып, төз лапас астына чыгып киттек. Тик яшьтәш кенә күренмәде. Бераздан, кыенсынып кына мин өйгә кердем; яшьтәшне алып чыгып китәргә кирәк иде. Ит безнең үзебездә — табак белән! Безнең әни бер сүз әйтмәячәк. Кердем — яшьтәш юк. Юк, вәссәлам! Аптырап калдым. Тыңлыйм — почмак якта берәү елый. Тыңлыйм — яшьтәш. Мин тиз генә шунда кереп киттем. Керсәм, күрәм: яшьтәш Бибиҗамал апаны кочаклаган да, үкереп елый.

— Бибиҗамал апай! Төнлә төшләремдә күреп уянып китәм! Габидулла минем иң якын дус иде бит! Кайларда вәйран булып йөри бит! Әле менә хәл белергә кердек. Егетләр әйтә, кермик, борчымыйк, диләр.

Мин куркып калдым: егерме яшьтә исерек кеше буламыни! Бу нинди гадәтсезлек? Яшьтәшне суырып алдым да, төз лапас астына алып чыктым.

— Син нәрсә? Әдәм мәсхәрәсе!— Ләкин караңгыда яшьтәшнен елмайганын тойдым.

— Тавышланма! Барысы да хәл ителде.

Биш-ун минуттан без өстәл өстендәге табак белән итне, мактыймактый, кирәнләп сыптырып утыра идек инде.

Дөресен әйтим, бу ризык минем тамактан үтмәде. Әмма, нишлисең? Яшьтәш — артист. Тукай үзенең замандашы журналист һәм җырчыга әйткәнчә — «Плохой артист!»

Күпмедер еллар узгач яшьтәш чирләде. Мин флоттан хезмәтне тәмамлап кайтканда ул инде дөнья йөреп (шахтада эшләп, комбайнер, шофер булып), авылга кайткан һәм җәйнең эссе көнендә тире жилет, киез итек киеп бакчада эшли, йортта абыйсының яшь балаларын карый иде. Аңа каравы кызганыч иде. Әле кайчан гына бит! Нибары егерме ел элек без — ядрә шикелле ташбаш малайлар — күзгә коры төннәрдә, олы егетләргә охшатып, тып-тын урамнарда гармун белән җырлап йөри идек. Ә хәзер... 26 яшьлек егетнең кулында яшь бала, абыйсы җиңгәсе баласы. Бөтен кеше эштә, ә ул бала карый. Тирбәтә, кулына ала. Мин моны күзәтеп утырам, ә ул безнең музыкаль яшьлекне сагынып сөйли. Әнисе мал карап йөри, ара-тирә кереп мичкә утын өсти, яшьтәш исә, әнисенең беренче оныгын күтәреп «вә-вә» дип көйли, әнисе тыштан кергән арада эмоцияләргә бирелә:

— И-и-и, сеңлем, яратам бит мин сине! Үчтеки, үчтеки!— баланы түшәмгә чөеп уйный. Мин моңа сокланып карап торам, ләкин йөрәкне нидер кисеп ала: авыру булмаса, шулай кеше баласын көйләп өйдә ятар идемени ул!

Ул арада аның әнисе канәгать чырай белән карап ала (оныгын яраталар!) һәм чиләк-табак күтәреп маллар янына чыгып китә. Яшьтәш исә дыркылдап ябылган ишеккә карап ала да, чыраен тиз генә үзгәртеп, мич янына килә һәм:

— У-у-у... Корт чаккыры!— дип куя. Аннан, миңа карап, күз кысып

ала. Мин барысын да аңлыйм: бичара, авыру булмаса, егет башы белән бала карап ятар идемени ул! Аңа бит «мин өйдә артык кашык түгел, мин дә хезмәт итәм» дигән нәрсәне исбатлау өчен генә кирәк ул «үчтеки-үчтеки!»ләр. Ә баланы ярата үзе...

Авыру булса да, бераздан ул фотограф һөнәрен үзләштерде. Район газетасына фотокорреспондент булып урнашты. Күңеле түгәрәкләнде. Миннән башка бөтен кешене сүгәргә ярата иде.

— Фотография — сәнгать ул, сез аны аңламыйсыз һәм аңламаячаксыз да...

Аның рәсемнәре район газетасыннан тыш Казанда чыга торган барлык газета-журналларда да басылдылар. Яшьтәш үзенә культуралы, интеллигентларча мөнәсәбәт таләп итә башлады. Авыл халкына нәрсә? Редакция машинасы белән авылга, фермага үзебезнең авыл егете Габдерәкыйб кайтып төшә.

— Ә-ә-ә, кайттыңмыни?— диләр.— Кемнәрне төшерәсең? Әйдә, безне дә төшереп чык әле.

Яшьтәш моңа рәнҗи. Нишләп алай йөрсен ул, аның бит редакциядән, ниһаять, партия райкомыннан алган заданиесе бар! Ул бит корреспондент! Аңламыйлар, наданнар!

Яшьтәшнең редакция машинасына утырып задание белән колхоз фермасына — урман буена килгәнен хәтерлим. Мин ялга кайткан жирдән фермага кергән идем. Машинадан райком инструкторы, район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы чыкты, иң ахырдан беретка кигән, кара күзлекле, фотоаппаратлар аскан яшьтәш күренде. Савымчылар, ферма мөдире белән сөйләшү китте. Яшьтәш бик вәкарь белән генә экспонеметрын көйли иде. Шул вакыт савым аппаратын караучы механик — шулай ук безнең яшьтәш Нурмый килеп чыкты, тельняшка кигән, куллары майлы иде. Фотоаппарат аскан яшьтәш янына килде дә, авылча гына итеп кулын сузды:

— Нихәлдә тагын, Гаптыр,— дип кесәсеннән «Прибой» чыгарды...

Машина китәр алдыннан яшьтәш бик рәнжүле тавыш белән миңа зарланды.

— Юк инде, малай, булмаса-булмый. Я инде, үзең уйлап кара: нинди «Гаптыр» булыйм инде мин аңа? Мин бит район вәкиле! Мин бит сәнгать кешесе! Әйтсен ул шулай дип авылда, мин капка төбендә утырганда — ялга кайткач. Ә бит мин монда — эштә! Юк инде, малай, кермәсә-керми инде кешегә аң... Я, нинди Гаптыр инде мин аңа...

Яшьтәш өч-дүрт ел эшләгәч, авыруы көчәеп, пенсиягә чыкты.

Берсендә — мин ялга кайткач дуслар килделәр дә, бүген ял көне, бездә сыра бар, балык бар, әйдә урманга барып утырыйк, диделәр. Мин үз гомеремдә бер генә тапкыр да авылда яшьтәштән башка беркем белән дә күңел ачып утырмадым. Тамагымнан үтми иде. Шуңа күрә машинаны яшьтәшләрнең капка төбенә китереп туктаттык. Машинада яшьтәш белән бергә эшләгән редакция хезмәткәре дә бар иде. Кердек — ишегалдында печән кабартып йөргән яшьтәшне күрдек. Өстендә телогрейка, аякларында олтанлы итек иде. Тымызык көнне тырма тотып, бөтнек, кырлык үләне, кура җиләге исе килеп торган урман печәнен кабартып йөргән яшьтәш ничектер картларга охшап калган иде.

— Мин бара алмыйм,— диде ул мөлдерәтеп миңа карап.— Менә, ахири, йөрәгемне тотып кара.— Мин аның йөрәгенә кулымны куеп, эсселе-суыклы булдым. Ватык арба, ватык мотор. Ул баз өстенә кереп китте дә, ысланган зур балык күтәреп чыкты.

— Минем өчен дә сөйләшегез! Минем өчен дә бер стакан сыра эчегез! Минем өчен дә имән төбенә ятып бер аунагыз...— дип күз яшьләренә буылды. Без зур газап хисләре кичереп машинага кереп утырдык.

Икенче тапкыр без аның белән житмеш беренче елның пычрак-каткак, бозлы-яңгырлы ноябрь аенда очраштык. Безнең әни үлгән иде һәм без, татар халкының гадәте буенча, кеше йортында кунарга мәҗбүр идек. Чакырып килүченең исәбе-хисабы булмады, әмма мине яшьтәш алып китте. Әнисе аш әзерләгән, чәй шаулаткан, урыннар җәйгән иде. Сөйләшеп сүз бетмәде. Менә бервакыт ятарга җыендык. Әнисе миңа урынны иң кадерле җиргә — түр йорттагы йомшак диванга әзерләгән иде. Ятар алдыннан яшьтәш сабый балага әйләнде дә калды.

— Ән-ни!— диде ул иңрәп.— Ән-ни! Яшьтәш белән бергә куныйк! Бер сөйләшеп калыйк... Яшьтәш, бер караватка ятыйк! Гомергә истә калсын.

Һәм без бер караватта йокладык. Миңа 41, аңа 43 яшь иде. Ул минем кулымны үзенең ватык йөрәге өстенә куйдыртты да, балаларча мине кочаклап, төне буе сөйләшеп чыкты. Минем өчен ул бик кадерле кеше иде — без сугыш вакытындагы авыр елларны хәтерләдек.

...Алар таза тормышлы, запаслы кешеләр иде һәм кырык беренче, кырык икенче елларның ач, салкын кышында күрше авылдагы мәктәпкә барышлый, бер дә юл өсте булмаса да, мин аларга кагылып уза идем. Яшьтәш инде киенеп беткән, сумкасын аскан, теге йомыш, бу йомыш тапкан булып, өйдә йөренгәләп тора. Борынны тартып мин килеп керәм. Керүемнең сәбәбен без икәү генә беләбез. Мин керүгә яшьтәш җанлана төшә. Почмак якта мич алдында эвәрә килеп йөргән әнисе белән сүз куерта:

— Әни, безнең теге меринос сарык бүген көндез бәтиләмәгәе. Бая ашарына салганда мин аның җиленен тотып карадым.

Шул арада кучкардан бүлмә ачкычын алып, миңа күз кысып ул өй алдына тая. Күз ачып-йомганчы бер телем ипи алып кереп минем кесәгә сала, сүзен дәвам итә:

— Көндез күз-колак бул инде син, әни, аңа (миңа тагын күз кысып ала)...

Аннан без ике чакрымлы араны йөгерә-йөгерә узабыз. Ул ипи телемен мин ничек онытыйм?

— Безнең эти шулай артист иде,— дип искә ала яшьтәш сугышта үлгән әтисен.— Кечкенә вакыт, әле́дән-әле Пауал тегермәненә йөрергә туры килә, миннән олы абый бар, ни өчендер, тегермәнгә аны түгел, мине йөртәләр. Аш ашыйбыз. Әти ит бүлә.

— Гапдрәкыйб улыма итнең зуррагын бирим әле, аның тегермәнгә төшәсе бар иртәгә,— дип минем алга бер кисәк ит куя. Күреп торам, итнең иң зур кисәге абыйга эләгә, белеп торам инде, әти һәркемнең яшенә карап бирә. Әмма, нишлисең инде, күз алдында «зурысын бирәм» дигәч, бер хәлең дә юк, риза буласың, иртәгесен пот ярым-ике пот арыш салынган капчык арбага куелган — каршы сүз әйтеп булмый...

— Мин,— ди яшьтәш,— матур сүз, тәмле сүз яратам. Сикертән Хикмәтулла абыйны беләсеңме? Җәйнең матур көнендә кәеф кылып кибет баскычында сөйләшеп утыра. Андагы мөлаемлек, андагы сөйкемлелек. Бераз гына төшергән була. Эшләпәсен күзенә басыбрак кигән булса — бел дә тор — кәефле. Редакция эше белән узышлый янына туктыйм, исәнләшәм. Кибеткә керәм. Ул — минем белән. Сораша, якын итә. Менә бит, малай, бер дә исем белән дәшми, әтине кушып сөйли. Миңа «Низамов» дип кенә дәшә. Әти исемен телгә ала. Минем күңел йомшый, әти искә төшә. Менә, малай, шунда саранланып кара инде син. Ә бит белә теге, ул — психолог. «Низамов» ди, зурлый — юмартланмыйча кара син. Ул да аңлый, мин дә аңлыйм — нишлисен?

Яшьтәш белән соңгы очрашу 1972 елның яңа елын каршылаганда — шәһәрдә булды. Ул врачлар якынрак дип, кышын Казанда уздырасы итте.

Яңа ел каршыларга ике сәгать кала, телефон чылтырады. Таныш, мөлаем тавыш иде.

— Яшьтәш! Мин сезгә килим... Миңа берни дә кирәкми, синең янда утырсам — шул җиткән.

Һәм ул безнең мәҗлестә «Боржоми» эчеп утырды. Җыелган барлык кунаклар да кунарга калдылар — урын-җир җиткерерлек түгел иде. Яшьтәш ишек янындагы элгечтән үзенең пальтосын алып килде.

— Җәйик шушында идәнгә, сөйләшеп ятыйк бер,— диде.

Без минем пальтоны җәеп, аның пальтосын бөркәнеп яттык. Очрашуның соңгысы икәнен икебез дә чамалый идек.

Мин еш кына архивымны актарам да, «хатлар» дигән папканы ачам. Анда яшьтәшнең авылдан, районнан язган хатлары. Гел җылылык, гел кайгырту:

«Яшьтәш! «Социалистик Татарстан»га шушы рәсемне кертеп чыга алмассыңмы? Шәех Зәбировның үз кулына тапшыр. Заказ иде. Анда җибәрсәм, хатлар бүлегендә озак ятар дип куркам.

Кәефем әйбәт, әлегә югославский дару белән йөрәкне терәп тотып торалар. Сине сагындым...»

Ул үлгәч, безнең авыл ятим булып калды. Кабергә сүз төмен белгән җор күңелле бер замана баласы кереп ятты.

## Черемховода су кызыл

Насибулла картны авылда Насый дип йөртәләр. Насибулла абзыйдан берөзлексез информация коелып тора. Ул үзе янача укый-яза белми, әмма хәтер! Сәләт! Андый сәләт белән соңгы заманда туган кеше һичшиксез фәннәр Академиясенең член-корреспонденты булыр иде.

Яшь чакта ул бәхет эзләп Стахеевларга килгән, Себер якларында, Анжерка, Кизил, Черемхово тирәләрендә булган. Беренче бөтендөнья сугышында германга әсир төшкән. Барын, күргәнен генә сөйли. Без, малайлар, ул сөйләгәндә көлешәбез, чөнки сөйләгән сүзенең дөреслеген тикшереп караганыбыз юк, шомарта дип уйлыйбыз. Аны тыңлап үстек, егет булдык. Җае чыкканда үзе югында аннан көлдек, мыскыл иттек. Әмма, эчтән генә көнләштек: дөрес булса, бик күп җир күргән бит ул!

Кырык еллардан соң укып беләм — Стахеевлар Казан губернасында ашлык белән эш йөрткәннәр. Иң зур складлары Алабуга, Чистай, Арча кебек урыннарда булган.

Безнең авылга сигез чакрымнар ераклыкта Казан артының иң эре алпавыты Габдрахман Ишморатовның җәйге дачасы, такта яру машинасы, пар тегермәне һәм ат заводы булган. Насибулла абзый Ишморатов байның бөтен нәсел-нәсәбен, эш-гамәлләрен сөйли.

Кырык елдан соң миңа дәүләт архивында казынып, эзләнеп утырырга туры килде. Насибулла абзый сүзләре монда документ формасында иде.

— Зюссен ул бередәрәк,— дип сөйләп китә иде ул кичен капка төбендә утырганда. Ул аны шундый итеп кул хәрәкәте ясап күрсәтә, әйтерсең, сүз күрше Камәр түтиләрнең мунча артындагы таш өеме турында бара.— Зюссен ул егерме чакрымнар бирегәрәк. Аршау — Берлин юлыннан барганда Берлинга килеп җитәрәк уңга керәсе. Анда Вюнсдорф дигән авылны узгач та, юл аермасы бар. Шуннан тагын уңга борылып, моннан алып второй эвеслегенә (икенче бригаданың басу түрендәге ындыр табагы) кадәр җир барсаң, Зюссен күренеп кенә тора...

Томск, Красноярск, Тайшет, Иркутск тирәсендәге юллар, вокзаллар,

елгалар, кумер учаклары — барысы да шулай үзебезнең авыл урамына күчерелеп үлчәнеп, өйрәнелеп бетте. Барысы да «Насый карт» авызыннан.

Малай вакытта бөтен кызыкканым ил-җир күрү, дөнья гизү, авылга кайтып беренче чиратта аны шаккатыру иде. Бу мәсьәләдә язмыш миңа карата миһербанлы булды. 1952 елда мин ил-җир күреп ялга кайттым. Ул мин күргән вокзаллар, диңгез портлары, крепостьлар! Ул Рига, Калининград, Вильнюс, Клайпедалар! Балтикада хезмәт иткән кеше белән кем генә җиңешә алыр безнең авылда!

— Кай тирәдә йөрдең?— диде Насибулла абзый килеп күрешкәч тә, гадәт буенча бер күзен кысып. Мин — инде житкән егет!— ашыкмыйча гына капка төбендәге эскәмиягә утырдым, вәкарь белән генә сүз башладым.

— Либава портында тордык,— дип тотынган гына идем, Насибулла абзый җанланып китте:

— Ә-ә, Либау! Латышлар аны үзләре Лиепая дип йөртәләр. Либау — русча исеме. Булдым, ник булмаска.— Ул нәрсәнедер хәтеренә төшерергә тырышты. — Ниме, теге собор-чиркәүләрен күрдеңме? Николай патша гыйбадәт кылган? Дүртенче елгы япон сугышына безнең караблар шуннан китә бит инде. Патша үзе озатып кала.

Мин — телсез. Новиков-Прибойның «Цусима» романын сөйли бит бу!

— Ниме, Кенегсбергта булдыңмы? Хәзер Калининград инде ул. Либаудан ерак түгел. Кенегсберг янында Пилау дигән крипич (крепость) бар. Алар бөтенесе элек безнеке булган. Анда Либау белән Пилау арасындагы сашше юлны күрдеңме? Пилауның урам ташлары әле дә шул көеме? Бөтеркәләп, комга кадап, фигуралап эшләнгән көеме? Чәчәк фурмасы биреп? Немесләр бик хәрәб итеп бетермәгәнме шәһәрне? Ул бит элекке безнеке! Хәзер, ниме, Балтийск дип йөртәләрме?

Мин ялга кайтыр алдыннан гына флот элемтәчеләренең ярышында катнашу өчен Балтийск шәһәрендә булган идем. Чыннан да, урам ташлары шундый. Чыннан да, элек Пилава дип йөрткәннәр.

— Без,— ди Насибулла абзый,— Либаудан чыгып киттек. Диңгезнең бик әшәке вакыты иде. Пилауга хәтле тәүлеккә якын бардык. Диңгез тыныч булганда унике сәгатьлек юл ул. Ниме, Клайпедада булдыңмы?

Миңа тыңлап утырасы гына калды. Сөйләшә торгач, Насибулла абзый Себер якларына китте һәм кинәт кенә кайсы шәһәрдә су нинди булуы турында сөйләп алды.

— Менә безнең бу як суы Свердлауга хәтле бара. Свердлауны чыккач, суның тәме үзгәрә. Алай начар ук түгел-түгелен, әмма үзгәрә. Андый су безнең бу якта Ижлау (Ижевск) тирәсендә дә бар. Ну инде Черемхауга (Черемхово) барып җитсәң... Анда су бөтенләй икенче. Үзе кызгылт сыман, үзеннән тимер, бакыр тәме килә.

Мин олы кешегә аркылы төшмичә генә, елмаеп утырдым. Әйдә, сөйләсен инде. Без дә дөнья күрдек. Су бар җирдә дә бер инде ул.

1957 елның көзенә мине диңгез офицерлары мәктәбенә белемне күтәрергә җибәрделәр. Поездда бик озак бардым. Тышкы дөнья белән мөнәсәбәт өзелде — купедагы юлдашларны күрә алмас дәрәҗәгә җиттем. Алар да шулай. Чөнки өйдән чыгып киткәнгә атна була, без әле һаман барабыз. Менә бер көнне кич ниндидер станциядә сәгатькә якын тордык. Паровозлар чажылдады, буферлар бәрелде, күмер, су алдылар. Кузгалыр алдыннан гына мин титанда инде кайнап чыгарга өлгергән суны эчтем. Һәм аптырап киттем: судан бакыр тәме килә иде.

— Бу нигә болай? — дип сорадым мичтә күмер болгатып торган проводницадан. Ул күтәрелеп карамыйча гына:

— Черемховода тордык бит, бу суны әле генә шунда алдык, — диде.

Алай икән... Иртәгесен иң беренче эш итеп мин стаканга су салдым

һәм көн яктысында карадым. Су бераз гына кызгылт иде. Барып урнашуга авылга хат яздым: Насибулла абыйның йөргән җире Черемховодан уздык, суларыннан тимер тәме килә, дидем. Бу хәбәрне, әлбәттә, аңа җиткергәннәр. Өч айдан соң авылга кайтып төшүем булды, күрешергә дип Насибулла абзый килеп җитте:

— Нихәл Черемхау якларында булдыңмыни?— диде, күзен кысып.— «Ерофей Павлович»та булдыңмы? Бик зур станция. Ә Байкалны каян уздыгыз? Өске юлданмы, аскыданмы? Анда бит хәзер яңа юл салганнар диләр? Аннан соң, ниме, теге стансада булдыңмы? Ничек соң әле? Теге, патшага каршы чыккан эфисәрләрне сөреп, шунда заводта эшләткәннәр? 1825 елда? (Сүз «Петровский завод» станциясе турында бара иде).

Менә шундый мәгълүматлы кеше — грамотасыз Насибулла абзый безнең авылның «профессоры» булып гомер кичерде. Мин Насибулла абзыйның кара кайгылы көннәрен күрдем, башта аның хатыны Бибинур тәтә, аннан буй җиткән зәгыйфь кызлары үлде, мәет күмгән көнне ул йортта ризык әзерләмиләр. Насибулла абзыйны ашарга алып кергәләдек. Ике тапкыр мин аңа әчемлек тәкъдим итеп карадым — икесендә дә баш тартты.

— Кайгың онытылып торыр,— дидем.

— Юк,— диде ул,— яшь вакытта да авызыма алмадым. Хәзер, олайгач, килешми инде.

Насибулла абзый хәзер авылдан күчеп, элекке алпавыт Ишморатовның җәйге утары булган җирдә — Лесхоз поселогында яши. Мин уйлап йөрим: Лесхоз тирәсендә аны тыңлап үскән балалар нинди бәхетле! Алар, һичшиксез, география, тарих факультетларына керерләр, диңгезчеләр булырлар, Насибулла абзыйдан балта остасы һөнәрен өйрәнерләр. Колхозда беренче сушилка, беренче ашлык амбарын, беренче эвеслекләрне күршесе Галимулла белән бергәләп салганны Лесхоз малайларына сөйлиме икән ул? Ул күргән илләр, ул кичергән гыйбрәтле хәлләр аның күңелендә әрәм булып ятмыймы? Ятмыймы? Аның тирәсендәге малайлар Черемховоның кайда икәнен чамалыйлармы һәм анда суның ник кызыл булуы турында аз гына да булса уйлап карыйлармы?

Повестьның бу өлешен мин язучыларның Пицундадагы иҗат йортында рәткә салып утырдым. Иҗат йортыннан кайткач та авылда Насибулла абзыйны очраттым. Туган нигезенә кунак булып килгән. Күрештек, хәл-әхвәл сораштык. Әлегә сәламәтлеге әйбәт, тик бер күзе генә начар күрә икән. Авылга ямь кергән, урамнар шатланган кебек.

— Үзең нихәлдә соң?— дип сорый Насибулла абзый, үз хәлен кыскача сөйләп бетергәч.

— Ярый,— дим,— менә әле өченче көн генә Кавказдан кайттым. Хәзер бераз авылда тормакчы булам.

Насибулла абзыйның бер күзе кысылды:

— Ниме, Кавказның кай тирәсендә?

— Син белмисеңдер инде аны, Насибулла абзый, синең ул якларда булганың юк бит.

— Юк шул. Дөньяны күп күрдем, ну ләкин Кавказ якларына барып чыга алмадым.

— Мин шул Гагра дигән каладан бераз гына көньяктарак булдым инде. Анда безнең эшләү өчен, ял итү өчен зур бер йортыбыз бар. Язган-сызган кешенең, дим...

Насибулла абзый, тилгән күзләгән үрдәк кебек, күзен кысып башын кыйгайтты.

— Алайса, син Колхидада булгансың инде?

— Әйе, син аны каян беләсең?

— Каян дип, беләм, болай. Аларның анда Пицундамы, ниме, бер

үзәнлеге бар бит. Теге заманнарда, әле җиргә Коръән иңгәнче, диңгез кичеп, анда грек дигән халык килеп йөргән. Менә шул турыда грекларда әллә ничә калын китап бар, ди. Үзләре гел утрауда яши, ди.

Мин авызны ачтым да калдым.

— Уникенче елда,— ди Насибулла абзый,— минем белән бергә бер абхаз егете эшләде. Анжерка шахтасында. Баграт исемле. Шул сөйли торган иде. Анда бер нарат бар ди, галимнәр шуның яшен белә алмыйлар, ди. Әллә ничә тапкыр Америка, Япония галимнәре килеп тикшереп караган, ди. Юанлыгы сигез колач дип сөйли иде Баграт...

...Пицундада мин яшәгән бүлмәдән нәкъ ике чакрым ераклыкта теге нарат тора...

## Арчин

Гатият Әсмасы дигән карчыкның бердәнбер улы Миңлебай сугышта ятып калды. Миңлебай яхшы кеше идеме, яманмы, моны хәзер инде әйтүе кыен. Һәрхәлдә, ак киндер алъяпкыч ябып, киндер бияләй киеп ат-арба белән йөргәне хәтердә. Колхозчылардан бер колхозчы иде. Гатият Миңлебае фәлән эш эшләгән дигән хәбәр ни бик яхшы, ни бик начар мәгънәдә ишетелмәде. Әмма Миңлебайның карт әнисе, хатыны һәм икеме-өчме малае бар иде һәм, ниһаять, ул киндер алъяпкычын, бияләйләрен салып, кырык беренче елның җәендә фронтка китте һәм шунда үлеп тә калды. Юньле кеше булгандыр ул, шулайдыр, чөнки аның үлгән хәбәре килгән көннәрдә алар нигезендә тагын бер фаҗига булды: авыр хәсрәткә түзә алмыйча, аның әнисенең — җыерчыклы битле тәбәнәк, юантык гәүдәле Әсма карчыкның — акылы ялгышты.

Акылы сидрәгән кешеләр авылда әлек тә булгалаган. Мәсәлән, авылның карт мулласының улы революциягә кадәр шундый җиңелчәрәк булган. Ул, күрәсең, ерак мәдрәсәдә озак еллар ятып шулай мин туздырып кайткандыр. Бичара, өйләнмәгән. Сөкәт кадәр гәүдә белән мәзәкләр эшләп йөргән. Арадан берсе: һәр ходай бирмеш көнне үзенең табигый хаҗәтен үтәр өчен авылдан ике чакрым ераклыктагы бер кечкенә күлгә барып кайткан һәм тәһарәт өчен суны шуннан гына ташыган. Ул кеше су алган кеп-кечкенә күлне (хәзер инде аның төбендә биш-ун чиләк су калган) халык әле дә булса «шәкерт күле» дип йөртә...

Шәкерт абзыйның иләс-миләслеге халык күңелендә матур бер истәлек сыман гына яши иде. Әмма сугышның һәм авылдагы ачлыкның иң авыр бер вакытында — 1943 елның җәендә Әсма карчыкның акылы ялгышу халыкны сискәндереп куйды. Әсма карчыкның кешегә бер зыяны тимәде, ялгышу аның баш миендәге бер генә күзәнәккә кагылган булса кирәк. Карчык йорт, килен, оныклар, хуҗалык өчен үзендә булган бөтен җаваплылыкны кинәт кенә онытып авылга чыкты. Урам буйлап сөйләшеп йөрде, теләсә ни вакытта, теләсә кемгә килеп керде һәм шунысы гаҗәп — кергән бер җирендә үзенең авырып киткәнен, башы эштән чыкканын сөйләп йөрде.

— Минем Миңлебаем үлгән бит, ишеттегезме әле?— дип, ул әллә кайгы, әллә шатлыклы хәбәр икәнен аерып булмаслык битараф тавыш белән сүз башлый иде.— Менә минем башымны шул харап итте...

Аларның йортлары каршында урам ямь-яшел чирәм иде һәм урамның урта бер җирендә диярлек карт, муртайган каен чуптарларын асылындырып, ничектер, бөтен урамга моң, сагыш таратып утыра иде. Сугышка кадәр авыл урамыннан трактор йөрми, ул вакытта тракторга вак-төяк ремонтны кырда, җир өстендә ясыйлар иде, автомашина

жәенә бер-ике генә уза һәм ул да узганда бөтен авыл малае, дөньяларын онытып, машина артыннан йөгереп, ничәдер минутка Гатият Әсмасының кырык өченче елгы халәтенә кереп ала иде. Карт каен иркенләп җәелде дә җәелде. Язын Гатият Миңлебаеның кечкенә малае ул каенның кәүсәсенә балта чабып эз ясый һәм без җыелып, җиргә ятып, чираттан каен суы эчә идек. Җәй уртасында исә ул эз кызгылталсу төстәге куе сироп белән каплана һәм аңа чебен, шөпшә куна иде. Каен зур, каен мәһабәт, эссе көндә аның төбендә талгын рәхәт күләгә...

— Моны тырамбай аудара аламы?— дип сорый Әсма карчыкның оныгы, бездән яшьрәк Мулланур. Безгә нәрсә? Бәхәс кыза.

— Моны тырамбай аудара алмый,— ди беребез.

— Ә парахут?

— Парахут? Ул аударыр...

Безгә нәрсә? Безнең Гатият Миңлебае җиккән кола аттан башка берни дә — пароход та, трамвай да күргән юк. Ә белмәгән, күрмәгән әйберләр турында бәхәсләшү күңелле эш. Һәм ул табигый дә: белгән-күргән әйбер турында бәхәсләшмиләр бит. Сугыш җәендәге бер давылда карт каен сынып ауды. Аны утынга турадылар. Аның төбе әле ике-өч ел — урамга тракторлар кергәнче калкып утырды. Карт каенны аударырга трамвай да, параход та кирәк булмады. Ул каен ауган җәйдә Гатият Миңлебаеның үлгән хәбәре килде. Ул җәйдә Әсма карчыкның акылы ялгышты.

Сугыш беткән ел авылга «Оргнабор» дигән оешмадан әледән-әле вәкилләр килгәли башлады. Көньяк Сахалин, Амур буе өлкәләрендәге колхоз-совхозларга эшче көчләр җыйдылар. Оргнабор рекламаларында шундый сүзләр бар иде: баргач та һәр семья торак урыны, эш урыны белән тәэмин ителә, сыер алу өчен дәүләт ссуда бирә, каралты тирәсендә фәлән сотый бакча, утырту өчен бәрәңге, яшелчә орлыклары һәм башкалар бирелә, балалар мәктәпкә урнаштырыла, тәэмин ителә, гарантияләнә...

Хөкүмәтнең бу гуманлы чараларыннан авылның күп балалы хатыннары файдаланды: ямьшәйгән өйләрнең тәрәзәсенә такта кагып, түшәк-ястыкларын төреп, күрше-күлән белән саубуллашып, ерак, озын юлларга чыгып киттеләр. Киткән кешеләрнең барысы да шунда төпләнде, хәзер инде авылга аларның таза, чибәр оныклары кайткалый. Алар үзләренең «предокларының родной очагларын» карарга төп нигезгә килеп китәләр.

Гатият Әсмасының да килене балаларын төяп шулай ерак якларга юл тотты. Тик Әсма карчык кына кыймылдарга уйламады. Бөтенесе — килен дә, оныклар да паспорт, туу турындагы таныклык юнәтеп, ерак юлга чыктылар, карчык исә үз нигезендә калды. Нәрсә ашап,ниләр эчеп яшәде икән ул? Аның өен кем карады икән?

Мин бервакыт без дә үсеп җиттек. Гатият Әсмасы шулай һаман ялгыз яши, колхоз аңа ай саен ярдәм күрсәтә. Минем хәрби хезмәттән ялга кайткан көннәр иде. Яшь кенә булса да минем сабакташны авыл Советы рәисе итеп сайлаганнар икән. Күрештек, сөйләштек, өстәл янында утырулар булды. Җәйнең җылы бер төне иде.

— Әйдә,— диде яшьти,— бер хикмәт күрсәтәм.— Сагынылган, урамга чыктык. Һәм капка-коймасы җимерелгән, алабута, ат кузгалагы баскан ишегалдына кердек. Йорт эчендә тоныкк кына ут яктысы бар иде. Без тәрәзәгә килеп битләребез белән сыландык.

...Әлеге төнне шул тәрәзәгә килеп текәлмәгән булсам, мин, ихтимал, язучылык дигән авыр, газаплы хезмәт юлын сайлап алмаган булыр идем. Шул тәрәзә минем рухымда бөтен бер борылыш ясады.

Өйдә җиделе лампа яна, ул лампа яктысында сәкедә Әсма карчык

утыра иде. Андагы шат чырай, андагы бәхет! Карчык үзенең малае Миңлебай һәм ерак җирләргә киткән килене, онықлары белән сөйләшә иде. Мин тынсыз калдым. Әсма карчык сәкегә бер күч күлмәк, сөлге, чүпрәк-ашъяулык таратып ташлаган да, йөзенә бәхетле елмаю чыгарып, рәхәтләнеп сөйләшә иде. Бу сөйләшүдә чынбарлык белән карчыкның хыялый-матур дөньясы шулкадәр буталган иде ки, минем башым әйләнеп китте.

— И-и, Миңлебай улым, алай димә син. Ерак җирдә аның барысы да кирәк була. Менә бу сөлгене ал син. Бу — минем яшь килен булып килгәндәге әйберем. Киҗеле сөлге. Анда Сахалинда киҗеле сөлгене каян табасың син? Мулланур, тик утыр, шайтан малай! Әбиең сине сагынмады дип беләсеңме? Ә? Ул хәтле, капка төбендәге каен ауды дигәч тә... Килен белән бик әйбәт яшәдек, Миңлебай. Киленнәрнең төрлесе булды сугыш вакытында. Килен мине рәнҗетмәде. Син дә аны рәнҗетмә. Мин монда калыйм инде, улым.

...Мин тәрәзәдән китеп сулыш алдым. Йорт эчендә тулы бер хыялый тормыш бара иде. Бу хыялый тормышны Әсма карчык үзе тудырган, үзе ясаган иде. Түзеп булмады, хәер, мин инде әлеге хыялый көч тәэсирендә идем, кеше тәрәзәсеннән карап торуның нинди түбәнлек икәнен белгән хәлдә, пыялага тагын текәлдем. Карчык сөлге, ашъяулыкларны төрә-сүтә, һаман рәхәтләнеп сөйләшә иде:

— И-и, Миңлебай улым, алай димә син. Киленнәрнең төрлесе булды сугыш вакытында. Килен мине рәнҗетмәде. Инде, улым, син үпкәләмә, мин ул Сахалинга бармыйм. Килен бик кыстап карады, югыйсә. Юк, дидем, Миңлебай улым кайтмыйча, ике аягымның берсен дә атламыйм, дидем. Инде менә син кайткач...

Шулчак өйдә үзәк өзгеч ачы тавыш ишетелде. Минем чәчләрем үрә торды. Әсма карчык кинәт торып тәрәзә янына килде дә йөзенә кызганыч рәвеш чыгарып, кычкырып җыр башлады. Мин битемне пыяладан алырга соңга калдым. Әллә ул тәрәзә янында без торганны белгәнме? Әллә белеп түгелме?

Безнең илләр дугай-дугай,
Бер дугайда без бугай.
Безнең хәлләр сездә булса —
Сез дә булырсыз шулай.

Минем тамак төбенә төен утырды һәм мин тәрәзәдән киттем. Безне күреп, сизеп җырламагандыр инде ул?

Яшьтәш урамга чыккач болай диде:

— Менә, ыслушай, үзең уйлап кара: шушы иләс-миләс карчык артасында күпме әләгә миңа. Без моны кая урнаштырып карамадык? Моңа күпме кеше катнашмады? Кача да кайта, кача да кайта. «Миңлебаем янына кайтам», дип гел алҗыта, аннан чыгып китә икән. Картлар йортыннан кача икән... Аннан үзе дә килеп җылады. Мине, ди, тегә йортка тапшырмагыз. Минем, ди, башыма зыян килгән, ул зыян ди, сезгә зыян ясамас, шушында яшәп, шушында үлим, ди. Мин, ди,— миңа карап әйтә,— синең ник борчылганыңны беләм, ди. Төннә ут калдырып, пужар-фәлән чыгарып, зыян-зәүрәт салудан куркасың син, ди. Сиңа, ди, Сталин кушкан, карт-корыны күзәтеп тор, җәрдәм ит, дигән... Син, ди мине шушы нигеземнән аерма. Әле минем Миңлебаем ранный булып яткан вәшпитәлгә барып кайтасым бар. Анда Миңлебаемның аякчуы (аяк киемнәре, портянкалар дигән сүз) калган. Әле Эспирлау каласына шуларны алырга барып кайтасым бар...

Яшьтәш кыен хәлдә иде.

Бер елдан соң авылга бөтенләй кайткач, Әсма карчыкның хәлен сораштым. Бичара, югалган. Үлгән, диделәр...

Әсма карчык турындагы риваятьләр соңга калып, чит кешеләр аркылы авылга килеп житте. Ниндидер саташулар аны улы Миңлебай үлмәгән, ә яраланып кына әле дә булса Свердловск шәһәрендә госпитальдә ята дигән бер информациягә китереп чыгарганнар. Карчык әллә ничә тапкыр поездга утырып Көнчыгышка таба китәргә омтылыш ясаган. Проводниклар аны утыртмаганнар. Ә көннәрнең берендә ул төнге пассажир поездының тамбурына кереп урнаша алган. Күпмедер сәгать баргач, әлбәттә, тотып, билетсыз икәнен белеп, аны Вятские Полянында төшергәннәр. Әлбәттә, вокзалда каңгырып йөргән карчык белән милиционер кызыксынган һәм бүлмәгә алып кереп сөйләшкән. Карчыкның бәхетенә, милиционер татар егете икән.

— Кая барыш, әби?— дигән.

— Эспирлауга.

— Нәрсәгә? Кемгә?

— Малаем вәшпитәлдә ята. Хәлен белергә.

— Билетың бармы?

— Миңа,— дигән карчык,— Сталин ирек биргән, Миңлебай улым билет биргән...

Милиционер шунда карчыкның саташулы сәяхәткә чыкканын аңлаган.

— Әби, дукәминтең бармы, син кайсы яктан?— дигән.

Алдындагы егетнең татар икәнлеген аңларга карчыкның ми куәте житмәгән. Югыйсә, ул үзен «Арча районыннан» дип әйтә алыр иде. Әмма тузган, саташкан минең ниндидер бер контроль күзәнәге аның милиционер алдында торганлыгын белдергән һәм карчык «Арча» сүзен татарча гына дип уйлап, алай гына ярамас, дип ышанып:

— Арчин,— дигән.

...Яшь милиционер аны, шактый баш ваткач, Арча булырга тиеш, дип уйлап, телеграммалар биреп, Арча станциясенә таба утыртып жибәрә. Анда Әсма карчыкны картлар йортына озаталар. Ике-өч ел узгач, теге милиционер Вятские Поляны пристанендә эшләүче бер кызга өйләнә. Теге кыз безнең авылныкы икән... Берничә елдан соң шул кыз һәм кияү аркылы Әсма карчыкның соңгы сүзе авылга кайтып житә:

— Арчин...

Бичара, протокол өчен «Арча» сүзе бик гади, бик авылча булыр дип уйлагандыр инде ул. «Арчин» — бу инде уен-муен түгел...

## Көзге кичләр

Шагыйрьләр язгы иртәләр, жәйге зәңгәр кичләр турында язарга яраталар. Һәркемнең үз вакыты, үз мәхәббәте була. Миңа, нигәдер, көз кадерлерәк. Мин көз көне үләрмен кебек...

Авыл көзе. Сугыштан соңгы, әле генә киерелеп сулыш алырга жыенган авылның хәлле көзе. Көндезгене ашауга караңгы төшә башлый. Нигез салырга, тәрәзәләрне кагарга, абзар-кураны рәхимсез кышка әзерләргә кирәк. Колхоз басуында инде эш тәгәлләнгән, игеннәр амбарга, бәрәңгеләр базга кергән — озын, тыныч кыш вәгъдә итеп, гел караңгыга таба акрын гына жир шары әйләнә...

Авылда бу вакытта мал-туарны арыш уҗымына чыгаралар, каткак, кар-боз бөртекләреннән бизәлгән яшел уҗым басуында инде карынында бозау үсеп килгән бәхетле, хәсрәтсез сыерлар йөри, әлегә сөт мул, ә уҗым катыгы — моның нәрсә икәнен авыл халкы гына белә... Абзар артларында киртәдән үрәчәләп әвеннәр куелган, монда эт эчәгесе, билчән катыш бәрәңге сабагы җилли, вакытында киптереп

печәнлеккә кертсәң, киң авызлы, беркатлы сыерларга, юеш танаулы ахмак сарыкларга менә дигән зур сый инде ул.

Абзар артларында ара-тирә хатын-кыз кайнаша, кулларында әле зур ак табак, әле ак сөлге, әле комган. Кемдер мал түшкәсен абзарга сөялгән киштәгә күтәрә, хатын-кыз кайнар су, сөлге белән мәш килә, мал суючының пычагын, кулын гел юып торалар.

Абзар өстеннән «чиякъ-чиякъ» килеп чәүкәләр очып китә, миләш ботагында, иләмсез зур койрыгына ышанып, саескан тирбәлә, әле каргалар казык башында утыра. Бераздан, табак-табак ит-май күтәреп, хатын-кыз өйгә юл ала, ир-ат, үткен озын пычакны абзар баганасына кадап, утын әрдәнәсенә сөялеп утыра һәм, уч төбен тәмәке уты белән жылыта-жылыта, әңгәмә кыздыра. Илдә иминлек, туклык, хөрлек. Менә без исән, менә без өйдә, менә безнең тамак тук...

Морҗадан сыек төтен күтәрелә, ул арада хуҗа хатын бавыр кыздырган, ә казанда ит кайный.

Кичен, яшьләр клубка җыелгач, өлкәннәр инде мал-туарга күз салып кереп йокыга яткач, абзар артында, өйдән чыгарып су түккән урынга авыл этләре килә. Күп түгел, берәү я икәү. Авыл этләре! Авыл кешеләре кебек гади, эчкерсез, беркатлы этләр... Тапкан сөякне алар шунда ук ятып, алгы тәпиләре белән тотып, үзара мырлаша-сөйләшә тәмләп кимерәләр, чыкырдаталар. Безнең авылда этләр барысы да бертөрле очлы авызлы, күз өсләрендә ак яки кара сызыклы, чиста тырнаклы була иде. Очлы борынлы бу этләр океан артыннан, яисә Германиядән чыккан әллә ниткән нәселле доглар, добберман-пенчер, овчаркалардан үзләренең беркатлылыгы, мөлаем карашлары һәм жиргә ятып ике «кул»ларына тотып тәмләп сөяк кимерә белүләре белән аерылып торалар иде. Эт тә матур була ала!

Соңгы елларда, тамак туйгач, без авылны шәһәрләштерү турында мавыгып сөйләштек. Сөйләшүгә катнашканнарның күпчелеге, кызганычка каршы, авылны шәһәр итеп күрергә хыялланды. Бу хыялга тотынучылар булды, авыл халкы терлек-туар асрамаска, хәтта бәрәңге, яшелчә утыртмаска өйрәнде, акча күп — сумка тотып башта авыл кибетенә, аннан машинага утырып шәһәр кибетенә юнәлде. Теге, абзар артында сөяк көтеп ята торган очлы авызлы мәхлук этләр дә акрынлап кимеде, чөнки абзар артына сөяк чыкмый башлады. Ала каргалар, саесканнар да андый авылның бакча киртәсенә, абзар түбәсенә кунмый башладылар. Тамак туйгач без, бүтән бернәрсә дә калмагандай, үзебез туып үскән авылны ничек мөмкин шулай тизрәк бетерү турында сүз куерттык. Тук кеше кызык бит ул...

Авыл тормышы үзенең поэтикасын югалту куркынычы алдына килеп басты. Трактор дөбердәтеп барысын да эшли. Тиз эшли, газапсыз, сытып, жимереп эшли. Трактористка да тиз кирәк, хуҗага да: эш бетте, тиз генә бер ярты, тиз генә бер консерва. Раз-раз, трактор эшләп тора, авызга бер сигарет, һәм — вәссәләм! Гуд бай! Тагын эшегез чыкса — пажалыста. Кайтыйм тизрәк, бүген «Рубин» белән «Динамо» уйный...

Юк, юк, алай ярамый! Алай түгел иде колхозчы...

Колхозчы көзен, эш беткәч, үз хуҗалыгында мал-туар белән кайнаша, кышлык ит әзерли иде. Менә монысы үзебезгә, монысы шәһәрдә урнашып калган балаларга, монысы — базарда сату өчен. Уйлана, исәп корыла.

Көз. Авыл көзе. Тын. Соңарган сары яфрак кыштырдап, агач ботакларына бәрелә-сугыла төшә. Ул инде бозланып авырайган. Крестьян әле генә зур эш эшләде: сыермы, танамы, бозаумы суйды. Хатын-кыз инде түшкәне, эч-башны урнаштырды, тире киерелеп инде киштәгә эленде. Крестьян, аркасын утын әрдәнәсенә терәп, күршесе белән бергә тәмле әңгәмәгә тотынды, тәмәке кабызды.

Әрдәнәдән хуш ис бәреп тора. Юкә утыны булса — бодай кабартмасы исе, чыршы-нарат булса — затлы скипидар, имән булса — чиклəвек хәлвәсе, зирек булса — хикмәтле буяу, каен булса — башны әйләндерерлек сумала, дегет исе. Әрдәнә сулый. Тын ала. Моны крестьян гына сизә. Ноябрьның салкынча бер кичендә салкын җиргә чүгәләп, тәмле әңгәмә корганда крестьян сизә: әрдәнәдә җәйге җылы бар, анда эссе аланның каен җиләкләре, моңсу сентябрьнең тупырсык гөмбәләре, кояшлы-кыска октябрь көненең балан, миләш исләре бар.

Әрдәнәгә терәлеп утырып сөйләшкән сүздән дә тәмлерәк әңгәмәне белмим мин...

Әмма крестьян лапасының матурлыгы анда гына түгел. Лапас эчендә бик күп кеше белми торган бер закончалык бар: әле генә синең борыныңа әрдәнәдәге юкә утыны исе бәрелде, ул синең башыңны әйләндерде, синдә рәхәт, матур уйлар тууга сәбәп булды. Тик бу — бер секундка гына. Шул вакытта кинәт кенә җиләкле печән исе килеп бәрелә, тагын баш әйләнеп китә. Монысы — печәнлектән, өстән. Лапас астында исләр әнә шулай секундлап, минутлап көрәшәләр, бу көрәш лапас астына яз исе килеп кергәнче, түбә кырында кус чәй төсле ахак бозлар асылынганчы дәвам итә. Аннан дөньяда яз яше башлый.

Көзге ризыклар — үзе бер матурлык. Безнең авылда көзен хатынкыз пешеренергә бик ярата иде. Көзге ризыклардан шалкан, чөгендер пәрәмәчләре, төелгән киндер орлыгыннан кыстыбый, мәңгегә югалгандай, инде тарихка китеп калдылар. Боларны киләчәк буыннар эзләп табармы, аларны пешерерләрме? Киндер орлыгы кушып төелгән чөгендер ягып пәрәмәч пешерерләрме безнең балалар? Әниләре иртән торышка казан төбеннән алып кайнар шалкан суы эчерерләрме балаларга! Кишер, кәбестә бөккәннәре пешереп, көзге матурлыкны, байлыкны мәңге хәтердә калдырырлармы?

Киндер орлыгы төю... Тук, тук, тук. Әни, бөкрәя төшеп, киледә бер сәгать, ике сәгать, өч сәгать төя. Арый, йончый. Бераздан мин дә катышып китәм. Төя торгач, киндер орлыгы хәлвә сыман бер массага әйләнә, киле тирәсенә бала-чага шул чакта җыела. Аннан, ул көнне, мичкә ягыла һәм затлы киндер мае исе морҗадан күтәрелеп авылга тарала. Бел дә тор: кыстыбый пешерәләр...

Көзен аяз кичләрдә ай моңсу була. Сентябрь ахырындамы икән ай кып-кызыл табак булып кичен күтәрелә, күтәрелгән саен яктыра, яшькелтләнә бара. Агачлар яфрак койганда, кичләрен җил чыгып, каралты саен бәйләнеп йөри, агачлы хуҗалыкларда озаккарак туктап кала. Көз — сагышлы да, моңлы да... Авыл көзе миңа һәрвакыт нәрсәдәндер, кемнәндер аерылу, мәңгегә аерылу турында тукып тора иде һәм мин көзге кичләрдә булган очрашуларны зур хәвеф белән генә кабул итеп яшәдем. Хәрби хезмәткә киткәндә шулай булды. Вәгъдәләшеп, зур сүзләр бирешкән бер кызым да юк иде, сугыштан соңгы елларда яшькә бездән зуррак кызлар шактый күп булып бөялеп калганнар иде, ул арада безнең яшьтәшләр сафка басты, шул арада бездән яшьрәк кызлар аларның барысын да кысрыклый башлады. Әмма кызлар акыллы — ул чорда һәр егет армиягә барасы заман — солдат хезмәтен узып, эшен бетереп кайтмаганнарны әле — «егет-малай» дип сөйләшәләр һәм алар белән танышып йөрешкәндә дә болай гына, юрамалый гына йөргән сыман тоелалар иде. Авыр сулап:

— Һи-и, әле синең кайларда йөреп кайтасың бар,— дип сүзне түгәрәкләп кенә куялар иде.

Военкоматтан чәчне кыркып кайтаргач, кызларга күренергә оялып йөрдем. Кепканы бер дә салмадым инде. Шул көннәрдә генә район үзәгенә эшкә килгән бер кыз белән танышкан идем. Минем дә кеше төсле вәгъдәләр бирешәсе, адреслар алышасы, ниһаять, колхозчы-

крестьян егетләре кебек армиягә киткәндә истәлек кулъяулык аласым килгәндер дип уйлыйм хәзер.

Зоя минем кырган башны бөтенләй күрмәде дә. Чөнки без аның белән кич кенә очраша идек. Менә бер көнне авыл советы секретаре мәктәпкә кош теледәй бер кәгазь тотып керде. Тәнәфес вакыты иде, мин аның артыннан укытучылар бүлмәсенә кереп барганда ук аңладым. Бу — повестка. Миңа. Ирләрчә булырга тырышып, тавышны калынайткан булып:

— Ничәсенә?— дидем. Үзем дулкынланам, сизмәсәләр ярар иде дип, стенадагы шүрлеккә класс журналын озак-озак куеп маташкан булам.

— Өченче уктәбергә иртән сигезгә,— диде секретарь кыз. Мин горур, бәхетле, ләкин моңсу тойгыларга чумдым. Шул тәнәфестә үк өлгералдына, «П» хәрефе ясап, укучыларны тезделәр. Хәзер хәтерләп бетерә алмыйм, шулай да гадәттән тыш купшы речь сөйләп ташладым бугай: Ватан чикләрен сакларга, сезнең тыныч йокыгызны тәэмин итәргә, газиз туфрагыбызны капиталистлардан, милитаристлардан актык тамчы канга кадәр сакларга, фәлән-төгән дип бетердем. Балалар бит — чын күңелдән тыңлыйлар. Мин дә чын күңелдән сөйлим, тик бер генә фальшь җибәрдем.— Тыныч күгебезне сакларга дип үк җибәрдем, бугай. Күк мәсьәләсендә миннән юк инде! Үз гомеремдә үз өебезнең түбәсенә дә менә алмадым, биеклектән әле дә куркам. Ленинградның мәшһүр опера театрында урыным балконга туры килгәч, кызык халәттә калдым: тәнәфес җиткәч, бөтен кеше кузгалып чыгып бара, миңа да чыгарга кирәк, әмма нәрсәдер комачаулый, кузгала алмыйм. Байтак азаплангач кына аңладым: мин кулларым белән балконның тимеренә чытырдап ябышканмын да, шуннан ычкына алмый утырам икән...

Шулай, хушлаштым. Әле дә күз алдымда: үзем җитәкчесе булган бишенче «а» классының бер кыз, линейкада басып торып, минем шәп речьне тыңлаганда берөзлексез елады. Ә кичен мин егетлек бәхете ташып торган бер халәттә Зоя белән очраштым. Ул кичне шомлы җил, ул кичтәге түгәрәк, зур кызыл ай. Ул ай, җилгә ачулангандай газапланып, район үзәге артындагы тимер юл куаклары өстенә күтәрелде дә, безгә озак карап торды. Коры, җылы җил урамдагы әле бер агачка, әле икенчесенә бәйләнеп шабыр-шобыр яфрак коя иде. Мәрхәмәтле җир! Мәрхәмәтле ай! Иртәгә бу вакытта нинди поездларга утырып, кайларга таба юл тотармын мин, бу ай иртәгә дә шулай моңсу булып, шулай озаклап күтәрелерме? Ә Зоя шунда мине берөзлексез үпте. Мин әллә нинди вәгъдәләр бирдем сыман, хатлар, телеграммалар, тагын әллә ниләр. Ә Зоя кайнар битләрен минем яңакка куйды да, гел мине үпте, бер сүз дә әйтмәде. Яшькә ул миннән бер-ике елга өлкәнрәк иде кебек. Зур кызыл ай, шомлы җил, иңрәгән карт усаклар, каеннар... Зояның тоз тәме килгән битләре, йомшак чәчләре, бантик куеп бизәлгән гади сукно эшләпәсе. Без чак-чак кына аерылыша алдык. Авыр, шомлы. Ун-унбиш көннән мин аңа хисләр тулы хат яздым: Балтик буйларыннан матросларча кайнар сәлам! Әле гомуми казармаларда гел утын кисәбез, чүп түгәбез, бәрәңге әрчибез, диңгез түгел, әле инеш тә күргән юк. Ләкин мин шунда үзебезнең биш елдан гына кавыша алачагыбызны әйтеп ташладым. Ай тулганда Зоядан җавап хаты килде. Ул хатны мин укымыйча ике-өч сәгать йөрдем: укысам, гомернең бер кызыгы да калмас кебек иде, бу рәхәтне тагы да сузасым килде. Әмма язмыш миңа сюрприз әзерләгән икән. Зоя миңа караганда аеграк булып чыкты: «Хатыңны алдым. Биш ел бик озак бит ул. Син кайтканда, беләсеңме, миңа ничә яшь була? Бу язышу бик мәгънәсез булачак, туктатыйк». Миңа бик авыр булды, минем күз алларым караңгыланып йөрде, Зояга мин бик рәнҗедем. Тагын теге шомлы кич,

зур кызыл ай, иңрәгән агачлар искә төште. Мин нәрсәнедер югалттым, ниндидер зарар килде минем рухи дөньяма...

Ике ел узып ялга кайткач, җәен мин нәкъ шул урамнарда йөрдем, кичләрен нәкъ шул агачлар төбендә булдым. Әмма җәйге кичләрне мин бик яратып бетермим: алар алдакчы булалар. Минем өчен җилле көзге кич, агачлар, газап белән күтәрелгән кызыл ай кадерлерәк, якынрак. Көзге кич — нәкъ Зоя кебек — алдамый... Ахырдан мине байтак кеше алдады, көлде, мыскыл итте; аның саен Зояга рәхмәтем арта гына барды. Мин аңа әле дә бәхет теләп яшим, тик кайда икәнен генә белмим. Ул бәхетлеме, аның гүзәллегенең һәм акылының кадерен беләләрме бу дөньяда? Теге көзге кичне ул хәтерләмидер инде, әмма мин ул кичне онытa алмыйм. Яшь күңелнең бик сизгер, бик нечкә, хәтәр тәэсирчән чагы иде ул... Мин аңа гел бәхет теләп яшим.

Көзге кыска көн төш вакыты узуга караңгылана башлый, киртә казыкларына йомрыланып өлкән яшьтәге каргалар утырып тора, яшь җилбәзәкләре, чыр-быр килеп, миләш башында этешә-төртешә соңгы миләшне ашыйлар, урамда таза аты-арбасы белән тире җыючы килеп туктый. Колхоз басуында сузылып яткан салам эскертләре томан сеңдерә-сеңдерә дөньяга йорт сырасы исе тараталар, ул эскерт араларында куышып, эскерт өстеннән мәтәлчек атып малайлар уйный. Килер бер вакыт, телевидениедән хоккей, футбол белән беррәттән авыл малайларының көзге көндә эскерттә мәтәлчек атып уйнаганнарын күрсәтерләр. Әгәр безнең буын кешеләре моңарчы таза-сау, поликлиникасыз, санаторийсыз яшәгәннәр икән, моның белән аларның күбесе әнә шул томанлы моңсу басулардагы эскерттә уйнауга бурычлы.

Көзен йокымсырап басып торган атлар, уйга талган сыман күшәп торган сыерлар... Җиргә тын гына караңгылык иңә, терлек-туар озын, ризыклы рәхәт төнгә әзерләнә, абзар-курада каефсез җан иясе тик аңа каз гына. Аның, бичара, күзләре кызарган, үткен пычак тоткан күрше Хәкимҗан аның эре, ак канатлы, алсу тәпиле балаларын кичә генә абзар артына алып барган, ә балалар аннан кайтмаганнар... Кичен бу йортта тальян тавышы ишетелгән, кызлар чыркылдашкан, ишектән пар бәргән, абзар артында озын авызлы этләрне куркытып кемдер йөргән. Каз йолкучы кызлар төн уртасында гына, өйалдына суынырга чыгарган бәлешнең югалганын сизгәннәр — егетләр эше бу! Начар гадәтле, тәрбиясезләр эше. Авылда монысы да бар...

Мин хәрби хезмәткә көз көне китеп көз көне кайттым. Агачларга бәс утырган, каткак, топольләр ак энҗегә бизәлгән, җирдә әле кар азмаз гына. Тып-тын кыска көннәр, тып-тын озын кичләр. Бер атна эчендә авылга өч-дүрт егет кайттык. Киләбез клубка, бер читкә барып горур кыяфәт белән утырабыз: без югында күпме малай-шалай егет булып йөргән, әллә ниткән пычтык кына кызлар, түгәрәк уенга кереп, шулар белән җырлап йөргән булалар. Дөньяда без шәп, без! Әй, сез, нигә бөтенегез дә җыелып безнең каршыга килеп басмыйсыз да, нигә бу уенны башларга, гомумән, клубка керергә, кич чыгарга һәм... бу дөньяда яшәргә бездән рөхсәт сорамыйсыз? Кара син аларны!

Ахрысы, без шулай уйлана идек.

Аннан, кайтышлый ишек яныннан узып барганда гына күзең төшкән кызның беләгеннән, погоннардан файдаланып, кыю гына тотып аласың. Яшь егетләр синең бәхеткә кызыгып карап кала. Урамга чыккач та теге вакытлардагыча кебек сүз таба алмыйча кайнар дулкын өстендә йөзмисең һәм дежур сораулар бирмисең (яшь вакытта кинодан чыккач беренче дежур сорау: я ошадымы?— дигән буласың. Кино булмаса, һава халенә тукталасың). Хәзер нәрсә! Хәзер синең һәр сүзең алтын бәясе. Чөнки сиңа инде — «һи-и, әле синең кайларда йөреп кайтасың бар?» дип скептикларча мөнәсәбәт юк, син инде — өметле кеше.

Вдруг син кайткан хуттан «әйдә ЗАГСка» дип ычкындырырсың? Синең яшьтә бит инде егетләр шаярып сөйләшмиләр. Син инде җитди кеше...

Гөлт итеп зажигалкадан папиросыңа ут кабызасың да, тамак төбе белән генә ирләрчә сөйләшеп барасың. Сөйләшеп дип, ул инде — син генә сөйлисең. Кыз бала нәрсә сөйләсен ул? Менә без Калининград вокзалында чакта... Менә без өч малай Мәскәүнең Казан вокзалында билет компостировать итәргә торабыз... Синең сөйләмеңдә компостер, вокзал, комендант, сутки, патруль, аттестат, требование дигән хәрби командировка терминнары никадәр күбрәк булса, кыз өчен шулкадәр серле, шулкадәр шәп син. Ә шәп буласы килә. Ир затының гомер буе шәп буласы килә. Шул омтылышы булмаган кешеләрне, ни өчендер, яратып бетермим. Ә шәп булырлык та! Безнең авыл — коры авыл, бездә — чишмә, инеш, маймыч, этли балык — вәссәләм! Ә син ерак диңгездән кайтасың... Авылның тарихында син — беренче. Тельняшкадан, кара бушлат, бескозыркадан. Ул, минсиңайтим, ленталар... Ул минсиңайтим... Хәер, бу эрелек — «шуышма» төшенчә. Диңгез портына таба сузылган тимер юлының вокзалында син — матрос. Синдәйләр монда — «муре». Утырасың, китәсең материкка таба. Аркада ленталар җилферди. Материктагы зур шәһәрнең вокзалы. Монда синдәйләр аралаша: соры шинельле солдатлар, офицерлар, һава көчләре, десант, танк, элемтә, эчке эшләр, чик буе гаскәриләре. Китәсең алга таба: башкала! Гражданскийлар күбәя, ә синең дәрәҗә арта бара. Лентаның берсе аркада, икенчесе — алда. Башкаладан үз шәһәреңә баручы поездга утырасың. Вагонда ленталы — син берүзең... Син инде матрос кына түгел, син инде — «диңгез бүресе», син монда — каптри, капдва... Кайтып төшәсең Казанга, вокзалга, син — каподин....[1]

Инде, инде үзеңнең чишмәле, маймычлы, этли балыклы авылыңа кайтып төшкәндә син — контр-адмирал! Шуннан да ким түгел. Бөтен кеше сиңа карый. Дөньяда син генә бар, бүтән бер кеше дә юк! Әмма, чираттагы ялдан хәрби хезмәткә кире кайтканда нәкъ шул ук әзлеклелек белән контр-адмиралдан матроска кадәр төшәсе була. Анысы авыр. Бөтенләй демобилизация белән кайтканда исә, теге «кире процессны» узмыйча «бөек» булып каласың — бәхет шунда!

Көзге кичләрдә без әнә шулай, энҗе бәс каплаган агачларга карап, капка төпләрендә контр-адмирал булып кызлар белән торгаладык. Шинель каптырмаларын ычкындырасың һәм без озата кайткан кызлар, бер дә кыстатып тормыйча, ул шинель эченә кереп, без мактанганны тыңлыйлар иде. Без шәп йөрдек...

Күрәсең, ул кичләр мәңгелек булып хәтердә калган: егет кешеләрдәге бераз гына мактанчыклыкны әле дә гафу итәм, гафу итәм генә түгел, кызыгып, көнләшеп куям!

Ул елның ноябрендә атналар буе авыл өстендә чиста зур яшел ай торды. Андый тулы айлы, бәсле көзге кичләрне мин башкача күрмәдем кебек...

## Соңгы сүз

Кырык өченче елмы? Әллә кырык дүртме? Без Масра як басу түреннән — безнең авылның офыгыннан — ындыр табагына чапкан борчак ташый идек. Атның башыннан җитәкләп покос арасына алып керәсең дә, як-яктагы басылган борчак чүмәләләрен сәнәк белән арбага төйисең. Берәү тырма белән йөк өстендә тора. Аннан, биек-биек булгач,

[1] Каптри, капдва — матрослар жаргоны: капитан третьего ранга; капитан второго ранга (кавторанг дип тә әйтәләр). Каподин — капитан первого ранга дигән сүз. (Автор.)

бастырык басасың. Көч житми, әмма хәйлә бар, бастырык басасы бауны арбаның арт тәгәрмәче тугымына чорныйбыз да, атны кузгатабыз. Тәгәрмәч, бастырык бавын үзенә чорнап, шыгырдатып йөкне бастыра. Димәк, без эшнең үзеннән эшләтәбез. Тамак тук, борчак ашыйбыз, арып өйгә кайтсаң — яңа бәрәңге ашы! Менә тиздән сугыш та бетәр. Авыр эш эшләгән саен безне дәртләндереп торучылар бар: көч чыкмыйча көч керми. Ә көчле буласы килә! Егет буласы килә! Кырык градуслы салкында да мәктәпкә барганда күрше авыл урамына кергәч, бүрек колагын күтәреп бәйли идек. Кызлар, безнең шул батырлыкны тиешенчә бәяләмичә:

— Колак исе чыккан!— дип көлеп калалар иде. Әйе, егет буласы, үсәсе, тизрәк бу җирләрдән әллә кая — зәңгәр күккә, ерак океаннарга, бозлы тауларга, калын тайгаларга, зур шәһәрләргә китәсе килә. Борчак төяү, бастырык басу вакытлы хәл, ерак сәфәрләр алдыннан бер көч җыю гына...

Шулай уйлап ат башын тотып покослар арасыннан камыт бавы шыгырдаганны тыңлап барганда мин кинәт туктап калдым. Күз алларымнан әллә ниткән мамык бөҗралар очты, тыным кысылды. Миннән дүрт-биш адым ераклыкта гына биек аяклы дүрт торна тып-тыныч басып тора һәм борчак чукыйлар. Тавык белән каздан башканы күрмәгән күзгә мондый күк гөмбәзе кунагын күрү бик көтелмәгән хәл булып чыкты, минем күзләр яшьләнде, тамак төбе җыерылды. Йөрәк типкәнне ишетеп тордым. Торналар озын биек аяклы, күк йөзендәге болыт кебек зәңгәрсу-кургаш каурыйлы, хәтәр озын томшыклы кошлар икән. Боларны карап торасы, рәхәтләнеп карыйсы иде. Әмма мин, үземнеүзем белешмичә, алар янына тилеләрчә торып йөгердем һәм нәрсәдер кычкырдым. Торналар киң канатларын мәһабәт чайкап, озын аякларын бөгеп җиргә иңеп алдылар да, һава ярып күккә күтәрелделәр. Мин аңга килгәндә алар:

— Торыл-лыйк! Торыл-лыйк!— дип сөйләшеп, Торна елгасы дигән урман кырына таба юнәлеш алдылар. Торналар бик биек, бик биек күтәрелеп очтылар. Ә мин җирдә суалчан кебек калдым. Шунда иң зур бәхет, иң зур рухи байлык җирдән аерылып, җиргә зәңгәр күк төбеннән карап йөрүдер дип уйладым. Торналар сихри күк йөзенә күтәрелделәр дә ерак-ерак киттеләр. Ә мин үземнең борчак, яшь бәрәңге, сәнәк, бастырык, бау, арба, межасына күк чәчәк үскән басуым белән җирдә ятим калдым.

Торналар шунда тормышымнан нәрсәнедер алып киттеләр. Мин үкенечле караш белән күккә күз юнәлтеп, авызымны ачып тордым. Их, нигә ашыктым соң? Ник тыныч кына карап тормадым? Гомерләр узган саен, еллар өстәлгән саен мин шул ашыгуымның очраклы булмаганын, ә табигать биргән бер гадәт икәнен төшендем. Мин бик күп нәрсәгә шулай уйлап бетермәгән көе ашыгып тотындым, ахырдан авыз ачып карап кала торган бер кеше булып формалаштым. Шулай да, торналар төшкән ул басу мәңгелек матурлык, шигърият чыганагы булып минем хәтеремә уелып калды.

Хәрби хезмәттә вакытта күргән хикмәтле шәһәрләр, портлар, затлы кафелар, бильярд заллары, шәм кырып сибелгән паркетлар, алтын погоннар, көмеш трубалар чыңы астында тигез атлап баручы колонналар, салютлар — берсе дә торналар төшкән әнә шул басуны оныттыра алмады. Авылга мин кайткан чак көздән кышка авышкан көннәр иде. Меңә бер көнне кичкә таба мине сагыш басты. Нәрсә житми? Син бит инде ерак җирләрдә намус белән хезмәт срогыңны үтәп кайттың, син бит инде туган нигезеңдә карт әниең янында чәй эчеп, киләчәккә матур планнар корып утырасың! Тагын ни житми?

Торналар төшкән теге басу түре житми икән. Җиргә караңгы иңәр алдыннан гына мин шул басу түренә юл алдым. Ашыктым. Барып жи-

тә алмам, юлда егылып үләрмен кебек тоелды. Барып җиттем. Кояш зур кызыл шар булып карлы дәрья артына кереп бара. Басу түре тып-тын. Күз күреме җирдә беркем, бернинди җәнлек юк. Җилнең әсәре дә сизелми. Кар әле юка, ара-тирә ул каралып тора, җилдә ашалган каткак балчык күренгәли. Шул тынлыкта басып торуы рәхәт, чамасыз рәхәт иде. Менә теге елны торналар шушы тирәгә төшкән иде. Менә бу тирәдә генә без борчак төяп йөргән идек.

Бу — дөньяның әллә нинди шигъриятле, моңлы җире. Монда элегрәк заманда кыр казлары да төшкән. Бу турыда җыр да булган, минем белән урамда бергә уйнап (күбрәк сугышып) үскән Мәгъсүм бар— ул бала вакытта бик моңлы иде. Әбисе үлгәч, урамга чыгып ул әбисен сагынып җырлый торган булды. Узган-барган кешеләр аның янына килеп:

— Я, энем бер җырлап күрсәт әле,— диләр иде.

Мәгъсүм түбән карап, күзләренә гадәттән тыш моң, сагыш чыгарып җырлый иде:

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра
Масра басу артында,
Безнең әби ята инде
Кызыл балчык астында.

Аннан, күзе яшьләнеп, өенә кереп китә иде. Адәм баласына әллә артык моңлы булырга ярамыймы икән? Мәгъсүм җиде яшьтә әнисез, тугыз яшьтә әтисез калды. Аннан үзе юллап, үзе йөреп балалар йортына китте, шунда менә дигән тәрбия алып кеше булды. Балтыйк флотына эләкте — менә мин хезмәтемне бетереп кайтып, әлеге Масра басу түрендә басып торам, Мәгъсүмгә кайтырга әле ике ел бар, бу моментта ул әле, бәлки, вахтададыр?

«Масра басу»да басып торганда нигәдер мин Мәгъсүм турында уйландым.

Берничә ел үткәч мин үзебезнең балачак турында «Яшь ленинчы» газетасына зур мәкалә яздым. Ул мәкаләдә яратып, сагынып, Мәгъсүм турында да язылган иде. Бик кызганыч, ул мәкаләдә мин «Масра басу» турындагы җырны гына телгә алмаган идем.

...«Масра басу» тын, бик тын. Шундый тын, дөньяның зыңлаган тавышы ишетелә, дөнья сабырлык, акыл чәчә, кызыл шар инде күмелеп бара, җир әйләнә, ә мин шушы мәһабәт тынлык уртасында торналар төшкән җирдә берүзем басып торам.

Бу — минем туган җирем...

*Пицунда. Август — сентябрь, 1979.*

## Рәдиф Гаташ

### Бабич

Әй, күңел! Синең дә
бар күгең, ул бар ич!
Ә күгең — йолдызлар
тулы ич, ул бай ич:
Анда — якты Тукай,
бар анда ул — Бабич!

Ах, Бабич, йөрәктә
йөртәм ак исмеңне!
Дөньямны тагын да
саф итәр өчен ме?
Сагынып мин сине,
кабатлыйм исмеңне!

Кошлар күп һавада —
лачыннар, күр, аз ич!
Син — биек очалган
горур кош ич, Бабич.
Хыял дус, ул кошның
канатына ябыш.
Каурыен булса да
калдырыр... Әй, Бабич,
исмеңнән ничә ел
шигъри күк балкый ич.

Күпләргә ут бирдең,
шигъри ут, син, Бабич!
Исемеңә җыр язам —
багышлау — ул бар эш!
Син көч бир, туган тел,
илһам бир, әй, Бабич!

* * *

Гүяки, сабантуй!
Гүяки, зур ярыш!
Шигырьдә ярышу —
сүз атында чабыш.
Син кайда, әй Бабич!
Җиңәрсең син барсын,
канатың, көч-атың,
талантың — ул бар ич!

Әй, мәшһүр шагыйрь, син —
моң кошы, сүз кошы,
кайт бүген — шигырьдә
бер генә сүз кушчы?!
Көтәбез сагынып,
бәйрәмнәр, күр, күп ич.
Сабантуй — мәңгелек!
Әй, кайт син! Биек оч!
Лачын кош, җырчы кош!

* * *

Иң башта далада,
аннары Уфада
Йолдызлар күргәндер
синең шат күзеңне,
алчак ак йөзеңне!
Аннары дусларың!—
Сокланган күп кордаш...
Сагынсын һаман да
шул чакны чал Кудаш...
Гасырның башыннан
ахырына җиткәннәр
сине бер күргәннәр —
остазым дигәннәр —
алар күп, исәннәр;
һәрчак сине алар
остазы исәпләр!
Әй, яңгырат, кайт та бер,
Өфенең залларын.
Уйна, айга ашып
атаклы мандолин!
...Я мәшһүр көлдергеч
сөйләсен мәзәкләр,
һөҗүе утында
сәүдәгәр — «мәләк»ләр
канатын көйдерсен!
Көлдерсен, көлдерсен!—

«Гаебене аңлар» [1]лык
халәткә китерсен!
Кайтып бер, бизәкле
капкасын ачса соң —
бер күрер идек ич
«Исемнәр бакчасы»н!
Шигърият кырларын
гөл иле ясар гел —
булышмас дисеңме
аңа соң «Газазил»?
Дошманнар күп булыр —
ә син яз анда да:
усалрак бит «Шөпшә»,
көчсез ул — «Кандала»...
Өлкәннәр үз итә
өзелми яныңнан:
Бүген, күр, Гафури,
иртәгә — Галимҗан.
«Галия» [2] әй гөрли,
Гыйлемме ул җыя?
Бал корты — шәкертләр —
тузгыган күч гүя,
тәртипкә чакырыр
«ректор»ыгыз — Зыя
Камали — син язган
тырыш «корт анасы»...
Казакътан, үзбәктән,
Дагстан, чиркәстән —
җыелган әй күпме
юксыллар баласы!
Бирегез аң-белем,
зур үссен рухият.
...Унҗиденче елда
килде тик — хөррият!

* * *

Әй, барлык тавышыңа
җырла, Шәйхзадә!
Моңарчы үтелгән
гомерләр, их, зая!
Тик дөнья катлаулы —
таякны кем алыр?
Байраклар күп төрле —
«юл авыр, болгавыр...»
Галимҗан Мәскәүдә,
Мәскәүдә — Мулланур...

[1] Куш җәяләр эчендәге сүзләр — Бабич шигырьләреннән.

[2] «Галия» — Уфадагы мәдрәсә исеме.

Кай якка ул барыр?
Аптырап йөргәндә
чакыра Оренбур...
«Кармак» [3]ка — һөҗүгә
мәйдан бар, урын зур,
барам, көт, Оренбур!

...Тик каян калка соң
тагын бу фетнәләр!
Яшь башны алар соң
кайларга илтәләр?..
Аңга кил — хаталар
күбәя, сузыла...

Без сезгә кушылдык,
кабул ит, кызыллар!
Сез — хаклык дуслары,
сез — Дутов дошманы...
Таныды бит Ленин
яшь Башкортстанны!
Мин язам, әй халкым!—
Сөйлимен бу хакта —
Башкортка — халкыма
«Көйле» ул «хитап»та!
Халкымны чакырам
иң дөрес юлга мин...

...Ә үзең?
Кайда син?
Яктыга чыккачтын
сүндеңме, Бабичым?!

* * *

Мәңгелеккә калды
җырыңда күңелең —
ак җаның... Инде оч,
иңлә син ил күген.
Син, димәк, мәңгелек
җыр өчен туган көч,
син — лачын, җырчы кош!
...Кошлар күп. Күңел дә
йолдызга, әй, бай ич.
Яктырта йолдызың,
ул якты, гел нурлы.
Исме дә матур ич:
— Шәйхзадә Бабич!
Ба-би-ич!

*1980—81*

[3] «Кармак» — Оренбургта чыккан сатирик журнал.

Әмирхан Еники

# СОҢГЫ КИТАП

## Урам буйлап

Каргалының үзендә кайтып керерлек бер якын кешебез калмаса да, мин сугыштан соң бер-ике тапкыр анда булып киткән идем. («Туган туфрак» хикәясе шул чакта язылды). Иң соңгы кайтуым 72 елның җәендә булды. Бу юлы мине Уфадан Гыйниятулла абзый, энесе һәм улы белән бергә, үзенең машинасында алып кайтты. Рульдә әлбәттә улы иде. Машина белән булгач, без Каргалының бөтен яланнарын — «Чабыл тау» итәгеннән алып, «Әркәсле», «Кара кош»ларга чаклы әйләнеп чыктык. Чәрмәсән буенда да булдык. Кичен «Каргалы тамак»ка кайтып, Гыйниятулла абзыйларга кардәш тиешле Хөсәен картта кунып, икенче көнне «Ташлы күл» аша «Ачылы күл»гә дә китеп бардык. Бик күңелле бер сәфәр булып калган иде ул.

Хәзер инде менә хыялым белән генә булса да туган авылымның урамыннан тагын бер узасым килә.

Кайбер үзем белгән һәм кешедән ишеткәннәрне искә төшерер өчен. Кызганычка каршы, башта ук телгә алынган әлеге «Каргалы тарихы» тулысынча минем кулыма кермәде, шуның аркасында Каргалының нәкъ менә үзенә караган өлеше белән миңа танышырга да туры килмәде. Ә ишеткән-күргәннәрдән генә чыгып сөйләү шактый рискованный эш — ялгышулар да, төгәлсезлекләр дә булырга мөмкин. Ләкин башка чарам юк, авыл тарихын яхшырак белүчеләр мине гафу итсеннәр!

Хуш, урам буйлап узабыз. Бу төп урам, бер өч чакрымга сузыла торгандыр. Һәрбер зур авылдагы шикелле ул монда да, инеш агымына карап, өчкә бүленеп йөртелә: югары оч, урталык һәм түбән оч. Билгеле, 150 ел дәвамында Каргалы бик нык үсә. Төп урам үзе дә һаман сузыла, аңа янәшә (параллель) урамнар да, шуларны аркылы кисеп узганнары да әкренләп барлыкка килә. Алар төрле исемнәрдә йөриләр. Мин белгәннәрдән, мәсәлән, югары очта зур гына Шатон урамы бар, урталык белән түбән оч арасында, инешкә таба Төбәк дигән җир дә бар. Моны Каргалының иң борынгы җире диләр. Шулар кебек төрле исемдә йөргән урам яки урыннар аз булмаска тиеш, ләкин мин аларның күбесен ачык кына белмим. Мәсәлән, авылда «эт җыены» дип сөйләгәнне еш кына ишетә идем, ә кайда, нәрсә ул — шуны ничектер һаман белә алмыйча йөрдем. Бактың исә, «эт җыены» дигәннәре ул безнең бабакайлардан ерак та түгел, югары оч белән урталык арасында бер урын икән. (Кемнеңдер капка төбе булса кирәк).

Ахыры. Башы журналыбызның узганчы санында.

Шунда кичкырын эштән бушаган ир-ат җыелып, тәмәке көйрәтеп, төрле мәзәк сөйләп, уткән-сүткәннән көлеп утыралар икән. Анда тел чарлаганнар, кызык уйлап чыгарганнар, күзләренә чалынган һәркемнең берәр көлке ягын тапканнар — кыскасы, халык «эт җыены» дигән исемне бик белеп таккан ул урынга. Бер генә мисал. Әйтик, авылда кемдер кемгәдер кызын ярәшер өчен башкода булып бара. Мондый мөһим вакыйга кешеләр теленә кермичә калмый. Һәм озак та үтмичә «эт җыены» бу вакыйганы менә болайрак ясап чыгара: Сукыр Хәлләсукыр Хәсәннең сукыр атын җигеп, сукыр Усманның сукыр малаеннан сукыр Гомәрнең сукыр кызына башкода булып барган... Менә шул. Ләкин бу «мәзәкнең» хикмәте шунда ки, ул коры уйдырма гына түгел, аның, ничек дим, үзенә күрә реаль җирлеге бар. Чынлап та шул вакыйгага катнашучылардан берсенең күзенә кайчандыр ак төшкән, икенчесе тагын чепи күзле икән, өченчесенең дә бит-күз тирәсендә ниндидер кимчелеге табылган, шуның өстенә җитмәсә, җигеп барган атының да бер күзе ага торган булган. Һәм шул җиткән дә — бөтенесен җиңел кулдан сукырга әйләндергәннәр дә куйганнар. Тик авылның көлә-көлә эче генә катсын!

Ярый, «эт җыенын»да уздык ди. Сезне, бәлки, авылның гомуми күренеше кызыксындыра торгандыр — ничегрәк ул, төзекме, тазамы, матурмы? Әйтергә кирәк, Каргалының утырган җире табигатькә бай түгел, зур суы да, урманы да юк, әмма авыл үзе бөтен, таза иде. Йортларның иң зур күпчелеге кара-каршы салынган, такта белән япкан йортлар. Капка-коймалары да тактадан. Еш кына калай белән япкан зуррак, матуррак йортлар да очрый. Берничә чардаклы йортны да беләм мин. Шулай ук бер генә бурадан салынган, салам түбәле, җил капкалы өйләр дә бар иде, ләкин алар, унга бер дигәндәй, әллә ни күп түгел иде. Кыскасы, халыкның зур күпчелеге урта һәм уртадан өстенрәк тормышлы хуҗалардан гыйбарәт булганга күрәдер инде, авылның гомуми күренеше дә «уртадан югары» әйбәт, төзек кенә иде. Таш пулатлар булмаган кебек, читәннән үреп, балчык белән сылаган өйләр дә юк иде шикелле — һәрхәлдә андый өйне мин хәтерләмим.

Каргалының бер кимчелеге булса, ул да аның яшеллеккә ярлылыгы иде. Агач бакчалары аз иде, җимеш агачлары бөтенләй юк диярлек, булса да шул сәрби дә сирень, миләш тә шомырт... Болары да сирәк йортларда гына. Бөтен авылның бакча дигәне ул абзарлар артындагы бәрәңге мәйданы — менә ансыз инде бер генә йорт та юк иде. Каргалы «бульбасы» шәп иде — бәләктәй кызыл бәрәңге!

Әйе, Каргалы зур авыл. Өч мәчете бар, өч мәхәлләгә бүленә. (Авылның зурлыгына караганда мәчетләр күп түгел иде). Бу җиргә иң беренче килеп утыручылар 20 хуҗалык (йорт) булса, 1926 елда инде аның саны 520 гә җитә. Йөз илле ел эчендә әнә ничек үскән ул!.. Каргалының җире дә күп, басу-кырлары да еракта иде. (Җир мәйданы 16 мең гектарга җиткән дип ишеткәнем бар). Мәгълүм булганча, революциядән соң, егерменче елларның урталарында артык зураеп киткән авыллардан иркенрәк җиргә күчеп утырулар башлана. Бу процесстан Каргалы да, билгеле, читтә калмый. Аның халкы да төрле тарафка аерылып чыга башлый һәм шул рәвешчә Каргалы җирендә кечерәк кенә яңа авыллар — елгачык үрендә «Каргалы баш», елгачык түбәнендә «Каргалы тамак», Әркәсле ягында «Бакча», Чабылтау артында «Зиреклебаш» барлыкка килә. Янә тагын «Бишкиртек» дигәне дә бар имеш, ләкин мин андый авылның барлыгын белмим — «эт җыены» уйлап чыгарган мәзәк кенә түгел микән? (Хәер, берничә йорт авыл очындагы киртләчле тау итәгенә күчеп утырган шикелле, бәлки шуларга бу «матур» исемне такканнардыр). Шуның өстенә күпмедер хуҗалык Чиләбе өлкәсендәге «Чобар күл» дигән җиргә дә күчеп китә. Мондый «аерылып чыгулардан» соң төп Каргалы үзе кечерәеп

һәм сирәгәеп калырга тиеш иде. Ләкин мин кайтып йөргән чакларда ул һаман искечә зур иде, тоташ иде, таралганы һич тә сизелми иде. Тыгыз утырган зур авыл үзенең йөзен тиз генә югалтмый, күрәсең. Әмма Каргалының чынлап үзгәрүе (дөресрәге, таралуы) сугыш вакытында һәм сугыштан соң башланды булса кирәк. Әйтергә генә ансат, Ватан сугышы фронтларында Каргалының биш йөзләп кешесе ятып кала. Теге вак авылларны кертеп исәпләгәндә дә бу коточкыч зур югалту! Алар барысы да бит йорт башы яки йорт терәге ирләр... Мондый югалтудан соң авылың бөтенләй юкка чыгып бетсә дә гаҗәп түгел. Әмма Каргалының беткәне юк. Ул яши, өтелеп, сирәкләнеп калса да һаман шул Каргалыкай буенда утыра ул. Тик кешеләре инде башка — сугыштан соң туган, өлгергән кешеләр. Борынгы картлар юк, беткән алар, булганнары исә миннән олырак яки минем яшьтәге картлар. (Бик күп малайлардан сирәк кенә сакланып калган замандашларым дияр идем мин аларны)... Шулай ук читтән килеп утыручылар да бар булса кирәк. Кайчандыр аерылып чыккан «Зирекле баш»ны да яңадан төп авылга күчергәннәр. Кыскасы, чишмә типкән, үлән үскән җирдә тормыш бетми — һаман дәвам итә ул. Бәрәкәтле җир кешеләрне үзенә җыя да, бәйли дә, тик аңа иминлек белән тынычлык кына булсын!

Хәзерге вакытта Каргалы терлек симертү (откормочный) совхозының бер бүлеге икән. Бу бик әйбәт хуҗалык булырга тиеш, чөнки Каргалының мал йөртерлек җирләре күп, элек заманда да авылдан унбиш көтү чыга торган булган.

Һәрбер зур авылдагы шикелле Каргалыда да халык бик чуар иде. Барысы бер яктан килүләренә һәм тел-гореф җәһәтеннән бер төсле үк булуларына карамастан, алар арасында шактый зур аерма да яшәп килгән. Иң элек алар сословиеләргә бүленгәннәр: күпмедер өлеше морзалар, калганнары исә гади крестьяннар. Бу соңгылары да төрле тамырдан чыгып, төрле исемдә йөргәннәр: «Мулла халкы» (Янгуразовлар), «Азый халкы» (Азиевлар), «Бүре халкы» (Килмәмитовлар)... «Мулла халкының» исеме кайдан алынгайнын югарыда әйткән идем инде (минем инәй шул халыктан), «Азый халкы» дигәне кеше исеме белән бәйләнгән булса кирәк, ә менә «Бүре халкы» дигәнен мин күпме сорашсам да ачык кына белә алмадым. Аларны усал, кара халык диләр иде, шуның өчен генә «бүре» кушканнармы, әллә моның бик ерактан килгән башка берәр тамыры да бармы? — билгесез.

Бу әйткәннәрдән тыш авылда бер үк фамилия йөрткән һәм бер тирәдәрәк оешып утырган ваграк төркемнәр дә бар иде — мәсәлән, Үтәшевлар, Мамлеевлар, Сундюковлар... Боларның да бер ишеләре морза (Мамлеевлар), икенчеләре исә (Үтәшевлар) бу дәрәҗәдән мәхрүм. Билгеле инде, сословиеләр арасында тигезлек булуы мөмкин түгел. Димәк, үзара мөнәсәбәтләр дә шуңа карап йөргән: морзалар үзләрен өстен санаганнар, «түбәннәр» белән аралашмаска тырышканнар, мәсәлән, «Бүре халкы»ннан кыз алмаганнар, кыз бирмәгәннәр. Гомумән алар нәсел тикшерергә яратканнар, борын'еш кына ишетелә торган «затлы» яки «затсыз» дигән төшенчә дә әнә шуннан килеп чыккан. Менә ни өчен морзалар элек-электән үк бары үзара (аерым очракларны исәпләмәгәндә) кыз алышып, кыз бирешеп килгәннәр һәм нәтиҗәдә Еникеевлар белән Терегуловлар бер-берсенә туганлык җепләре белән бик нык бәйләнеп, чуалып беткәннәр. Бу бәйләнешләрне минем атакай бик яхшы белә иде. Һәм мин аны бик гаҗәпләнеп тыңлый торган идем. Чөнки мин үзем «туганлык җепләрен» белү җәһәтеннән бик «аңгыра» булып чыктым, шактый якыннарның да кайсы яктан, ничек туган булуларын гомерем буена диярлек аерып бетә алмыйча йөрдем.

Әйе, кайчандыр элек заманда әнә шулай булган, әмма револю-

циядән соң сословиеләр юк, бетерелгән иде инде. Минем үземә сословие мөнәсәбәтләрен күрергә дә, татырга да туры килмәде, чөнки мин үскән Дәүләкәндә байлар бар иде, ярлылар бар иде, ләкин морзалар юк иде. Каргалыга кайткан чакларымда гына «морза» сүзен ишеткәли идем, хәер, анда да инде берәү дә үзен исән баштан морза дип атамый иде. Хәзер барысы да бер тигез, барысы да гади авыл халкы, крестьяннар... Әмма шулай булса да «морзалык» дигән уй-караш кешеләрнең, ничек дим, каныннан чыгып бетмәгән иде әле, ара-тирә сүздә яки мөнәсәбәттә үзен сиздереп куйгалый иде.

Кечкенә бер эпизод — әле дә онытылганы юк. Мөхәммәдъяр дәдәкай туеннан соң, 22 елның гаҗәеп матур килгән җәендә булса кирәк, мин кемгәдер утырып, тагын Каргалыга кайттым. Ишек алдына үтеп, тарантастан төшүемә, француз бөркәнчек ябынган Хәнифә җиңгәчәй— яшь килен — җәһәт кенә каршыма килде дә чүгенеп, ягъни реверанс ясап) миңа «Исәнмесез, кече морза!» дип ике кулын сузды. Мин бу көтелмәгән хәлдән шактый югалып калдым, кызарып-каушап кына җиңгәчәйгә кул бирдем, ләкин шул минутта гына аның болай зурлап күрешүен аңлап җиткермәдем. Тик бераздан гына минем бәләкәй башыма килеп җиткәндәй булды: кара, мин морза икәнмен ләбаса! Кече морза! Менә ни өчен яшь җиңгәчәй минем белән, гафу итегез, 13 яшьлек маңка малай белән чүгенеп, ике куллап күрешкән икән. (Безнең Каргалыда яшь киленнәр киявенә туган тиешле ирләр белән күрешкәндә хөрмәт йөзеннән әнә шулай чүгенеп алалар, ягъни реверанс ясыйлар иде. Бу аларда бик борыннан килгән гадәт. Хәзер юк, күптән беткән). Шулай итеп, мин дә зур хөрмәткә лаек булдым. Дөрес, морза булуның хәзер өч тиенлек тә әһәмияте юк, моны бөтенесе белә дә торганнардыр инде, ләкин шулай да борынгы гадәт буенча «морза» дип зурлап дәшүне онытып бетермәгәннәр имеш! Соңыннан күпме күрешергә туры килсә дә җиңгәчәйдән мин алай чүгенеп тә чөеп дәшкәнне бүтән ишетмәдем.

Ни өчендер минем атакай Каргалы халкын мактарга ярата торган иде. Затлы, төпле халык ди иде, инсафлы, әдәпле, туган җанлы, ачык күңелле, укыган зур кешеләр дә чыккан дип тезеп китә торган иде. Ихтимал, бу аның Каргалыда үткәргән ир-егет чакларын, өйләнеп бәхетле яшәгән вакытларын һәм якыннан аралашкан, йөрешкән дус-ишләрен сагыну белән бәйләнгәндер. Картлыкка таба ул дус-ишләрнең күбесен югалтсаң, тормышың һаман авырая, күңелсезләнә барса, үткәннәрне сагынып утырудан башка ни кала?!. Сагынырлык үткәнең булу үзе бер зур юаныч! Әмма мин үзем яшьтән үк атакай сүзенә ышанып бетмәдем, чөнки минем дөньяга күзем бөтенләй башка вакытта, башка шартларда ачылды. Әлбәттә, һәр җирдәге шикелле Каргалыда да яхшы кешеләр аз булмагандыр — бу кадәресен берәү дә инкарь итмәячәк (намуслылык, инсафлылык гомумән күп кешеләргә хас сыйфат, тик ходай аны һәркемгә дә тигез бирмәгән). Шулай ук Каргалы халкының уку-белем ягыннан күрше тирәдәге авыллардан өстен торуына да ышанырга була. Шулайрак танылган да Каргалы... Әмма ләкин бердәмлек белән татулыкка килгәндә, юк, монысы инде, туптуры гына әйткәндә, иллюзия! Халыкның сословиеләргә бүленгәнен күрдек, һәм шушы сословиеләрнең үз эчендә дә кешеләр тигез түгел, күптән инде төрле социал катлауларга бүленеп беткәннәр. Берәүләре баеган берәүләре бөлгән, күпчелек исә шушы ике уртада. Әлеге түбән сословиядән саналган «Азый», «Мулла», «Бүре» халыкларының бик таза тормышлылары булган шикелле, «морзаларның» да атсыз-тунсыз азап чиккән фәкыйрьләре бар иде. Кыскасы, мәшһүр Каргалының үзендә социал типларның төрлесен — баен, сатучысын, ярлысын, хәерчесен, укыганын, укымаганын күрергә, хәтта зимагуры белән карагын да очратырга мөмкин иде. Һәм кемнәр генә чыкмаган бу чуар халык-

тан — большевигы да (Нигъмәт Еникеев), меньшевигы да (Гомәр Терегулов), эсеры да (Хәллә Еникеев)... (Билгеле, мин монда мисал өчен бирәр генә фамилияне күрсәтү белән чикләнәм). Бәс шулай булгач, нинди бердәмлек һәм татулык турында сүз булырга мөмкин ди?! Антагонизм һәм көрәш — менә нидән гыйбарәт Каргалының да тарихы. Революция елларында, шулай ук колхозлашу вакытында бу көрәш гаилә эченә керә, ике туган арасында башлана. Срур тутакайның сөйләгәне әгәр дөрес булса, Каргалы кешесе Габдрәхим Еникеев, кызыллар Бохараны азат иткәннән соң, шәһәрнең беренче коменданты булган, ә шул ук вакытта аның бертуганы Искәндәр акларда офицер булып йөргән. Ике братның үзара талашканын элегрәк минем дә ишеткәнем бар иде ди, Срур тутакай... Югарыда мин Еникеевларның туганлык җепләре белән уралып беткәнен әйткән идем, әмма сыйнфый көрәш законы җепләрне генә түгел, чылбырларны да өзгәләп ташлады. Моның дистәләрчә мисалын китерергә мөмкин булыр иде, ләкин мисалсыз да бик яхшы аңлашыла торган хакыйкать.

Инде үзем белгән кайбер кешеләр турында сөйләп үтәсем килә. Заманында Каргалыда Рәхмәтҗан дигән зур бер бай булган. Мәкәрҗә ярминкәсенә олау-олау тире-яры илтеп, аннан чәй-шикәр төяп кайтып сәүдә иткән диләр. Атакай аны «Рәхмәтҗан җизни» ди иде, димәк безгә кардәшлеге дә булган икән. Мин аңардан калган йортны да әзрәк хәтерлим әле. Ул бабакайлардан түбән очтарак, кайчандыр тазашәп, ә хәзер шактый искергән тузган калай түбәле зур бер йорт иде. Анда Рәхмәтҗан байның улы Камалетдин абзый тора иде. Картаеп барган кеше иде инде, атакай да аңа «Камалетдин абзый» дип дәшә иде. Менә шул зур колаклы, зур борынлы, битен эре сызыклар ерып төшсә дә үзенчә ничектер мөлаем чырайлы һәм мәзәк кенә сүзле абзый НЭП вакытында атна саен Дәүләкән базарына кырык чакрым Каргалыдан җәяүләп килә торган иде. Башында керләнеп беткән эшләпә, өстендә озын чабулы әллә иске бушлат, әллә иске җилән, аягында читек өстеннән киндерә белән урап бәйләгән чабата, кулында юан гына таяк — арып-талып безгә килеп җиткәч, өйгә дә кереп тормыйча, тизрәк түбән баскычка лып итеп хәл җыярга утыра иде. Димәк, ул чакта аның аты-мазары булмаган. Арып килүенә карамастан, ул энем белән миңа ни өчендер гел генә: «Нихәл сез, очлыкайлар!» дип дәшә торган иде. Күрәсең, үзенчә шаяртуы булгандыр инде...

Мин Камалетдин абзыйны чынлап кызгана идем, нигә килеп йөри, нигә атлы кешегә утырып килми дип уйлана идем. Әллә утыртмаганнар, әллә үзе утырырга теләмәгән — хода белсен! Базарда ни эше калган дисәң, ул шунда тире-яры җыючыларга булышып, үзенә әз-мәз акча төшерә икән. Байлык бер айлык, хәерчелек саклап тотсаң гомер буена җитә диләр... Камалетдин абзый да әнә шундый хәерчелеккә дучар булган бер кеше иде. Һәм белгән байлар гадәтенчә салырга да бик ярата иде, мәрхүм!

Ә менә бай Гали Дәүләкән базарына шәп атта, яхшы тарантаста килә торган иде. Ул безгә керми иде, ләкин атын капка төбендә туктатып, тарантастан төшмичә генә атакай белән сөйләшеп китә иде. Мин дә аны шул чакта гына күреп калгалый идем. Тулы-таза гәүдәле, шома-тулы битле, матур зур күзле бу кеше атадан калган мал белән түгел, ә үзенең зирәклеге һәм булдыклылыгы аркасында ничектер баеп киткән имеш. Авылдагы иң матур йортны, янәшәсендәге таш кибетне, ишегалды түрендәге калай белән япкан амбарларны да ул инде үзе салдырган. Ләкин шулардан башка (әйтик, җир биләү, мал асраута килгәндә), аның әллә ни зур байлыгы булмаган дип тә сөйлиләр иде. (Артык баеп китәргә бәлки өлгерә алмыйча да калгандыр.) Шулай да бөтен авыл аны «бай Гали» дип кенә йөртә иде. Колхозлашу башланганчыга кадәр үзенең шәп йортында торган — бу вакыт-

та инде ул сату итмәгән, ә базар йөреп дәүләткә тире җыйган. Соңыннан байдан бушатылган йортны күпмедер вакыт китапханә итеп тотканнар, аннары ни өчендер мәктәп ихатасына күчереп, өен үзенә, чардагын үзенә аерып салып куйганнар дип ишеттем... Йортның хуҗасы башта Архангельск якларында булып, шуннан соң Сәмәркандта озак кына торып, ахры гомерендә Уфага кайтып, шунда вафат була. Аның улы Касыймны бик әйбәт хирург диләр иде, ләкин ул да инде дөньяда юк.

Атакай белән Гали абзый бер заман кешеләре, борыннан ук дус та булганнар, бер-берсен табышкач, соңгы көннәренә хәтле хат та язышып тордылар. Моннан берничә ел элек кенә атакайның кайчандыр Гали абзыйга җибәргән фоторәсемен миңа Уфадан алып кайтып бирделәр. Урам фотографы гына төшергән рәсемнең артында җыр сыманрак «шигырь» дә бар. Менә шуннан бер генә өзек:

Бар иде безнең яшь вакыт,
Уйнап-көлеп йөргән шат вакыт.
Үткән гомерләрне сизми калдык,
Килеп җиткән имеш карт вакыт.

Бу юлларны язганда атакайга 75 яшь булган. Әйе, үткән шул инде, яшьлекләре генә түгел, заманнары, чорлары да күптән үтеп киткән... Һәм үтәчәк икән ул, кем генә булуыңа да карамастан!

Әмма үткәнгә борылып кайтсаң, һич уйламаган хәлләргә тап буласың. Менә искә төште әле, бик күптән инде мин кемнәндер (әллә Шәриф җизнидән, ләкин тәгаен генә әйтә алмыйм) шундыйрак бер сүз ишеткән идем: чын булса, Хөсәен Ямашев та бай Галинең чардаклы яшел йортында берничә көн кунак булып киткән имеш! Гаҗәпләнергә ашыкмагыз! Хикмәт шунда, тарихка исеме кереп калган татар меньшевигы Гомәр Терегулов Гали абзыйның бертуган агасы... Менә шул Гомәр Ямашевны Каргалыга алып кайткан да булса кирәк. Дөресме бу?.. Әлбәттә, бернинди язма дәлил юк, бары сүз генә, ләкин булуы да бик ихтимал. Моның өчен ике төрле нигез бар: беренчедән, алар Казандагы учительский школада бер заманда укыганнар, димәк, Каргалыга кайтулары да шул чакта булырга мөмкин, чөнки шәкертнең шәкерткә ияреп кунакка кайтуы элек гадәти бер эштән саналган. Икенчедән, «Урал» газетасының соңгы берничә номеры Гомәр Терегулов имзасы белән дөньяга чыгып кала. Бу факт Ямашев белән Терегуловның «Урал»ны чыгарган вакытта шактый якын бәйләнештә булулары турында сөйли түгелме?.. Әгәр шулай икән, димәк, «Урал» чыккан чакларда яки чыгудан туктатылгач, Гомәрнең Хөсәенне үз авылына кунакка алып кайтуына да ышанырга була. Минемчә, искитәрлек берни дә юк монда. Тормышта кем кем белән генә очрашмый да аерылышмый.

Хуш, тагын нәрсә?.. Каргалының мин белгән кешеләре әле телгә алынганнар белән генә чикләнми, әлбәттә. Безнең кардәш-ыру күп иде, кайбер якыннарына мин малай чакта барып та йөри идем. Әйтик, Саттый (тулы исеме Гапсаттар) җизниләргә яки Сәгыйт бабакайларга. Боларның берсе безнең бабакайга, икенчесе әбыкайга бик якын кардәшләр. Икесе дә бездән түбән очтарак торалар. Саттый җизниләрнең ишек аллары үзе бер ялан диярсең — ифрат зур иде, тапталмыйча яткан җирләрендә кыр чәчәкләре дә үсә иде. Малны да заманында күп асраганнар булса кирәк, утлауларындагы еллар буенча җыелган, тапталып басылып беткән иске тирес әйләндереп алган читтәннән дә биегрәк булып өелгән иде. Без, бала-чага, тауга менгәндәй шуның өстенә менеп уйный идек.

Саттый җизни турында кызык кына нәрсәләр сөйлиләр иде. Ата-анасыннан зур байлыкка ия булып калгач, аны минем бабакайның тутасына, яшькә үзеннән күп олы кызга өйләндергәннәр. Кияү әле

чынлап та бик яшь булган, өйләнгәч тә малайларга ияреп чана шуарга йөри икән. Әгәр «җизнине» тау шуганда орсалар-елатсалар, хатыны Гөлҗиһан табагач күтәреп чыга икән дә бөтен малайларны пыр туздырып куа икән. Бик үткен-чая булган диләр яшь килен!

Болар борынгы кешеләр, үзләре генә түгел, балалары да күптән картаеп, үлеп беттеләр. Балаларының балалары инде картайдылар. Иң олысына — медицина докторы, профессор Гыйниятулла абзый Тереголовка хәзер 89 яшь! Иң кечеләре — Мичурин шәкерте, дәүләт премиясе лауреаты, профессор Хәсән Еникеев та минем чамаларда булыр. Бу — Саттый җизниләрнең әлеге ялангай ишек алдында аунап үскән малай. Аның шул чагын мин аз гына хәтерлим, ләкин соңыннан безгә бүтән беркайчан да очрашырга туры килмәде.

...Ә менә Сәгыйт бабакайларның ишек аллары тар иде, каралтылары рәттән тезелеп киткән иде — шулайрак күз алдымда саклана. Аның каравы, яшел калай түбәле йортлары зур да, бик таза да иде. Бөтен җирдә тәртип, чисталык, ничектер шәһәр йортларын берaз хәтерләтә иде. Сәгыйт бабакайның ике улы — Гомәр белән Гали — учительләр иде, бәлки аларның да бу йортка тәэсирләре булгандыр. Шулай ук дәүләт думасы члены Гайса морза Еникеев та Сәгыйт бабакайның якын туганы. (Бертуганнар түгел микән?) Күрәсез, алар үзләренә аерымрак, мәдәниерәк (яки «затлырак») токым булганнар. Безгә кардәшлекләре, әйткәнемчә, әбыкай ягыннан.

Гайса морза бер вакытны Уфадан безгә (Дәүләкәнгә) дә килеп киткән иде. Зур гәүдәле мәһабәт кеше, йөзе-бите дә эре, чал чәчле, яланбаш, өстенә нечкә киндердән иркен күлмәк киеп, билен тар гына каеш белән буган. Атакай мине, аңа күрсәтер өчен булса кирәк, залга чакырып алды. Гайса абзый миңа ни өчендер русча дәште, мин билгеле, аңа җавап бирә алмадым. Шуннан соң ул зур кулы белән минем башымны тотып, әкрен генә селкеткәндәй итте, ниндидер бер җылы сүз дә әйтте, ләкин мин бик кызарып, залдан тизрәк чыгып киттем.

Гайса морза Еникеевның тарихы, минемчә, игътибарга лаек. Үзе ул учитель, аннары Оренбург байлары Хөсәеновларның башта доверенные, соңыннан опекуны булган кеше. Өченче һәм дүртенче дәүләт думасына сайлангач, аның трибунасыннан изелгән вак милләтләрнең аң-белем, культура өлкәсендәге мәнфәгатьләрен яклап, аларга күбрәк хокуклар таләп итеп еш кына речьләр сөйләгән. Аның чыгышларына Ленин үзе игътибар иткән дигән сүз дә бар. Революциядән соң Вятка шәһәрендә, аннары Уфада торып, 31 елны үз әҗәле белән вафат була. Әле үткән гасырның ахырында аның Оренбург һәм Уфа губерналары буенча борынгы татар-башкорт җырларын җыеп йөргәнен югарыда әйткән идем инде. Кыскасы, татар дөньясының катлаулы заманында яшәп, нидер эшләп, ниндидер эз калдырып киткән шәхесләрнең берсе. Алар аз булмаган — милләтенә үзләренчә хезмәт итәргә тырышкан һәм күптән онытылган шәхесләр...

Азрак читкә тайпылдым бугай... Каргалыдагы мин белгән якын кардәшләр, билгеле, барысы да алай бер тигездән түгел иде. Кайберләре баерак, кайберләре ярлырак, ләкин артык фәкыйрьләре юк иде шикелле, һәрхәлдә, миңа андыйларын күрергә туры килмәде. Әмма шулай да мине бик гаҗәпләндергән бер хикмәтле кардәшләребез бар иде. Алар дүрт брат: Хәсән, Хәллә, Гомәр һәм иң кечеләре Әбүбәкер. Бабакай ягыннан безгә бик якын кардәшләр. Мин Хәсән абзый белән Әбүбәкерне яхшырак белә идем. Аларның йортлары урам аша, мәчеттән аз гына югарырак. Сирәк кенә булса да шуларга кергәли идем. (Минем чамадарак бер кызлары бар иде, күрәсең, шуна ияргәнмендер инде.) Ләкин, дөресен генә әйткәндә, аларның йорты мине беркадәр шомландыра торган иде. Ник дисәң, гаҗәп тә искергән, тузган, котсыз, шапшак бер йорт иде ул... Юк, аны һич тә фә-

кыйрьләр йорты дип булмый — кара-каршы салынган, такта белән япкан һәм кайчандыр ул таза-бөтен дә булгандыр, әлбәттә... Әмма хәзер шулкадәр бетәшкән, ходаем, әйтерсең аңа йөз ел буена да кеше кулы тимәгән. Бүрәнәләре кап-кара, түбәсендә яшел мүк, тәрәзә пыялалары керосин тапыдай зәңгәрләнеп тора. Болдыр баскычлары да, өй алдының идән такталары да күптән черек — басканда бер башы батып китсә, икенче башы күтәрелеп китә... Инде ызбаның эченә кергәч, андагы тәртипсезлеккә, шакшылыкка исең китәр. Өйнең бөтен түрен иңләп алган киң сәке өстендә сәләмә юрган, каткан туннар буталып ята, ястык-мендәрләрнең тышы юк, бер кат сүрү генә, җөйләреннән мамыклары чыгып тора. Монда, күрәсең, урын җәю, урын җыю дигән нәрсә юк — кичтән менәләр дә яталар, иртән торалар да китәләр. Шулай ук чәй урынын да җыеп тормыйлар, өстәлдә эчелгән чәшкәләр, каткан ипи сыныклары, өсте ябылмаган сөтләре, ә өйдә умарта күчедәй чебен уйнап тора... Мич аралары, морҗа буйлары тулы таракан... Мин гадәттә бу өйгә курка-курка гына керә идем һәм тизрәк чыгып китү ягын карый идем. Һәм нигә болай икән дип аптырый да идем. Чөнки башка бер өйдә дә мондый өелеп яткан шапшаклык юк, иң ярлы дигәнендә дә үзенчә чисталык — җыештырган, себергән, бусагасына хәтле сап-сары итеп юган — аяк салмыйча атлап кермиләр дә. Ә монда? Әллә искиткеч мәнсезлек, әллә коточкыч ялкаулык, әллә баштан ашкан хәерчелек — аңлап булырлык та түгел. Дөрес, байлык юк инде ул, ис кенәсе дә сизелми, ләкин бит аталарыннан мирас булып калган хәерчелек тә булмаска тиеш. Безнең бабакайлар нәселе электән үк таза хәлле булган, игенне дә күп иккәннәр, малны да күп асраганнар. Боларның аталары Миңнебай карт та шул нәселдән бит, әнә йортның да алты почмаклысын салдырган заманында. Алайса эш нәрсәдә соң? Соңыннан кызыксынып, сорашкан чакта, минем атакай: Хәсәннәрнең хәерчелеге үтә ялкаулыктан, иҗтиһат итмәүдән, ата малын ашап бетерүдән дип аңлата торган иде. Ләкин аларның җирләре күп имеш, тик үзләре файдаланмыйча күбрәк арендага бирәләр, шуның белән яшиләр имеш. (Иксәләр дә бер-ике дисәтинә арыш яки бодай да берничә таяк тары гына чәчәләр икән.) Бәлки шулайдыр да, башкача ничек аңлатасың бу әкәмәт хәлне?!

Мин үзем Хәсән агайны (Каргалыча әйтсәк, агакайны) яхшы ук хәтерлим. Озын буйлы, нечкә аяклы, чандыр бер кеше иде ул, йөзе кара тутлы, әзрәк шадрасы да бар. Үзе тапаган эре сасы тәмәкене җыен чүп-чар кәгазьгә төреп тарта, бармаклары тырнак төбенә хәтле кара-сарыга әйләнеп беткән була. Мин аның бер вакытта да чалбар кигәнен күрмәдем (ахрысы, булмагандыр да), әллә кызыл, әллә көрән төстәге тупас киндердән теккән, төбе асылынып төшкән ычкырлы ыштаннан йөри, башында ертык эшләпә, аягында чабата киндерәсе белән бәйләп куйган иске калош. Әмма ул морза-дворянин! Ул шуны белә һәм шуна карап үзен тота да. Искиткеч горурлык һәм тәкәбберлек үзендә! Шуның өстенә ул философ та әле. Мин аның чүгәләшеп тәмәке тарткан җирдә, янындагы агайларга ашыкмыйча гына акыл сатканын тыңлап торганым бар. Әлбәттә, мин бер нәрсә дә аңламый идем, әмма һәр сүзенә җитди мәгънә биреп, вәкарь белән сөйләвенә, ә агайларның, килешкәндәй, башларын селкә-селкә тыңлауларына караганда, сүз һичшиксез дөньякүләм зур мәсьәләләр турында барган булырга тиеш. Сөйли-сөйли дә ул ахырдан, башын чөебрәк: «Шылай вет ул, абзыкайларым!» дип куя. Янәсе, сез дә, мужиклар, белеп торыгыз!

Әнә шундый бөлеп бетсә дә, ямаулы киндер ыштаннан йөрсә дә «морзалык» һавалыгын югалтмаган кызыклы бәндәләр сирәк кенә булса да очрый иде әле ул чакларда. Хәтта Каргалының үз саилчесе дә бар иде — шул ук Еникеевлардан... Мин дә әле аны яхшы хәтерлим. Чын исемен ачык кына белмим, бәлки Бикмөхәммәт булгандыр, ләкин бөтен авыл

аны «Бирәхмәт» дип йөртә иде. Озын буйлы таза кеше, өстендә озын чикмән, башында җәен-кышын мескен бүрек, иңбашы аша зур гына киндер капчык аскан... Кулында шомарып беткән озын таяк... Капкадан килеп кергәч, ул тонырак калын тавышы белән исәнләшә, хәләхвәл сораша, аннары баскычка утырып ашыкмыйча гына дога кыла. Сәдаканы бер вакытта да сорап алмый, бирсәләр — хуп, бирмәсәләр, сүзе юк. Аның каравы үзе куеныннан кечкенә шешә чыгарып, балачагаларга, үсеп килгән кызларга бармак бите белән генә ислемай сөртеп китә иде.

Авыл халкы бу таза агайны диванага саный иде. Әмма ул диваналарның иң юашы, иң зарарсызы, балалар шикелле үтә беркатлысы. Шуңа күрә аның исеме дә халык теленә бер синоним булып кергән, ягъни артык беркатлы ваемсыз кешегә еш кына үртәп: «Их син, Бирәхмәт!» дип әйтә торганнар иде. Ләкин чын Бирәхмәтнең үзеннән бервакытта да көлмиләр, рәнҗетмиләр, хәтта этләр дә аңа өрмиләр иде бугай... Бөтен табигате белән ул, ничек дим, кешеләрнең шактый тупасланган күңелләрендә ирексездән шәфкать-миһербанлык хисләре уятучы бер алла бәндәсе иде.

Әйе, Каргалы кешеләре бик төрле-төрле, һәм табигый инде, мондый авыл төрле вакыйгаларга да бай булган. Чорына карап, аның өстеннән дәһшәтле өермә-давыллар да узгалаган.

Шуларның берсе, мәсәлән, гражданнар сугышы вакытында булып ала. Мәгълүм ки, 19—20 елларда Татарстан һәм Башкортстанның кайбер төбәкләрендә «Сәнәкчеләр» дигән бер кара фетнә калкып чыга. Баштарак ул беркадәр җәелеп тә китә. Менә шул «сәнәкчеләр»нең зур гына бер төркеме Чакмагош якларыннан Каргалы тирәсенә дә килеп житә. Алар җиде-сигез чакрымдагы Сынны авылында тукталып, шуннан берничә җайдакларын Каргалыга «ультиматум» белән җибәрәләр: давай, сез дә безгә кушылыгыз!.. Ә Каргалы зур авыл, исемле авыл, әгәр ул кушылса, тирә-яктагы ваграк авыллар да күтәрелеп чыгачак, имеш. Нишләргә? Авыл хәрәкәткә килә, кайный, шаулый, ике көн өзлексез җыен (сходка) дәвам итә. Берәүләр чыгу, кушылу ягында, икенчеләр катгый рәвештә каршы... Ахырда бәхәсне хәл итәр өчен Каргалы мәктәбенең мөдире Гыйниятулла Терегуловны җыенга чакырып китерәләр. Әйтергә кирәк, «сәнәкчеләр»нең бер кабәхәт эше — мөгаллим һәм мөгаллимәләрне үтереп йөрү булды, ә Каргалыда инде мондый хәлнең булуы мөмкин түгел, халыкның укытучыларга хөрмәте зур, чөнки укытучыларны үзе күп биргән авыл. Гыйниятулла абзый, билгеле, халыкны «сәнәкчеләргә» кушылмаска өнди, кушыла калсалар, Каргалының харап итәчәкләрен әйтә. Аннары «сәнәкчеләр» хәрәкәтенең контрреволюцион бер фетнә генә булуын, тиздән аның басылачагын яки үзеннән-үзе сүнеп бетәчәген аңлата. Халыкның бит күпчелеге каршы бу фетнәгә... Юк, кушылу асла ярый торган эш түгел. Каргалы өчен бу гомерлек бер кара тап булып калачак! Һәм соңыннан ул җәзасын да күбрәк күрәчәк!

Менә шуннан соң җыен «кушылмаска» дигән карарын чыгара. Инде хәзер бу карарны Сыннида көтеп яткан «сәнәкчеләр»гә җиткерергә кирәк. Кемгә тапшырырга моны? Ахырда бу хәтәр эшне Нигъмәтулла дәдәкайга йөкләгәннәр. Ул бик шәп атка нярсез генә атланып Сыннига киткән, барып җиткәч, сәнәкчеләрнең башлыклары янына кереп тормыйча, тик авыл урамының бер очыннан икенче очына чаклы: «Халык, ишетегез! Каргалылар кузгалмый, Каргалылар кушылмый!» дип кычкырып узган, имеш. Аның артыннан «сәнәкчеләр» чыгып, Каргалы чигенә җиткәнче куа килгәннәр, ләкин куып җитә алмаганнар...

Моны миңа Нигъмәтулла дәдәкай югалганнан соң, Мәдинә җиңгәчәй сөйләгән иде. Чынмы, дөресме бу?.. Ышаныр өчен тагын кемнәндер ишетәсе килә иде. Ләкин кемнән, бик күп еллар узган, ул вакыйгалар-

ның шаһитләре дә калмаган диярлек... Һәм менә 79 елның җәендә Уфага баргач, мин әлеге Каргалы җыенында халыкны «сәнәкчеләр»гә кушылмаска өндәгән Гыйниятулла абзыйның үзеннән сорадым: «Нигъмәтулла дәдәкайның Сынныга җибәрелүе дөресме-түгелме?..» «Дөрес булуы бик мөмкин,— диде Гыйниятулла абзый.— Күп еллар узса да яхшы хәтерлим, җыеннан соң күрше авылларга атлар чаптырдылар. Ә Сыннырга Нигъмәтулланың җибәрелүенә мин бик ышанам, чөнки ул араларында иң кыю йөрәкле, алгыр кеше иде...» Шулай диде Гыйниятулла абзый — вакыйганың үзәгендә булган кеше!

Инде Каргалы тарихыннан тагын бер борынгырак вакыйганы да искә төшерик. Бу — «Әси карак» вакыйгасы.

Хәзер ничектер, әмма мин малай чакларда Каргалыда Әсинең исемен һәм аның көен ишетмәгән кеше булды микән?!.. Аннан соң инде бик күп еллар узды, буыннар алышынды, Каргалы таралды — ихтимал, Әси үзе дә һәм көе дә әкренләп онытылгандыр яки онытылып барадыр. Ләкин бөтенләй үк онытылмасын иде ул — халкыбыз тарихының кечкенә, әмма гыйбрәтле бер сәхифәсе булып саклансын иде. Түбәндә сөйләнәчәк вакыйганың моңа хакы бардыр дип ышанасым килә.

Хуш, кем соң ул Әси, кай заманда яшәгән һәм ниләр кырган? Атакай сөйләгәннәрдән һәм Срур тутакайның миңа биреп торган русча язмасыннан чыгып, мин кыскача гына шуны әйтә алам: үткән гасырның икенче яртысында Каргалыда Әсәдулла Хәбибулла улы Еникеев дигән бик гайрәтле, кыю, тәвәккәл, һәм әйтергә кирәк, үзенчә акыллы да бер кеше булган. Әси аның кыскартылган исеме — шушы исем белән ул халык теленә кереп тә калган. Үзе морза, ләкин шул заманның милли һәм игътисади кысулары нәтиҗәсендә булса кирәк, бу кеше караклык итү, талау юлына баса. Ялгыз башы гына түгел, ә Каргалы кешеләреннән үзенә бер шайка оештыра, шуның оста, хәйләкәр җитәкчесе булып танyла. Аның уң кулы — Сәлиәсгар Еникеев, Әсинең үзе кебек үк кыю да, батыр да булган... Бөтен «эшне» икәү корганнар, икәү алып барганнар. Урлау-талау мактаулы эш түгел, әлбәттә, ләкин хикмәт шунда ки, алар, Әси шайкасы, Каргалының үзендә беркемнең дә малына тимәгән, шулай ук якын-тирәдәге татар-рус авылларын да бервакытта да борчымаган. Алар бары бик еракка китеп, хәтта Оренбург һәм Сембер губерналарына чыгып, шундагы боярларны талаганнар, чиркәүләрне басканнар. Күп вакытта талаган малларын Каргалыга да алып кайтмыйча каядыр юлда яшереп калдыра торган булганнар.

Ә авылның үзендә Әсәдулла агай мөхтәрәм, өстәвенә бик диндар бер кеше, биш вакыт намазын калдырмый, мәчеткә дә чалмадан гына йөри. Үзенчә юмарт, миһербанлы да булган ул. Урлап кайткан атны суйса, итен еш кына ятимнәргә, фәкыйрьләргә өләшкән. Атакайның әйтүенә караганда, ул ерак кырларда кое казыткан, ватылган күперләрне төзәттергән. Аш мәҗлесе үткәргәндә гел генә: «Хәзрәтләр, алдыгызга килгән ризыкта бер локма харам нәрсә юк, тыныч җан белән ашагыз!» ди икән.

Авыл халкы Әсәдулла агайның чын гамәлен һичшиксез белеп торган, әмма ләкин һичкем аңа бармагы белән дә төртеп күрсәтмәгән. Хәтта авылның мулласы да тел яшергән. Шулай да полиция бик нык эзләнә торгач, ахырда Әси каракның эзенә төшә. Аннары таланган боярлар да һаман Каргалы ягына күрсәтеп, каракларны шуннан эзләргә кирәк дип әйтә килгәннәр. Бернечә тапкыр куа да чыкканнар, ләкин Әсиләрнең атлары дөлдөл шикелле берәүне дә артларыннан җиткермәгән. Әсинең үз аты, имеш, тезгенен муенына салган килеш абзар ышыгында һәрвакыт бәйләүсез генә торган. Берәр төрле хәтәр гуа калса, Әси ишек төбенә чыгып сызгыруга, туры, аты шунда ук юыртып, килеп тә җитә икән: Әси сикереп кенә атлана да, исеп киткән җилдәй юк та була, имеш!

Полиция кешеләре еш кына Каргалыга тентү белән килә башлыйлар. Ләкин берни тапмыйча кире китәргә мәҗбүр булалар. Халыктан һәм авыл мулласыннан сорашып та бер нәрсә белә алмыйлар. Хәтта бер тентүдән соң, шул ук төнне Әси, ярдәмчесе Сәлиәсгар белән бергә, Уфага барып, губернаторның махсус үзе генә җигеп чыга торган ике иң шәп атын да урлап китә. Шунда ук яңадан Каргалыга тентү килеп җитә, ләкин бу юлы да нәтиҗә шул ук: Әси намазлык өстендә, беркем бер нәрсә күрмәгән, атларның монда эзе дә юк!

Әси шәүләсе артыннан болай бушка чабу тагын күпмегә сузылган булыр иде, әмма Каргалы өстенә килгән бер зур афәт аның тотылуын тизләтә. 1871 елны Каргалы якларында бик көчле корылык була, игеннәр кибеп бетә, халык икмәксез кала. Кышны уздырып, язга чыкканда инде авылда ачтан үлүчеләр дә була башлый. Менә шул ачларга ярдәм итү теләге белән Әсәдулла Еникеев үзенең агасы Хисмәтулланы иң якындагы Языков боярына үтенеч белән җибәрә. Үтенеч шул: господин Языков Каргалы халкына яңага хәтле берничә олау икмәк әҗәткә биреп торсын, яңа ашлык өлгерү белән кайтарачаклар — моны Әсәдулла Еникеев үз өстенә ала. Шуның белән бергә ул, Әсәдулла морза, моңарчы Языков имениесенә тимәгән шикелле, моннан соң да тимәскә сүз бирә. Морза сүзе ант кебек үк нык булачак!

Языков үтенеч белән килгән Хисмәтулла агайны башта сабыр гына тыңлый, ләкин сабырлыгы бик тиз бетә башлый, бите-муены кан йөгергәндәй бүртеп чыга, аннары сикереп тора да Әсәдулланың үзен дә, барлык Каргалы халкын да ворлар, разбойниклар дип акырып-бакырып сүгәргә тотына. Ачтан кырылып бетсәләр дә бер бөртек тә бирмәячәген әйтә һәм ялчыларын чакырып, Хисмәтулланы имениесеннән төйгечләп озатырга куша. Ялчылар Хисмәтулла агайның кулларын каерып бәйләп, үтерә язганчы кыйнап, Каргалы юлына чыгарып ташлыйлар.

Билгеле инде, Әсәдулла Языков боярының бу явызлыгын җәзасыз калдырмый. Бояр имениесен ул яхшы белә, тик форсат кына көтә. Һәм озак та үтми, форсат үзеннән-үзе дигәндәй килеп тә чыга: имениедә бояр хатынының туган көнен бәйрәм итәләр. Тирә-яктан бик күп кунаклар җыела. Һәм шул ук төнне Әси дә туры атына атланып, ялгызы гына бояр имениесенә юнәлә. Ләкин ул таларга бармый — үч алырга бара. Җәйге кыска төн, тирә-юнь тып-тын, зур йортның бөтен бүлмәләрендә ашап-эчеп ауган кунаклар йоклый — кунаклар гына түгел, эт булып арган хадимләр дә төрлесе-төрле урынга тәгәрәшеп беткәннәр. Менә шул чакта Әси туп-туры боярның йокы бүлмәсенә тәрәзәдән сүләндәй тавыш-тынсыз гына сикереп керә дә киң агач караватта тәмле генә гырлап яткан хуҗаның өстен кинәт ачып та ташлый. Бер кат нечкә озын күлмәктән генә яткан бояр шунда ук коты алынып, күзләрен ачып җибәрә. Әси аңа иелеп, шыпырт кына әйтә: тавышыңны чыгарасы булма, ату урыныңда ук буып үтерәм,— ди. Аннары чигенә биреп, кулындагы чи каештан ишеп үргән кыска саплы озын камчысы белән: — Менә бу сиңа ачларга ярдәм итмәгән өчен, мине, Әсәдулла морзаны, разбойник дип атаганың өчен, минем братым Хисмәтулла морзаны кыйнатып җибәрүең өчен! — дия-дия чажлатып яра башлый. Камчы сызгырып төшкән саен боярның нечкә күлмәге аша канлы юллар бүртеп чыга, үзе караватында еландай үрле-кырлы сикеренә, әмма үрсәләнеп ахылдаса да кычкырырга батырчылыгы җитми. Камчыдан кеше үлми — бояр моны бик яхшы белә. Әси уңлы-суллы яра-яра да кире тәрәзәдән сикереп юкка да чыга. Каргалыга ул кайтып тормый, күршедәге Галышево дигән рус авылына барып, шундагы дусларында яшеренеп ята.

Менә шуннан соң инде Әсине тотар өчен Каргалыга губернатор үзе җибәргән егерме кешелек коралды отряд килә. Өч ай буена отряд Әсине һәм аның уң кулы Сәлиәсгарне эзли, көтеп тә ята, әмма алар икесе

дә жиргә сеңгәндәй юкка чыгалар. Бары тик солдатлар китkәч кенә Әси белән Сәлиәсгар өйләренә кайталар. Ләкин отряд кемнедер яшерен күзәтүче итеп калдырган булса кирәк, озак та үтми боларның икесен дә җомга намазыннан чыккан чакта тотып алалар һәм Уфа төрмәсенә озаталар.

«Әси карак» эше буенча тикшерү шактый озакка сузыла. Ике-өч губернадан җыелган материал нигезендә «Әси шайкасы»на катнашы булса да, булмаса да Каргалының кырык-иллеләп кешесенә гаеп тагыла. Бу кадәр зур эш ачылгач, губерна суды, бөтен Каргалы халкын ерак Якутиягә сөрергә рөхсәт сорап, Петербургтагы сенатка мөрәҗәгать итә. Кыскасы, Каргалы дигән авылны моннан куарга, бетерергә кирәк. Бу хәбәр Каргалы халкын, билгеле, бик нык борчуга сала. Авыл шаулый, авыл аптырый — нишләргә, ничек итеп бу коточкыч афәттән котылырга? Ахырда күп сүзләрдән соң, авылның бернечә өлкән кешесе, мулласы һәм старостасы яклау сорап, татар бояры Тәфкилефкә баралар, Тәфкилеф морза үзе дә зур алпавыт булу өстенә патшаның ышанычын казанган һәм иң югары хөкүмәт даирәләре белән бәйләнештә торган кеше. Әлбәттә, ул боярлар мәнфәгатен саклау ягында, ләкин бу очракта гаделсезлек бик ачык күренеп торганлыктан (Каргалының бөтен халкы да карак түгел ләбаса!), килгән вәкилләрнең гозерен тыңлап, сенат белән сөйләшеп карарга риза була. Шулай итеп, аның сөйләшүе нәтиҗәсендә сенат бөтен Каргалыны Себергә сөрүдән туктата, ләкин бер шарт белән: Каргалы халкы үзе Себергә сөрелергә тиешле кешеләрне күрсәтеп, шуларның исемлеген төзеп бирсен! (Күрәсең, тикшерүчеләр үзләре гаеплеләр белән гаепсезләрне аерып бетә алмаганнар). Башка чара юк, авылны саклап калыр өчен сенат таләбенә риза булалар. Авыл үз кешеләрен яхшы белгәндер инде, менә шул нигездә Әси белән Сәлиәсгарнең иң якын иярченнәреннән егерме кешене күрсәтеп бирәләр. Шул рәвешчә, Каргалыдан барлыгы 22 гаиләне хатын, бала-чагалары белән бергә Себергә (Якутск губернасына) сөргенгә куалар. Алар киткәндә бөтен авыл кузгала, тәгъбирләр әйтеп, хәер-догалар теләп, карты-яше елашып, озатып калалар. Авыл халкының Әси каракка бернинди ачуы да, үче дә булмый, киресенчә, аны гайрәтле дә, үзенчә гадел дә бер кеше итеп яраталар һәм хөрмәт итәләр. Моның шулай икәнен халык арасында бик тиз таралып өлгергән «Әси карак» көе үзе дә ачык күрсәтеп тора. Бу көйне Әси үзе чыгарган имеш, диләр. Һәрхәлдә, сүзләре анык булырга тиеш. Китәр алдыннан Каргалы тавына менеп, авыл өстенә карап җырлаган имеш. Менә аның кайбер җырлары:

Менәр идем тауның башына,
Утырып җырлар идем кашына.
Киткән җирләрдин исән кайтсам,
Тарих язар идем ташына.

Туры атыкаем-малыкаем,
Атламыйсың, сикереп чабасың.
Туры атыкаем-юлдашкаем,
Ятлар кулына инде каласың.

Бу бик моңлы озын көй. Минем атакай да аны еш кына җырлый торган иде. Хәзерге вакытта 86 яшьлек апам — Срур тутакай исенә төшергәндә әкрен генә җырлаштыргалый. Аның бу көйне һәм үзе белгән Каргалының тагын кайбер көйләрен җырчылардан кемгә дә булса биреп калдырасы бик килә иде. Минем үтенүем буенча Мәхмүт Нигъмәтҗанов Мәскәүгә бер баруында Срур тутакайда булып, аңардан һәм якын туганыбыз Зөләйхадан ул көйләрне магнитофонга язып та алды. Бәлки югалмас, бәлки сакланыр да әле Каргалының ул борынгы гаҗәеп көйләре!

Әсәдулла Еникеев — «Әси карак»ның соңгы гомере турында бернчә генә сүз. 25 елдан соң ул Себердән Уфага кайтып, шунда үзенә йорт алып, күпмедер вакыт яшәп кала. Каргалыга да кайта ул. Һәм безнең өйдә кунак та булып китә. Ап-ак сакаллы мәһабәт картның сезнең өйдән чыгып, җигүле чанага иплән кенә утырып киткәнен үзем күреп тордым, агакай аның тун чабуларын кыстыргалап, капкага чаклы озатып калды дип сөйләгән иде миңа Срур тутакай. Димәк, Әсәдулла үзенең туган авылында искечә һаман да мөхтәрәм бер кеше булып саналган.

1907 елны Әсәдулла бабайны ни өчендер яңадан кулга алалар, һәм шунда — Уфа төрмәсендә ул вафат та була. Билгеле, бу батыр йөрәкле кешене бары гади карак дип кенә тану дөрес булмас иде. Самодержавиегә һәм боярларга каршы ниндидер ачу, үчегү ята, минемчә, аның бу хәтәр-кыю хәрәкәтендә. Кара реакция елларында патша хөкүмәтенең аны икенче тапкыр төрмәгә ябып, ниһаять, шунда үләргә мәҗбүр итүе дә әллә кайчангы караклыгы өчен генә булмас, әлбәттә. Ул заманда гади караклар һәр авылда диярлек очрап торган, әмма Әси кебек легендага әверелеп, җырларга кереп, халык хәтерендә яшәгәне меңнән бер генә!

Әсәдулла бабайдан һәм аның җырыннан аерылганчы, гомумән Каргалы көйләре турында кыскача гына әйтеп китү кирәктер, ахрысы. Әйе, Каргалының үзендә генә җырлана торган көйләре бар иде. Мин аларны күбрәк атакайдан ишеттем — ул, мәрхүм, җыр сөюче иде. Шулай ук Нигъмәтулла дәдәкай да җыр сузарга бик һәвәс булган. Мин аның Абзан туенда җырлаганын һич тә онытасым юк. (Бу хакта мин, хәтерләсәгез, «Җиз кыңгырау» хикәясендә язган да идем.) Кызганычка каршы, Нигъмәтулла дәдәкайның җыры иртә өзелде.

Алардан соң мин ул көйләрне гел генә диярлек Срур тутакайдан һәм Зөләйхадан ишетә килдем. Без, якын туганнар, кайчагында ничектер туры килеп Мәскәүдә очрашабыз: Казаннан мин барам, Алма-Атадан Зөләйха белән Шәрәф, Уфадан Рауза яки Ләйлә килгән була... Бөтен кич буена диярлек Срур тутакайның борынгы әйберләр һәм рәсемнәр белән тулы, шунлыктан тыгыз, тәртипсезрәк тә бүлмәсендә җыр тыңлап, үткәннәрне сагынып утырабыз. Срур тутакай пианинода үзе уйнап, үзе җырлый — әкрен генә итеп, әмма бик җиренә җиткереп, үткәзеп җырлый. Уйнап-җырлап туктагач, безгә борылып, шул көй кузгаткан берәр вакыйганы яки кешене хисләнеп-дәртләнеп сөйләп тә ала.

Зөләйха да үзе уйнап, үзе җырлый — аның тавышы көчлерәк тә, иркенрәк тә. Атасы мәрхүм кебек башта тамак кыргалый, башын чөебрәк уйлана, шуннан җай гына башлап җибәрә — җыр хыялны ияртеп әллә кайларга алып китә-китә, ә моңы, әйтерсең, юка гына ефәк булып йөрәкләргә йомшак кына урала да урала. Ул күбрәк «Ялан» көен җырлый, җырлап тынгач әкрен генә: «Бу көйне атакаем печән чапканда еш кына җырлый торган иде» дип әйтеп куя.

Мин үзем җырдан мәхрүм кеше, әмма бик тиз тәэсирләнәм, беренче җырдан ук инде миңа яшьләремне тыю бик авыр була. Җыры да бит нинди — бәгырьгә төшәрлек!

Каргалыкай буе, ай, камышлы,
Камышлары аның тавышлы.
Еллар белән еллар бер үк түгел,
Быелгысы никтер сагышлы.

Кызык хәл, бик әсәрләнеп тыңлаганга күрәме, мин җырлаган көйләрнең исемнәрен белә алмыйча кала идем. Менә «Әси карак» көе дидем, «Ялан» көе дидем (ләкин башкортның «Ялан-җиркәе» түгел, бөтенләй башка) — тагын нинди көйләр? Тагын «Исмәгыйль җизни көе» дип бер моңлы-озын көй җырлыйлар:

Казаннардин килгән әй җиз курай,
Ефәк калфак кигән кыз уйнай.
Үзе дә уйнай, үзе җырлай,
Күңелкәе аның кемне уйлай.

Аннары «Шәйсолтан», «Шакир көе» дигәннәре дә бар. Болар барысы да Каргалының саф үз көйләре, бүтән бер җирдә дә миңа аларны ишетергә туры килгәне юк. Шулай ук безнекеләр «Агач башы»н да бик яратып җырлыйлар, ләкин бусы инде читтән килгән булырга тиеш. Ул кайчандыр шактый таралган, хәзер исә онытылып бара торган бик матур көй, Фәйзи Биккинин уйнавында грампластинкага да язылып калган, тик аны бездә башкачарак — сузыбрак, бормалырак җырлыйлар.

Каргалының үз көйләре барысы да башкорт көйләренә тартым — борылма-күчешләре белән өзелмичә сузыла, бер күтәрелә (көчәя), бер төшә (әкренәя) торган озын көйләр. Һәм шушы охшашлык мине еш кына уйландыра иде: нидән бу, башкорт җиренә күчеп утыргач һәм башкортлар белән аралаша башлагач кына туганмы алар! Ләкин болай уйлау бер дә нигезле түгел кебек. Безнең халык, күргәнебезчә, бик борынгы халык. Ике мәртәбә ул яшәгән җирен алыштыра, башта Азов диңгезе буйларыннан Россия үзәгенә, ә күпмедер гасырлардан соң башкорт җирләренә күчеп утырырга мәҗбүр була. Я, әнә шул меңнәрчә чакрымнарга сузылган далаларны, урман-суларны арбалар шыгырдавын тыңлый-тыңлый үткән чагында ул үзенең моң-зарын көйләргә салып җырламагандыр дисезме? Һәм аның бу җыр-моңнары буыннан-буынга күчә килмәгәнме әллә? Менә бу җыр үзе генә дә шул хакта сөйли түгелме?

Сибелеп тә төшкән, бөгелеп тә үскән
Юл буенда ялгыз бер бодай.
Газиз башны туган илкәйләрдән
Аермасын гына бер ходай.

Юк, башкорт җиренә дә ул йөрәге, өметләре белән бергә үзенең җыр-көйләрен дә алып килгән, әлбәттә. Инде охшашлык бар икән, нигә моңа артык гаҗәпләнергә? Башкорт асылда дала халкы, безнең ерак бабайлар да кайчандыр далада яшәгәннәр. Башкортның тамыры кыпчактан диләр, безнең чыгышны да кыпчак белән бәйлиләр. Тарихның саргайган сәхифәләрен актара башласаң, бик хикмәтле нәрсәләр килеп чыгар иде. Менә бит, хәтта телдә дә охшашлык юк түгел: башкорт «атай», «агай» ди, ә без «атакай», «агакай» дибез, ләкин болай дәшү безгә һич тә башкорттан кермәгән. Бик борыннан һәм бик ерактан килә ул. Аннары тагын башкортның яратып куллана торган «җиңгә» сүзе бар: өлкәнрәк хатыннарга, бигрәк тә ага тиешле ирнең бичәсенә гел генә «җиңгә», «җиңгәй» диләр. Безнең төмәннәр дә нәкъ менә кардәш тиешле өлкән кешенең хатынына «җиңкай» дип дәшәләр (Бертуган агасының хатынына һәр җирдәге шикелле «җиңгәчәй» диләр.) Күрәсез, бер үк сүзләр, тик әйтелешләре генә төрлечә.

Дөрес, безнең төмәннәрнең теле башкортныкыннан гына түгел, күпчелек татарныкыннан да шактый нык аерыла. Бу тел асылда мишәр теленең бер диалекты булырга тиеш. Ләкин ул Касыйм татарлары, шулай ук Нижгар мишәрләре теленнән сизелерлек аерылып та тора. Касыймлылар сүзне ничектер әйтеп бетермичә бер-берсенә ялгабрак һәм кабаланыбрак сөйлиләр, шуңа күрә аларны тиз генә аңлап та булмый. Каргалы төмәннәре исә сүзне өзеп, тулы әйтеп, авыз тутырып сөйләргә яраталар. Аннары каты мишәрләргә хас «ч» урынына «ц» кулланып (әйтик «пыцак» дип) сөйләү дә аларда юк. Әмма күп сүзләрнең әйтелеше шулай да мишәрчә: ү (өй), үләнү (өйләнү), түән (төен), әтәм (әйтәм), чаука (чәукә), койрыйк (койрык) һәм башкалар... Ә менә бу

шактый еш әйтелә торган сүзләр Каргалыга гына хас түгел микән: малыкаем («җаныкаем» мәгънәсендә), әмән («гүя» урынына), гареп (гарип — «мескен», «бичара» мәгънәсендә йөри). Тегендә, Тамбов җирендә яшәгән чакларында рустан кереп калган сүзләр дә бар: ызба (өй), кучарка (кочерга — кисәү агачы), внука (онык) — шуның ишеләр тагын булырга тиеш. Мәсәлән, Каргалыга кайтып йөргәндә мин малайлардан еш кына «пырт» дигән сүзне ишетә идем. «Әдә, пыртка киттек» дип мине чакыра торганнар иде. Баштарак һич тә аңлый алмадым: нәрсә булырга мөмкин ул «пырт» дигәннәре? Үзе, җитмәсә, авылдан шактый читтә дә икән. Ахырда бер ияреп баргач, күрдем мин ул «пыртны»: тегермән буасы икән ләбаса! Малайлар мине шунда су керергә чакырганнар икән... Ярый, безнеңчә буа — Каргалыча «пырт» та булсын ди, ләкин кайдан килеп кергән ул әкәмәт? Хәер, сез аңлагансыздыр инде, русның «пруд» сүзе шулай кереп киткән икән безнең Каргалы теленә.

Билгеле, Каргалы халкының телендә генә түгел, көнкүрешендә, гореф-гадәтләрендә дә үзенчәлекләр җитәрлек күп. Бәйрәмнәре, туйлары, уеннары да башкачарак булган аның. Мәсәлән, яңа ел кергәч айлы төндә су тулы чиләккә билгеләп салган кашыкларны ак кар өстенә чыгарып сибеп, бәхет сынау уены Каргалыдан башка тагын кайда гына бар икән? Җитмәсә, исеме дә «раштуа уены»?! Ләкин мин берәдә алары турында җәелеп тора алмыйм, чөнки, беренчедән, белүем чамалы, икенчедән, Срур Сүнчәләйнең Каргалы туен һәм уеннарын бик белеп, тәфсилләп язган кызыклы мәкаләләре безнең журналларда («Казан утлары» белән «Азат хатын»да) заманында басылып чыккан иде. Шулай булгач, язылганны кабатлаудан мәгънә юк, теләгән кеше үзе дә табып укыр.

Хуш, Каргалы турында тагын нәрсә әйтәсем калды? Бик күп еллар узды шул. Балачак хәтере күргәннәрне ни чаклы гына нык беркетмәсен, барыбер әкренләп бик күбесе онытыла-югала бара икән. Аннары хәтер сандыгы да кечкенә бит әле, бер биш-унъеллык «хәзинә» җыелгандыр инде аның төбендә, хәлбуки аннан соң алтмыш еллап гомер узып та киткән. Бик төптә калган шул балачакныкы! Әмма иң аянычы, балачактан ук туган туфрактан аерылып торгач, еллар үтү белән ул үзенең тансыклыгын һәм кадерен югалта да башлый икән. Ләкин бер кайчан да онытылмый, юк, онытылмый! Миңа ни өчен ишеткәннәремне генә булса да әйтеп бетерәсем килә. Алары да инде күп калмады.

Каргалы халкының туганлык җепләре белән үзара бик нык бәйләнеп, чуалып беткәнен кабатлап булса да әйтергә туры килә. Бабакайлар, әбикайлар, агакайлар, җизниләр, кияүләр, җиңкайлар, җиңгәчәйләр — барысы да бит бер авылда яшәгәннәр, хикмәте хода! Якын туганнарын аерыр өчен махсус сүзләре дә булган. Әйтик, ике бертуган балаларын «тудык» дигәннәр һәм үзара «тудыкай» дип сөйләшкәннәр дә (аеруча, хатын-кызлар). Тудыклардан туганны «тумачи» дигәннәр. Тагын «трачи» дигәне дә бар икән әле — бусы инде тумачилардан туган дүртенче буын. (Беренче буын бер ата-анадан туганнар.) Ләкин гамәлдә бу сүз йөрми диярлек, чөнки туганлык бик ераклашкан, кемнең кемгә «трачи» булуын белүе дә бик читен.

Шулай ук картларга буйсыну, картларны хөрмәт итү дә көчле булган. Билгеле, бу гадәт гомумән татар халкына хас сыйфат, ләкин төманнәрдә ул аеруча нык сакланган. Гаиләдә бабай үлсә, әби «баш» булып калган — аңа берсүзсез буйсынганнар. Һәр эштә диярлек бу шулай. Хәтта сөйлиләр: түр башында туксаннан узган әби калтыранып утыра. Юньләп күзе дә күрми, колагы да ишетми, акылы да инде әйле-шәйле генә. Шулай да аның ап-ак сакаллы улы,— күптән кызла-

рын биргән, улларын өйләндергән йорт хуҗасы бабай — берәр җиргә кунакка яки туйга барырга кирәк булса, иң элек әнә шул түр башында калтыранып утырган карчыктан сәкегә таянып, үрелеп, иплəп кенә рөхсәт сораган:

— Анакай, кәбәм, безне вет Ибәй кодаларга кунакка дәшкәннәр иде, рөхсәт итәрсез микән?

Карчык җавап бирергә ашыкмый, башын селкетеп утыра бирә, аннары йокысыннан айныгандай сорый:

— Нәстә әтәсең?

— Кунакка дәшкәннәр иде дим, рөхсәт итсәң...

— Кемгә?

— Ибәй... Ибәтулла кодаларга?

— Кем ул, нинди кода?

— Соң, үзебезнең Җәмилә киленнең аталарына инде... Түбән очка.

Карчык тагын озак кына дәшми торып, кырыс кына әйтеп куя:

— Ярый, барырсыз... Тик дөньягызны онытып утырмагыз, якты күздә кайтыгыз!

Ак сакаллы картның әйле-шәйле анасыннан әнә шулай рөхсәт алуы — бу бер дә арттырып әйтелгән сүз түгел. Шулай булган заманында. Картлар рөхсәтеннән (яки фатихасыннан) башка бер генә эш тә эшләнмәгән.

Аннары түмәннәрдә хатын-кызлар да шактый ук хөрлек белән файдаланганнар. Карчыклар йөзләрен яшермәгәннәр, хатыннар олырак ирләрне очратканда битләрен яулык чите белән генә каплый төшеп узганнар. Яшь киленнәр француз бөркәнчек ябынганнар, иренең туганнары белән күрешкәндә чүгенеп (реверанс ясап) кул биргәннәр. Кызны күрсәтмичә бирү яки егетен күрмичә чыгу кебек кыргый гадәтләр дә булмаган. Кыскасы, «Кара йөзләр» кебек фаҗиганең Каргалыда булуы мөмкин дә түгел.

Инде исемнәр һәм кушаматлар турында берничә сүз. (Кушаматлар кайда гына юк ул, ләкин бу очракта үзенә күрә бер «гыйлләсе» бар.) Хикмәт шунда, безнең Каргалыда фамилияләр аз, бер үк исемнәр бик күп. Үзенең һәм атасының исеме туры килгәннәр дә аз түгел. Шул сәбәпле монда кешеләрне кушаматсыз аерып та булмый. Әйтик, бер үк фамилиядә ике Кәлимулла бар икән, аның берсен «болаш Кәлимулла», икенчесен «гыжнай Кәлимулла» дип йөрткәннәр. Кыскасы, кушаматсыз берәү дә юк. Хәер, бөтен авылга бер кеше булган диләр. Исеме аның Әхмәт икән. Менә шул абзый бер мәҗлестә: «Минем кушаматым юк, мин коры Әхмәт кенә» дип мактанган имеш. «Әһә, алаймыни?!» дигәннәр тыңлап утыручылар һәм шунда ук аны «Коры Әхмәт» дип йөртә дә башлаганнар. Мактану харап иткән абзыйны!

Ләкин бик күп кушаматларның «чыгышы» билгесез, махсус төпченмичә белеп тә булмый, шулай да кайберләренең «тарихы» мәгълүм. Мәсәлән, «Кердеш Нури» дигән кеше булган. Ул кайчандыр Мәмти (Мәфтүхә) исемле хатынга өйләнеп, шуның йортына хуҗа булып кергән. Шуннан инде аңа «кердеш» дигән кушамат тагылган. (Хәтта яңа сүз иҗат иткәннәр.) Яки «Әйләнчек Сафины» алыйк. Бу кеше берәр җиргә барыр өчен атын җигеп, ишек төбенә тарттыргач та, чыгып китә алмыйча, өе тирәсендә һаман әйләнә дә тулгана икән. Шуның өчен аңа «әйләнчек» кушаматы бик урынлы тагылып та кала.

Кушаматлар фамилия шикелле атадан балага да күчкән. Әйтик, атасының кушаматы бәлеш икән, малайлары да «бәлеш» булып йөргән. Минем тагын «чөчеләр» («төче» сүзеннән), «нәмиләр» дип күпләп әйткәнне дә ишеткәнем бар — бу инде тоташ бер токымның кушаматы булса кирәк. Бер кушаматның хәтта фамилиягә әйләнүен дә ишеткән идем. Югарыда «болаш Кәлимулла» дигән кеше телгә алын-

ган иде — менә шуның бер улы атасының кушаматын тоткан да фамилиягә әйләндергән. Хәзер үзе дә, балалары да «Булашевлар» булып йөри икән.

Әйе, болар барысы да элек иде — миңа чаклы һәм мин бала чакта булган хәлләр. Аннан соң күп сулар акты, күп җилләр исте, буыннар алышынды, тормыш алышынды. Тулаем дөнья бик нык үзгәрде. Бу үзгәрешләрдән минем туган авылым Каргалы да читтә торып калмады, билгеле. Бөтен җирдәге шикелле хәзер инде анда да бай да юк, ярлы да юк, һәр җәһәттән тигезлек, барысы да бер чама тук һәм мул яшиләр... Борынгы озын көйләр урынына кыска-дәртле көйләргә җырлый торганнардыр, иске уеннар да онытылып беткәндер — клубка йөри яки телевизор карый торганнардыр (бөтенесе булмаса да), кушаматларның да кирәге беткәндер, яңа буын бер-берсенә, ихтимал, «фәлән фәләнович» дип кенә дәшә торганнардыр... Хәтта ялан-кырларның да исемнәре онытылып бетмәде микән? Ә матур иде ул, табигатьнең үзеннән алып, халык биргән исемнәр: «Торна кичүе», «Төлке чокыры», «Үгез куагы», «Бозау басуы», «Әркәсле», «Зирекле баш», «Тозлы куш» һәм башкалар, һәм башкалар. Хәзер алар совхоз җирләре, зур-зур участокларга бүленеп беренче, икенче, өченче бригада басулары дип кенә йөртелә торгандыр, мөгаен.

Озын сүзнең кыскасы, мин белгән өч мәчетле иске Каргалы юк ул. Дөрес, шул ук урында, шул ук исемдә кечерәк бер авыл тора, әмма бу инде башка авыл, яңа авыл.

Каргалы халкының читкә сибелүе турында сүз булган иде инде. Кайбер фамилияләр, мәсәлән, Еникеевлар белән Терегуловлар анда бөтенләй диярлек калмаган да имеш. (Хәер, бөтенләй үк булмас, монысына никтер ышанып бетәсем килми.) Һәрхәлдә, бик күпләр киткәннәр — бигрәк тә яшьләре... Һәм бик күптән, революциягә чаклы ук башланган да ул. Революциядән соң инде берәмләп кенә түгел, күмәкләп тә китә башлыйлар. Бу хәлнең, төрле социаль сәбәпләрдән башка, тагын бер «гаепчесе», минемчә, школа булса кирәк (ни өчен «мәктәп» димәвемне тиздән аңларсыз)... Эш шунда ки, Каргалыда әле узган гасырның ахырларында ук инде русча укыту башлана. Мәчет каршындагы мәдрәсәдә мулла абзый балаларга дин сабагы укытса, минем инәйнең атасыннан калган нарат йортта Ибәтулла учитель бары тик русча укыткан. Шулай итеп, авылда русча укый-яза белүчеләр һәм башлангыч белем алучылар елдан-ел әкренләп арта барган. Соңыннан Казан, Уфаларга китеп, укуын дәвам итүче кайбер яшьләр әнә шул Ибәтулла учитель шәкертләре — шулардан инде беренче врачлар, агрономнар, землямерлар чыга да башлый.

Бу гасырга кергәч, унынчы еллар тирәсендә булса кирәк, татар-башкорт балалары өчен Каргалыда комташтан зур школа салына. 1911 елда ачылган бу школа Высшее начальное училище дип атала. Тирә-яктагы татар, башкорт авылларыннан күпмедер укучылар җыела, рус авылларыннан да укырга киләләр, ә Каргалының үз малайлары барысы да диярлек шунда кереп укыйлар. Зур, якты класс бүлмәләре, уку әсбаплары, тәҗрибәле укытучылар белән тәэмин ителгән школа үзенең шәкертләренә шактый төпле белем бирә. Бетереп чыгучыларга югарырак уку йортларына керү өчен юл ачыла, ә бик күбесе школа биргән белем һәм хокук белән үзе укытучылык итә башлый. Каргалы укытучыларын ул заманда бөтен тирә-як авылларда очратырга мөмкин иде.

Менә шул школа аркасында диясем килә, Каргалы яшьләренең күпләп читкә китүләре башлана да инде. Бигрәк тә егерменче — утызынчы елларда агылып китә башлыйлар. Бәләбәй белән Уфаны әйткән дә юк, Казан белән Мәскәүгә дә барып житәләр. Уку, уку, кайда гына

булса да, ничек кенә булса да уку! Әйтәсе дә түгел, мактаулы омтылыш! Алардан урта һәм югары уку йортларын бетергән күпме белгечләр илгә таралды. Бөек Ватан сугышында Каргалы кешеләреннән 20 полковник, 12 врач булган имеш — шуны да миңа әйттеләр. (Бер җиргә 54 врач дип тә язып куйганмын, ләкин бусы артык күп, кеше ышанмас.) Тора-бара алардан галимнәр дә чыкты. Хәзерге көндә бер Казанда гына Еникеевлар һәм Терегуловлардан берничә профессор бар. Татарның беренче медицина профессоры Әбүбәкер Терегулов та Каргалы баласы — Казан университетын 1911 елны ук бетергән булган. Фән өлкәсендә династияләр туды дип тә әйтергә мөмкин. Мәсәлән, Уфада Гыйниятулла абзый Терегулов үзе профессор, улы профессор, сеңелесенең кызы профессор — барысы да медицина докторлары. Гыйниятулла абзыйның энесе Искәндәр абзый Мәскәүдә Бауман институтының профессоры иде, ә кырыкка да җитмәгән улы МГУ профессоры, дөнья күләмендә танылып барган галим диләр.

Бер авыл өчен бу бик күпкә китте дип, бәлки ышанмаучылар да булыр, ләкин мин һич тә арттырмыйм. Болар бит барысы да — әлеге школа чәчкән орлыклар. Башта аталары укыган, алар балаларына югары белем бирергә тырышканнар — шулай ялганып киткән инде ул. Аннары яшь буынның бик күбесе Каргалыда да тумаган.

Уйлыйм ки, әгәр Каргалыда үскән булсам, мин дә шул агымга ияреп киткән булыр идем, бу язучылык дигән шактый азаплы «кәсеп» бәлки төшемә дә кермәс иде. Язасы килү теләген миндә Дәүләкән мәктәбе уятты, ә Каргалы школасында укучылар татар әдәбияты белән бөтенләй диярлек кызыксынмыйлар иде. Шуңа күрәдер инде дөньяга дистәләп врачлар, инженерлар, агрономнар биргән Каргалыдан бер әдип, бер артист, бер рәссам чыкмады. Хәлбуки сәнгатькә талантлы егетләр-кызлар бар иде, бик матур җырлаучыларны да, рәсем ясап мавыгучыларны да мин үзем беләм, ләкин алар ышанычлырак һәм бәрәкәтлерәк эшне сайладылар. Шулай да күп еллар узгач, сугыштан соң безнең сәнгать өлкәсендә ниһаять миңа адаш фамилия калкып чыкты — бу композитор Ринат Еникеев. Үзенең әйтүенә караганда, аның атасы Әхмәтгәрәй Еникеев Каргалыда туып үскән кеше, әмма әнисе бөек Тукайга якын кардәш икән. Ихтимал, Ринатның зур музыкаль таланты әнисе ягыннан килә дә торгандыр. Ә бәлки атасы ягыннан да юк түгелдер, ул тарафта да бит җырларга да яратканнар, көйләр дә чыгарганнар. Хәер, бу кадәресен инде Ринатның үзеннән ишетү яхшырак!

Тарихи дәреслек өчен шуны да әйтеп китү артык булмас, минемчә: әле революциягә чаклы ук яңа салынган таш школа бинасында яшь учительләр тарафыннан спектакльләр куелган, концертлар оештырылган. Революциядән соң исә бөтен җирдәге шикелле Каргалыда да бу эшләр аеруча җанланып китә. Бик теләп, катнашып йөрүче яшьләр күп, спектакльләр, концертлар әледән-әле булып кына тора. Бер кайтуымда Каргалы спектаклен мин дә күреп киткән идем. Школаның киң, озын коридоры. Бер башына сәхнә корылган — шунда «Урал суы буенда» дигән спектакль бара. Коридорның калган өлешенә озын-тар эскәмияләр тезелгән — аларда тыгызланып утырган тамашачылар. Алдагы рәтләрдә утыручылар спектакльне тыныч кына карасалар да, ишек төбендәрәк бер дә тынычлык юк — кемнәрдер, ни өчендер һаман шунда шаулаша. Шул чакта баш рольне уйнаучы егет залга шауламагыз дип бер кычкырып сала да, аннары яңадан һични булмагандай, үз ролен уйнап китә. Бик кызык булып тоелган иде бу миңа. Шуңа күрәдер, ахрысы, ул спектакльне мин бер дә онытa алмадым.

Шулай ук Уфаның үзендә 1908—10 еллар тирәсендә һәвәскәрләр тарафыннан куелган спектакль һәм концертларда да Каргалыдан

чыккан яшьләр шактый ук актив катнашканнр икән. Моны минем кулыма кергән бер ефәк программадан ачык күрергә була: анда язылган фамилияләрнең күбесе Еникеевлар да Терегуловлар. Шулар арасында яшь шагыйрь Сәетгәрәй Еникеев та бар — ул скрипкада чибәр генә уйный торган булган. (Бик яшьли үлгән авылдашым шагыйрь турында мин бу язманың башында кыскача гына әйтеп үткән идем инде.)

Шул рәвешчә, Каргалы яшьләренең үзешчән сәнгатькә, гомумән татар мәдәниятенә тартылуы азатлык җилләре искән чакта нык кына көчәя, ләкин җилләр исеп тынгач инде бу энтузиазм әкренләп сүрелә һәм тына. Аның караву, укуга, белем алуга омтылыш бик нык арта, яшьләр авылдан агылып китә башлый. Әлбәттә, укып белем алу, белгеч яки галим булу бик күркәм эш. Тик менә Каргалы үзе генә мөгезен салган карт сыер шикелле күпмедер вакытка кысыр кала. Әмма кысырлык ул мәңгелек түгел, үтә торган нәрсә — шулай юатасым килә сай инеш буенда тын гына утырган авылымны.

Илебез бик зур, кайда гына торсаң да бер үк ватан, әмма шул чиксез ватанның тузандай бер ноктасы кешенең, карт әдип әйткәнчә, яшел бишеге. «Каргалы» дигән нокта да минем җанымда әнә шундый матур, кадерле, мәгәр томан белән өртелгән бер образ булып саклана. Ләкин «яшел бишектән» төшеп, кырыс дөньяга чыгып китүемә бик күп еллар узды шул инде, хәтта сагыну кебек бик табигый хис тә әкренләп сүнде, бетте диярлек. Менә туган авылымның урамыннан хыялым белән генә каранып узган булдым. Билгеле, күп нәрсәне танымадым, күп нәрсә онытылган, шул сәбәпле үткәннәрне искә төшерү белән генә чикләндем. Бабаларым гомер иткән нигез юк, мин туган йорт та юк, бала чагымда ялан тәпи бәбкә үләнен таптап йөргән ландай иркен ихата үзе дә юк. Алар барысы да хәзер бары тик хәтердә генә, бары тик искә генә төшерергә мөмкин. Сирәк кенә кайткан чакларымда да мин йортыбыз урынында буш яткан, чүп баскан җирне күреп, үземнең шушында тууыма ничектер ышана алмыйча китә идем.

Инде иң соңгысы... 1979 елның җәендә мин Бөгелмә поезды белән Уфага барышлый көндез Каргалы турысыннан уздым. Вагон тәрәзәсеннән китмичә карап бара торгач, авылга якынлашуымны тауларыннан белеп алдым. Атакай мәрхүмнең «Тезелеп кенә киткән кызыл тауларым, өстегездә куян ауладым» дип җырлаганы ничектер искә төшеп куйды. Әйе, бу ак маңгайлы кызыл таулар мин бәләкәй чакта биек тә, мәһабәт тә кебек иде, ә хәзер вагон тәрәзәсеннән алар ничектер чүгеп тә һәм боекланып та калган шикелле күренделәр. Инде менә Каргалы үзе... Элек ул, ялгышмасам, тимер юлына бик якын иде, ә хәзер шактый ераклашкан, инеш буйлап кына таралып утырган бер авыл. Күрәсең, тимер юлга якын урамнар күчепме, китепме беткәннәр... Үзгәргән, нык үзгәргән... Каргалыкай!.. Поезд кызу узды, кирәгенчә күрергә өлгереп тә булмады. Шулай да мин артка каерылып булса да, һаман авылның сирәк йортларын күреп калырга тырышып бардым.

Поезд авылны үтеп киткәч, ерак та түгел «Чәрмәсән» разъездында туктады. Вагоннардан сирәк-мирәк кенә кешеләр төште. Мин дә төштем һәм Каргалы юлына чыгып баручы олы гына яшьтәге ике хатынны туктаттым. Исәбем әзрәк сорашып, сөйләштереп алу иде.

— Сез Каргалыданмы, апайлар?

— Ийе, Каргалыдан...

Ләкин алар ашыгалар иде бугай — теләмичәрәк туктадылар. Шуңа күрә мин туп-туры гына сорадым:

— Сезнең Әхмәтҗан картны ишеткәнегез бармы?

— Кайсы Әхмәтҗанны? — диде минем соравыма каршы хатыннарның кечерәк буйлысы.

— Тәлпи Әхмәтҗанны, йорты урталыкта, мәчеткә каршы гына иде.

— Юк, белмибез, ишеткәнебез юк,— диделәр болар.

Хәер, белмәүләре гаҗәп тә түгел — бик күптән үлгән карт. Ләкин инде аның улын белергә тиешләр. (Хатыннарга бер 55—60 яшь булыр.)

— Ә соң аның улы Нигъмәтулланы белә идегезме?

— Кайсы Нигъмәтулла тагын?

— Шул ук урталыкта яшәгән Татыра Нигъмәтулланы?

Хатыннар бер-берсенә карадылар, аз гына уйландылар, аннары башларын селекteләр:

— Юк, белмибез. Урталыкта андый Нигъмәтулла тормый.

— Хәзер тормый, ә элек тора иде.

— Ий, элеккесен кем белеп бетерсен, җаныкаем,— диде хатыннарның чандыр-озыны.— Хәзер вет урталыкта мәчет тә юк, йорт та юк, сафхуз гаражлары анда.

Шулай итеп, бу авылдаш хатыннар минем бабамны гына түгел, үзләренә күпмедер замандаш булган дәдәмне дә белмиләр булып чыкты. Дөресен генә әйткәндә, моңа да артык исем китмәде. Нигә кирәк аларга дөньяда юк кешеләрне белеп тору?! Тереләрен белергә дә бәлки ихтыяҗлары юктыр — беткәнмени башка кайгылар?!

Инде мин алардан: «Ә сез үзегез кем буласыз соң?» дип сораганны көттем, ләкин алар хатыннарга хас мондый кызыксынуны да күрсәтмәделәр.

— Ярый, апайлар, юлыгызны бүлдем,— дидем мин аларга, һәм алар, үзара нидер сөйләшә-сөйләшә, китеп тә бардылар.

...Тау битендәге үләннәрне селкетеп-тарап җылы гына җил исә. Ачы әрем исен китерә ул миңа — туган-туфрак исен... Коры җирдә, эссе кояшта үскән ак әрем исе бик үткен була — бала чактан ук сеңеп калган бу таныш исне картайгач та бик яратам. Үзгәрми һәм бетми торган ис ул минем өчен!

*Сентябрь, 1980 ел.*

*Беренче өлеш тәмам*

## Фәннур Сафин

# САНДУГАЧ ҖЫРЫ

### Таң

Җилләр өзгән яфрак сыман
Көннәр оча — еллар кими.
Һәр тәүлек ул бер романдай,—
Көннәр сөйли, төннәр сөйли.

Бер уйласаң, бу заманда
Еллар кыска, чорлар кыска.
Көчкә ялгап өлгерәсең
Гасырларның очын очка.

Шул тизлектә сиңа, кеше,
Үз-үзеңне тапмак кирәк.
Сызылып кына таң атканда
Ничек йоклап ятмак кирәк?!

### Туган җиремә

Кай тарафка гына күз атсам да,
Чишмә сыман ургып моң чыгар.
Иманнәрең гүя юл югалтып
Туктап калган моңсу юлчылар.

Бу юллардан күпме сагышлылар,
Бәхетлеләр җырлап узгандыр.
И Туган җир, сүнмәс шатлыкларың,
Кайгыларың белән сызландыр.

Кырларыңнан җыям моңнарымны,
Бирдәнберем — туган төбәгем.
Китсәм дә мин үзем еракларга,
Синдә кала минем йөрәгем.

## Юл алдыннан

Юл алдыннан сулыш алсак икән,
Тынычлансак икән юл өчен.
Кайгыларны каршыласак икән,—
Ярсымасак икән юк өчен.

Юл алдыннан бер киңәшсәк икән,
Билгеләсәк икән җил көчен.
Имин-тату без яшәсәк икән
Һәм яшьнәсәк икән ил өчен.

## Сандугач җыры

Ал нур гына яуган таңнарда
Сандугачлар безгә эндәшә:
«Матурлыгын тоеп дөньяның,
Кеше дустым, җирдә мең яшә!»

Кадерләп тә сөеп туймыйбыз
Сандугачлар сайрар таңнарны.
Күзләрнең дә табып кояшын,
Җылытырбыз әле җаннарны.

Шунда хәтта кипкән яфраклар
Истәлекләр белән җылыныр.
Язып алган кебек тасмага,
Ишетелер дәртле-моңлы җыр.

## Илт син, шигырь, кешеләргә

Ялкынланып бию, тылсымлы моң
Тулган сыман җанга наз булып,
Барып җит син, шигырь, кешеләргә
Хыяллардан күчкән яз булып.

Моңландыр син, шигырь, уйландыр син
Йөрәк түрләренә юл табып.
Тик калмасын күңел гамьсез килеш,
Юк, кирәкми андый урталык!

Синең моңны борынгыдан килгән
Таһир-Зөһрә рухы сугарган.
Элеккедән рухы булмаганнар
Баткаклыкка кереп югалган...

Йолдыз саны хәтле бездә хыял,
Уйнап кына тора кулда эш.

Туган илдәй уртак булсын безнең
һәрбер сагыш, һәрбер куаныч.

Шундый уйлар, шундый хисләр белән
Кушып тормыштагы бар ямьне,
Илт син, шигырь, илт син кешеләргә
Йөрәк кебек кайнар сәламне!

## Ирләр

Сүз салкыны чәчне бәсерәйтте,
Килде төннәр күзне сукырайтып.
Без аларны, җенне куган кебек,
Кудык дога түгел, шигырь әйтеп.

Җимереп уздык ләхет суыкларын,
Җәһәннәмгә очты зәмһәрирләр.
Сезнең, безнең кебек кешеләр барда,
Ирләр әле, димәк, һаман ирләр!

●

Беләм синең миннән китәсеңне,
Беләм сине югалтасымны.
Шулай да мин: «Вакыт, ашыкма,— дим,—
Яшереп тор бераз кайчыңны.

Сагыну тулы араларны кисмә,
Анда минем бәхет ярала.
Болай да бит юллар гына түгел,
Еллар ята безнең арада.

Ашыкмачы, Вакыт, ашыкма син,
Туктатып тор поездларыңны.
һәр вагонда, һәр тәрәздә — сагыш,
Озаталмыйм сөйгән ярымны.

Озаталмыйм кайгым-шатлыгымны,
Тик каршылый гына алам мин.
Хәтта узган минем өчен яңа,
Хәтер утравында янам мин.

Күрәсеңме, Вакыт, һәр тәрәздә,
һәр караште сары көз ята».
...Каршыларга килә дә йөрәгем,
Мәңгелеккә ярын озата.

## Каршылыйк

Их син, язмыш, җирнең талантларын
Ай һәм йолдыз диеп атадың.
Айга карап улар бүреләрне
Урманнарда яшереп сакладың.

Хаклык эзләп юлга чыга кеше,
Чыккан кебек бәхет эзләргә.
Хаклык исә читтә генә түгел,
Ә бәхет тик Туган җирләрдә.

Кайвакытта бәхет ява сыман
Күк капусы кинәт ачылып.
Күзең ачсаң, янда кайгы тора.
Тормыш. Канун. Бөек каршылык.

## Чишмә китә

Хуҗаларча сөеп дәшкән кешенең
Оныклары югын төшенеп,
Үпкәләгән бөек зат шикелле
Чишмә китә быел күченеп.

Чишмә китә, урыны, комы кала,
Яра җөе сыман,— күр әле!
Һәм аптырап тып-тын кала урман,
Йолкып алынгандай йөрәге.

Җыр яңгырый кинәт. Шомлы, моңлы
Аһәң килә сынып, имгәнеп.
Әкрен генә, сүзсез җырлый урман,
Гамь дулкыннарында тирбәлеп.

Еларсың да, урман, җырларсың да,—
Синең телне белгән кешенең
Варислары китә, чишмәләре,
Киткән кебек яшәү күченеп...

Ләлә Хәйдәрова

# КЫРЫМ ХИКӘЯСЕ



Исәнме, диңгез! Саумы, гүзәлкәй!.. Синең белән ешрак күрешүне теләп, дулкыныңа көмеш акча ыргытып киткәнгә күпме вакыт үткән... Бередә гадәткә кергән бу юрау юш килмәде бит, менә ничек озак күрми тордым үзеңне... Диңгез, минем уйларымны аңлагандай, яр читенә зуррак дулкын какты, аяк очларыма орынып, кире чигенде...

Диңгез өстендә кичке тынлык. Дулкыннар да бик арыган кебек яр буена салмак кына килеп сыеналар... сыеналар да, шунда башларын салып, йокыга талалар шикелле. Шулай җил-давыл ихтыярына буйсынып, кайнап яшәп кара әле син. Ял итәсең, яр куенына сыенасың, тын гына, тыныч кына хәл җыясың да килер...

Дулкыннарның хәлен аңлый идем мин, чөнки тормыш давыллары мине дә шушы дулкыннар кебек аямый-нитми таш кыяларга китереп бәргәләгән, арыткан-алҗыткан иде. Әйе, мин бик арыган идем...

Еракта-еракта кораб йөзә. Ул ялгызы гына бара, ләкин кая туктасын белә. Мин дә ялгыз хәзер, мин дә тормыш диңгезендә ялгыз гына йөзәм. Әмма кая барып туктармын — белмим...

Әйе, мин ялгыз, ә кайчандыр минем дә сөйгән ярым бар иде, ләкин ул йөрәгемә озак еллар төзәлмәслек яра салып китеп барды. Шактый вакыт узгач, миңа үземне аңлый торган яхшы күңелле, акыллы кеше очрады һәм ул тормыш юлдашым — баламның әтисе булды. Шушы диңгез буенда аның белән утырдык, ул мине туй сәяхәтенә алып чыккан иде. Ул вакытта диңгезнең шифалы сулары элекке сагышымны юып алып киткән кебек булды — тынычландым, үземне өзелеп яратучы, тугрылыклы юлдашым булу мине бәхетле итте. Бүген бу ярда без икәү утырырга тиеш кешеләр идек. Хәзер инде ул юк...

Бер уйлаганда гаҗәп тә кебек: күңелеңне мәңгелеккә әсир иткән кешене башка берәү әкренләп кысырыклап чыгара алсын инде. Алай микән соң?.. Ә нигә ул вакытта йөрәк яшерен дә, татлы да, газаплы да өмет белән кысылып тибә? Нинди өмет булуы мөмкин. Ул бит инде үлгән, димәк, өмет булу мөмкин түгел.

«Ә яшьлек мәхәббәтең исән бит!»

Бу сүзләрне миңа, әйтерсең, дулкын пышылдады. Исән!.. Менә ул унсигез ел буена кем өчендер исән, кем өчендер яши... Әллә тагын шул кеше синең уйларыңа кереп чорналамы? Әллә кайчандыр сагышларыңны юып алып киткән диңгез дулкыннары аларны тагын синең яныңа, ярга кире чыгарып салдымы?

Нигә мондый уйлар? Кирәкми! Мин бит дәваланырга, уй-сагышларны, ялгыз башыма калган дөнья мәшәкатьләрен онытып ял итәргә килгән кеше.

Диңгездән килгән салкынча җил битемне сыйпап узды. Мин, уйларымнан айнып, уянып киткән кебек булдым: кайтырга кирәк, соң инде.

Бүлмәгә кайтып кергәндә, күзгә каршында урта яшьләрдәге бер чибәр генә хатын бизәнеп тора иде. Ул да ял итәргә килгән.

Таныштык. Яңа күршем Раиса Кузминична бик сүзчән булып чыкты. Берничә минут эчендә ул бөтен тормышы, дус-ишләре турында сөйләп өлгерде.

Тик шуннан соң гына:

— Сез кайсы яклардан? — дип сорап куйды.

— Казаннан.

— Димәк, татарочка,— диде ул һәм, мин җавап бирергә өлгергәнче үк, минем ирем дә татар бит, дип аның турында сөйләргә, аны мактарга тотынды. Иренең татар булуы мине әллә ни гаҗәпләндермәде: руска чыккан татар кызы, рус кызына өйләнгән татар егетләре азмыни хәзер?! Тик Раиса Кузминичнаның «Минем Ахмедчигым» дигән сүзләре генә йөрәгемне чәнчеп үттеләр дә, әле генә диңгез буенда калган уйларымны яңарттылар.

Яңа күршем сүзен дәвам итте:

— Кешегә бәхет ничек килә бит: берәүләр гомер буе йөрешеп-сөешеп тә кавыша алмыйлар. Ә мин Ахмедчигым белән бер көнне танышсам, икенче көнне кияүгә дә чыктым. Күз ачып йомарга да өлгермәдек. Так удачно, так удачно!.. Әни ачуланып та, тиргәп тә карады. Мәхәббәтне сүз белән генә чигендереп буламы соң?..

Мин бу сүзләрне инде ишетми дә идем кебек. Минем колак төбемдә «Ахмедчигым» дигән бер генә сүз яңгырый... Күңел нәрсәдер сизенә, мин нигәдер калтыранып куям. Ахырдан:

— Сезнең ирегез кем соң? — дип сорамыйча булдыра алмадым.

— Врач... элек хәрби врач иде.

— Фамилиясе?

— Бакиров. Әллә беләсезме?

— Юк, юк... Мин болай гына. Зинһар, дәвам итегез...

Әхмәт кызларын бик ярата икән. Кызлары Рушана быел унынчы класска барачак, ул да әнисеннән бигрәк әтисен ярата...

Болай булгач, минем белән бер бүлмәдә ай буе Әхмәтнең хатыны Раиса Кузминична торачак! Менә сиңа ял...

«Түз,— дидем мин йөрәгемә.— Түз! Язмыш бу!»

Әхмәт бик тә тугрылыклы ир икән, күп хатыннар иргә ышануны ахмаклык дип саный, ә менә Раиса Кузминична ышана.

Кайчандыр аңа Кадрия үзе дә ышана иде бит, әйе, ышанып аның белән Ерак Көнчыгышка китә язган иде. Әгәр Әхмәтнең туганнан-туган апасы Әминә булмаса, киткән дә булыр иде һәм нәкъ Раиса Кузминична кебек, мине генә ярата дип, ышанып яшәр иде. Ә ул шушы тел бистәсенә бер кичтә гашыйк булган һәм аңа табынып яши. Менә сиңа ирләр! Без хатыннар аларга ышанабыз шул! Кайнар пышылдап: «Син генә!» дип миңа гына әйтә ала дип уйлыйбыз.

Раиса Кузминична бер кочак фоторәсемнәр сөйрәп чыгарды: менә ире (ул! Әхмәт!), менә алар өчәүләп төшкәннәр — әтисе кебек кара күзле, озынча йөзле, чәч толымнарын күкрәгенә салган кыз әтисе белән әнисен кочаклаган.

«Котлыйм, Кадрия, хәзер бик тыныч ял итә аласың!»

Ә нигә бу вакыйга минем тынычлыгымны алырга тиеш соң әле? Миңа бит аның өйләнгән булуы да, баласы барлыгы да яңалык түгел. Кыскасы, мин бу турыда уйламаска, Раиса Кузминична белән артык

гәп куертмаска тиеш. Кемнең яшь чагында сөйгән егете калмаган да, кемнең сөйгәненә кем бармаган. Бетте. Нокта.

Санаторий тормышы барыбызны да җай гына үз агымына ияртеп алып китте. Бүлмәдә тагын ике кеше бар. Берсе — Нина Александровна, ләкин мин аны «Нина» дип кенә йөрим, ул үзе шулай теләде. Архангельскидан, математика фәннәре докторы — шундый гади, шундый яхшы хатын. Без инде аның белән эш, тормыш хәлләре, бала-чагалар турында сөйләшергә дә, кайгы-шатлыкларыбызны уртаклашырга да өлгердек. Әллә аңа бөтенесен сөйләп бирергәме? Юк! юк! Беркемгә берни сөйләмәскә! Болай да, Хәмитнең фаҗигале үлеме турында сөйләп, бер төнне йокламыйча кичердек бит инде.

Икенчесе — Тамара. Ул — Курскидан, инженер, бик чая, давыллы итеп заманча яши белә торган хатын. Миннән бераз яшьрәк. Ул үзенең тугыз яшьлек кызы — Аленушка белән. Тамараның, билгеле, үз хәле хәл. Килгән кичне үк хәрбиләр санаториендәге Гриша исемле бер майор белән танышып өлгерде. Кич саен кайтып Гришасы белән ниләр сөйләшкәнен, кая барганын, алдагы планнарын колакка пышылдый.

Дәваланабыз. Көннәр Нина, Тамара, Аленушка белән үтә. Соңгы вакытта Гриша да безнең белән диңгезгә йөри башлады. Врачыннан качып чыга, шуклана башласа, «врачыңа әйтәбез!» дип куркытабыз. Ул бик тапкыр, телгә оста, мәзәк капчыгы, көлдереп үтерә.

Раиса Кузминична экскурсияләргә йөри, безнекеләр аны нигәдер (күп сөйләшкәнгә, ахрысы) баштан ук бик өнәп бетермәделәр. Теге ханым белән каядыр чыгып югалалар, төнлә гырлавын гына ишетәбез. Ходаем, гырлап та карый соң, такылдык булуы җитмәгән... Тукта! Бусы инде артык хатын-кызларча... көнчелек тә түгел микән?.. Айһай!.. Бик яхшы күңелле кеше булып чыкмыйсың бит әле син, Кадрия ханым.

Үзем дә сизмәстән аның уңай якларын санарга керешәм: сөйкемле хатын, яшь чагында чибәр булгандыр, гел көлеп сөйләшә, җөмлә саен тәмләп елмая — тукта, бусы уңай сыйфатмы соң?! Күп укыган, күп белә, ул күрмәгән бер генә кинофильм да юктыр. Кыскасы, Әхмәт абзаң хатынының рухи үсешен тоткарламаган. Менә тагын Әхмәт... Аның нигә кирәге булды соң әле сиңа?

Кузминична зәвык белән киенә белә. Әхмәте... Я алла!.. Әхмәт... Нәрсә соң бу?

Мин үз-үземне тиргәргә тотынам. Ничек тиргәмисең ди... Әле биш ел элек кенә нәп-нәни улымны кочкан килеш Хәмитнең салкын күкрәгенә капланып үксүемне онытырга мөмкинме соң? Нинди үкенечле, нинди газаплы югалту кичердем бит мин. Хәмитнең кабер туфрагына йөземне орып: «Сөеклем, мин сине бик, бик яратам... Исән чагыңда «яратасыңмы?» дигән сорауларыңа икеле-микеле җаваплар биреп газаплавым өчен гафу ит! Улыбыз-балабыз хакына кичер! Хәзер бөтен тормышымны, бөтен хисләремне синең улыңа-балабызга бирәчәкмен»,— дип ант эчүләремне онытым да мыни инде?..

Хәмит — яхшы кеше, мине ярата, баламның атасы — әмма аңа карата олы хис — ярату дигән нәрсә юк дип, шул хакыйкать белән килешеп яшәгәндә кинәт кенә аның үлеп китүе мине бөтенләй акылдан язар хәлгә җиткерде. Үкенү, кызгану, өметсезлек — мине еллар буе бертуктаусыз Хәмит турында уйларга мәҗбүр итте. Коточкыч очраклылык аркасында гомере өзелгән иремә мәхәббәтем үскәннән-үсә барды. Әхмәт исә Хәмит үлеменнән соң үзеннән-үзе югалды, аның

югалуын үзем дә сизми калдым. Гөнаһ шомлыгы, бу Кузминичнасы каян килеп чыкты диген син...

Тамара белән Гриша мине автобуска кереп утырган җиремнән кире алып чыктылар. «Көн сүрелгән, һава әйбәт — җәяү генә кайтабыз!» диделәр. Шаяра-шаяра, төрле мәзәкләр сөйли-сөйли кайтып җиткәнне сизми дә калдык.

Аленушка безне капка төбендә үк каршы алды, нигәдер ул бүген җитдиләнеп киткән шикелле. Баланың үзебезгә генә әйтер сүзе барын аңлагач, кичен танцыга чыгарга вәгъдә биреп, Гришаны тиз генә озаттык. Кызый, икебезнең дә кызыксынып аннан сүз көтүебезгә масаеп, бераз эндәшми барды, тимер капканың чөен суырып алды да безне ишегалдына уздырды. Аннан серле итеп як-ягына каранды һәм безгә эчендә алтын балык йөзеп йөргән авторучка чыгарып күрсәтте. Без исебез китмичә генә Тамара белән күзгә-күз карап елмаештык.

— Ә сез аны миңа кем биргәнне белмисез! — диде Аленушка, иреннәрен турсайтып.

— Син нәрсә бер ручкадан табышмак ясадың, берәр малай бүләк иткәндер әле,— диде Тамара, миңа күз кысып.

— Әйтәм бит белмисез дип, миңа аны...— Алена тагын бик мәгънәле итеп күзләрен тутырып безгә карады. Тамара, түземлелеген җуеп, кулын селтәде һәм юеш купальникларын эләргә тотынды.

— Миңа аны Ахмед Халилович — Раиса Кузминичнаның ире бирде... Вот. Ул бүген Калининградтан очып килде. Шундый кызык абый — фокуслар күрсәтә белә! — Аннан кызының сүзенә игътибар итми киемнәрен элеп маташкан әнисенә карап: — Озын буйлы, шундый чибәр,— дип өстәде.

— Аның чибәрлегенә Рая апаң сөенсен инде!

Аленаның беренче сүзеннән үк мин инде егылып китәр хәлгә җиткән идем. Тамара белән сүз көрәштерүләрен бөтен игътибарым белән тыңларга тырышып, баскан урынымда тора бирдем. Әллә төш, әллә өн. Төшем генә булса соң?

— Кадрия, ни булды?.. Кояш астында озак ятма, дидем мин сиңа, кызу суккандыр. Әйдә өйгә,— дип, Тамара мине култыклап та алды. Йокыдан яңа уянган кешедәй, аңыма килдем — кинәт кенә тайпылып урамга ташландым.

— Тамара, мин анда керә алмыйм... барасы җирем бар... китим әле мин...

— Нәрсә син, кич бит инде, пляждан кайткан килеш кая барасың? Күлмәгеңне алыштыр ичмасам!

— Э... ә... ә! Әйе шул, алайса зәңгәр күлмәгемне генә чыгарып бир, урындык артында,— дидем мин, ишеккә таба карарга да шикләнеп. Бераздан ул минем күлмәкне, туфляларны тотып беседкага килеп керде. Миңа сәеррәк бер караш ташлады да кия алмый аптыраган бер җиңемне табып бирде. Сүзсез генә салып ташлаган киемнәремне җыйды. Аннан тиз генә чыгып китәргә чамалавымны абайлагач, ишеккә аркылы басты. «Беркая да китмисең, хәзер мин дә өстемне алыштырам».

Мин, беседкадан чыгып, слива агачы артына яшеренгән килеш ишеккә күз ташладым. Менә өйдән Раиса Кузминична һәм «ул» килеп чыкты, әйе, «ул!», бернинди шик булуы мөмкин түгел!..

Менә «ул» тәмәке кабызды, баскычтан төште. «Аһ! Бакчага чыгалар!..» Мин тиз генә беседкага чумдым... Нәрсә соң бу? Ник килгән? Минем турыда беләме, юкмы?.. Нишләргә соң? Кая качарга? Әллә берәр сәбәп табып кайтып китәргәме?

— Лапочка, что-то с тобой происходит,— диде Тамара, сак кына

минем иңемә кагылып.— Әйдә, алар фатир карарга киттеләр,— диде, минем беседкадан чыгарга батырчылыгым җитмәүне сизеп.

Әле кичке ашка иртә, без санаторий паркындагы аккошлар йөзә торган күл янына барып утырдык. «Рәхмәт сиңа, Тамара, рәхмәт, акыллым. Җиңел холыклы, кызу кеше булсаң да, күңелең сизгер, нечкә синең, рәхмәт, җаныкаем. Янәшәмнән эндәшми килүең, күл буенда утырганда да берни сорашмавың, теләреңә салынып, хатын-кыз тирәсенә сырышырга йөргән «егетләр»не шома гына озатуың өчен дә рәхмәт сиңа. Үзем сүз башламый торып, бер генә сүз дә эндәшмәвең өчен мең-мең рәхмәт сиңа, дускаем!»

Мин аны кочаклап алдым: «Тома! Ашарга барырга кыстама мине, яме, кадерлем!»

— Ялагайланма! — диде гаҗәп кырыс тавыш белән Тамара.— Хәтта өстәл артында сытык кыяфәт белән утырып, минем аппетитны бозарга да ирек бирмәячәкмен. Кичке ашка нәрсә бирелсә — бөтенесен ашап бетерергә сүз бирсәң генә, мин бүген кич Гришаны сиңа алыштырам, киттек!» «Аһ, Гриша бар бит әле!»... Мин сүзсез-нисез Тамарага иярдем, бүгенге кичне аннан башка үткәрә алмаячак идем.

*

* *

...Университетның IV курсында укый идем ул елны. Туганнан-туган апамның бер бүлмәсендә торам. Кышкы сессия вакыты, диаматтан имтихан бирергә җыенабыз. Дәресләр бетеп, «читалка»га барыр алдыннан аяк өсте генә капкалап маташканда күрше Газиз бабай килеп керде. Ул инде берничә мәртәбә, берничә фәлсәфи проблема буенча дини китаплардан «үтергеч» дәлилләр, аксиомалар китереп минем белән бәхәсләшкән, ниһаять, миңа тәэсир итәргә маташуның «файдасыз» икәнлегенә инанган — киң күңелле, үткен телле, сөйкемле генә бер бабай иде. Киенеп, башлыкны эләктереп китәргә җыенганны күрүгә, ул ишеккә аркылы төште: «Тукта, кызым, синең белән мәслихәт итәсе зур бер эш бар! Чыраеңны сытма әле син, шайтан сабагың бер кая китмәс»,— дип, ишек янындагы урындыкка — үзе янына мине дә утыртты.

— Бер бик тә шәп җегет бар, укымышлы, тәуфыйкълы кыз кирәк. Мин, мондый четрекле мәсьәләләр чишәрлек вакытым юклыгын аңлатып, урынымнан ук кузгалдым.

— Утыр, олы кеше әйткәч! — бабаем чынлап ук ачуланды бу юлы.

— Үзең турында сүз бармый — чәнчелеп кит, шул урыс китапларын кочаклап карт кыз булып кал! Әмма минем энекәшкә бик чибәр, инсафлы татар кызы табып бир.

— Ну, Газиз бабай...

— Нулама! Савaплы эш ул. Духтырлыкка укучысы юкмы шунда бераә?!

— Духтырлыккамы?.. Бар, Газиз абый,— дидем мин, кинәт кенә күңелемә килгән фикергә сөенеп.— Таныштырам. Только ял көнне яме, ә хәзер китим инде...

— Юк... Булмый... Ял көнне китә ул, оча. Дәлни Вастуктан ялга гына кайтты бит ул. Әфисәр, капитан, ваянный брач! Во! — бабай кәкре баш бармагын тырпайтып күрсәтте.

— Алайса иртәгә, кич сәгать биштә кыз бездә булыр.

— Тукта!!! Шәпме соң кыз?

— Бик, бик шәп. Чибәр, акыллы, бер егет белән дә йөргәне юк...

Таныштырам Маһинур белән, ник таныштырмаска. Җаныкаем, нинди әйбәт кыз бит, чибәр, акыллы, уңган! Күзләре чыккандыр бу егетләрнең, шуны күрмиләр — егерме өч яшь бит инде аңа, әле бер генә егет тә озата кайтканы юк үзен. Менә кемгә кирәк яучы, таныштырырга да — калганын үзләре карарлар. Аз мыни кеше киңәше белән танышып үз бәхетен табучылар. Ә менә Маһинурны шулай гына кияүгә биреп булачак — артык тыйнак ул.

Маһинур сәгать дүрттә үк килде. Озын толымлы, коңгырт күзле, аксыл чырайлы чибәр генә, тыйнак кына кызны күргәч, Газиз бабайның күңеле булды — мине алгы якка чакырып чыгарды да, тагын кәкре баш бармагын тырпайтып күрсәтте:

— Ничә яшьтә?

— Егерме өч.

— Әткәсе-әнкәсе бармы?

— Әтисе сугышта үлгән, әнисе апасы белән генә тора.

Маһинур, түр бүлмәдә ялгызы гына утырасы килмичә, безнең янга чыкты. Газиз бабайны озатуга без апа белән аның кием-салымын тикшерергә керештек. Соры кәшимир күлмәген салдырып, минем яңа кофтаны киерттек. Ал кофта, кара юбка бик тә килешә, дулкынланудан бит урталары алсуланган! «Менә бу кәләш, ичмасам!» — Мин аны кочагыма алып зырылдатып әйләндерергә тотындым.

— Дускаем, өч көннән диамат икәнен онытма, мине җибәр инде яме! — Әмма Маһинур минем кулларыма чытырдап ябышты:

— Кадрия, дустым, китмә инде? Алар килгәнче генә тор! Булмый, үзем генә... әллә ничек... зинһар өчен!

Ә бит безнең уй бөтенләй башка иде. Маһинур «минем янга» дип килә дә, апа «хәзер кайтырга тиеш» дип аны көттереп утырта, шул арада «ялгыш кына» кунак егете белән Газиз бабай килеп керә. Шул исәп белән уку залында китапларым, конспект-дәфтәрләрем калды. Әмма Маһинурның йөзенә карагач, аның нинди хәлдә икәнен төшендем, һәм «чирканчык» алырга булышырга ризалык бирдем.

«Егетләр» (Газиз бабай, аның кияве Фатих абый һәм кунак егет) килеп кергәндә без политэкономия китабына капланган килеш бик тырышып «өстәмә кыйммәт»не өйрәнә идек. Килеп керделәр, Фатих абый таныштырды. Егет шәп! Озын буйлы, аксыл озынча йөзле, дулкынланып торган коңгырт чәчле, ходаем, ничек пар килгәннәр! Рәхмәт төшкере, Газиз бабай үзе дә канәгать кыяфәт белән мыек астыннан ничек мут елмая, җыерчыклар сырып алган кечкенә күзләре утлы күмер кебек шаян очкыннар чәчә! Ярар, диаматка кадәр өч көн бар бит әле, бер сәгать вакытымны дустымнан кызганып тораммы соң.

Өстәл әзер, түрдә балкып егет белән кыз утыра. Фатих абый безтабын әзерли башлауга кибеткә чыгып бер коньяк, бер портвейн, ике банка гөмбә кочаклап керде. Мин, алъяпкычымны ябып, мич алдында кайнаша башладым: чуенны тартып алып, капкачын ачуга, өйгә каз ите белән пешкән бәрәңгенең тәмле исе таралды. Студентның ачыкмаган чагы булмый диләр, ә инде гөмбә, бәрәңге, яңа арыш ипиенең тәмлелегенә бер дә чыдар әмәл юк иде. Миңа оялып-нитеп торасы юк, рәхәтләнеп ашыйм. Мине күзләмиләр ич! Алъяпкыч алдына чуеннан бераз корым тиде тиюен, әйдә ярар.

— Җәмәгать, сез мине гафу итегез, минем читальный залда китап-дәфтәрләрем ята, имтиханга хәзерләнәбез — китәргә рөхсәт итегез — дип әйтеп бетерергә дә ирек бирмәделәр, «кияү егете» мине тангога чакырды. (Бер-ике рюмканы төшерү белән Фатих абый пластинкаларга тотынган иде.)

Шушы танецтан соң ычкынып булса, минем эш бетте, әмма шома

егет тагын вальска чакырды. Вальс бетүгә мин аны көчләп диярлек урынына утырттым һәм, бушаган тәлинкә-кашыкларны җыйнап, алгы якка үттем. Ирләр тәмәке тартырга чыгып киттеләр, ә мин Маһинур янына кердем. «Ничек?» дим, «Ошый!» ди бу, кулымны кысып. Я алла, яучы булу бик җиңел эш түгел икән! Егеткә дә ошыйдыр инде, утызга җитеп килгән кешегә ни кирәк? Миңа рәхмәт әйтеп туймас әле, шундый кыз белән таныштыргач.

Хәзер инде мине апаның җибәрәсе килми, чәй табыны гына әзерләшкәнче китмә, ди. Чәй табыны янына утырыштылар, мин чия вареньесын вазаларга салып маташканда, ишекне бик хәсиятләп ябып, алгы якка Фатих абый чыкты. «Утыр әле! — ди бу миңа.— Ну, туй ясыйбызмы?»

— Ясыйбыз! Ошашсалар... («Кыз ошатты» дип, кинәт кычкырып, дустымның дәрәҗәсен төшерәсем килми бит).

— Егет ошыймы дип сорыйм бит инде үзеңнән!

— Маһинурга ошаса, миңа ошавы мөһим түгел...

— «Мөһим түгел», имеш, менә шартлатып туй ясыйбыз да, үзеңне энекәшкә бирәбез дә җибәрәбез.

— Ярар, ярар, Фатих абый, минем сезнең шаяртуларыгызны тыңлап торырга вакытым юк.

— Мин шаяртып сөйләмим бит, сеңелкәш, әле менә тәмәке тартырга чыккач: Ничек, мәйтәм, кайниш, кыз ошыймы? — дим.— Ошый, бик ошый,— ди бу.— Алайса — туй, мәйтәм.— Ник кайсы ошый, дип сорамыйсың? — ди бу, шомлык.— Соң үзеңә дип чакырганыдыр инде,— дим, тинтәк баш. Ә ул: беренчедән, әле аларның берсе дә минеке түгел, икенчедән — чакырып китергәне түгел, Сабира апада торганы — корымлы алъяпкыч япканы,— ди.

Минем аптырап, куркып калуымны күргәч, яңадан урыныма утыртты:

— Кыскасы, кайниш сиңа гашыйк булган, аңладыңмы?! Асыл егет! Мондыйны син әкәдим наук бетерсәң дә таба алмыйсың. Аттестатка чыккан акчасын ай саен әткә-әнкәңә биреп барачак. Шаккатма, әткәгә-әнкәгә бер кыз икәнеңне әйткәч үзе шулай дип җавап бирде.

— Аһ, менә ничек? Ничек ансат кына, ә! Песи баласы алырга килгәннәрмени!.. Фатих абый, хәзер үк чыгып китегез, берегезнең дә эзе булмасын! — дидем мин, ачуымнан буылып.

— Кара син аны, ничек куа! Кара син аны, ә! Мин бит синең өеңдә түгел, наныкаем, Хәкимҗан абзый белән Сабира апа өендә.

— Гафу итегез, зинһар өчен! — Мин артык кызып китүемне, олы кешегә алай кычкырырга да, кеше өеннән куарга да хакым югын аңлап алдым. Бөтен йөзем, колакларым ут булып яна башлады, күзләремә яшь тулды. «Бичара Маһинурым минем, ошый ди бит әле, әнекәйгенәм, ошый ди бит! Нишләдем мин, яхшылык эшләдем янәсе, шәп егет табып бирдем...»

— Ярар! Сеңелкәй, алай бик коелып төшмә әле син. Дус кызларының ирләрен аертып баручы чибәрләр дә була әле бу дөньяда. Әнә Әминә апаның...

— Фатих абый, зинһар өчен туктагыз!

Мин түр бүлмәгә кереп Маһинурның колагына: «Дускаем», әйдә минем китапларны гына тапшырып кайтыйк, аннан... аннан мин сине үзем озатырмын...» — дип пышылдадым.

— Нигә син?!

Без киендек, алар да киенделәр. Мин иң соңгы кеше булып ишектән чыктым. Алда Маһинур, Фатих абый һәм теге егет баралар. Минем китапларымны тапшырырга бергә бардык, аннан Островский урамы

чатына — трамвай тукталышына килдек. Маһинурга алтынчы трамвай кирәк иде. Мин инде соң икәнлекне дә, Маһинурны озатыр кешеләр барын да уйлап алгач, барысы белән дә саубуллашып, өйгә борылдым. Озатсын әле, бәлки килешеп китәрләр.

Капкага җиткәндә кемдер мине көчле куллары белән эләктереп тә алды.

— Кая качасың?!

— Сез?! Ә Маһинур, ул кая, ник озатмадыгыз? Алайса, хәзер мин аны үзем озатам...

— Тынычланыгыз, трамвайга утыртып җибәргәч кайта инде ул.

— Трамвайдан соң егерме минут җәяү барырга кирәк әле аңа. Яңа бистә зираты янындагы баракта торалар, бик куркыныч бит анда. Мин аны кунарга калдыра идем... Их, сез!

— Слушай, аны озаталар. Фатих абый калды аның белән. Аннан соң... миңа оны озатырга ярамый, аңла, ярамый...

— Ә нишләргә соң инде?

«Шуны да белмисеңме?» дигәндәй, елмаеп, ул минем иңнәремә кулын салды, әйләнгән сыман кискен хәрәкәт ясап, мин аның кул астыннан чыктым. Әмма бу кешегә «нахал» диеп яңагына менеп төшеп булмый шул, яше белән дә өлкән, аннан әлеге дорфалык дип атарга мөмкин булган хәрәкәтен дә ул нииндидер шаян, хәтта оялчан елмаю белән йомшартты да куйды.

— Әгәр ул... сезне ошаткан булса? — дим.

— Кадрия, син бала түгел инде, тарихи материализм өйрәнеп йөрисең үзең. Бер нәрсәне аңла: Маһинур турында сүз бармый. Мин синең белән сөйләшәм... син хәзер мине куып та җибәрә аласың, өметләнерлек җылы сүз дә әйтә аласың!

— Ай-һай ничек җиңел? Бер күр дә җылы сүз әйт, имеш.

— Син, балакай, логикадан имтихан бирдеңме?

— Логика, логика... Маһинурны имтиханга әзерләнеп утырган җирдән алып килдем мин... Сез әле аңа ошадыгыз да бугай. Менә кайда ул логика...

— Тагын Маһинур...

— Талашалар димме? — җир астыннан үсеп чыккан кебек безнең янда Фатих абый пәйда булды.

— Фатих абый?.. Син Маһинурны озатмадыңмыни?

— Һы, кара син аны! Ул монда егет белән сайрашып торсын, мин аның дус кызын озатып йөрергә тиеш! Кара син аны! Минем бит хатын, ике бала бар. Үзе аны озатасы егет белән сөйләшеп тора...

Мин йөгереп кереп урыныма капландым. «Әнекәем, бер үзе киткән! Төн уртасында! Яңа бистәгә... Бер үзе...»

...Иртәгесен, читалкага барып керүгә, миңа өчпочмаклап төргән бер хат суздылар. Хатны мин өч кабат укыдым, нигәдер үземне төш күрәмдер кебек хис иттем. Маһинурның барлык язганнары да аңыма барып житми кебек иде. Төнлә, сәгать бердә Яңа бистә күпере астында ук трамвайлары ватылып (каһәр төшкән 6 нчы маршрут) җәяү киткән... Зират эченнән бер үзе кайткан... Я алла, ярый әле юлында явыз бәндәләр очрамаган. Әнисе кызын күрүгә елап җибәргән, аннан орышкан... Әмма иң аянычы — исән-сау өенә кайтып әнисе күкрәгенә сыенгач та бетми торганы — теге шома офицерга гашыйк булган... Кыз төне буе йокламаган... Кич сәгать бишкә «республиканка»га чакырган, бик тә минем белән сөйләшәсе — эчен бушатасы килә икән...

*

* *

Университеттан кайтып өстемне чишенергә өлгермәдем, ишек шакыдылар, килеп җиткәннәр: Фатих абый һәм ул! Мин аны ачуланырга тотындым, нигә авыз ера ул, кичә нишләгәнен оныткан мы?!

— Ә нинди гаебем бар соң әле минем?!

Аңлата алмаслыгыма ышангач, ярдәмгә дип Маһинурның хатын чыгардым. Төнлә бер ялгызы кайтуын тасвирлаган урынын күрсәттем. Тәэсир итте!.. Агарынып китте, күзләрендә елмаю сүнде.

— Әйдә, бергә барабыз янына, мин гафу үтенергә тиеш!

— Чынлапмы?!.

Маһинурга мин бер сүз дә әйтмәдем, мине күрү белән ул китапларын тапшырды. Баскычтан төшеп җиткәч, аларны күрде дә, елмаеп җибәрде, икесе дә балкып күрештеләр. Я алла, шушылай килешеп кенә китсеннәр иде! Минем пальтоны Фатих абый, Маһинурныкын ул киертте. Урамда алар икесе алдан, артларыннан Фатих абый белән без барабыз. Фатих абый шаярта: урам буйлап кыз култыклап барганны Әминә апаң күрсә, нишләтер иде икән? — ди. Ә тегеләр сөйләшәләр, җаныкайларым, көлешкәләп тә куялар. Мин «егетем»не бераз тоткарлаган булам. Ул арада «кунак» борылып безгә кул болгады: «Яшьләр! Артта калмаска!» Без тагын Островский чатына, кичә Маһинурны озаткан җиргә килеп җиттек. Уен-көлке сөйләшә торгач, дыңгыр-дыңгыр итеп трамвай да килеп туктады. Мин дустымның кулын кыстым, офицер абзаң аны терсәгеннән тотып трамвайга алып кереп китте, без Фатих абый белән кул болгап калдык. Алар елмая, без елмаябыз... Трамвай кузгалды һәм... безнең егетебез трамвайдан кире сикерде. Миңа аны-моны уйларга вакыт юк иде — йөгереп барып, кызулап өлгермәгән трамвайның баскычына килеп ябыштым, аннан... аннан тегеләр дә сикереп менделәр. Уңайсыз тынлык урнашты. «Электростанция» тукталышына җитәрәк, әйдә төшәбез дигән мәгънәне аңлатып, кунак тагын минем кулга орынды. Мин төшегез дигән ишарә ясадым, ул минем колакка: «Алдагы тукталышта син төш!» дип пышылдады һәм честь бирде. Төшеп калдылар.

...Без Маһинур белән урам буйлап кар шыгырдатып бер генә сәгать йөрмәгәнбездер. Аннан ул өйләренә чакырды, үпкәләтүдән куркып кердем, әнисе Җәмилә ападан кичәге хәл өчен гафу үтендем, чәйләр эчтек.

Өйгә кайткач, апага бөтенесен сөйләп бирдем. «Җүләр син! — диде ул кыска гына итеп.— Нинди кешене мыскыллап йөртәсең, малай-шалай түгел бит ул сиңа! Иптәш кыз, имеш! Кеме соң ул дус кызыңның, иреме, егетеме?» Минем аңа җавап бирер чамам юк иде, нигәдер бүгенге кич күңелдә авыр тәэсир калдырды, егет һәм Фатих абый алдында уңайсыз килеп чыкты. Чынлап та, мәҗбүри яраттырып булмый бит инде, ә мин үземне нәкъ балаларча тотам — аны да, Маһинурны да уңайсыз хәлгә куям. Алар әле, «Акком асты» тукталышына барып, мине көтеп торганнардыр, ә аның аякларында ботинка, өстендә шинель... Мин тагын төне буе боргаланып йоклый алмый яттым. Бу юлы инде Маһинурны түгел, нигәдер, аны — Әхмәтне уйладым.

Иртәгесен ул килмәде... Ул кичне соң гына Газиз бабай килеп керде, мин аңа күтәрелеп карарга да уңайсызландым — ул сизелерлек дәрәҗәдә ачулы иде.

— Авырый, бик каты тамагына чыккан, жары кырыкка җитә язган,— бу сүзләрне әйткәндә ул минем якка шелтәле караш ташларга да онытмады — моны мин аңа карамаган килеш тә тойдым.

...Өч көннән ул килде, йөзе тагын да агарган, күз төпләренә күксел күләгәләр төшкән иде.

— Я, диамат ничек? — диде ул, шул хәлләрдән соң да минем өчен генә мөһим булган нәрсәне исендә тотып.

— Әле хәзер генә имтихан бирөп кайттым. Бәхеткә каршы, җиңел сорау туры килде. Ә сезнең... мин сезне авырый дип ишеткән идем...

— Теге кечне шактый туңылды, аннан сине кабат югалткан кайгыдан кибеткә кереп берәр йөз белән тамак чылаттык. Ул да бик салкын иде.

— Гафу итегез инде...

— Зарар юк, үтеп бара инде. Аның каравы, Казанда менә тагын берничә көн тора алам — больничный бирделәр.

— Мин гаепле инде...

— Әлбәттә, син гаепле, менә шуңа күрә дә сиңа каты җәза — иртәгә татар театрына барырга әзер бул, яме!

— Ярар!

Театрга киеп барырдай яхшы киемнәрем юк иде, лекцияләргә ничек йөргән булсам, шулай киттем. Партерның өченче рәтен тутырып аның туганнары утыра икән, барысы белән күрешеп чыкканчы колакларым ут булып яна башлады. «Мине күрсәтергә алып килгән, аны ошатаммы-юкмы икәнне дә белмәгән килеш, туганнарын җыеп алып килгән... Үзен ошатмаслар дип башына да китерми...» Утлы таба өстендә утыраммыни. Я алла, менә спектакль дә башланды. «Хуҗа Насретдин»ны икенче мәртәбә каравым булса да, бөтен игътибарым сәхнәдә. Менә Хуҗа Дәрвиш белән сөйләшә:

Дәрвиш: — Дәрвиш алла кунагы, инсафыңа кил, дивана, кабул ит! Кунак ит!

Хуҗа: — Алай булса, капканы ялгышкансың, әнә аның йорты — моннан манарасы күренә. Син шунда бар. Ул кунак итсен!

Халык гөж килә, мин генә көлә алмыйм. Ә ул... ул... сәхнәгә күз дә салмый, миңа таба борылып, туп-туры йөземә карап утыра. Минем ачу, үпкә сүрелә төшә, яңагыннан йомшак кына этәреп башын сәхнәгә таба борам, колагына «Әбҗәлилов!» дип пышылдыйм.

Тәнәфес вакытында Әхмәт мине буфетка чакырды, мин, «чыкмыйм» дигән мәгънәне аңлатып, башымны чайкадым. Шул чакны аның белән янәшә утырган чибәр генә ханым миңа борылды.

— Бу минем апам Әминә — мин аларда инде. Соң кайткан өчен дә, суык тиергәнгә дә, салсаң да колакны бора. Кыскасы, әни урынына калган апам, ятим бала бит мин.

Әминә апа алтын тешләрен күрсәтеп елмайды, колагындагы алкасы елкылдап куйды, өстендәге яшел кофтасының төймә читләре дә алтын, ахры. Әхмәт миннән рөхсәт сорап буфетка китте, ә без Әминә апа белән утырып калдык. Безнең сөйләшер сүз юк, мин кулымдагы программаны бөтәрләдем, ә ул сул кулының ике бармагындагы алтын балдакны һәм берсе гәрәбә, берсе ахак кашлы ике йөзекне азапланды. Ярый әле Әхмәт тиз килеп җитте. (Фатих абый чират алган булган.) «Бусы тамагы авырткан кешеләргә!» диде ул һәм зур гына тартманың өстен ачып, конфет тәкъдим итте, Фатих абый мороженое өләште. Спектакль беткәннән соң, Әхмәтнең миңа якалары кыршылып беткән пальтомны киертеп маташуын күргәч, Әминә апа инде мыскыллы елмаюын яшерүне кирәк тә тапмады. Аның өстендә мин исемен дә белмәгән җәнлек тиресеннән тегелгән тун иде.

— Урамда озак катып торма, авыру икәнеңне онытма! — диде ул, «торма!», «онытма!» сүзләренә аеруча басым ясап.

— Есть, авыру икәнне онытмаска! — диде Әхмәт, үкчәсен үкчәгә бәреп, уң кулы белән чигәсенә орынгандай итте.

Безнең капка төбендә «катып торырга» ирек бирмәдем мин аңа. «Бар инде, бик соң хәзер... безнең тирә бик куркыныч...» дидем.

— Рәхмәт, иртәгә кадәр, тыныч йокы! — Әхмәт минем кулымны сак кына учларына алды, аннан иреннәренә китерде. Мин икенче кулым белән капканың келәсен тарттым (кеше кайтасы булганда шулай калдырабыз), өйалдына кердем. Караңгы өйалдында бераз торгач, кире чыгып, урамга күз салдым: зифа буйлы шинельле егетне ир белән

хатын ике ягыннан култыклап алып киттеләр. Багана башында чайкалып торган электр лампасы яктысында мин таныш тунны шәйләдем...

Ах, минә ничек!.. Куркыныч имеш! Беркатлы да инде мин. Ялгыз йөртәләрме инде аны... Кыз озата барганда да артыңнан саклап килсеннәр әле. Бәлки чит шәһәргә килеп төшкән туганнарына (Әхмәт Новосибирскида үскән, Казанда бала вакытында гына булган) хөрмәт, игътибар йөзеннәндер...

Иртәгесен егет үзе килгәнче апасының миңа адресланган «мактау сүзләре» килеп житте. «Авыл кызы... хаерче... Теге җүләре (бусы Әхмәт була инде) күзен дә алмый бит шуннан... Театр карамады, күзе гел анда булды. Нишләтте икән ул аны... Әллә сихерләде микән?» дип әйтә ди.

Кыскасы, менә шул: элек Маһинур, аннан апасы... Алдагы очрашуларда тагын шулай яшь чакта үтеп чыгып булмастай тоелган вактөяк киртәләр очрый торды...



*

* *

...Аккошлар инде пар-пар булып бәләкәй өйләренә кереп йокыга талганнар. Санаторий паркында каравылчы бабайдан башка берәү дә калмаган. Без Тамара белән аның плащын бөркәнеп өйгә атладык. Санаторий капкасы янындагы фонарь яктысында Тамара сәгатенә күз салды. Икенче унбиш минут. Кешеләр йокыларын туйдырып өлгергәннәрдер инде, бик шәп, миңа шул гына кирәк тә...

Диңгез буе шәһәрләрендә җәйге төннәрдә гаҗәп тыныч сизәсең үзеңне. Тәбәнәк кенә коймалар артында виноград үрмәләп үскән беседка. Беседка саен кеше, аяк астында артык өлгерүдән коелган сливалар сытыла, йөзенә алсулык йөгергән грушалар баш очында эленеп кала. Этләр өрә, әтәчләр кычкыра. Авыл да, шәһәр дә бу; ялгыз да син, түгел дә; сәламәт тә син, авыру да; санаторийныкы да син, иреклe дә — курсовка дигән әйбер менә шул инде...

Үзебезнең урамга борылуга мин кинәт туктап калдым, капка төбендә свитер кигән бер кеше тәмәке тартып тора иде. «Ул!» ...Тамара миңа карап башын чайкап куйды, аннан:

— Гриша! Кил әле монда, Кадрия синнән курка,— диде.

Гриша папиросын җиргә салып таптады да, безгә таба атлады.

— Кызый, синең үзеңә эләгәчәк хәзер! — диде Ул, кыйнарга җыенган кешедәй җиңнәрен сызганып.

— Кадрия гаепле, Гриша, бүген кич буе чабуыма ябышып йөри.

Мин аларны калдырып беседкага уздым (бүген без Тамара белән шунда йоклыйбыз) җәелмәгән урынга чишенмичә генә капландым; шактый арылган, аяклар гүли, баш чатный. Инде бераз гына булса да йокларга иде, болай гына йоклап булмаячак — үрелеп өстәл өстендәге тартманы ачтым — димедрол кабып су белән эчеп җибәрдем. Тамара минем турыда Гришасына сөйләр микән?

Күп тә үтмәде, Тамара керде. Урындыкка утырды да, башымны сак кына күтәрде.

— Нәрсә син, әллә елыйсыңмы?

— Юк.— Ул ышанып житмәде, ахры, элек битемне, аннан мендәрне капшап карады.

— Молодец, лапочка!

— Том! Гафу ит инде мине.

— Нәрсә турыда син?

— Мин бит сезнең бер кичегезне урладым.

— Глупости... Тор әйдә, урын җәябез. Сиңа хәзер үк йоклап китәргә (Тамара тәрәзәдән төшкән фонарь яктысында сәгатен карады) һәм кимендә биш сәгать йокларга кирәк.
— Әһе, мин инде йоклап барам. Ике таблетка димедрол йоттым.
— Тома!
— А!
— Гришага сөйләдеңме?
— Бераз... Нәрсә, әллә әйтмәскә идеме?
— Юк... Ничек әйтмисең инде... Нәрсә ди соң?
— Романтично! — ди.
— Дур-рак!
— Ха-ха-ха! Иртәгә үк мин бу сүзне җиткерәчәкмен.
— Ошадымыни?
— Аһа!
— Яңа сүз түгел бит...
— Зато урынлы.
— Тамара! Син ничек уйлыйсың, миңа ун көн буена качак булып яшәргәме әллә җыенып, иртәгә үк китеп барыргамы?
— Дура!
— Рәхмәт, мы — квиты.
— Җаныкаем, нервларыңны бозма, Кузминичнаның ире ич ул, аның өчен син борчылырга. Әнә хатыны кайгыртсын. Җитте, йокла!
«Ничек бу Тамара уен сүзне дә урынлы итеп әйтә белә!.. Кузминичнаның ире! Шушы сүз йөрәккә салкын бер дулкын булып килеп орынды, җиңел булып китте...»
Иртән Нина Александровна: «Подъем!» — дип кычкыргач кына уянып киттек.
Ашханәдән чыгуга безне Гриша каршы алды. Җәяүләп диңгезгә киттек. Гриша җитдиләнеп калган: шаярмый да, көлми дә. Тамара гына ара-тирә берәр шуклык эшли, әмма ул да шактый тыйнак иде бүген. «Мине кызганалар!»... Шушы уй йөрәкне чәнчеп үтте, бәхеткә каршы, диңгез ярына килеп тә җиттек. Барган көйгә пляж халатын салып ыргыттым да диңгезгә чумдым. Әй мәрхәмәтле, мәгърур, салкын һәм шифалы диңгез суы! Нигә «Кара диңгез» диделәр икән соң сине, син бит зәңгәр диңгез! Мин чалкан ятып су өстендә чайкала башладым, «зәңгәрлегән» дә аңа күк бүләк иткәндер әле; исемә бала чагым — әниемнең кичләрен кул эше белән утырганда җырлаган җыры исемә төште:

Зәңгәр һава, зәңгәр болыт,
Зәңгәрләтә диңгезне.
Зәңгәр һаваларда йөзгән
Айдан эзлим мин сезне...

Хәзер Әхмәт тә, Кузминична да юк иде инде, зәңгәр һава астында, зәңгәр диңгез дулкыннарында тирбәлгән, хөр, ябь-яшь табигать баласы гына бар иде. «Нигә Алмазымны алып килмәдем соң мин, янымда улым чайкалса, миңа тагын ни кирәк?» Бу уй мине Тамара Аленушкасы белән килеп төшкән көннән бирле эзәрлекли иде. Әйе, әйе, ул вакытта Әхмәт белән очрашу да җиңелрәк булыр иде.
Мин ярга чыктым. Тамара Гриша белән яр буенда комда утыра.
— Шәп йөзәсең син! — диде Тамара.
— Здорово! — дип кушылды аңа Гриша.— Су кызы диярсең!
Мин толымнарымны сыгып өеп куйдым. Кызындык, су коендык, карта уйнадык; аннан квас мичкәсе янындагы чиратка кушылдык. Бидон, фляга тоткан шәрә кешеләр янында плавкилардан гына балалар кайнаша, минем улым әнә теге сары чәчле малай белән бер чама инде, минеке кара, әтисе кебек чем кара. Ерак та түгел өсте каплаулы

индыр табагы хәтле җирдә раскладушкаларда кешеләр ята. Алар кояштан качып, һава ваннасы гына алалар; кайсының кан басымы югары, кайсының йөрәге начар. Гриша, тәмәкесен кабызып, читкә чыкты — киоск ышыгына басты, Тамара белән икәү калдык.

«Кызлар! Сездән соң квас эчәргә мөмкинме?» Таныш тавыштан мин кинәт дерт итеп киттем. «Ах, үзебезнең кызлар икән әле, исәнмесез!» Минем каршымда үзем кебек үк ялангач Әхмәт елмаеп тора иде.

— Исәнмесез!

Тамара тагын миңа ярдәмгә ашыкты! «Гриша! — диде ул, тамак төбеннән калтырап чыккан куе тавышы белән,— безнең полкка тагын берәү өстәлде. Кайчандыр хәрби кеше булуы белән синә иш, ә Кадрия белән алар милләттәшләр, якташлар да бугай әле...»

— Рәхим итегез безнең сафка! Без бик шат.

Кара инде син бу язмыш шуклыгын, очрашудан качып йөреп, нинди кыяфәттә күрешергә туры килде. «Крымская» дигән су шешәләрен сеткага төяп диңгез буена киттек, мин тиз генә халатымны киеп куйдым. Җәймә тирәсенә утырышканда Әхмәт тә трикодан һәм жилфердәп торган ефәк күлмәктән иде инде. Гриша җыелма стаканнарны су белән мөлдерәтеп тутырды да икебезгә сузды (стакан икәү генә иде).

— Якташлар хөрмәтенә!

— Рәхмәт!

Бу сүзләрне әйткәндә мин беренче мәртәбә аңа күтәрелеп карадым: олыгайган, чигә чәчләренә кырау төшкән, әмма күзләре... күзләре шул ук... Шундый ук нурлы, шулай ук моңлы һәм сагышлы. Икебез дә эчеп бетердек. Аннан Тамара белән Гриша эчте, алар кавырсын стаканнарын чәкештереп көлешеп алдылар. Кыскасы, беренче уңайсыз минутлар артта калды. Дилбегә Тамара кулында иде. Ул карталар чыгарып салды. Әхмәт белән янәшә утырмаганга, без кара каршы булып чыктык. Карта уенында минем осталык бик чамалы — аңа сораулы караш ташлау минем төп шөгылем булып китте. Ә аның күзләре һаман елмаялар, мин аптырап калган минутларда үрелеп минем карталарга күз сала һәм Тамараның: «Ярамый, ярамый!» — дип ризасызлык белдереп кычкыруларына да карамастан, миңа нинди картадан йөрергә кирәген әйтә. Әмма безнең икебезнең дә уйлар карта уенынан ерак иде бугай...

«Менә кайда икән алар!» — гадәтенчә елмаеп Кузминична басып тора иде. «Ходаем, Әхмәт кенә түгел бит әле ул, Кузминичнаның ире дә! Ә мин Әхмәт кенә дип уйлап, үземне ничек тотарга белми коелып төштем...»

Ни генә булмасын, Кузминична килеп гөрселдәп Әхмәткә сөялеп үк утыруга, мин айныган кебек булдым, җиңел сулап куйдым, хатыны янына ял итәргә килгән кеше, очраклы гына сиңа юлыккан. Ә мин тинтәк ниләр кичермәдем. Яшьли килгән авыр кайгы, ялгызлык — кешене артык тәэсирләнүчән итә, ахры. Минем елыйсым да, көләсем дә килә иде.

— Автобус! — Тамара кычкырып җибәрде һәм кулымнан тартып торгызды.— Гриша! Әйберләрне ал! — үзе мине житәкләгән килеш автобус тукталышына чаба башлады. Без ахылдап автобуска кереп утырдык. «Гомергә автобус белән йөрмәгәнне! Кара инде бу Тамараны, ниләр генә уйлап чыгармый!»

— Без чыннан да автобус белән кайтабызмы? — диде йөгереп килүдән сулышы капкан Гриша Тамарага гаҗәпләнеп карап.

— Әлбәттә,— диде Тамара бәхәсләшергә урын калдырмый торган тавыш белән.

— Кызынырга да, коенырга да ярамый торган Кузминичнасы белән пляжда рәхәтләнсен әле! — диде Тамара минем колагыма.

— А мин Ахмедны ресторанга чакырмакчы идем,— диде Гриша, авыр сулап.

— Кайчаннан башлап санаторий ашлары ярамый башлады әле сиңа? — диде ачулы тавыш белән Тамара.— Әнә Кузминичнасы белән барсыннар ресторанга.— Тамараның кинәт кырысланып калуы хәтта миңа көлке тоела башлады.

— Тамара! Ә мин синең нигә һәм кемгә ачулануыңны аңламыйм!

— Карасана, аңламый, бусы да аңламый!.. Ахмеды да кемне кемгә алыштырганын аңламаган. Ирләрнең күбесе хатынсыз йоклый алмаганга гына өйләнә. Нәрсә миңа күзеңне акайттың,— дип, алгы утыргычтан безгә борылган Гришаны да битәрләп алды Тамара.— Бик беләсегез килсә, ирләр сайламый хатыннарны, без — хатыннар сайлыйбыз. Ухаживать итү, тәкъдим ясау кебек рәсми яклар да безнең теләк буенча эшләнә. Ә сез, сез, гомерегез буе кечкенә бала кебек, җил уңаена хәрәкәт итәсез. Кеше сүзенә карыйсыз, җил уңаена борыласыз да бөтенләй кире якка юлыгызны дәвам итәсез! Алай рәхәт бит, кая таба барсаң да барыбер түгелмени.

Мин Тамараның кулыннан тоттым, аңа автобустагы кешеләр игътибар итә башлаганнар иде. Ә Гриша исә, «буран» чыкканда ышыклanудан башка чара булмаганлыкны аңлатты, күлмәк якасын күтәрде, муенын, башын яшергәндәй итте.

Автобустан төшеп, баскан саен иңеп калучы кызган асфальт буйлап барганда Гриша тагын баягы сүзне ялгап җибәрде:

— Кадерлем, мин сине сайладым кебек. Син мине түгел.

— Ялгышасың, мин сине сайладым, чөнки бик яхшы танцевать итәсең, телең шактый шома, корсагыңа игътибар итмәсәң, кыяфәтең дә ярыйсы. Ял вакытын үткәрергә ярар, дидем. Ә син, Кадрия кармагыңа эләкмәгәч, янәшәңдә торганга күрә генә мине танецка чакырдың һәм шунда инде үзең минем кармакка эләктең.

— Ха-ха-ха! — Без Гриша белән урам яңгыратып көлә башладык.

— Менә сиңа аңлашу!

— Чыннан да, бүген кич тә Тамара теләсә генә очраша алабыз бит әле, ул теләмәсә юк,— диде Гриша.

— Теләмим, әлбәттә.

— Тыңла әле, күгәрченкәем, син ниндидер бер офицер ачуын никминнән аласың.

— Җитте, телеңә салынма. Кичен күл янына кил, сәгать сигездә Кадрия белән шунда булырбыз.

Тамараның күңелендә ирләргә карата юшкын булып утырган нәфрәт, ачу, әрнүнең серен мин белә идем (аның ире ике баласы булганнан соң хыянәт иткән — аерылганнар, ә ул аны оныта да, гафу да итә алмый). Гриша ул турыда беләме-юкмы? Тамара исә ул турыда сөйләргә яратмый.

— Мин бүген сезне икегезне генә калдыра алам. Очраштык — «таныштык», диңгез буена кем килмәс. Гафу итегез мине, хатын-кыз шулай сентименталь була инде ул. Ә хәзер мин үземне яхшы хис итәм. Ул хатыны янына ялга килгән, тимәгез аңа.

— Би-ик кирәге бар! — Тамара тагын кызып китте.— Кадриянең күләгәсен дә күрсәтәчәк түгел хәзер мин аңа. Чөнки ул синең кисеп ташлаган тырнагыңа да тормый. Чиләгенә күрә капкачы, Кузминичнасы белән булсыннар. О-о-о! Ничек пар килгәннәр алар!..

— Томуся! Минем ашыйсым килә.

Тамара ышанырга да, ышанмаска да белми текәлеп күзләремә карады. Минем чыннан да үлеп ашыйсым килә иде.

— Яхшы,— диде ул шактый сүрелеп.— Алай булса, бик яхшы!

— Мин дә ашарга барам, димәк, кичке сигезгә күл буена.

— Әйе.

Чыннан да, өч көн буена без өчәүләп «аңардан» качып диярлек йөрдек. Кырымның атаклы көньяк яр буйларында экскурсияләрдә булып кайттык. Ул да тыныч кына хатыны белән ял итә иде бугай. Квартирага күршегә урнашкан, аякларын дәвалау өчен врачтан рөхсәт алган, ди. Миңа хәтта шулай югалып калуым, үзләрен борчуым өчен Тамара белән Гришадан оят була башлады. Үз-үземне кулга алдым, алар алдында тыныч һәм шат булып күренергә тырышам. Әмма күңел урыныннан купкан иде инде. Мине бер генә теләк эзәрлекли — улым янына, Казаныма ашкынам. Ярый әле, өч көн алдан китү өчен билетка заказ биргән идем.

...Бүген Тамара белән Гриша мине ялгыз калдырырга риза булдылар. Сәгать унда ук беседкага кереп яттым (Клавдия Михайловна анда лампочка куйган). Кулыма китеп алдым. Укып булмый... Ике көннән китәм! Күпме генә тезгенләргә теләсәм дә уйларым кабат Әхмәткә әйләнеп кайта. «Димәк, мин монда икәнне белмичә хатыны янына килгән... Мине әллә кайчан онытып бетергән инде ул... Җүләр дә инде мин, Тамара әйтмешли, унсигез елдан бирле гаиләле ир сине уйлап торамы?»

Мин торып өстемә халатымны кидем, өстәл янына килеп утырдым. Кечкенә көзгене алдымарак тартып куйдым: аннан миңа ике бите комачтай кызарган, күзләре дымланган, чәчләре тузгыган (китап укырга да, йокларга да һич исәбе булмаган) бер ханым карап тора иде. Нишләргә соң, Тамарасыз бер генә минут та тора алмыйм икән ләбаса?! Чемоданымны сөйрәп чыгардым да, әйберләремне әйбәтләп тутырырга тотындым. Кыюсыз гына ишек шакыдылар. «Әнекәем, әллә улмы?! Юктыр, берәрсе шаяртадыр». Мин, чемоданны ябып, кровать астына шудырдым. Шаку кабатланды. «Нинадыр әле!»

Иңем белән җиңелчә генә килеп орынуга — такта ишек дәррәү ачылып китте: «Ул!..»

— Мөмкинме?

— Юк, юк! Нәрсә син, кит кеше күргәнче. Мин бит бер үзем генә!

— Беләм... Курыкма!.. Барысы да кинода.

Минем йөрәк тибешем үземә үк ишетелә башлады. Аны беседка ишек төбендә озак тотып булмый, ишегалдындагы электр лампасы буйдан-буйга яктыртып тора бит үзен.

— Кер тизрәк! — Килеп керү белән ул мине куллары белән кочып алды, ятьмәгә эләккән балык кебек чабалануыма карамастан, әле чәчемнән, әле маңгаемнан, әле кулларымнан үбә башлады.

— Ах, шундый кешемени әле син! Кычкырам мин хәзер, минем ялгыз калудан файдаланып төн кунагы булып килдеңме, ирсез хатын дисеңме?!

Аның өстенә салкын су койдылар мыни, ул кинәт кенә мине үзеннән читкә этәрде һәм ишеккә сөялгән килеш күзләрен тутырып миңа карап тора башлады. «Кычкырам» сүзе куркыттымы, башкасымы — аңламый торам. Әмма бер нәрсә көн кебек ачык, шулкадәр җанга якын коңгырт зур күзләр тагын берәр минут миңа текәлеп торсалар — мин үзем үк килеп аның күкрәгенә капланып үкси башлаячакмын. Я, хода! Ник шул кадәр газаплыйсың...

Күзләр идәнгә текәлделәр, ул шунда торган урындыкка утырды, юк, утырмады — шуып төште...

— Гафу ит! Минем хакта шулкадәр начар уйлый алырсың дип башыма да китерми идем... Нигә качып йөрисең соң син? Көндезләрен күрсәм, шулай бәреп керер идем мени! Мин бит... Мин монда сине күрү, бер генә мәртәбә булса да сине күрү өчен килдем. Син минем

күңелемдә гомерлеккә калдың, гомерлеккә... Син хәзер ирекле кеше... «Ул» минем үзен яратып тормаганымны белә. Кызым инде үзе бер егетне ярата... Мине аңлар... Әгәр син риза булсаң...

Ярталаш ачык калган ишектә Тамара күренде, мине озакка ялгыз калдырасы килмәгән инде, җаныкаемның. Әлек миңа, аннан Әхмәткә күтәрелеп карады да: «Комачауламадыммы?» — диде.

— Юк, мин аңа барысын да әйттем инде. Шуны әйтү өчен төньяктан очып килдем. Үзе уйласын, мин җавап көтәм. Тик, үтенәм — качып йөрмәгез...

Тамара Әхмәтне өстәл янына чакырды һәм аның сүзләрен илтифатсыз калдырган сыман: кызы, эше, тормышы турында сораша башлады. Аннан киносеанс бетәрәк, китәргә киңәш бирде. Әхмәт гафу үтенеп башын иде һәм ни өчендер рәхмәт әйтеп чыгып китте.

Калган ике көнне без очрашып-сөйләшеп йөрдек. Тамара уйлауны, хөкем чыгаруны минем үземә калдырды. Әмма иртәгә китәм дигән көнне, ягъни ике көннән, «озату» кичәсе оештыруны үз өстенә алды. Мин Әхмәткә җавапны шунда бирергә булдым.

...Менә ул кич. Виноград тәлгәшләре астында ишегалды уртасында өстәл. Аның өстендә «Шампанское», «Коньяк», «Массандра» шешәләре. Клавдия Михайловна «чебурики» пешергән, үрдәк кыздырган, тау-тау җиләк-җимеш, яхшы конфетлар. Магнитофон янында Әхмәт белән Аленушка кайнаша. Күңелдә моңсулык та, өйгә кайту шатлыгы да бар. Бераз ашап та, «төшереп» тә алгач, кешеләрдә бию өянәге купты. Гриша баштан ук Раиса Кузминична белән булды, ашаганда да бергә утырдылар, Тамара бүген Кадриясе белән аерылыша, шуңа күрә күңеленә ошаган хатынны сайлап алырга үзе рөхсәт биргән, имеш. Ә Раиса Кузминичнага житә калган — авызы колагында: ара-тирә иренә горур караш ташлап ала. «Менә, янәсе, синең хатының да төшеп калганнардан түгел, нинди кешеләр күз төшерәләр үзенә». Бу авантюра дүртебезгә генә билгеле, шуңа күрә безнең изге күңелле хуҗа хатыныбыз — Клавдия Михайловна: «Иреңне үпкәләтмә!» — дип Раиса Кузминичнаны берничә тапкыр кисәтеп тә куйды.

Мин үзем теләп Тамара белән Әхмәт уртасына утырдым. Хатыны Гриша белән булгач, ул кая барсын инде? Ә мин китәсе кеше, тагын да зуррак хокукларга ия: бер Тамара, бер Әхмәт белән биедем. Сөйләшмибез, ул да никтер тынып калган. Тик күз карашы белән генә көйдерә, кулны кысып-кысып куя. «Соңгы вальс» диделәр.

— Нәрсә көтәсең син? Ник бер сүз дә әйтмисең!

Мин дә аның соравына сорау белән җавап бирдем.

— Әхмәт! Син кызыңны яратасыңмы?

— Бик яратам, минем бөтен куанычым ул булды...

— Кызың сине ярата мы?

— Бик! Хәтта әнисеннән дә күчлерәк.— Әхмәтнең күзләрендәге моңсулык юкка чыкты, ул балкып елмаеп куйды — кызын күз алдына китерде, ахры.

— Ә нигә аны ташлап качарга җыенасың?

— Ул зур инде, үзе егетләр сөя. Аннан... аннан мин аңа гел ярдәм итеп торачакмын.

— Ә мин улымны бер вакытта да бер кешегә дә алыштырмас идем. Син үпкәләмә миңа. Син ялгышасың, кызың сине әнисеннән көчлерәк яратмый, бәлки кайбер сыйфатларың өчен артыграк хөрмәт итәдер. Шулай ук син аны үзең дә әнисеннән көчлерәк яратмыйсың. Яратсаң, миңа андый тәкъдим ясамас идең. Баласын калдырып, икенче кешегә мәхәббәтен эзләп киткән ана бик сирәк очрый. Ә ирләрнең күбесе чибәр хатын итәгенә тагылып китәргә риза. Монда инде хатыннар үзлә-

ренең эгоизмына юл куймаска тиеш. Кечкенәдән үк эгоистларны женем сөймәде, әле дә алар миндә чиркану хисе тудыра. Инде, хатын уртасы булгач, үз-үземә хыянәт итеп, баласын атасыннан, хатынын иреннән аертып, үз күңелемне күрү җаен эзләмәячәкмен.

— Кадрия! Нигә син миңа мораль укыйсың? Син мине очраган бер хатын итәгенә тагылып китәргә торган җилкуар дип беләсеңме? Мин бит сине унсигез ел буена яратам. Кешенең үз бәхетенә омтылырга хакы юкмыни? Нинди эгоизм булсын бу?

— Ярар, син эгоист түгел, ди. Кызың турында да уйладың, хәл иттең, ди. Ә минем улым турында уйладыңмы син?

— Ул бит синең үз яныңда — безнең белән бергә була.

— Иң газиз, иң якын өч кешенең мөкатдәс хисләрен таптап ирешкән бәхетнең тулы буласына ышанасыңмы син?

— Син бәхетле булачаксың, улыңны мин үз баламнан артык күрәчәкмен.

Инде соңгы вальс беткән, күңелләре күтәренке кешеләр төркем-төркем булып төрле җирдә күңел ачалар. Без дә өстәлнең бер читенә килеп утырдык. Тамара, тиешле интервал калдырып, безнең тирәдә чуала. «Якташлар бәхәсләшә» дип берәр мәртәбә кешеләргә аңлатма да биреп куйды. Чыннан да без инде, гашыйклардан бигрәк, кызып-кызып бәхәсләшкән кешеләргә күбрәк ошый идек.

— Әхмәт! Бала-чага булма. Без бит — тормыш сынауларын үткән, төрлесен күргән кешеләр. Берәр елдан безнең «гыйшык» сүрелер, безнең яшьтә ул әле иртәрәк тә булыр. Аның урынын, гадәттә, уртак балалар, бергәләп тергезгән тормыш учагы, бер-береңә ияләнү, бер-береңнең тугрылыклы, саф күңелле икәненә ышану, кыскасы, гаилә тарихы ала. («Әнекәем! Нинди дөрес, нинди кырыс, боздай салкын сүзләр дә сөйли беләм икән бит мин кирәк чакта...»).

— Ничек бу кадәр расчетливый кешегә әйләндең син. Әллә ирең синең шундый...

— Җитте!.. Булды... Менә аңлаштык та...

— Гафу ит!

— Минем иремә кагылырга синең хакың юк...

— Шундый җавап бирерлек булгач, нигә суздың, нигә газапладың мине.

— Мин үзем дә газапландым...

— Кадрия!!!

— Җитте... Нокта куйдык.

— Син дә яратасың бит!

— Нигә сузасың?! Ир кешегә килешми. Безнең яшьлек хатабыз өчен синең кызың да, минем улым да гаепле түгел.

...Беседкага ялгыз кайттым (Тамара Гришасын озата). Сакида соңгы кич һәм... гомумән соңгы кич... Тирә-як тып-тын, буш. Йөрәк әрнеп-әрнеп сызлый...

«Тормышыңны бозма! Балаңны ятим итмә! Барысы да искечә калырга тиеш!» Үз сүзләрең бит, Кадрия! Үзең шулай теләдең! Тагын ни кирәк сиңа? Бу сүзләрне әйтү сиңа ничек авыр булганын да, соңыннан ничек өзгәләнәчәгеңне дә аңламый бит ул!

Мин инде аны онытып бетерә язган идем бит, нигә монда килеп кабат яңартты ул аны? Ни хакы бар? Нигә ул тагын тыныч кына хатынын култыклап өенә кайтып китәргә тиеш тә, нигә бер Кадрия генә утта янарга тиеш? Соңгы көрәшү бит инде. Нигә саубуллашканда бер генә мәртәбә аның күкрәгенә сыенырга йөрәгең җитмәде соң синең? Иртәгә бу вакытта ике арада меңнәрчә чакрымнар торачак. Ә бүгенгә кечкенә генә бакча һәм тәбәнәк кенә койма аерып тора.

...Аннан... аннан мин нишләгәнемне үзем дә сизми калдым. Әхмәт

ишегалдына кереп бер-ике адым атлау белән чайкалып китте: ул исенә килеп өлгермәде — муенына килеп сарылдым... Әхмәтнең кайнар сулышы битләремне, муеннарымны пешерә иде... «Иркәм, иркәм, менә нинди син! Иркәм, сылуым, рәхмәт, рәхмәт сиңа... Ой, менә бит нинди син...»

Ул мине сак кына баскычка китереп бастырды — без икебез дә шунда гына аңга килдек. Калтыранган куллары белән каяндыр ачкыч эзләп тапты һәм нигәдер мине тагын күтәреп алып, ниндидер бер тәрәзә каршына китереп бастырды. «Хозяйка өйалдында йоклый, хәзер мин керәм дә тәрәзәне ачам...»

Мин ап-ак эчке күлмәктән аның тәрәзәсе алдында ялгыз гына басып торуымны төшенгәч, бөтенләй айнып киттем һәм, яшен утыдай, килгән юлымнан кире ташландым.

Ишек янында аяк тавышлары ишетелгәндә мин инде эчке калтыравымны тыярга, тигез суларга тырышып, берни булмагандай үз урынымда ята идем. Тамара икән. Керде, туфляларын салды, ут яндырмый гына чишенергә тотынды. Кыштырдау — кинәт кенә беседка ишеге каерылып ачылды — Тамара куркып кычкырып җибәрде, чакырылмаган кунак Әхмәт иде, әлбәттә.

— Кадрия кайда? Кайда... Кадрия!

— Котырдыңмы әллә? Нигә шулай акырасың? Йоклый бит ул!

Тамара ут яндырды.

— Кара әле, Тамара... чыннан да Кадрияме ул? — диде Әхмәт, ярым пышылдап.

Мин көлүдән ничек тыелырга белми тончыга башлаган идем инде.

Тамара утны сүндерде һәм Әхмәткә «тыныч йокы» теләде. Ишекне бикләгәч, чишенеп бетте дә минем караватыма утырды — өстемдәге җәймәмне ачып ыргытты.

— Бу «фырт егет»не ничек итеп «утлы таба»га бастыру серен бәлки миңа да ачарсың, ханым?

Җавап урынына мин аны кочагыма алдым, үз яныма яткырдым, колагына пышылдап кына әле булып үткән вакыйганы сөйләп бирдем. Ул, гадәтенчә, тын гына, бүлдерми генә тыңлады.

— Әллә син анда шушы килеш кердеңме? — диде ул ахырдан, тузган чәчләремнән, тәнне иркәли торган ефәк төнге күлмәгемнән сыйпаштырып.

— Әйе, мин бит инде йокларга җыенган идем...

— Молодец, ой, нинди молодец син!.. Шушы кыяфәттә, шундый сылу зат кочагыңа килеп керсен дә, шуны ычкындыр әле син! Ха-ха-ха! Дурак, ну и дуррак!

— Шыпырт,— мин учларым белән аның авызын томаладым.

— Ты делаешь успехи, дорогая! Ә хәзер тыныч кына йокла. Ә ул төне буе үрле-кырлы сикерәчәк.

...Китәргә санаулы сәгатьләр калып бара. Тамара белән без бакчага чыгып утырдык: минем аңа вәгъдәм бар — татарча җырларга — ул аларны пленкага язачак.

Менә магнитофонның яшел күзе җемелди башлады, Тамара «башла!» дигән ишарә ясады.

> Күзләрдән соң язлар килми,
> алда — салкын, ак кышлар.
> Китәсез дә мени,
> Китәсез дә мени,
> Китәсез дә мени, аккошлар?

Мин ниндидер эчке сиземләү белән үземә төбәлгән күз карашын тойдым. Куркып кына күзләремне күтәрдем, груша агачына сөялеп

Әхмәт басып тора, тавышым калтырап китте — юк, сынатмаска, сынатмаска!

Әллә ничек үтте яшьлек,
Соң очрашты язмышлар.

Без икебез дә аны күрмәгәнгә салыштык, ахры. Мин бит барыбер аның өчен җырлый идем, тыңласын әйдә!

Хушлашырга безгә
Иртәрәк бит әле...

Юк, булмый, хәзер елый башлыйм. Мин инде дымланып өлгергән күзләрем белән Тамарага күтәрелеп карадым, ул мине берсүзсез аңлады. Әхмәт янына барып нидер әйтте, аннан бакчадан озатып чыгарып җибәрде.

— Иркенләп җырла хәзер. Көчкә озаттым... Пленка үзенә булыр дип вәгъдә биргәч кенә китәргә риза булды. Ой, Кадрия, нишләгән ул... хәтта миңа да кызганыч тоела башлады. Күз төпләре күм-күк, йөзе ап-ак...

— Җитәр, Тамара! Бу хакта башка сөйләшмик инде, яме! Әйдә, лучше җырлыйм.

Тамара татар көйләренең моңлылыгына, мәгънәлелегенә таң калып утырды. Аннан мине кочаклап алды:

— Дускаем, син бик дөрес эшләгәнсең, бер дә үкенмә. Ул синнән шундый кыюлыкны беренче очратуында ук көткән, юк кына каршылыклар аңа киртә булган. Моңа кадәр бер син генә газаплангансың, әйтерсең, аның бер генә гаебе дә юк. Ничек җиңел карыйлар алар бу мәсьәләгә — ничек аңсат кына үзенең хатасын төзәтергә уйлаган ул. Кабат килеп синең йөрәгеңне таптап китәргә ни хакы бар аның? Татысын менә шуларның җәзасын. Бүген төнне кичергәннәрен гомердә онытмаячак ул хәзер.

*
* *

...Алар барысы да мине Саки вокзалында озатып калдылар. Тамара елый-елый үпте. Гришасы еламый гына. Нина сытылырга торган алсу-сары грушалар китереп тоттырды. Әхмәт каты итеп кулымны кысты. Кузминична юеш ирennәре белән битемне чылатты. Барысы да кул болгап калдылар. Хуш, Саки! Хуш, сүнәргә хөкем ителгән өметсез мәхәббәтем!..

# Газинур Моратов

●

Бер йотым су җитми кала —
Ирләр ава.
Бер мәнсез зат аркасында
Илләр ава.

Әгәр көн дә яңгыр орса —
Иген чери.
Гыйлем, Акыл казанында
(Бомба өчен!)
Металл эри.

Буталчык бу дөньялыкта
Миләр туңа.
...Акыл тапкан күпме табыш —
Югалту да.

●

*Күгәрченнәр — кошлар дәүләтенең*
*Кешеләргә килгән илчеләре.*

Шәһәр бакчасында — күгәрченнәр.
Сарып алганнар да сабыйларны,
Җим чүплиләр. Әллә кеше затын
Кандашлары диеп саныйлармы?

Ә лачыннар, тургай, сандугачлар
Ник өркәләр икән, ятсыналар?
Юкса, бездә дә бит лачын рухы,
Былбыл җаны яши. Нигә алар
Һаман ераклаша бара бездән,
Ераклаша бара гамәлләре?

...Уйлап баксаң, илче кошлар белән
Ныклап аңлашасы, әй, бар әле!

## Нəсихəт

Әй, сез, күзләр, ташламагыз
Үткәннәргә гамьсез караш —
Алар безгә бага һаман
Яшь аралаш, кан аралаш.

Әй, сез, күзләр, Бүгенгегә
Текәлмәгез комсызларча.
Хөр күңелле, бәйсез җанга
Ни ул мөлкәт, ни ул акча?!

Әй, сез, күзләр, Киләчәкне
Өмет белән күзаллагыз!
...Уллар — безнең туар таңнар,
Туар таңнар — күз алмабыз.

## Син

Горурлыгым. Мескенлегем.
Таянычым. Абынуым.
Тугрылыгым. Хыянәтем.
Ихтыярым. Табынуым!

Бергәлегем. Ялгызлыгым.
Нәфрәтем. Мәхәббәтем.
Әсирлегем. Хөрриятем.
Яшәешем. Һәлакәтем!

●

Бу янулар яну түгел әле,
Фатихасыз булсаң картлардан...
— Минем хакта шигырь чыгар,— диеп,
Сөйләшмиләр безнең якларда.

Гәзит ертып махра төрә-төрә,
Гәп куертып яткан чакларда,
Әйтеп куя бабай: «Бу нигезне
Сезгә инде, улым, сакларга...

Нигезебез — халык рухы безнең,
Халык моңы, халык аһәңе.
Шул аһәңнәр белән горурлан син,
Белеп яшә олы бәһаңне».

...Гәзит ертып махра төрә-төрә,
Гәп куертып яткан чакларда,
— Минем хакта шигырь чыгар,— диеп,
Сөйләмиләр безнең якларда.

Әлмәндәрдәй бабайларның ләкин
Өмет күзе — бездә, яшьләрдә...
Безгә язсын җыр язмышы булып,
Моң язмышы булып яшәргә.

## Табигатьтә

Табигать төрледән-төрле
Төсләргә мана-мана,
Язын — яшел, кышларын — ак
Җырларын яза бара.

Бардыр, бәлки, җыр язуны
Танырга теләмәгән.
Дөнья өчен Мәҗнүннәрчә
Яныргa теләмәгән.

Әмма, бу табигатьтәге
Һәрни ачык, гади күк:
Ул — тик яза... Исән чакта
Танылмаган даһи күк.

---

# Ркаил Зәйдуллин

## Сезнекеме?

Нәрсә җитми? Ник сулкылдый күңел? —
Аягына баса-баса моңның,
Бер ялгызым менә төннәр буе
Урамында йөрим авылымның.

Үткән давылларны төштә күреп
Өянкеләр йоклый — дөнья тынган.
Йөрәгемне өтә кайнар сулыш
Бәреп чыгып туфрак, җир астыннан.

Йөрәгемне өтә кайнар аваз
Кем пышылдый миңа? Кемнең өне?
Астан килә, астан ургый сорау:
«Безнең дәваммы син, безнекеме?»

Бабаларым! Шул ук җегәр миндә,
Шул ук иман яши йөрәгемдә!
...Ә кемнәрдер әнә таптап үтә
Сезнең сөякләрне гамьсез генә...

Мин дә туңам — сез өшисез икән,
Сезгә эссе икән — мин дә янам!
... Саумысез! — дип дәшәм туган телдә,
Туган телдә — димәк, сезнең дәвам.

Иманым нык, шул ук сезнең иман!
Таңнарыма чыгам, кичеп төнне.
...Нигә һаман тыныч түгел күңел:
Сезнең дәваммы мин, сезнекеме?

## Сәйдәшне сагыну

Үз җаныма текәлдем бу кичтә,
Җаным гүя алтын мәгарә...
Ямансу җыр булып тепкеленә
Бер күз яше төште тәгәрәп.

Тирән итеп сулыш алырга да
Җөрьәт итми торган бер мәлем...
Яңгыраганда җирдә Сәйдәш моңы,
Үз җаныма менә төбәлдем.

Анда Сәйдәш моңсу көлемсери,
Сибелә көй, әкрен, тын гына.
Сибелә язмыш... Җирдә яшәүләре
Читенрәк икән моңлыга.

Сибелә көй, ярсып-ярсып ала,
Монда күкрәү, яшен яшьнәве!
Читенрәк икән шашкан җанга
Җир йөзендә янып яшәве.

Сибелеп кала язмыш. Ә көй килә —
Вакыт үзе — биргән бәһане.
Ә көй бездә! Бәгырьләргә сеңгән
Сәйдәш моңы, Сәйдәш аһәңе.

...Шушы кичтә, әй, бәбәкләремнән
Сытылып чыккан сыңар күз яше!
Шул аһәңне син сыйдырсаң иде,
Син сыйдырсаң иде Сәйдәшне.

## Лашманчылар

*Ай-һай Себер таулары,*
*өзелә камыт баулары;*
*Камыт бавын бәйли-*
*бәйли*
*сызыла йөрәк майлары.*

Лашманчылар бәете

Карт иманнәр тәнен балта кимерә,
Ава агач... Әллә бәгырь өзелә?..
Беләкләрдә куәт ташый, тик менә
Карурман зур — алда гомер, түз генә.

«Бу ыругта каян мондый рух?»— диеп
Гаҗәпләнә җәллад коллар көченә.
...Ава имән, ава ирләр ачынып,
Агачлар да, бәгырьләр дә киселә.

Кара урман, юллар ябык — кайту юк.
Богау түгел, камыт бавы өзелә.
...Лашманчының ал канына манчылган
Мәгърур кораб йөзеп йөри диңгездә.

Буран дулый карурманда шашынып,
Бүре улый, бүре шундый якында.
Ялгыз учак... ут суыра җаннарны,
Һәм кар төшә каберләргә сак кына.

## 18 гасыр. Петербург зинданында яткан Батыршаның соңгы догасы [1]

Алла!
Ничек болай булды соң әле бу?
Зәгыйфь идемени безнең оран!
Ялгыштыкмы? Аһ, бу газап...
Юатмасмы диеп
Ничә төннәр җыр чакырам, җыр чакырам.

Алла!
Кисеп алды җәллад телебезне,
Дога укып булмый хәзер мәкам белән.
Ярый әле пар күзләрем исән-имин —
Яшәешнең асылын күрә белем.

Алла!
Телем җирдә ауный, авызда кан,
Яңгыр юа даладагы кайнар эзне,
Батып барган кояш яна бәбәгемдә,
Ә саташкан кулым һаман кылыч эзли.

Алла!
Һай сусадым, бик җырлыйсым килә,
Елый-елый бер кычкырып җырлар идем
туган телдә.
Үзем үлгәч, әгәр исән булса,
Җырым очып кайтыр иде туган илгә.
Әгәр илем исән булса...

...Ай нурлары сытылып керә зинданыма.
Дөньяда төн. Миндә менә шундый халәт.
Суза зынҗыр соңгы җырны, безнең җырны,—
Чәчелә каргыш, чәчелә өмет, чәчелә нәләт!
Суза зынҗыр соңгы җырны... Алла!
Озаккамы мондый халәт?!

[1] Батырша — патша җәберенә каршы Башкортстанда күтәрелгән мәгълүм восстание җитәкчесе.

# УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: ЭШЛӘР ҺӘМ КЕШЕЛӘР

Марат Әмирханов,
Рөстәм Кильматов

## ЯҢА КҮПЕР



Чират көтеп, Идел ярында куна-төнә машина йөртүчеләрнең аһ-зарын тыңлаганыгыз, ишеткәнегез бармы сезнең? Үшән ат кебек пошкыра-пошкыра су өстендә салмак кына тирбәлүче паромны, кулларыннан килсә, тын белән суырып алырлар иде алар. Көтеп торудан авыр нәрсә юк, дип юкка гына әйтмәгәннәр, күрәсең. Кулында сәгатенә 100 чакрым тизлек белән йөрүче «корыч айгыр» бит әле. Ә аның әрҗәсендә... Хәер, анысы төрлесендә төрлечәдер. Ничек кенә булмасын, ул әйберләрне зарыгып көтәләр. Чират һаман сузыла да сузыла, койрыгы ике-өч чакрымга җитәдер, шәт.

Шул вакыт, төтен алкасы өрдереп, бер җиңел машина килеп туктады. Шоферы ут борчасыдай җитез, шук егет. Осталыгы да бар. Кара, ничек боргалый машинасын, тар гына аралыкларны да җиңел генә үтеп, һаман алга омтыла.

— Тукта!

Кабиналардан бер-бер артлы җиргә кешеләр сикерешә башлады.

— Чиратны бозма!

Егет нидер аңлата, кәгазьләр күрсәтә: файдасыз. Су буендагы чираттан да гадел, катгый чиратны күргән юк иде.

Бу көнне без Зеленодольск шәһәре янында Идел аша чыгу өчен чират торучы 150 машина санадык. Ниндидер сәбәп белән паромның да берсе эшләми иде.

— Ичмасам, минутларның кадере турында сөйләп, әчне пошырган булалар,— дип, теге яктан ачу белән тәмәкесен җиргә ыргытты кара тут йөзле бер шофер.

Шоферны аңларга була: ул эш өчен яна лабаса. Сүз белән эшнең тәңгәл килмәвенә борчыла.

Әйе, автомобиль промышленносте бик кызу темплар белән үсә. Бу Татарстан мисалында да бик ачык күренә. Безнең күз алдыбызда Кама буенда, дөньяны таңга калдырып, автомобиль гиганты калкып чыкты. Ул проект куәтенә җиткәч, илебез ел саен 150 мең «КамАЗ» машинасы, 250 мең дизель алачак. Хәзер үк инде баш конвейердан тәүлек саен 350 дән артык автомобиль төшеп тора.

Халык хуҗалыгы йөкләренең 38 процентын машиналар ташый. Өстәвенә, аларның көч-куәте, уңайлыгы арта. Әйтик, ике арба таккан «КамАЗ» автопоезды бер юллауда гына да 30 тонна йөк йөртә. Аның кайдадыр тоткарланып торуы дәүләткә бик кыйммәткә төшә түгелме соң?

Болар, әлбәттә, һәркемгә билгеле нәрсә. Әмма аны бүрекне һавага чөеп кенә хәл итеп булмый. Дөресен генә әйткәндә, соңгы елларда бездә дә бик күп юл төзелде. Казан-Чаллы юлын гына карагыз: күзгедәй шома магистраль. Казанда өченче дамба шәһәр эчендә йөри торган машиналарның кирәк-кирәкмәгәнгә үзәк аша йөрүенә чик куйды. Дамба үзенең архитектурасы белән дә бик отышлы — тирәякка ямь биреп тора.

Казан янында Идел аша күпер салу мәсьәләсе күптәннән, узган гасырда ук күтәрелеп килгән. Күпернең зарурилыгы турында бик күп тикшеренүләр үткәрелгән, докладлар язылган. Соңга таба хәтта Зеленодольск янындагы тимер юл күперләренең аралыгына җайлаштырып проект та ясап караганнар. Тик барып кына чыкмаган. Ниһаять, 1978 елда тиешле оешмаларга Казан янында Идел аша салыначак күпернең проектын төзү тапшырыла. 1980 елның мартында проект раслана.

Казан күпере Идел аша салынган һәм салыначак күперләрнең соңгысы булмас, мөгаен. Без зур тизлекләр чорында яшибез. Сүз, әлбәттә, транспорттагы тизлек турында гына бармый. Транспорттагы тизлек җәмгыять тормышындагы үзгәрешләр, фән-техника прогрессының үсеше нәтиҗәсе генә. Халык хуҗалыгы ихтыяҗларына туры килгәч, Кама буенда әнә нинди гигантлар калкып чыкты. Казан-Чаллы автомагистрале, инде тәгәлләнү алдында тора торган Әгерҗе-Круглое поле тимер юлы. Тиздән сафка басачак мәһабәт Кама буасы — болар барысы да Түбән Кама территориаль-промышленность йолдызлыгының юлдашлары. Хәзер менә илебездә җитештерүче көчләрне урнаштыру үзенчәлекләре Казан күперен төзү мәсьәләсен көн тәртибенә куйды. Ул Уралны, Көнбатыш Себерне, Идел буен Үзәк белән тоташтыручы бик әһәмиятле транспорт корылмасы булачак. Аның республика халык хуҗалыгын үстерүдәге роле аеруча зур. Мәсәлән, әлеге дә баягы яр буенда кичү көтеп ятучы ачулы шоферларның күбесе Татарстанның Идел аръягы районнары хуҗалыкларыннан булып чыкты.

— Төзелеш материаллары ташыйбыз. Көнгә бер рейс белән әллә ни майтарып булмый, — ди озын буйлы яшь шофер.

Мондый шартларда, һичшиксез заманча клублар, ашханәләр, терлек каралтылары, йортлар салу җиңел түгел. Идел аръягы колхоз-совхозларында төзелешнең бүгенге көн таләпләренә җавап бирмәве, бер яктан, шушы сәбәп белән дә аңлатыла. Дөрес, күптән түгел КПСС өлкә комитеты, ТАССР Министрлар Советы Апас, Буа, Югары Ослан, Чүпрәле, Тәтеш һәм Кама Тамагы районнарында төзү оешмалары куәтләрен ныгыту һәм башкарыла торган эшләрнең күләмен арттыруның конкрет чараларын билгеләделәр. Аларны тормышка ашыру уңышлы нәтиҗәгә китерер. Ә күпер бу мәсьәләләрне тагын да киңрәк, масштаблырак хәл итү өчен мөмкинлекләр бирер. Монысы да бәхәссез.

...Машина җиңел генә тирбәлеп алга чаба. Юл тигез, киң. Ул ике яктан да яшел куаклар белән камалып алынган. Әледән-әле матур итеп, зәвык белән эшләнгән пассажир павильоннары, бензин салу станцияләре, ял итү урыннары күзгә чалынып китә. Бу архитектура корылмалары табигать кочагына шулай җайлы, уңайлы кереп сыенганнар, әйтерсең лә, алар табигать белән бергә яратылганнар.

— Менә килеп тә җиттек, — диде шофер, — алда — Казан!

Без сәгатькә күз салдык: Чаллыдан чыкканга нибары ике сәгать вакыт үткән иде.

Машина уңга борылды. Мәшһүр Казанның чал Кремле, Володя Ульянов укыган университетның биек биналары, безне сәламләп озаткандай, кояш нурларында балкып калдылар.

— Элек, күп вакыт әрәм итеп, шәһәр эченнән Горький шоссесына чыга идек, әйләнмә юл салгач, эшләр җайланды, — диде шофер.

Трассага кергәч тә, тизлек кимемәде. Миллионнан артык кеше яшәгән зур шәһәр янынннан узуыбызны бары магистральдәге дүрт рәт машиналар гына белдереп тора.

— Шушымыни инде Идел күпере? — дип сорап куйды янәбызда утырган юлдашыбыз.

Алда, чыннан да, як-яклары ак буяуга буялган корылма пәйда булган иде. Яр буенда шырпыдай төз нарат агачлары үсеп утыра.

— Казанка аша салынган яңа күпер бу, дүртенче дамба, — диде шофер үзенең хәбәрдар булуына бераз мактаныбрак, — дөресен генә әйткәндә, Идел күперенең корылмалары әйләнмә юлга борылгач ук башланды инде. Болары аның аерым өлешләре генә.

Сөйләшә-сөйләшә килә торгач, Юдино урманын үтеп киткәнебезне сизми дә калганбыз. Менә бу матурлык ичмасам! Алда гүзәл Идел җәйрәп ята. Дымык су өстендә ап-ак җилкәнле көймәләр йөзә, очлы борыннарын һавага чөйгән «Метеор»лар каядыр ашыга. Югары Ослан ягындагы биек кызыл яр, яр итәгенә тернәкләнеп үскән озын агач шәүләләре, җылы көннәрдәге рәшәне хәтерләтеп, суда чагылып тора...

Ә күпер?! Тартылган җеп шикелле туп-туры ак бетон корылма үзенең төзлеге, гадилеге, үлчәмнәренең камиллеге белән матур...

Безнең хыялыбыз канатларына утырып аз гына киләчәккә экскурсия ясавыбызны «Каздорстрой» тресты управляющие В. И. Усатенко хуп күрде.

— Нәкъ проектта каралганча, — диде ул көлемсерәп.

Идел аша салыначак Казан күпере проекты — СССР Транспорт төзелеше министрлыгына караган берничә фәнни-тикшеренү һәм проект оешмалары галимнәренең иҗади эзләнүе, инженерларның төгәл исәп-хисаплары нәтиҗәсендә барлыкка килгән катлаулы корылма проекты. Аны эшләүдә Бөтенсоюз транспорт төзелеше фәнни-тикшеренү институты, «Союздорпроект» һәм «Гипротрансмост» проект-эзләнү институтлары катнашты. Алар күпер һәм аңа килү юлларын төзүнең экономик зарурлыгын һәм техник мөмкинлекләрен исбат иттеләр. Мәсәлән, исәпләүләр күрсәткәнчә, күпер елына 14 миллион сумлык транспорт чыгымнарын янга калдырырга мөмкинлек бирер дип көтелә. Аны төзүгә тотылган акча үзен биш-алты елда аклаячак.

Аңлашыла булса кирәк, күпер тулы бер комплексны тәшкил итә. Шунысы әһәмиятле, бер урында да машиналарның тизлеген тоткарлаучы текә борылышлар, юл чатлары калу каралмаган. Трасса тимер юл белән өч урында очраша, өчесендә дә алар белән кисешмичә өстән уза. Әлбәттә, күперләр ярдәмендә. Монда инде вакытны минутлап кына түгел, секундлап та санарга була. Чөнки магистральдә уңайлылык белән ныклык, матурлылык белән ышанычлылык, хәвефсезлек белән тизлек органик бердәмлектә хәл ителә.

Күпер салу — шөгыль. Ә менә тарихта үз исемен калдырган күпер төзүчеләр бармак белән генә санарлык. Шулар арасында рус уйлап табучысы, Идел буенда туып-үскән И. П. Кулибин аерым урын алып тора. Моннан 250 ел элек бу халык остасы Нева елгасы аша 300 метр озынлыгындагы аркалы күпер моделен төзеп, аны сызып

карый. Кызганычка каршы, замандашлары И. П. Кулибинның тәкъдименә чынга ашмас хыял итеп карыйлар. Шулай итеп, зур сәнгать югарылыгындагы проект кәгазьдә генә кала. Кызганыч, әлбәттә. Модель үзе имтиханны бик уңышлы тота, югыйсә. Ә бу бик мөһим. Теге яки бу үзенчәлекне искә алмау нәтиҗәсендә кайбер илләрдә фаҗигале хәлләргә дә юлыгалар. Әйтик, Англиядә Тей елгасы аша металл күпер коралар. Проектына тел-теш тидererлек түгел. Ныклык запасы да зур — 20 тапкырдан артып китә. Тик бер генә нәрсә исәпкә алынмаган, ул да булса — бу төбәктәге җилнең көче, юнәлешләре. Мәрхәмәтсез җил ел ярымда күперне җимереп ташлый. Мондый сабаклар проектчыларны, төзүчеләрне күп нәрсәгә өйрәтә. Хәзерге заман күперләренең металл конструкцияләр тоташкан урыны миллиметрлар белән генә үлчәнә. Йөзләгән тонна катлаулы конструкция һәм ... миллиметр. Башка сыймый хәтта!

Казан күперен 3 нче күпер отряды салачак. Тәҗрибәле, оешкан, сәләтле коллектив. Идел аша Астраханьда, Ульяновскида, Горькийда шундый ук күперләр төзегән. Тик һәр корылманың үз «йөзе», үзенә генә хас сыйфатлары бар. Ярты эшне су астында башкарырга кирәк бит әле. Ярый ла Идел үзен тыныч тотса, ярсыган чаклары да күп бит аның.

Күпернең суднолар йөриячәк өлешен төзү шулай ук катлаулы эшләрдән санала. Бу өлеш конструкцияләрен җыю әллә ни катлаулы түгел түгелен. Яр буенда, корыда гына башкарачаклар аны. Аннан, махсус пантоннарга төяп, кую урынына гына алып барасы кала. Деталь-блокларны проектта каралганча төгәл урнаштыру — монысы чын мәгънәсендә ювелир эше.

— Күпернең дүрт аралыгыннан суднолар йөриячәк, — диде монтажчылар бригадиры Равил Сираҗиев.

Без аны Моркваш ягында очраттык. Җиргә нык басып йөри торган көчле беләкле кеше ул Равил. Һаман тышта эшләгәнгә күрә йөзе каралып, сырланып беткән. Шуңа күрәдер, ахрысы, кырыс күренә. Үзе турында сүз чыкса, аңгәмә йомгагын хезмәттәшләре турында сөйләүгә оста гына борып җибәрә. Без аның тәҗрибәле оештыручы гына түгел, яхшы рационализатор икәнен дә белә идек. Шул хакта сорагач, ул җавап биреп тормады, будкадан чыгып килүче берәүгә:

— Рауэль, бире кил әле! — дип кычкырды. Безгә карап янә өстәде: — Менә дигән монтажчы, быел гына Халыклар Дуслыгы ордены белән бүләкләнде.

Рауэль Тимуршин, чыннан да, үз эшенең чын остасы икән. Аңа һәрвакыт иң җаваплы, иң авыр эшләрне генә тапшыралар.

Монтажчы һөнәре — кыюлар һөнәре. Аларга биектә дә эшләргә, су астына да төшәргә туры килә. Павел Хлусов әнә шундый утнысуны кичкән монтажчы. Белмәгәне юк: бетончы да, такелажчы да, балта остасы да һәм, әлбәттә, кыю монтажчы да. Астрахань, Ульяновск, Горький, Сарапул янындагы күперләрне төзешкән. Аңа инде 53 яшь, әмма һөнәренә һаман турылыклы.

— Ялга чыкканчы, Казан күперен дә төзешәм әле, — ди ул, ныклы ышаныч белән.

Әйтәсе дә юк, хәзер техник мөмкинлекләр зур. Элеккеге кебек һәр детальне, һәр терәкне урында беркетеп мәшәкатьләнәсе түгел. Махсус мәйданчыкларда җыясың, «кадаклыйсың» да, авырлыгы йөзләрчә тонна булган әзер конструкцияләрне куәтле механизмнар ярдәмендә тиешле урыннарына, «шылт» итеп китереп утыртасың. Уңайлы да, арзан да. Әмма бу әле эш бетте дигән сүз түгел: ни дисәң дә, аралыклар кала, аларга плитәләр җәяргә кирәк. Юлның ике як чите-

нә тимер-бетон борыслар сузмасаң, комиссия эшеңне кабул итми, чөнки юл хәвефсезлеге кагыйдәләре шуны таләп итә. Җәяүлеләр турында да кайгыртасы бар. Кыскасы, төзелеш эшенең шактый өлеше шушындый «вак-төякләр»дән тора.

— Без нәкъ менә шул «вак-төякләрне» ясау белән мәшгуль инде, — диде бетончылар бригадиры Нина Бугрова.

Нина отрядның производство базасында күптәннән эшли, бригадир булганына да 14 ел узып киткән. Ярдәмчеллеге, туры сүзлелеге өчен ихтирам итәләр аны. Бервакыт ул бетончы Матрена Бубарева янына килеп туктый.

— Күптәннән кранчы белән иза чигәбез: берсе килә, икенчесе китә. Әллә соң син тәвәккәллисеңме, Матрена? — ди ул, хезмәттәшенә туп-туры карап.

— Техника белән бер дә эш иткәнем юк лабаса, булмас ла миннән!

— Алай кырт кисмә, еламаган баланың гына күзеннән яшь чыкмый.

Матрена Бубарева бригадирның сүзенә колак сала, курсларда укып кайта. Хәзер яхшы кранчы, бригаданың үз кранчысы.

Күпер төзүчеләр отряды электр монтеры коммунист Фәрит Фасеев, «Почет билгесе» ордены кавалеры шофер Виктор Птицын, газ белән эретеп ябыштыручы Фәнис Сәлахов һәм башка бик күпләрнең әчкерсез, намуслы хезмәте белән көчле.

Без күпернең берничә елдан үзен аклаячагы турында әйткән идек инде. Тик, ничек кенә булмасын, һәр транспорт корылмасы бик күп чыгымнар таләп итә. Әйтик, бер чакрымлы асфальт юл җәю өчен 1 миллион сумга якын акча тотарга кирәк. Безнең республикабызда гына да 10 мең километрга якын юл түшәлгән. Илдә Идел аша күперләр дә күп: хәзер ун күпер бар. Казан күпере — унберенчесе.

Казан күпере кебек уникаль корылманы башкарып чыгу бик зур инженерлык хәзерлеге таләп итә. Эшнең һәр өлеше, һәр төре, аларны эшләү ысулы алдан ук планлаштырылырга тиеш. Казан күперенең эш проекты «Главмостстрой»ның Саратовтагы махсус конструкторлык бюросы белгечләре Г. В. Иванов, Н. И. Вавилов иптәшләр җитәкчелегендә төзелде. Күперне корачак 3 нче күпер отряды инженерлары шулай ук бу эштә якыннан торып катнаштылар.

План-графикның үзенчәлеге шунда: аның нигезен әзер төзелеш продукциясе тәшкил итә. Моңа кадәр, билгеле булганча, төзелеш оешмасының эшчәнлегенә бәя күпме акча тотылуына карап бирелә иде. Хәзер исә теге яки бу объектның тулаем яки аерым-аерым өлешләренең әзерлеге таләп ителә. Бу ысул, һичшиксез, эшкә уңай йогынты ясаячак. Тагын бер яңалык, дөресрәге, күптәнге бер яңалык, дөресрәге, күптәнге бер яңалыкның дәвамы — бригада подряды. Подрядның өстенлекләре инде күптәннән исбат ителгән. Әмма кайбер сәбәпләр аркасында ул промышленность төзелешендә әле хәзергә кадәр акрын кертелә. Күпер төзүчеләр бу алымның мөмкинлекләреннән тулырак файдаланырга булганнар. Бирелә барлык эшләрнең 60—63 процентын Злобин ысулы белән башкару күздә тотыла. Бу бик яхшы күрсәткеч булачак. Үзенең туган тармагы торак төзелешендә дә бригада подрядын кертү 30 процентган артмый әле.

— Бригада подряды төгәллекне, җитезлекне, исәп-хисапны ярата. Шулай да аның төп сыйфаты — тәртип,— диде күпер төзү отряды начальнигы А. Курилов. — Ул эшчене, аеруча җитәкчене, белгечне тәртипкә өйрәтә.

Хак сүзләр. Бригада подряды эшне оештыруның камил рәвеше ул. Монда барысы да алдан уйланган инженерлык исәп-хисабына корылырга тиеш.

Отряд начальнигы инженер эшенең бөтен баскычларын да үткән. Шуңа күрә ул бу алымның тылсымлы көчен бик тиз сизеп алган. Коллектив унынчы бишьеллыкта берничә тапкыр Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыга. Анатолий Павлович үзе «Почет билгесе» һәм Халыклар Дуслыгы ордены белән бүләкләнә.

Җитәкченең осталыгы, барыннан да элек, теләсә нинди авыр бурычларны да үтәп чыгарлык коллектив туплауда күренә. Бу һәр җирдә шулай. Ләкин күпер кебек катлаулы корылмаларны төзегәндә инженерның, белгечнең иҗади фикерләве һәрвакыт беренче урында тора. Шуңа күрә инженер кадрларны тәрбияләүгә, үстерүгә зур әһәмият бирә бу җитәкче. Биредә үзләрен чын белгечләр итеп таныткан кешеләр күп. Баш инженер Б. В. Баранов, әйтик, Себердә, Камада, Вяткада чыныгу алган, аның ярдәмчесе В. А. Лосев беренче имтиханны Горький янындагы күперне салганда үткән.

Казан күперен салу турында рәсми кәгазьләргә кул куелгач, Анатолий Павлович үз бүлмәсенә Рәшит Ибраһимов һәм Геннадий Пиядин иптәшләрне дәшеп ала.

— Сезнең һәр икегезне өлкән прораб итеп билгеләргә исәплибез. Моңа ничек карыйсыз? — ди ул. Беразга тынлык урнаша.— Я, нәрсә, шөлләп калдыгыз?

— Бик җаваплы эш бит. Аннан соң Идел аша күпер салганыбыз да юк әле, — ди Рәшит Абдулбариевич, дулкынлануын сиздермәскә тырышып.

— Әйе, — дип куәтли дустының сүзен Пиядин. — тәҗрибә...

— Кайдан да булса бер башларга кирәктер бит!

Һәм башлыйлар. Р. Ибраһимов уң як ярдагы, Г. Пиядин сул як ярдагы эшләргә җитәкчелек итәләр. Ике дус, тагын берничә елдан күбекләнеп аккан Идел уртасында, тимер-бетон терәкләргә соңгы плитәне — дуслык плитәсен урнаштыргач очрашачак. Кул биреп, бер-берсен тәбрикләрләр. Шул чакта «ура» тавышлары яңгырар, һавага баш киемнәре очар...

Ә хәзер корылманың беренче объектында, Займище янында тимер юл өстеннән салына торган күпер төзелешендә сварка утлары җемелди.

Күпер төзелешендә эшне тулы куәтенә башлап җибәрү өчен ныклы тыл, база кирәк. Асфальт-бетон заводлары, складлары, транспорт базалары, кешеләргә торак — саный китсәң, үзе бер җитди төзелеш программасы. Күпер төзү отряды кешеләре быел, нигездә шул эшләр белән шөгыльләнделәр. Бу 1982 елның җәендә хәлиткеч һөҗүмгә күчү өчен зарури шарт иде.

Быел гидромеханизаторлар, «Трансгидромеханизация» тресты-ның 480 нче төзелеш идарәсе яхшы эшләде: саклау һәм ярдәмчел дамбаның беренче чиратына миллион ярым кубометр ком кудырып, үз бурычларын намус белән үтәп чыктылар. Барысы 5 миллион кубометр ком кудыру планлаштырыла. Аның өчен уннарча километрга торба сузасы юк. Мәрхәмәтле һәм юмарт Иделкәй анысын да үзе бирә, төбендә менә дигән ком. Комның да нинди әле — ката торганы. Кайберәүләрнең ничек инде ком катсын?» — дип гаҗәпләнүләре бар. Әйе, ката икән шул. Чөнки җир өстенә комга ияреп энә очы кадәр генә лай шарчыклары да чыга һәм ком бөртекләрен шул шарчыклар ябыштыра.

Ком кудыру тәгәлләнгәч, дамба кырыйларын, тимер-бетон плитәләр белән тышлау каралган. Моның өчен, мәсәлән, 33 мең кубометр

җыелма конструкция эшләп чыгару күздә тотыла. Күпме бу, азмы? Күп. Бу кадәр материал белән 23 чакырым озынлыкта менә дигән бетон юл эшләргә булыр иде. Менә нинди зиннәтле юрган ябыначак яр буе.

Билгеле булганча, һәр корылма — зурмы ул, кечкенәме — әйләнә-тирә мохитка теге яки бу дәрәҗәдә тәэсир итми калмый. Күпернең, беренче карашка, зыяны да булмаска тиеш кебек. Беркайда бернинди тоткарлык юк — элдерт кенә. Тизлекне үзгәртмәгәч, автомобильләрнең зарарлы төтене дә аз чыга, ягулык та янга кала. Болар бик әһәмиятле факторлар. Үз машиналары булган кешеләргә дә туристлык маршрутлары киңәя, ял итүчеләргә дә уңайлылык арта.

Шулай да... ком кудыруны гына алыйк. Ул, һичшиксез, елганың табигый халәтенә нindидер үзгәреш кертәчәк. Чөнки 5 миллион кубометр комнан зур гына тау өяргә дә мөмкин булыр иде. Ә аны елга төбеннән алырга кирәк. Төптә тыгыз хәлендә ятканда фильтр ролен үтәгән алтын бөртекле комлы су массасы өскә чыгарылгач, үзен икенче төрлерәк тота башлый: суны болгата. Бу хәл килеп чыкмасын, Идел пычранмасын өчен проектта комплекслы чаралар билгеләнгән. Мәсәлән, дамба итәгендә вакытлы корылмалар төзү планлаштырыла. Шулай ук ком тавының өске өлешен даими рәвештә ишеп торуның да файдасы булыр. Идел — халык байлыгы. Гүзәллеге, саф суы белән ул киләчәк буыннарны да шатландырырга тиеш.

А. П. Курилов кабинетында бер тылсымлы кайчы саклана. Алтыннан да коелмаган, бриллиант ташлары да юк үзенең. Ә шулай да алтын-көмешләрдән дә кадерлерәк. Нәкъ әкияттәгечә, ул хәрәкәткә килдеме, кешеләргә шатлык киләсен көт тә тор. 1952 елда Астраханьда, 1960 елда Ульяновскида, 1965 елда Горький шәһәрендә ал тасмаларны урталай кискән бу кайчы һәм юллар киңәеп, аралар якынаеп калган. Соңгы мәртәбә кешеләргә Казанның Х. Ямашев һәм Г. Ибраһимов проспектлары кисешкән урында күпер төзелеп беткәч күренде бу. Шәһәр халкы бик риза булып калды.

Хәзергә тылсымлы кайчы чигүле атлас мендәрдә ял итә. Озак та үтмәс, аның белән Казан күперенең ал тасмасын кисәрләр. Шунда инде Зеленодольск кичүе янында чират көтеп яткан агайларның да йөзләрендә елмаю кабыныр. Күп мени ул җиде-сигез ел гомер?!

## Самат Шакир

# ИЛ һӘМ ХАЛЫК РӘХМӘТЕ

Иртәнге сәгать алтылар тирәсе. Табигатьнең иң саф, иң күркәм вакыты. Яз кояшы җир өстенә җылы нурларын сибә. Агачлар йомшак җилдә әкрен генә тирбәләләр. Түбә кыекларында күгәрченнәр гөрли. Шул гаҗәеп матурлыкка сокланып авыл урамы буйлап урта яшьләрдәге бер кеше атлый. Менә ул райком бинасына килеп керде дә беренче итеп стенадагы барометрга карады. Аннары «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхозга телефоннан шалтыратты. Аннан колхоз председателе тавыш бирде.

— Хәерле иртә, Харис Галимуллович, — диде секретарь.— Чәчүләр ничек бара?

Колхоздан тавыш: — Болай ярыйсы гына... — диде.

Секретарь тавышы күтәрелә төшә:

— Нинди ул ярыйсы гына! Күпме чәчтегез?

Чәчү әйбәт бара икән. Әмма яңгырлар булганлыктан эш бераз туктап калган.

— Вакытында яңгыры да кирәк!

— Бик дөрес, Шамил Фәхретдинович!

— Темпны түбәнәйтмәгез! — диде секретарь. — Хәзер сезгә барып чыгам. Бүтән колхозларда да булырга исәп.

Трубканы куйгач, райком секретаре тагын барометрга карап алды: үч иткәндәй, һаман яңгырга күрсәтә... Секретарь, коридорга чыгып, шоферга: «Социалистик Татарстан»га барабыз. Әзерлән» — диде дә, яңадан телефонга ябышты һәм Ленин исемендәге колхозны сорады. Председатель кырда булып чыкты. Партоешма секретаре икенче бригадада икән. Колхоз бухгалтеры белән сөйләшеп алдылар:

— Күпме чәчтегез?

— Иртә культураларны иртәгә төгәллибез.

— Сыйфат ягы ничек?

— Отлично!

— Бүген барып карыйм...

Ул тагын берничә колхозны алып сөйләште, кайбер председательләр җир өлгереп җитмәүдән зарландылар. Секретарь аларга нинди ярдәм кирәклеген сорады. Тегеләр әйттеләр.

Шамил Фәхретдинович кирәкле кәгазьләрен инде портфеленә салганда, райкомның икенче секретаре Фатих Сибгатуллин һәм идеология секретаре Рәшидә Кариева кереп, үзләренең бүгенгә билгеләгән планнарын белдерделәр. Икенче секретарь терлекчелек эше буенча «Якты юл» колхозына бара. Шамил Фәхретдинович моны хуплады да ашыгып берничә сүз өстәде:

— Чәчүне онытмагыз, чәчүне! Минем колхозларга китеш...

... «Уазик» таш юлдан элдерә. Төнлә яңгыр яуган. Бүген дә явачак. Ләкин яңгырга сылтап соңарырга ярамый. Бабасы Шиһапның сүзләрен хәтерләде Шамил. «Язгы көннең сәгате, минуты алтын бәясе. Ул елны туйдыра... Аз гына соңга калу да йөзләрчә пот ашлыкның булмавы дигән сүз». Әйе, аның кендеге кырга берегеп үскән бабакае икмәкнең кадерен бик яхшы белә иде.

Шамил Сираҗиев элекке Кызыл юл районы, Иске Кенәр авылында туып үсте. Зираты зур булса да кечкенә авыл. Җире уңдырышлы түгел. Печмәнтау белән Иске Ашыт арасындагы басу әлләни уңыш бирмәгән. Әтисе Фәхретдин абзыйның зары юкка түгел:

— Җир түгел бу — тоташ вак таш оясы. Сука тимерен ашап үтмәслəп бетерә...



Утызынчы елларда авыл халкы «Чулпан» исемле колхозга берләшә. Бик тырышып, бил бөгеп эшләп, җиргә ашлама-тирес кертеп югары уңыш ала башлыйлар. «Чулпан» районда алдынгылар рәтенә керә. Укый-яза белмәгән председатель Әһли Биктов эшне «кара хисап» белән җайга сала.

Менә хәзер Шамил аның көләч йөзен, зәңгәрсу-соры күзләрен хәтерләде. Аның улы Лотфулла, күрше малайлары Габделнур, Газизләр белән Иске Ашыт мәктәбенә укырга йөрделәр. И, ул бала чакның күңелле, алтын вакытлары! Яхшы укыганы, ял көннәрендә колхозга булышканы өчен әтисе Шамилгә костюм-чалбар алып кайткан иде. И, куанды да соң малай! Сабан туенда кияргә кемнең шундый костюмы бар? Әнә Газиз дә, Лотфулла да узган елгы костюмнан бит.

Шамил укуда гомумән тырыш булды. Әтисенең сүзләрен әле дә булса онытмый: «Уку бик кирәк, улым! — Батыр берне, укыган меңне ега,— дигән бит бабайлар». Тулы булмаган урта мәктәпне алдынгы укучыларның берсе булып тәмамлагач, ул «Чулпан» колхозында эшли башлый. Бик яшьтән ат җене кагылган малай язын җир сөрдә, җәйләрен урман кисүдә катнашты. МТСтан ягулык ташыды.

Көннәрнең берсендә кайгылы хәбәр Кенәргә дә килеп ирешә: Герман фашистлары безнең илгә каршы мәкерле сугыш башлаган... Авылның типсә төп түнтәрерлек таза ирләре, димәк, Шамилнең әтисе дә яу кырына китәләр. Колхозның терәге булып яшүсмерләр, хатын-кызлар, картлар һәм балалар гына калды. Һәм лозунг та бары тик бер генә: «Син бүген фронт өчен нәрсә эшләдең?». Олы яшьтәге агайлар белән, барча үсмерләр белән бергә сугыш Шамилне дә авыр эшләргә җикте: басудан көлтә ташулар, ындыр табагында эшләүләр, башта ат белән, соңга таба сыер җигеп дәүләткә ашлык тапшырулар, ерак урманга утын кисәргә барулар.... Өс киемнәре тетелгән, ашарга бәрәңге күмәче дә шыр су умач... Яз җитүгә кузгалак, акбаш, кычыткан ашлары... Сугышның чиксез-чамасыз авырлыгы халык җилкәсенә көннән-көн ныграк баса бара. Фронттан кулсыз, аяксыз кайтучылар күбәйде. Күрше Миңлеҗан да кулы яраланып кайтты һәм бригадир булып эшли. Укый-язуга таман бу кешегә Шамил булышты — колхозчыларның көнлек эшләрен хезмәт кенәгәләренә ул язып бара. Фронттан килгән хатларны, газета хәбәрләрен дә колхозчыларга балалар укый, кичен сукыр лампа яктысында сугыш кырындагы әтиләр-абыйларга хатлар да сырларга кирәк... Тормыш газабы авыр дип тормый, яшьлек романтикасы да үзенекен итә: кичләрен клубка җыйналалар, үзәк өзгеч итеп тальян

сыздырып җибәрүгә җыр башлана, биюләр китә. Кепкасын кырын салган Шадра Вәли шунда.

1943 ел килеп җитә. Шамил дә Кызыл Армия сафына алына һәм Ерак Көнчыгышка җибәрелә. Шул ук елны хәрби курста укып сержант дәрәҗәсе ала. Башта ул подразделениедә комсорг буларак тырышлыгы белән таныла. Аның отделениесе хәрби тәртип һәм сугышчан хәзерлек ягыннан алдынгыларның берсе була һәм Шамил Сиражиевны партия сафына кабул итәләр. Яшь коммунист үзлегеннән укып белемен күтәрә, алдынгы кече командир булып таныла. Соңга таба аны партоешма секретаре итеп сайлыйлар. 1945 елны япон самурайларына каршы сугышта ул взвод командиры була, батырлыклары белән таныла. Аңа бирелгән бер характеристикада, мәсәлән, болай диелгән: «Подразделениедә партоешма секретаре булып берничә кат сайланды. Сугышта үзен аерата кыю күрсәтте, дисциплинасы, сугышчан һәм политик хәзерлеге буенча башкаларга үрнәк булды, командирлар һәм начальниклар аңа берничә мәртәбә рәхмәт белдерделәр».

Туган якларындагы тыныч хезмәткә ул 1950 елны гына кайта.

Башта районда социаль-тәэминат бүлегендә өлкән инспектор, 1952 елдан хезмәт ияләре депутатларының Кызыл юл район Советы башкарма комитеты секретаре булып эшли. Тырышлыгын, сәләтле оештыручы булуын искә алып, Казандагы югары партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Анда да Ш. Сиражиев алдынгыларның берсе була. 1959 елны хезмәт ияләре депутатларының Дөбъяз, ә 1963 елны Саба район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары итеп сайлана. Кыскасы, Шамил Фәхретдинович, җитәкче кадр буларак, 1965 елда Балтачта КПСС райкомының икенче секретаре итеп сайлану дәрәҗәсенә ирешә. Ул коммунистларның ышанычын аклый, халык алдында зур авторитет казана, районның алга китүенә үзеннән зур өлеш кертә. Аны Балтач район Советы башкарма комитеты председателе итеп сайлыйлар. 1978 елдан ул партия райкомының беренче секретаре булып район партия оешмасын җитәкли башлый...

Секретарь «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхозның кырларын бик җентекле күзәтеп барды. Яңгыр яуса да җир өсте ныгып, кибеп килә. Кадерле вакытның минутларын санап, чәчүне дәвам итәргә кирәк. Машинаны туктатып, әнә ул сөрелгән җирнең туфрагын учка алып карады. Ашлама кертелгән балчык ярмаланып тора. Колхоз алдынгылары кышкы агрочараларны тырышып, намус белән үтәгәннәр бит, рәхмәт төшкере. Районда шактый озак эшләгәнгә, ул һәр колхозны, аның җитәкчеләрен, хәтта колхозчыларны да биш бармагы кебек яхшы белә. Шундый хәл була: бер колхоздан жалоба белән киләләр: янәсе, колхоз председателе бәрәңге утырту өчен ат бирми. Шамил бу кешеләрне шунда ук фаш итә: үзләре Казанда яшиләр, ә авылда 80 яшьлек әниләре тора. Аңа акча бирмиләр, бүтәнчә дә ярдәм итү юк, киресенчә, аның мал-туарын суеп Казанга ташыйлар. Бәрәңге утыртырга дигән сылтау белән ат алып, Малмыжга аракыга чапмакчылар икән.

— Әниегезгә бәрәңгене колхоз утыртып бирер,— ди секретарь.— Ә сез биредә берни эшләмичә эчеп-исереп йөрмәгез!

Колхозчыларның да төрлесе бар: берәүләре җан-тән белән дигәндәй бирелеп, тырышып, җиң сызганып эшли, икенчеләре өстән-өстән генә элдереп, күбрәк акча каеру ягын карый. Җитмәсә бик еш сәрхуш була, җәмәгать тәртипләрен боза, хатынын, балаларын кыерсытып акча даулый, бирмәсәң — өй әйберләрен сата. Дөрес, мондыйлар аз, ләкин күренгәли әле.

Каршыга «Уазик» килә иде. Шамил аның «Социалистик Татар-

стан» газетасы исемендәге колхоз председателе Харис Галимуллин икәнен шунда ук белде. Ул машинадан ашыгып төште дә секретарь белән исәнләште.

— Эшләр ничек бара? — диде секретарь. — Чәчү ник тукталды?

— Кичә яңгыр яуды. Бүген җир инде ярыйсы. Хәзер чәчә башлыйбыз.

— Минут та соңгармаска кирәк!

— Әйе, бик дөрес әйтәсез!

— Сезгә бу бишкөнлектә күчмә Кызыл Байрак бирелә. Эшләрегез нигездә әйбәт, әмма тагын да тырыша төшегез, — диде секретарь. — Быел бөртеклеләрнең гектарыннан күпме алырга мөмкин дип уйлыйсыз?

— Кимендә 20 центнер.

— Арттырып та булсын иде...

Алар чәчелгән җирнең сыйфатын сөйләшә-сөйләшә карадылар, терлекләр, бигрәк тә савым сыерлар турында сүз барды. Сөт савып алу колхозда яхшы куелган. Әмма ирешелгәннәр чик түгел әле. Шамил Фәхретдинович шуңа басым ясый. Район республикада сөт буенча беренче урында тора. Ә «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхоз район күләмендә беренче. Аның тырыш кешеләрен район һәм өлкә газеталарында мактап язганнар. Әмма житәкчелек йомшарса, темп кимесә колхоз бер урында таптанырга мөмкин. Сираҗиев председательгә сорау бирде:

— Ә районда мактаулы үзешчәннәрегез ничек хәзер?

Председатель салмак тавыш белән:

— Артистларыбызга яңа костюмнар тектердек. Коллективка бик ошый, — диде. — Шушы көннәрдә генә зур концертларын карадык. Яхшыра баралар.

Алар авылга бергә кайттылар. Идарә бинасы алдында бишьеллык планны үтәүгә чакырган плакатлар, почет тактасында алдынгы терлекчеләрнең, механизаторларның фоторәсемнәре ялтырап тора. Көнгә бер пот сөт савып алган Замфирә Гомәрова хөрмәтенә дан флагы күтәрелгән иде. Ул тырыш савымчы. КПССның XXVI съездына делегат булып сайланды. Авылның көнкүреше, культурасы соңгы елларда шактый алга китте. Алты һәм дүрт почмаклы, шифер түбәле яңа йортлар күп күренә. Капкалар һәм коймалар да матур итеп буялган. Урамнар төз һәм тигез. Төрле тарафка таш юллар сузылган. Авылның ямь-яшел болыны, көмеш кебек сулы Шушма елгасы күзләр явын алып, күңелне тартып, сокландырып тора. Буасы һәм тегермәне бар. Салавыч авылындагы тегермәнгә ерак авыллардан да киләләр.

— Тегермән тартамы?

— Бик әйбәт, Шамил Фәхретдинович.

— Болыннарыгыз күңелгә рәхәт булып күренә. Сабан туен да шунда үткәрергә исәплисезме?

— Әйе.

— Быел ничә колхозчы яңа өй өлгертте?

— Егермегә якын.

— Ничә колхозчыда телевизор бар?

— Телевизорсызлар бездә бик аз. Кайберләрендә төсле күрсәтә торганнары да бар.

— Колхозчыларның барысы да терлек асрыймы?

— Барысы да.

Шамил Фәхретдинович КПСС өлкә комитеты секретаренең күптән түгел кисәткән сүзләрен кабатлады: «Кайбер колхозларда хуҗалык терлекләрен сату күбәйде. Колхозчылар Казаннан сөт сатып алалар. Өйдә пешермичә икмәкне дә Казаннан ташучылар бар».

— Безнең күрше Киров өлкәсе колхозларында хәлләр шулайрак. Ерак китәсе түгел. Әмма безнең колхозда андый хәлнең булганы юк һәм булмаячак та.

Секретарь тагын сорау бирде:

— Быел унынчы классны тәмамлап чыгучыларыгыз күпме?

— Кырык биш,— диде председатель.— Алар белән беренче класста укыган чакларында ук туган авылны ярату, шунда калып эшләү хакында әңгәмәләр алып барылды. Җәйге каникул вакытларында колхозыбызга зур ярдәм иттеләр. Быел да унынчы класстан соң үзебездә эшкә калачакларын белдереп идарәгә гариза керттеләр...

Терлекчелектә ике сменалы эшкә күчкәч бу колхоз күзгә күренеп алга китте. Яңалыкны бөтен республика хуплады. Хәзер инде бөтен район терлекчеләре дә ике сменага бүленеп эшлиләр. Моның уңай нәтиҗәләр бирүен бүтән райондагы колхоз җитәкчеләре дә белеп, терлекчелектә эшләүчеләрне Балтач районына җибәреп, эш тәҗрибәсен өйрәнәләр. Татарстандагы районнарның райком һәм шәһәр комитеты секретарьлары һәм райбашкарма комитеты председательләре дә килеп, моның файдалы якларын, гомумән, районның уңышларын күреп фикерләрен әйттеләр. Хәтта Мари АССРның райком секретарьлары һәм колхоз председательләре килеп үзләренә кирәкле күп кенә яңалыклар белән таныштылар. Шуларның барысыннан да районның җитәкчеләре, димәк, Шамил Фәхретдинович та, рәхмәт ишетте.

Ул бүген дә берничә колхозда булып, аларның язгы чәчү барышы, сыерлардан сөт савып алу, нәселле терлекләрне үстерү, колхозлардагы һәм хуҗалыклардагы яңа төзелешләр белән танышты. Кайбер өйләргә кереп, колхоз кешеләренең көнкүреше белән дә кызыксынды. Бөек Ватан сугышында илебезнең азатлыгын саклап баш куйган батырлар да аз түгел авылларда. Алар семьяларының хәле белән аеруча кызыксынды секретарь.

Менә Тимирязев исемендәге колхоз. Аның үзәге Норма авылында. Олы юл өстендә утыра. Председателе яшь һәм тырыш егет Сәйдәш Исрафилов. Партком секретаре Гәптерәүф Сәләхов та төпкә җигелеп эшләүчеләрнең берсе. Колхоз алты авылны берләштерә. Соңгы елларда күзгә күренеп үсә. 4819 гектар сөрүлек җире бар. Быел бодайдан уртача 17 центнер уныш алганнар. Умартачылыктан доходлары мул. Унынчы бишьеллык план күп тармаклар буенча арттырып үтәлгән.

Райкомның беренче секретаре килгәндә идарәдә колхоз председателе белән берлектә район халык контроле комитеты председателе, райком бюросы члены Габделбәр Бәйрәмов та бар иде. Чәчелгән җирләрне кырга чыгып карадылар. Авылның матур урамнары, буяулы өйләре сокландырды. Культура йорты каршына ясалган һәйкәл тирәсен дә әйләнеп килделәр. Ташка язылган исемнәр яңгыр һәм җилдән тоныклана башлаган, аларны бронза белән яңадан язып чыгарырга кирәклеге әйтелде. Авыл төзек, урамнарга таш җәелгән, әмма кайбер күперләр искергән. Аларны яңарту турында да сүз булды. Икенче колхозга баргач Шамил Сираҗиев туп-туры сыер савучылар янына китте. Партком секретаре да биредә иде. Сыерларны берәмләп диярлек карап чыктылар. Нинди азыкларны яратыбрак ашаулары, сөт бирүләре, ясалма орлыкландыру мәсьәләсе белән аеруча кызыксынды секретарь. Чөнки биредә бу эш шактый яхшы куелган, бүтән колхозлар да үрнәк ала, кысыр калуларны бөтенләй булдырмаска тырышалар.

Балтачка соң гына кайтса да, Шамил Фәхретдинович райкомда шактый вакыт утырды әле. Иртәге эшләрне планлаштырырга, көнлек почтаны карарга кирәк иде. Ул партия работниклары турында газета-журналларда чыккан яңа язмаларны көтеп ала һәм бик кы-

зыксынып, җентекләп укый икән. В. Кочетовның «Өлкә комитеты секретаре» дигән китабын аеруча ошаткан. Шуннан кайбер өзекләрне бүген дә куен дәфтәренә язып куйды. Бәлки әле «Менә шундый китаплар күбрәк булсын иде»,— дип тә әйткәндер яки уйлагандыр...

Өйдә аны кечке аш һәм Ләмига ханым әйтәсе куанычлы хәбәр көтә иде: Казан медицина институтында укый торган кызлары Гөлсинә зачетларын һәм экзаменнарын отличнога биргән. Балтач мәктәбен алтын медаль белән тәмамлаган комсомолка кызның институтта да алдынгы студентка булуына ничек сөенмисең ди?

Татарстан АССР Верховный Советы депутаты буларак Ш. Сираҗиевка сайлаучылар күп кенә ихтыяҗларын яки сораулар белдереп хатлар язалар. Бүген дә өч хат килгән. Шуларны укып чыкты һәм аштан соң ук җавап язарга утырды. Ләмига ханым исә дәрес планы төзергә тиеш иде. Ул утыз ел чамасы инде укытучы булып эшли. Мәгариф өлкәсендәге тырыш хезмәтләре өчен Ләмига Сираҗиевага Татарстанның атказанган укытучысы дигән мактаулы исем бирелде. Уллары Илдар, Балтач урта мәктәбен алтын медаль белән тәмамлап, Казан дәүләт медицина институтында укыды һәм ординатория тәмамлады. Хәзер Казанда хирург булып эшли.

«Тырышкан тапкан, ташка кадак каккан», — ди халык. Саный китсәң, Шамил Фәхретдиновичның үз эшләре, үз фидакарьлеге дә тиешенчә тәкъдир ителде бит. Японнарга каршы сугышта батырлыгы өчен хөкүмәтебез аны медальләр белән бүләкләгән иде. Ә тыныч тормыш елларындагы хезмәтләре өчен ул ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек булды. Ә күпме Почет грамоталары, рәхмәт хатлары... Халык бәхете өчен көрәшүчеләрне ил онытмый.

Авыл халкы иртә уяна. Ә райком секретарьлары тагы да иртәрәк тора икән. Һәм үзләрен аямыйча эшләргә күнеккәннәр, дисәң ялгыш булмас. Шамил Фәхретдинович тагын гадәттәгечә иртә уянды һәм кичә бер эше эшләнми калуы кылт итеп исенә төште: автомашиналарга техник хезмәт күрсәтү цехын әзерләп бетерү турында сөйләшергә тиеш була. Шул эшләнмәгән. Ашап-эчкәч, ашыгып «Сельхозтехника» управляющиеның эшенә шалтыратты. Управляющий Иван Сергеев туры килмәде. Өенә шалтыратты. Аның белән сөйләшкәч, кичә очраган бер ветеранның үтенечен башкару өчен, райкомга китте. Аннары бюро членнары белән сөйләшү, аппаратка күрсәтмәләр бирү...

Ш. Сираҗиев өчен иң кадерле нәрсә, минемчә, вакыттыр. Ул кайчакта хәтта өен, үз хуҗалыгы мәшәкатьләрен бөтенләй онытып район эшләренә муеннан чума... Райком бюросы членнары Габделбәр Бәйрәмов, Фатих Сибгатуллин, Рәшидә Кариева, Илдус Нигъмәтуллин, Дамир Габдрахманов, Мәгъфур Гарәфетдинов иптәшләргә дә шул «чир» йоккан — ял-йокы белән исәпләшмиләр. Вакыт турында сүз чыкты исә, Ш. Сираҗиевның күңеленә борынгы язучыбыз Габделҗаббар Кандалыйның «Якутлар табыладыр вакыт белән, вакытлар табылмыйдыр якут белән» дигән тирән мәгънәле сүзләре килеп төшә. Һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Вакыт ул — бик күп нәрсәне хәл итә.

Шамил Сираҗиев партия һәм Совет органнарында озак эшләп күп тәҗрибә туплаган җитәкче. Ул һәр тармакка әһәмият бирә, бернәрсәне дә җитди игътибардан читтә калдырып эшли алмый. Бигрәк тә кадрлар мәсьәләсе, моннан унбиш ел элек, махсус югары белемле колхоз председательләре, белгечләр районда аз иде. Хәзер алар туксан процентка якын. Үз эшен яхшы белүче, үз колхозында төпләнеп калган председательләр һәр колхозда диярлек. «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхоз председателе Харис Галимуллин, «Яңа тормыш»ныкы Рәшит Җамалиев, «Якты юл»да Хәмит Гә-

рәев, Шаумян исемендәге колхозда Мөхәммәт Нәбиев, «ВЛКСМның 50 еллыгы» колхозында Наил Сәлихов моның ачык мисалы. Алар районның алдынгылары, үз эшләрен энәсеннән җебенә хәтле белеп эшләүче җитәкчеләр. Ш. Сираҗиев аларны фронттагы алгы сызык командирлары белән тиңли. Эшкә бер генә минутка салкын караш та — җиңүгә юл яруны кыенлаштыра. Хезмәт фронтында да шундый ук хәл. «Арбаның алгы тәгәрмәче кая барса, арткы тәгәрмәче дә шунда тәгәри», — ди торган булган Шамилнең бабасы Шиһап. Алтын сүзләр!

Секретарь барометрга карады. Бүген аяз булачак. Димәк, чәчүне бөтен тизлеге белән, киң фронтта дәвам итәргә кирәк! Ул, тиз генә җыенып, яңадан колхозларга чыгып китте. Берничә колхозда булып, һәр вакыттагыча, хуҗалык башлыкларының игътибарын бик күп нәрсәләргә юнәлтте. Эш сүлпән барган кайбер тармакларны тәнкыйтьләп алды, яхшы үрнәкләрне хуплады һәм бүтәннәргә дә шуны гыйбрәт итте. Ш. Сираҗиев үзе зоотехник та. Шуның өчен ул районда барлык колхозларның да нәселле терлекләр үрчетүенә, күп үрчем алуга аеруча зур әһәмият бирә. Соңгы унбиш елда ясалма орлыкландыру юлы белән җирле терлекләрдән югары класслы холмогор токымлы сыерлар үрчетү — көн тәртибенә куелган үзәк мәсьәлә! Бу турыда ул барлык колхоз председательләренә, зоотехникларга һәм ферма мөдирләренә бар белгәнен аңлата, сораулар бирә, кирәкле ярдәм күрсәтәчәкләрен әйтә.

Әйтик, тагын юллар мәсьәләсен алыйк. Биредә эшли башлаганда юллар, күперләр шәптән түгел, яңгырлы көннәрдә машиналар батып ята, дәүләткә ашлык тапшыру туктала иде. Ә менә хәзер ул җиңел машинада таш юлдан җилдереп бара. Районның кайсы гына төбәгенә барсаң да шундый таш юллар түшәлгән, цемент-бетон күперләр салынган. Бу — колхоз җитәкчеләренең һәм авылдагы эшчәннәрнең тырышлыгы, алтын куллары белән эшләнде. Колхоз авылы кешеләренең тормышы яхшыру белән культурасы да үсә, алар көн саен диярлек кинофильмнар, спектакльләр карыйлар, концертларда үзләре катнашалар. Авыл интеллигенциясе белән бергә сыер савучылар, дуңгыз караучылар, тракторчылар һәм комбайнчылар да үзешчән сәнгать түгәрәкләренә йөри — спектакльләр куялар, концертларда чыгышлар ясыйлар, хәтта шигырьләр, җырлар да иҗат итәләр.

Районда халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү дә яхшы куелган. Яхшы сыйфатлы мебельләр эшләү буенча Карадуган промартеле бөтен республикага билгеле. Ул товарны Татарстаннан гына түгел, башка республикалардан да килеп алалар. Балтач фабрикасы теккән бүрекләр һәм туннарны күпләр мактап кия һәм рәхмәт хатлары язалар.

Ш. Сираҗиев тирә-якны күзәтеп, болыннарның, су буйларының ямена сокланып барды. Шушма елгасы әнә ничек матур борылыпсарылып ага. Гражданнар сугышы елларында монда каты бәрелешләр булган, легендар Азин җитәкчелегендәге кызылармеецлар Колчак башкисәрләренә каршы үзләрен аямыйча көрәшкәннәр. Чепья мәктәбендәге музейда бу турыда күп кенә документлар, сугышчыларның кораллары һәм бүтән төрле экспонатлар саклана. Музей җитәкчесе Гарифҗан Галиев бу эшкә гаять бирелгән булып чыкты һәм шуңа күп вакытын бүлә, тырышлыгын багышлый.

Секретарьның машина тизлегеннән күп тапкыр җитезрәк уйлары тиз генә арада әллә кайларны урап өлгерде. Җырларда макталган Шушма дулкыннары аның табигатьне саклау турындагы уйларын кат-кат кузгатты. Кайбер район колхозларында табигать байлыкларына саксыз карыйлар, елгалар, чишмәләр кибә, болыннар, куаклыклар ташландык хәлгә килә. Ә биредә... Нинди хозурлык! Шушма үзе

мөлдерәп тора, куе куаклыклар, әрәмәлекләр ямь-яшел. Анда мең төрле моң таратып кошлар сайрый. «Юк, — дип уйлый секретарь, — бу алтын хәзинәне саклау гына түгел, аны һаман арттырырга, кирәгенчә файдаланырга кирәк. Әйтик, мәсәлән, табигый елгалар, күлләрдәге балыкларны күбрәк үрчетсәң, күпме рәхәтлек һәм өстәмә ризык, сәламәтлеккә файда булыр иде!»

Секретарь бөтен районны һәр яктан шулай мөкәммәл булган, шаулап торган мул бакча итеп тә күз алдына китерде. Шагыйрь Һади Такташның сүзләрен хәтерләде:

> Хыял безнең өчен чит бер нәрсә.
> Һәрбер теләк якын киләчәк!

Районда кадрлар белән эшләү соңгы елларда яхшырганнан яхшыра бара. Колхозларда үз авылларының белгечләре, җиргә кендекләре белән берегеп үскән яшьләр тырышып эшли. Шуларның күбесе унъеллык мәктәпне бетергәч биредә калган. Моның өчен һичшиксез күп көч куелган әлбәттә. Бу эш аеруча Балтач, Чепья, Янгул, Смәел урта мәктәпләрендә яхшы куелган. Һәр мәктәптә укучылардан төзелгән бригада эшли. Янгул урта мәктәбе бригадасын коммунист, Бөек Ватан сугышы ветераны Гарәфи Гарипов җитәкли. Бригадага егерме гектар җир бүленеп бирелгән. Анда бәрәңге һәм тамыразыклар үстерелә. Югары уңышка ирешкәне өчен бригада социалистик ярышта районда гына түгел, Россия Федерациясендә призлы урыннарны ала. Бригаданың алдынгы члены Римма Бариева, мәсәлән, Ставропольдә үткәрелгән ярышта катнаша. РСФСР Министрлар Советы Председателе Соломенцев, ВЛКСМ Үзәк Комитеты беренче секретаре Пастухов һәм мәгариф министрлыгы хозурында була. Шул ук мәктәп укучылары Нургаян Гәрәев, Сәрия Газизуллина Мәскәү һәм Ставрополь шәһәрендә үткәрелгән слетларда катнаша. Укучылар бригадаларының эш нәтиҗәләре «Уңыш бәйрәме»ндә күренә. Бу тантаналы бәйрәмгә җитәкчеләр, белгечләр, производство алдынгылары, хезмәт ветераннары, мәктәпнең колхозда яхшы эшләүче элекке укучылары чакырылалар. Монда бригада алдынгыларына Почет грамоталары, кыйммәтле бүләкләр бирелә. Укучылар үз иңшаларында да бу турыда бик җылы итеп, горурланып язалар. «Безнең иң беренче бурычыбыз — тырышып уку һәм хезмәтне ярату. Мин җәй көннәрендә комбайнчы ярдәмчесе булып эшләдем. Комбайнчы коммунист Нургаян абый Сөнгатуллинның хезмәтенә сокландым, эшемдә аңа охшарга тырыштым!» — ди Илдус Әхәтов. Ул хәзер Казан дәүләт университетында укый һәм диплом алганнан соң туган авылына кайтачагын белдереп хатлар яза.

Унъеллык мәктәпләрнең барысында да хезмәт дәресләре укытыла һәм өченче класслы тракторчылар-машинистлар хәзерләнә. Соңгы өч елда районның унынчы класста укучыларның тугыз йөзе тракторчы-машинист таныклыгы алган һәм хәзер авыл хуҗалыгында тырышып эшли. Күп кенә мәктәп укучылары колхоз производствосында үзләрен танытып хәзер районның атаклы кешеләре булганнар. Чепья урта мәктәбен тәмамлаган Рузилә Кашапова, мәсәлән, фермада алдынгы савымчы була. Почет грамоталары һәм кыйммәтле бүләкләр ала. Аннары аны Урта Көшкәт авыл Советы председателе итеп күтәрәләр. Ул СССР Верховный Советы депутаты булды.

... Унынчы бишьеллык планны үтәү буенча Балтач — республикада алдынгы районнарның берсе. Ул КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПСның һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Почет грамотасына лаек була. «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхоз КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы,

ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Унынчы бишьеллыкта эш нең югары сыйфаты өчен» дигән истәлек билгесен яулап ала. Игенчелек һәм терлекчелек продуктлары җитештерү һәм дәүләткә сату планнарын үтәүдә ирешкән уңышлары өчен шул ук колхоз Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. «Яңа тормыш» колхозы хезмәтчәннәре 1980 ел нәтиҗәләре буенча Бөтенроссия социалистик ярышында җиңеп чыктылар. Бу җиңү өчен хуҗалыкка РСФСР Министрлар Советы һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл байрагы бирелә. Унынчы бишьеллыкта район буенча һәр сыердан 3000 килограммга якын сөт савып алынган. Районның барлык колхоз һәм совхоз фермаларында диярлек нәселле терлек асрыйлар. Шулай ук игеннәрдән дә шактый югары уңыш яулап алуга ирешелгән. Унынчы бишьеллыкта ирешкән уңышлар өчен районның күп кенә колхозчылары, механизаторлары, колхоз җитәкчеләре орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә.

Тырыш һәм кайнар йөрәкле коммунист, Бөек Ватан сугышы ветераны Шамил Сираҗиев районның әнә шулай алга китүе өчен армый-талмый эшли. Сүз уңаенда тагын шунысын да әйтеп үтү, безнеңчә, урынлы булыр: аның район тормышыннан алып язган мәкаләләре, язмалары Мәскәүдә һәм Казанда чыга торган газета-журналларда еш басылалар. Ул хәзер районның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәген яктырткан китап өстендә эшли.

Районадагы колхозларның эш тәҗрибәләрен өйрәнергә Мари АССРдан килгән бер председатель болай дигән:

— Чыннан да үрнәк алырлык эшләрегез күп икән. Яңага юл яруыгыз, зур хезмәтләрегез өчен сезгә олы рәхмәтебезне белдерәбез, Шамил Фәхретдинович!

Күпләр күңелендәге сүзләрне әйткән бит ул. Ил һәм халык рәхмәте — кешегә моннан да зур мәртәбә, моннан да зур ихтирам һәм хөрмәт юк!

Мансур Вәлиев

# ШАГЫЙРЬ УТЫ

Инде шактый сизелерлек булып күзгә авышкан җәйнең бер кичә иде. Көндез салкынча, рәхәт һава бөркеп торган урман хәзер, кичен үзеннән ниндидер шыксыз, җанга ят булган караңгылык тарата. Безнең йортлар урнашкан алан иртәнгә хәтле әнә шул караңгылык эчендә калган.

Бу — язучыларның Аккош күлендәге иҗат йорты.

Быел без — яшьләргә дә аннан бүлмә бирделәр. Ләкин әле, яңа гына салынып беткән йорт булганлыктан, тулысынча көйләнеп, тиешле бөтен нәрсә белән җиһазландырылып бетмәгән. Шуңа күрә ут та юк.

Җәй буе шәһәр ыгы-зыгысында ятып инде тәмам туелган иде, мин йорт үзе әзер булу белән бирегә күчеп килдем. Хәзер менә мондагы беренче төнемә кереп барам. Тәрәзә каршына ук килеп баскан кара-кучкыл иманнар, олы күләгәле юкәләр бүлмәдәге караңгылыкны тагын да көчәйтәләр. Мәңгелек серләргә ия бу зур урманнан, аның үзенә генә мәгълүм тормышыннан юка пыяла белән генә аерылган булу, ниндидер бер курку дип кенә әйтеп бетерелә алмаган эчке халәт тудыра. Бу, күрәсең, әлеге кара урман серлелегенең күңелгә күчүеннәндер, әле үзеңә аңлашылып җитмәгән бер халәттә яши башлавыңнандыр, шуның тәэсиредер...

Әнә шул халәттә утырганда, әкрен генә тышкы ишек ачылып китте һәм берәү өйгә керде. Каршы чыккач, мин күршебез Сибгат ага Хәкимнең таныш тавышын ишеттем.

— Төн караңгы, ут кирәк булыр...— диде ул, кулындагы шәмен миңа сузып.

Шулай итеп бу август кичендә Аккош күленең тагын бер йортында ут кабынды.

Зур кара урманга сыенып ук утырган яңа өй тәрәзәсендәге әлеге ут тыштан ничек күренде икән?

Мөгаен, ул ут үзенең кабынуы, яна башлавы белән бу өйне урманның иге-чиге күренмәгән караңгылыгыннан аерып куйгандыр. Аны — «бу кешеләр өе» дип күрсәткәндер; монда кешеләр яшәячәк» дип, сүзсез генә аңлаткандыр.

Кеше рухы да табигатьнең чиксез караңгылыгы эченнән әнә шулай килеп чыгып, әнә шулай аерылып китә, үсеп китә, күрәсең.

Ә миңа, өйдә утыручыга, бу ут дөньядагы бөтен прожекторлардан яктырак кебек иде, көчлерәк сыман иде. Ни өчен шулай тоелган?

Мөгаен, тере ут, чын ут, җанлы ут булгандыр.

Прожекторлар алар күзне чагылдыралар, ерактан балкыйлар, әмма аларда — салкын ут, җансыз ут. Аларга күз кызыга, ләкин күңел тартмый. Аларны күргәч җан әсәрми, талпынмый, омтылмый.

Ә бу ут исә — кешегә кирәк яктылыкны да, җылылыкны да, ягымлы матурлыкны һәм үзенә генә хас булган бертөрле назны да — барысын да бергә җыйган, үзе шуларга әверелгән. Бу ут адәм баласының баш сәләте, акыл көче белән уйлап табылган яктылык кына түгел. Аны кешелекле ут дияргә дә мөмкин сыман...

Шагыйрь Сибгат Хәким поэзиясе белән әнә шул ут арасында бер зур уртаклык бар

төсле. Юк, мөгаен, поэзиясе — язганнары гына түгел, шагыйрьнең үз табигате, шәхесе дә нәрсәсе беләндер табигый, чын утның кешегә бер үк вакытта якты да, җылы да биреп, аны кадерләп-иркәләп тә януына тартым бугай аның.

Әлеге онытылмаслык кичкә кадәр шагыйрьнең иҗаты белән беренче мәртәбә тирәннән танышуым — шагыйрь җаны белән очрашуым бик нык истә.

Ул вакытта мин Ерак Көнчыгышта идем. Без, офицерлар, данлыклы Уссури тайгасы эченә үк кертеп салынган казармаларда яшәп, укып ятабыз: хәрби эшне өйрәнәбез, үзебезнең частьларга, солдатлар каршына киткәнче, «коеп куйган офицер» булыйк дип йөрибез. Тормышыбызның көне дә, төне дә хәрби хезмәт кагыйдәләре, аның катгый бурычлары белән шыплап тутырылган. Башка һичнәрсәгә урын юк сыман.

Әмма кешенең тормышын, аның яшәү рәвешен чагыштырмача тиз арада үзгәртеп, икенче кыяфәткә кертеп булса да, аның эчендәге бер нәрсәне алай кинәт алыштырып кую мөмкин түгел икән. Җан, күңел дигәнеңнең яшәве тиз генә үзгәрә алмый икән...

Мин дә эчемдә нәрсәнеңдер авырая, тула барганын, яшәешемне борчый, тынгысызлый башлавын тойдым. Бу, күрәсең, җан җирсүе булгандыр. Аның үз җирлеген, туфрагын эзләве булгандыр. Тәрәзәдән ерак түгел үсеп утырган ялгыз өянке дә җил, давыл вакытында кабарынып, канатларын җилпеп каядыр күтәрелеп очып китәргә җыенган ялгыз кошны юкка гына хәтерләтмәгәндер ул чагында миңа.

Шулай яшәп ятканда Хабаровскига командировкага җибәрделәр. Хабаровск — зур шәһәр; ул Ерак Көнчыгышның икенче башкаласы. Һәм, билгеле, тайгадан башкалага эләккән кеше башта бераз каушый, нәрсәгәдер ашыга, дулкынлана, күрәсең. Аның үзенә бирелгән кыска гына вакытта әлеге башкаланың бөтен «башкалыгы»н күрәсе, тоясы, аңлыйсы киләдер. Хабаровскига җиткәндә мин дә нәкъ шундый хәлдә идем. Ләкин барыбер юлымны китап кибетеннән башладым. Һәм уңдым да. Миңа анда Сибгат Хәкимнең «Советская Россия» нәшрияты 1973 елда чыгарган китабы очрады. «Соңгы елларда язылган шигырьләр» китабы.

Сезнең бик ерак җирдә үз авылдашыгызны очратканыгыз бардыр. Бу китапның табылуын мин бары тик әнә шуның белән генә чагыштырыр идем. Танышыңны күргәч ерак илдә барысын бик кадерләп, сагынып, ашыкмый-кабаланмыйча, зур игътибар белән искә аласың, күз алдыңа китерәсең. Үткән тормышың әр-яңадан җанлана, аерып торган мең чакрым аралар югала, син, әйтерсең, тагын шул бик кадерле җирдә гомер итеп ятасың... Тик хәзер инде сиңа туган җиреңдә үткән һәр матур көн тулы бер гомер кебек тоела.

Зур ераклыклар, олы лупа кебек, күңел күзе көчен бик нык арттыралар икән алар. Шулар аша карагач туган җирдәге тормышның һәр нәрсәсе бай мәгънәле, тирән һәм ягымлы күренә икән аның. Сибгат Хәкимнең бу китабы минем өчен тугыз мең чакрым ераклыкны юкка чыгарды. Мине туган җиргә алып кайтты. Бу китап аша туган як тәэсире, аның тартуы һәм Хабаровскины күрергә омтылыш хисе бер-берсе белән ярыша да, янәшә дә тора алмаслык булып чыктылар. Андагы шигырьләрнең — туган җир чәчәкләренең исләренә исерү, җырларын тыңлау, аңлый алу һәм үз җирең белән иң якыннан тоташа, ялгана алу бары тик япа-ялгыз калгач кына мөмкин иде. Шәһәрнең гүзәл Амур буена җәелеп утырган иркен, матур паркта утырып мин җирдәге иң гүзәл төбәк — туган ил белән тоташтым. Ике арада салават күпере булып шигърият калыкты. Ул көнне мин Сибгат ага шигырьләренең һәрберсен искиткеч тирәнлектә кабул иттем: һәммәсе үзенә бик озакка туктата, уйландыра, моңарчы ишетелгәннәре, җыр булып яңгыраганнары да биредә бөтенләй яңа төсмер, тирәнрәк мәгънә ала иде. «Башка берни дә кирәкми, үзем чапкан печәннәрне бер туйганчы иснәсәм...»

Тыштан гап-гади тоелган бу сүзләр миңа, мөгаен, элек әллә ни тәэсир итмәгәннәрдер. Чөнки мин әле ул чагында туган җир дигән сүзләрне бер ияләнелгән төшенчә буларак кына кабул иткәнмен, аның нәрсә икәнен аңлау, чын кадерен белү өчен миңа туган җирдән аерылып карау, ансыз торып карау кирәк булган.

Менә хәзер миндә туган җирне сагынуның иң көчәйгән, ул хиснең күңелдә иң

тулган, иң ташыган чагы. Хәзер инде мин шагыйрьнең югарыдагы сүзләренә никадәр йөрәк моңы, никадәрле ихлас кичереш салынганын бик яхшы аңлыйм. Чөнки алар үземдә ярсып, диңгез сыман дулкынланып тора. Әйе, дисең, чыннан да сау-сәламәт булып, туган җирдә намуслы эш белән көн күрү — кеше өчен иң зур бәхет икән! Ә шагыйрь моны бик матур итеп: «үзем чапкан печәннәрне бер туйганчы иснәсәм»,— дип әйткән. Бу инде, мөгаен, сугыш мәхшәрләрен кичкән, дошманның ангыр кебек яуган пулялары астында алга барган, кышын, көзен һәм язын юеш окопларда яткан, әнә шуларның барысы вакытында да һич онытмый, үз авылына кайтып бер кирелеп печән чабу бәхете турында хыялланган кеше сүзләредер. Ниһаять, ул шул бәхеткә ирешә алган, җиңү яулап үзенең туган туфрагына исән-сау әйләнеп кайткан. Икенче көн иртүк торып болынга, басуларга таба атлаган. Әнә шунда аның йөрәк түреннән үзләреннән-үзләре шигъри сүзләр агылган — «башка берни дә кирәкми, үзем тапкан чишмәләрнең ятып эчсәм суларын», «... дусларның мин гомрем буе тойсам җылы карашын». Шул шигырьдә яшәгән лирик герой Сибгат Хәкимнең бүтән күп кенә әсәрләренә дә килеп керә. Ул — кыска гына итеп әйткәндә, җир кешесе. Үзенең чыгышы, нәсел-нәсәбе белән, бүген тормыш итү рәвеше белән һәм киләчәге белән җирдән, авылдан аерылуны күз алдына да китерә алмаган кеше.

Җир кешесе. Безнең әдәбиятта бу геройга караш төрле чорда төрлечәрәк булды бугай. Кайвакытларда аны заман җилләренә игътибарсызлыкта, чорны искә алмауда гаепләүләр күренгәләде. Болар, күрәсең, җиргә ябышып яткан җир кешесенә карата әйтелгәндер. Аның эшенең, язмышының үзенчәлеген искә алмыйчарак, әлбәттә.

Ләкин еллар үтү белән безнең — үтә заманча кешеләрнең — күз карашлары яңадан җир кешесенә юнәлә түгелме?! Замана тормышы тудырган күп кенә мәсьәләләргә ышанычлы җавап табарга теләп киләбез без яңадан җир кешесе тормышына, аның яшәү рәвешенә. Мәсәлән, бүген безне җир кешесенең әхлакый матурлыгы, сәламәт рухы, дөньяны ашыкмыйча — җиде кат үлчәп кенә бер карарга килүе шактый уйландыра һәм, яшермик, еш кына бу сыйфатлар безне кызыктыра да. Чөнки аларның киресе булган холык белән без инде шактый гына хаталар эшләп ташлаганлыгыбызны беләбез.

Елганың борылган төшендә,
Бик хәтәр төшендә елганың
Тал тора, таза бер тал тора,
Еламый, көтмә син елавын...

Җилкәсе суелган, күп түзгән,
Калын, киң җилкәсе яралы;
Яшәгән шушында, үстергән
Шушы җир һәм шушы яр аны.

Менә шушы тал — әйтерсең, халыкның сәламәт рухы, какшамас һәм олы иманы. Ул ничек кенә бәрсәләр дә түзгән. Ә талның ныклыгы сәбәбен шагыйрь шушы җирдә, шушы ярда үсүдә күрә.

Бу тал образы шагыйрьнең үзенә дә ничек туры килә!

Ә бер шигырендә исә ул үзе һәм үз нәселе белән ачыктан-ачык таныштыра:

Безнең буын — озын чылбыр ул,
Кырлар буйлап узган юлдыр ул.
Озын чылбыр. Бик күп боҗралар.
Ул боҗралар — бар да без алар...

Алдарак ул үзенең җиргә карашын да «Җир — икмәгең, җир ул язмышың»,— дип, бик мәгънәле сүзләр белән белдереп үтә.

Менә шушындый рух хөкем сөргән шигырьләрне уку миңа Ерак Көнчыгышта үз авылдашларымны күрү сыман иде. Аларны укыгач җанга ниндидер җиңеллек килгәндәй тоелды. Бу үзгәреш тә, билгеле, шигъърият тәэсиреннән иде.

Шигырьләрдәге лирик геройны без җир кешесе дип кыска гына билгеләп үтсәк тә, ул җиргә генә ябышкан һәм үз эшеннән башка бүтән берни дә белергә теләмәгән кеше түгел. Менә мондый тавышларны да ишетә торган җир кешесе ул:

**Сәгъди тавышы килә кебек кырдан:**
**Без адаштык, коткар, Габдулла;**
**Атны җәллим үзебездән бигрәк,**
**Сине алып кайткан ат туңа.**

Кыска гына дүрт юллык шигырьдә нинди табигый һәм тирән образлылык! Сәгъди тавышы безгә дә килеп җитә, безне дә уйландыра.

Ә бер шигырьдә исә шагыйрь нәкъ минем халәтне әйтеп биргән.

**Төшенмәгән кешеләр арасында,**
**Еракларда, читтә телемнән,**
**Мин кирәксез; аерылган да җаным**
**Туган җирдән — үзенең тәненнән,**
**Бер бушлыкта әшсез әйләнә күк,**
**Авырлыгын тоймыйм гәүдәнең!**

Шулай итеп Ерак Көнчыгышта мин үзем өчен зур шагыйрь ачтым. Җаныма, рухыма, күңелемә иң нык, иң тирән үтеп керә алган шагыйрьне таптым. Шагыйрь генә дә түгел, күрәсең. Анда минем кебек күпләргә әнә шундый авыр чакларда җиңеллек китерә, таяныч була алган олы җан ияләренен белдем бугай. Ә андый көчкә ия булу — зур, житди, төпле шигъри дөнья дигән сүздер. Кешеләр нык ышана алырдай, таяна алырдай дөнья иҗат ителү билгеседер ул...

Ә еллар үтеп, яңадан Казанга кайткач, мин Сибгат ага Хәкимнең өлкән буын шагыйрьләрдән берсе икәнен һәм Язучылар союзында иң актив, тынгысыз җәмәгать эшлеклесе саналуын белдем. Шунда, аның тормышын берникадәр якынрак арадан күреп йөри-йөри, мин зур шигъриятнең туу серләренә дә төшенә яздым кебек. Юк, олы поэзия ул, без кайчагында күзаллаганча, сәнгатьнең иң тирәндәге хикмәтләренә ирешү генә түгел икән, биредә мөһимрәк нәрсә — тормыш киңлеге, яшәү хакыйкатьләренең тирәнлеге икән. Шагыйрьнең кешеләр арасында, заманның иң тынгысыз урыннарында йөрүе, аның йөрәгенең иң яңа үзгәрешләргә, тенденцияләргә дә ачык булуы, аларны аңларга, үзе өчен ачыкларга тырышуы — менә шулар барысы да эчтәге иҗат утын сүндерми, сүрелдерми тота икән.

Шагыйрьнең җәмәгать эшчәнлеге турында сөйләгәндә, безнең өчен мөһим бер сыйфатны әйтми китеп булмый. Үзе алынган эшләрне шау-шу тудырып, бөтен кеше күрерлек итеп, гомум игътибарны җәлеп итәргә тырышып эшләми — аңа масаю чит, әнә кадәр эш эшләп, дөя хәтле сүз сөйләүчеләрдән түгел ул.

Безнеңчә, бу шәхеснең тирәннән туган тормыш ихтыяҗларына карата күңел сизгерлеге. Теге яисә бу эшнең кирәклеген, халык, әдәбият өчен мөһимлеген алдан ук тоеп, белеп торуы. Аңа үзенең җаны, рухы белән эчтән омтылып яшәве. Менә шул сыйфатлар аны шагыйрь буларак кына түгел, кеше буларак та зур һәм чын мәгънәдә җитди итә. Ә кешелек җитдилеге, олылыгы үз чиратында шулай ук бик зур вазифалар йөкли бит ул. Кешеләрнең, замандашларыңның сиңа ихлас ышана алуы дигән сүз. Тулысынча ышанган кешеңә бит ул киңәш сорап та, ярдәм көтеп тә, бер эчне бушатып сөйләшеп кенә алу өчен дә еш киләсең. Сибгат ага Хәкимгә дә кешеләр күп киләләр.

Ә миңа аның яшьләр белән аралашу рәвеше аеруча якын. Юк, моны эш дигән шактый коры сүз белән генә аңлатып булмый. Шагыйрь үзе дә аны ниндидер эш, үзенә кемдер йөкләгән вазифа дип уйламый. Яшьләр белән аралашуны үзенең көндәлек тормыш ихтыяҗы дип саный шикелле. Бу да — олылык, тормыш белән бергә атлап бару, чын яшәү билгесе. Олыгайгач та дөньяның, яшәүнең үзәгендә торып калу күренеше.

Яшьләр аңа күп киләләр. Нилектән алай? Сәбәбе нәрсә? Иң беренче сәбәп, мөгаен, иҗаттыр. Аның яшьләрне кызыктырырлык тормышчан һәм югары дәрәҗәдә сәнгатьчә булуыдыр. Икенче мөһим сәбәп — Сибгат аганың, җитди мәгънәләр, уй-фикерләр, хисләр үтә тыгызланган иҗат биеклегеннән төшмәгән, түбәнәймәгән халдә,

яшь иҗатчы белән бик тиз аңлашу таба алуы, ихлас сөйләшә, уйлана, эзләнә алуы. Ул яшьләрне өйрәтеп кенә дә тора алыр иде бит. Яшьләр аның алтын бәһасе торырдай сүзләрен тыңлап, күңелләренә сеңдереп торырга тиеш дип кую да мөмкин сыман бит. Әмма шагыйрь алай итми. Болай эшләүнең нәрсәседер аның бөтен табигатенә, холкына ят. Күрәсең, бусы да чын олылыкның бер чагылышыдыр. Шул ук вакытта бу үзенчәлек шагыйрьнең һаман да дөнья һәм яшәеш турында уйланудан туктамавы, әле һаман ачыкланып бетмәгән күп сораулар күреп торуы, аларга иң кешелекле җаваплар эзләве — нечкә җан хәрәкәте бару турында да сөйли. Шушы халәт инде күпме дөнья күргән кешенең дә җанын тынгысыз итә, һәрчак борчулы итә. Ә бу исә — йөрәктәге ялкынның сүнмәве дигән сүз. Эчендә ут яшәү дигән сүз. Ялкынлы, утлы иҗат дигән сүз.

Шагыйрь гомеренең иң бөек һәм иң зур мәгънәсе дә, мөгаен, әнә шул ут булудадыр. Шагыйрьнең кешелек кичерешләре, хисләре белән туктаусыз янып яшәвендәдер. Аны барысы да борчый, хисләндерә. Аңа һәммәсенә җавап табу кирәк. Чөнки ул белә — аның сүзен халык көтеп тора. Халык кадәр халык! Ул үз улыннан олы сүз, мәгънәле сүз, кешелекле матур сүз көтә. Шагыйрь бу хакта беркайчан да исеннән чыгармый.

**Союз түгел, йөз язучы түгел,**
**Калмаганнар куркып ничек, әй,—**
**Хакыйкатьне әйтеп бирер өчен**
**Бер Толстой җиткән, бер Тукай.**

Сибгат ага Хәким каләмдәшләрен Толстойча, Тукайча язарга чакыра. Үзе дә бөтен күңеле белән әнә шул бөек иҗат биеклегенә омтыла. Олы яшьтә булуына карамастан, олы эшләргә алына, поэмалар, яңа шигырь бәйләмнәре иҗат итә. Әлбәттә, яшьләрдән һич калышмыйча ил буйлап, республиканы гизеп йөри. Һәр сәяхәт шагыйрь җанын әсәрләндерә, дәртләндерә.

Ә шулай да аның өчен иң ямьле һәм иң моңлы бер җир бар. Җанын, йөрәген бөтен матур урыннардан ныграк тарткан җир. Ул — шагыйрьнең туып-үскән җире. Чөнки ул барысыннан да элек — менә шушы җирнең, шушы табигать төбәгенең баласы. Аның үзен дә, аны тапкан анны да менә шушы табигать тудырган, үстергән, тәрбияләгән. Әйе, әйе, тәрбияләгән дә!

Әмма үзенә бик кадерле бу якка кайткачтын да шагыйрь кешеләргә барып бәйләнгән җанының икенче яртысын оныта алмый:

**Бер генә көн кырларны син әйлән,**
**Бер генә көн калып йөр әле;**
**Зур янүда кушыла икән бергә**
**Җир йөрәге, халык йөрәге.**

Яисә, икенче бер вакытта ул үзенең туган як кырларында болай уйлана:

**Кырларда давыл, кырларга**
**Бер генә кара, дустым:**
**Арышлар уйный җилләрдә,**
**Дулкыннар кара-кучкыл.**

**... Моңнарым баса башымны,**
**Бетми торган моңнарым.**
**Онытма мәңге борчулы**
**Шул кырларда мин барын.**

Әйе, шагыйрь үзе дә сизмичә диярлек иҗат дөньясының иң төп сыйфатын әйтеп ташлый — «мәңге борчулы... мин». Ул «мин» — гел хәрәкәттәге диңгез сыман, бер дә җылысын киметми торган учак сыман, гел дөрләп янып яшәгән ут шикелле. Алар кебек тынгысыз ул «мин».

Ә кайчак без шагыйрьне тып-тын калып уйланган, уйга баткан хәлдә күрәбез. Әйтерсең, ул менә шушы гаять катлаулы, бик четерекле яклары булган тормышны аңлау, тою өчен табигатьнең үзе тарафыннан яратылган бер җан, бер зат...

Соңгы елларда яңгырый башлаган һәм бик тиз арада киң танылу тапкан «Өянкеләр» җыры безнең күз алдына шагыйрьнең нәкъ әнә шундый образын китереп бастыра. Өянке... Халкыбыз күңеленә никадәр якын агач бу! Эш нәрсәдә? Ни өчен күңелгә аеруча үз тоела, аеруча кадерле күренә? Авыл җиренең иң ямьле урыны булган су буенда үскәнгәме? Иң кадерле яшьлек хатирәләребез килеп бәйләнгәнгәме әллә?.. Әллә ул үзенең бөтен барлыгы белән ниндидер серле моңлылыкны, тирән уйчанлыкны чагылдырамы? Әллә халык аеруча хөрмәт иткән тыйнак җитдилек, күңел матурлыгы, төплелекне үзенә туплаган бер кеше сыманрак күренәме безгә ул сабыр өянкеләр? Бәлки барысы да бардыр... Тик олыгайган шагыйрь өчен ул өянкеләр— без аңлаганның барысына караганда да моңлырак, мәгънәлерәк, якынрак. Өянке — гүя бу дөньяның барлык моңын үзенә җыйган бер зат, бер үлемсез җан... Ниндидер бер мизгелдә дөньяда шагыйрь белән өянке генә калган сыман, алар икәве генә сөйләшкән, серләшкән төсле тоелып китә хәтта...

**Сезгә эндәшми мин кемгә**
**Эндәшим, өянкеләр!**
**Җитте минем дә сезнең күк**
**Картайдым дияр көннәр.**

Нәкъ халык моңы, халык җыры кебек күңел капкаларын киереп ачып эчкә, күңелләр түренә үтә. Шагыйрь мондый тәэсир көченә ничек ирешә соң?

Моның ише юлларны яза алу өчен халкың белән бергә, чордашларың белән бергә бик күпне, бик күпне кичергән булу кирәктер. Тормыштагы бик күп кайгы-шатлыкларның синең күңелеңә моң булып туплануы, җыйналуы кирәктер... Һәм менә шундый сабыр, әмма тыгыз, кайнар хисләрне шигырь ахырында: «Кимедәге өянкеләр, сезгә баш ияр кемнәр?» — дип әйтеп бирә алу кирәктер...

... Шигърияттә кызык кына бер үзенчәлек яши: хисләр тирәнәя, җитдиләнә барган саен, аларны укучыга җиткерүче сүзләр ничектер һаман гадиләшә төшә, һаман кешелеклерәк була бара. Бу, гадәттә, олы шагыйрьләр иҗатында бик еш күзгә ташлана. Аерым гына алып карасаң гап-гади сүз, шигырь юлының шагыйрь йөрәге тарафыннан хасил ителгән кайнарлыгы аны никадәр бай мәгънәле итә, тирән яңгырата! Пушкинда шулай... Тукайда, Туфанда шулай... Сибгат Хәкимнең җитмеш еллык гомер тәҗрибәсе белән яктыртылган иҗат дөньясында да шулай...

Олы шигъриятне һәм андагы олы шәхесне үзем өчен мин әнә шулай ачтым.

... Җәйләрен, ил буйлап йөрүдән, туган ягына йөреп торудан калган буш вакытын Сибгат ага Хәким Аккош күлендә үткәрә. Хәер, шагыйрь, иҗат кешесе өчен буш вакыт, эшсез чак бар микән ул? Әнә, ул урманга, табигать эченә, дөньяның бөек фәлсәфәсен танырга ашыга. Бу аның иҗатына ныклык, камиллек, озын гомер бирәчәк... Әнә, ул кешеләр янына, алар белән бер сөйләшеп алырга, эч серен бүлешеп үзе тагын да баерга ашыга. Кешеләр аның иҗатына яңа хисләр, тормыш турында яңа уйлар бирәчәк...

Әнә, ул үзенең язу өстәле янына ашыга. Күңелдә җыелганның, тупланганның һәммәсен намус кебек ак кәгазьгә төшерергә ашыга. Бу язу өстәле безгә, кешеләргә, йөрәк түренә үтеп һич онытылмый торган матур-матур шигырьләр бирәчәк...

Менә шушы өч төрле ашыгу: табигатькә, кешеләргә һәм иҗат дөньясына ашыгу— әллә шигъриятнең көчен шулар билгели микән? Шушы өч хәрәкәт әллә аның йөрәгендәге ялкынга янарга кирәкле чималны биреп, китереп тора микән? Шагыйрьнең мондый шигыре бар:

**Төнге ике. Өстәл, кәгазь, кара.**
**Яз дим үземә, нигә тукталдың!**
**Яз, язмау бит оят — тәрәзәдә**
**Уты янган чакта Туфанның.**

Димәк, аның да карап үзенә көч һәм дәрт алган уты бар икән. Күрәсең, мондый утлар сүнмичә буыннан-буынга күчеп килә.

Без дә бүген шагыйрь Сибгат Хәким иҗаты яндырган утны ерактан күрәбез. Ул ут җылы да, якты да, ягымлы-кешелекле дә һәм шуңа күрә безгә бик кадерле дә. Чөнки ул — кешелекне миллион еллар буена җылытып килгән уттан кабынган ут. Ышанычлы ут.

················

Нил Юзиев,

филология фәннәре докторы

# УЙЛЫ ТУЙРА

Ренат Харисның иҗат портреты

Ренат Харис 60 нчы елларның урталарында ук үзенчәлекле шигъри авазын ишеттергән, кыю эзләнүләре белән әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә юнәлткән, бәхәсләр уяткан, һәм шуннан бирле актив һәм даими эшләп килүче, поэзия йөген җигелеп тартучы шагыйрьләребезнең берсе. Әдәбият мәйданына ул хисе басыла төшкәч, азау һәм акыл тешләре чыккач, поэзия үсешенә үзенең ачык карашын булдыргач килеп керде. Рухи һәм шигъри аякка басу, чыныгу чоры озаккарак сузылды. Беренче җыентыгы 1968 елны «Җир һәм кеше» исемендә дөнья күрде. Бу вакытта инде аңа 27 яшь иде. (Белүебезчә, Тукай 27 яшьтә үзенең иҗат юлын тәмамлый). Моның сәбәпләрен шигъри тулпарының үшәнлеге белән генә аңлатуы кыен, сәбәпләре тирәндәрәк — шигъри һәм иҗтимагый мохиттә. Хәзер аңа 40 яшь. Моны ул үзе «ир уртасы» дип атый. Ә ир уртасы,— аныңча әйтсәк, «кыр уртасы, җир уртасы, җыр уртасы».

**Кыр уртасы...**
**Бар көчемә җырлап йөрим мин —**
**Ир уртасы.**
**Тавышымның болытларга җитүен тоям.**
**Болытлардан минем тавыш яңгыр коя.**

Р. Харисның хәзер тулы тавыш белән җырлаган чагы, иҗаты мул җимеш биргән вакыт. Безгә калса, Р. Харис үз «җырының» уртасына әле җитеп кенә киләдер, җырлыйсы җыры күбрәктер кебек тоела. Күңел шулай булуын тели. Әмма шунысын ачык әйтергә була — шигърият кырында шактый күп эшләгән, нәтиҗәле эшләгән: ун елга — җиде китап аз түгел («Җир һәм кеше», 1968; «Кайтаваз», 1969; «Ак сөлге», 1971; «Яңа көн», 1972; «Бизәк», 1974; «Баскычлар», 1976; «Уйлы туйра», 1978). Һәр җыентыгында укучыларга тик яңа әсәрләрен генә тәкъдим итә — әсәрләрен кат-кат бастырмый. Һәр китабын исә иҗат үрләренә якынайтучы баскычлар итеп карарга була. Аларда шагыйрь шәхесенең чыныгуы һәм баюы да, дөньяны, җир һәм кешене аңлавы — аңлатуы тирәнәюе дә, осталыгының чарлана баруы да чагыла.

«Кеше» ораториясенең либреттосы өчен Р. Харис 1979 елны Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды. Соңгы елларда байтак шигырьләре рус теленә тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә «Русские вороты» (1977) һәм «Войди в мой дом» (1980) исемле, Казанда «Листья» (1979) диган җыентыклары дөнья күрде. Ир уртасы шагыйрь үзенең «җыр уртасы»н тавышының әнә шулай еракларга барып ирешүен тоеп һәм күреп каршылый.

Ренат Харисны поэзиянең йөрәк эчкәрәк яшеренгән, акыл өскәрәк чыккан, фикер-

хис ягы өстенлек алган шигырьләре метафора белән катлауландырылган стиль юнәлеше вәкиле дип санарга була. Андый шигырь типларының структурасы да, укучыга тәэсир итүе дә үзгәрәк.

Шагыйрь үзе дә, шигырьләрендәге туйралары да уйлы. Ул фикерен үтемле итеп, уйландырырлык итеп әйтергә омтыла. Мондый шигырьләр үзләре төрле-төрле. Кайберләре — үтә җыйнаклар, фәлсәфи фикергә тартымнар. Баштарак чорда язылганнарында Дәрдмәнд поэтикасының тәэсире ачык сизелә. Әйтик:

> **Табып ләззәт уенда һәм куенда,**
> **Калды ул гомер елгасы буенда.**
> **Тарих ансыз китте...**

Соңрак ул әлеге иярүдән читләшеп, хикмәтле фикерне үз аһәңендә халыкчан итеп яңгыратуга иреште:

> **Аякны гына чага елан —**
> **Елан янына баш егыла.**

Икенче берләре сүзгә саран булсалар да, ул кадәр үк кыска түгелләр. Мондый шигырьләрдә фикер публицистик-рационалистик характер да алып куя. Менә шундыйларның берсе:

> **Галилей хаклы булганда**
> **Бөтен башка кешеләр, халыклар, илләр**
> **Хаксыз булган.**
> **Хак сүз туганчыга хәтле**
> **Җир турында шулай да нахак сүз туган...**
> **Кеше**
> **Җиргә сеңгән нахак сүзне**
> **Бруно, Пушкин, Җәлил булып**
> **Каны белән юа.**

Биредә шигырь структурасын логик фикерләү — тарихи чорларны, фактларны һәм шәхесләрне янәшә куеп, чагыштырып карау, аларның аерымлыгын табып, хөкем-нәтиҗә чыгару билгели. Шагыйрьнең шәхси «мин»е читтәрәк — шигырьдә турыдан-туры күренми, әмма позициясе ачык — ул гаделлек, хак сүз ягында. Үткенлек белән фикернең әнә шулай афористик гомумиләштерелеп әйтелүенә игътибарны туплау шигырьдән хиснең кысрыкланууын да өлешчә аклый, әмма барыбер аклап ук бетерә алмый: шагыйрь мөнәсәбәте, кичерешне тагы да ачыграк, тулырак сизелсә, андагы акыл өстенлеге үзенең өстенлеген тагы да көчәйтә генә төшәр иде.

Шәхси «мине» турыдан-туры күренеп тормаган шигырьләреннән тыш Р. Харисның акылга хис активрак кушылган, автор кичерешне ачыктан-ачык сизелеп торган шигырьләре дә байтак, һәм аларның мондый типтагылары — акыл белән хиснең тыгызрак кушылуына нигезләнгәннәре елдан-ел арта бара. Андыйлары аның миңа җылырак та, тәэсирлерәк тә тоела.

> **Йөрәк кыса кайчак, тән кысыла...**
> **һавадандыр, диләр, һавадандыр...**
> **Урасы ашлыкны черетә яңгыр,**
> **һавадандыр —**
> **һава җирдәге бар нәрсәгә кагылып тора,**
> **Ил җирләрне минем белән тоташтыра,**
> **Кипрны да, Кытайны да, Ливанны да,**
> **Чилидагы канга баткан диварны да,**
> **Танкларның җирне бозып даңгырдавын...**
> **Тән кысыла... Йөрәк кыса... һавадандыр...**

Мондый шигырьләрдә шагыйрьнең кичереше тулырак ачыла, тарихи конкретлык та ачыграк.

Р. Харисның фикер шигърияте әнә шулай бер төрле юнәлештә, бер төрле рухта, бер төрле калыпта гына түгел, төрлечә ачыла. Ул фикернең көтелмәгәнчә шигъри яңгыравына ирешү юлында иң актив эзләнүчеләрнең берсе. Моның өчен ул, мәсәлән, әйбер-күренешләр арасындагы көтелмәгән мөнәсәбәтләрне табуга еш таяна, шул «көтелмәгәнлек» һәм әйтелеп бетмәгәнлек укучы фикерен уйланырга этәрә:

**Быелгы җәй елак хатын кебек —**
**Иңгә асылынып һәр көн елый.**
**Еласа да күзе матур!**
**Былтыр аның күзе коры иде.**
**Ләкин кылый —**
**Безнең бәхеткә кырын карады...**

Шуңа да парадокслар, метаморфозалар аның поэтикасында шактый урын ала. Шагыйрь диалог алымына да, халыктагы гыйбрәтле хикәятләргә дә еш мөрәҗәгать итә.

Р. Харисның байтак шигырьләрендә акыл үткенрәк һәм хәрәкәтчәнрәк, хис тыенкырак ачыла. Андый тип шигырьләр дә яшәргә хаклы. Аларны поэзиянең уги баласы итеп кыерсыту шигъриятнең үзен кыерсыту булыр иде. Хикмәтле сүз әйтү поэтикасына, акыл шигъриятенә өстенлек биргән стиль юнәлеше хәзер шактый нык тамыр җибәрде. Әмма аның үсү һәм киңәю юлында авырлыклары, аны үзләштерүдә кыенлыклар да юк түгел. Р. Харисның да аерым шигырьләрендә фикернең ачыклыгы һәм үзенчәлекле яңалыгы җитми.

Шигырьдә кыскалыкка, фикердәге тыгызлыкка омтылу шигъриятне югалту бәрабәренә булырга тиеш түгел. Ә бездә кайвакыт кыскалык үзмаксатка әверелеп китә. Шуның нәтиҗәсендә тегеләй дә, болай да аңларга урын кала торган, яисә әчтәлеге шактый ук «зәңгәр томан» белән өретелгән парчалар туа. Шундыйларның кайберләрен Р. Хариста да очратырга мөмкин:

**Бөек халык бәхәсләшми,**
**Бөек халык юл саба,**
**Мылтык көпшәсендә**
**Ядрә белән очрашмаска**
**Җай таба.**

Шигырьдәге сүзләр аны ирониял мәгънәдә түгел дип уйларга нигез бирә. Әмма фикер аерым очракта — тынычлык өчен көрәшкә бәйле, рәвештә — үзен акласа да, аның гомумиләштерелеп алынуы каршы сораулар уята: бөек халык бәхәсләшүдән, ядрә белән очрашудан курыкмый бит ул, ди укучы һәм шагыйрьнең игътибарын ил тарихына юнәлтә. Халкыбыз гел мылтык көпшәсе белән очрашып (?) торган, без вак халык мени, ди?.. Фикернең үткен әйтелүе белән мавыгып, аның берьяклы яңгыравыннан да сакланырга кирәк,— мондый тип шигырьләрдә шагыйрьне шундый куркыныч һәр чак сагалап тора. Икенче бер куркыныч та бар. Кайбер шигырьләрендә, автор, кыскалык белән, я катлаулы метафоралар белән артык нык мавыкканда, акылның өстенлеге хисне шигырь мәйданыннан бөтенләй кысып чыгара,— тыенкы хис тыелган хискә әверелә. Шигырьнең тәэсир итү көчен кимәтә торган шундый якларына Р. Харис киләчәктә игътибарын көчәйтә төшәр дип ышанырга кирәк.

Поэзиядә фикер һәм хис катламыннан тыш шундый ук әһәмиятле роль уйнаган, шулай ук бәхәсләр уяткан сурәтлелек дигән төшенчә бар. Бу өч төшенчә бер-берсеннән аерылгысыз яши һәм укучыга бер бөтен хәлдә шигырь булып ирешә. Әмма шигъри иҗат процессында һәм теориядә сүз белән сурәт тудыруның үзен аерым гына алып йөртәләр. Р. Харис поэзиясенең бу ягына аерата игътибарлы. Элегрәк — сугыштан соңгы елларда поэзиядә шактый нык тамыр җибәргән декларативлык һәм

коры риторика белән мавыгуга ул иҗатының баштагы чорында ук каршы чыккан иде. Алардан качу юлын Р. Харис шигырьне метафорик сурәтләр, үтә шартлы фантастик алымнар белән баетуда һәм яңартуда, шигырьнең ассоциатив тирәнлекләрен яңарак алымнар ярдәмендә тәрлеләндерүдә, сүзнең җегәрен арттыруда күрде. Дөресен әйтергә кирәк, бу юлда ул иң тырышып эзләнүчеләрнең берсе булды. Шуңа да күзгә ташланырлык уңышлары беренче җыентыгы «Кайтаваз»да ук күренде. «Дәрдмәндкә» дигән циклдагы байтак шигырьләрне мисалга китерергә мөмкин булыр иде. Менә «Кибән» исемле лирик этюд.

Яз көне кибән-кибән болыт
Җиргә сеңгән.
Көз көне җирдә шытып чыккан
Болыт-болыт кибән.

Шагыйрьнең Дәрдмәнд поэтикасына игътибарын юнәлтүе поэзия өчен шактый гыйбрәтле күренеш булды. Аңа кадәр Дәрдмәнд шигърият дөньясында модалы исем түгел иде. Рус поэзиясендә Фет, Тютчев, Блок белән дә шундыйрак бер хәл булып алуы мәгълүм: алар тарихта — үз чорларында калган кебек тоелды. 60—70 нче елларда бу шагыйрьләрнең иҗаты кабат бер яшәрү кичерде. Укучылар кабат аларны яраткан шагыйрьләре итеп кабул иттеләр. Дәрдмәнд тә хәзерге заман укучысына якынайды. Дәрдмәндкә назирәләр язу яшь шагыйрь өчен олы бер шигъри мәктәп булды. Дәрдмәнд аны сүзнең җегәрен һәм аһәңен тоярга, сурәтнең халыкчан гадилегенә ирешергә өйрәтә. Шунысы кызык: «Кайтаваз»дагы «Дәрдмәндкә» циклы башка шигырьләрдән үзенең нәкъ әнә шундый сыйфатлары белән аерылып тора. «Метаморфоза», «Иркәмә» кебек циклларда яшь шагыйрьнең башка остазларына да иярүе үзен нык кына сиздерә: Р. Харис сурәтләрдә оригинальлеккә омтыла, метафораларны берсе янына икенчесен тыгызлап өя. Мәсәлән:

... Эрисем килде — сулуым бозга
әверелде үпкәмдә.
Кичер, иркәм, озак эредем —
суык сүзем
йөрәгемнән кояшымны
сөйрәп чыгып киткәнгә.

Күренеп тора, яшь шагыйрьнең метафораларны яңартуда тырышлыгы бар, әмма сурәтне катлауландыру белән мавыгуы шигырьдәге драматик тойгының көчен киметүгә китергән. Шигъри телнең авырлыгы турында шагыйрьнең беренче җыентыклары уңае белән басылган мәкалә-рецензияләрдә дә әйтелә. Р. Харис тәнкыйть фикеренә колак салып, сурәтнең яңалыгыннан һәм катлаулыгыннан качмастан, аның ачыклыгына, эчке мәгънәсенең шигырь логикасында калкурак чагылуына, укучы аңына якыная төшүенә игътибар итте. Ачыклык, күргәзмәлелек көчәйде, рәссамнарча уйлау — эш итү осталыгы тагы да тулырак ачылып китте. Бу хасиятен — төсләр, детальләр, күренешләр белән уйларга ятратуын аның баштагы шигырьләрендә дә чамаларга була иде. Әмма әле ул аның индивидуаль сурәтле фикерләвенең ачык чагылышы булып ук күренми иде. Хәзерге Р. Хариста рәссамлык стихиясе башка шагыйрьләргә караганда да, үзенең баштагы чорына караганда да көчлерәк ачыла. Бу аның шәхси табигате белән дә нык бәйле булса кирәк. Рәсем Р. Харисның — кече яшьтән яраткан сәнгать төрләреннән берсе. Ул әле хәзер дә буш вакытларында рәсем ясау, һәртөрле тамырлардан, ботаклардан сыннар, шүрәлеләр «кисү» белән мавыга. Иҗатында да әлеге теманың урын алуы («Рәссам» поэмасы, «Пумала»; «Сагыш» шигырьләре), рәссамнарның хезмәте турында белеп һәм яратып язуы очраклы түгелдер. Шигырьнең сурәтләү тукымасында төс бизәкләрен актив куллануында да Р. Харисның, әлеге дә баягы, җанындагы рәссамлык хиреслеге чагыла булса кирәк. Аның шундый шигырьләре дә бар, ул аларда табигатьне дә, кешеләрне дә, музыканы да, аларның кылган гамәлләрен дә, уйларын да төсле итеп күрә. Менә кеше уенның төсле ачылышы:

Төссез уйдан томан калка,
Зәңгәре — хисләрне яңарта,
Кара уем җирдә ята,
Ә ак уем чәчәк ата.

Өзектән күренгәнчә, шагыйрь төсләрне куллануда аларның халыкта беркетелгән символик эчтәлегенә таяна: ак төс — шатлыкны, пакьлекне, бәхетне, кара — бәхетсезлекне, яманлыкны, яшел — яшәрүне, тереклекне аңлата. «Кар рәсем», «Кышкы вокзал», «Кочак тулы чәчәк», «Сары камыш» кебек шигырьләренең поэтикасы әнә шушы халыкчан табигатьле төсләр символикасына, төсләр контрастына нигезләнгән. Бер шигырьдә ул фәлсәфи планда, икенчесендә — публицистик рухта, өченчесендә — табигать күренеше рәвешендә күренә. Дүртенчесендә — түбәндәгечә наянрак сөйләшү — диалог рәвешендә ачыла:

— Ак болыттан нәрсә ясар идең,
тотып бирсәм!
— Икебезгә ап-ак тирмә!
— Карасыннан ни ясарсың
тотып бирсәм!
— Килсә карарбыз. Тотып бирмә!

Р. Харис турында язылган тәнкыйть мәкаләләрендә: «Шагыйрь үзенең эзләнүләрендә, поэтикасында китаби традицияләргә таяна»,— дигән фикер кабатлана. Әлеге фикердә дөреслек булуын инкарь итмәстән, мин шагыйрьнең поэтикасы шундый ук ныклы җепләр белән халык иҗатына барып тоташуын да куәтләр идем. Шагыйрь халыкта кулланылган төсле сурәтләрнең тагы да яңарак мәгънәви-эмоциональ төсмерләрен эзли. Сары төсне куллануда да, мәсәлән, шагыйрьнең традициягә таянуын һәм аны шул нигездә үстерүен ачык күрергә була: сары чәчәк, сары камыш, сары яфрак сурәтләре аңарда да сагышны яки тормыш сүнүен аңлатып киләләр. Бер шигырендә исә сары сурәте яңарак контекстта ачыла:

Коела яфрак... каңгылдаша кыр казлары...
Яфрак, яфрак коела димсез!
Шул казларның
Гомер үткәнгә уфтанып
Саргаешкан авазлары
Коела аяк астына...

Авазны төс белән белгертеп буламыни? Була икән. Халык сөйләмендә дә бит «яшел тавыш» дигән гыйбарәне ишеткәнебез бар. Тик моңача «саргаешкан авазлар» дигән сүзләрнең янәшә килүен очраткан юк иде. Бирелә ул яңа төсмерләре белән һәркемгә дә аңлаешлы булган катлаулы бер метафора рәвешендә ачылып китә.

Р. Харисның мәгънәле шигъри детальләрне, тормышның һәр төрле күренешләрен тасвирларга һәвәслегендә дә, шул күренеш-этюдларның фәлсәфи-шигъри икенче мәгънәләрен күрсәтергә омтылуында да рәссамлыкка бик тә якын булган гомуми тенденция ята. Менә «Уйлы туйра» шигыре:

Туры туйра башын чөйгән,
Башына болыт, тамырына туфрак тигән.

Күренеш-сурәт гади табигать күренешеннән башлана һәм шуның белән тәмамлана да:

Инде туйра — олы имән.
Башы күк утына, тамыры җир утына тигән.

Аңлыйсыздыр, шигырьнең эчтәлеге иман турында түгел — ул чара-сурәт кенә. Шагыйрь фикерне күренеш-пейзаж — көнкүреш планында алып бара да, тормыш, яшәеш, фәлсәфә планына күчереп куя. Иманнең поэзиядә ныклык символы, озын гомерлек билгесе, тарих юлдашы буларак ачылганын күргәнебез бар иде. Бу шигырьдә ул яңарак хасияттә ачыла — ул символ түгел, әмма шундый ук күчерелмә мәгънә уята торган вазифасы бар — күренеш фәлсәфи фикер уята торган шигъри метафора булып әверелә. Р. Харис үтә шартлы, фантастик ситуацияләрне дә фикер-хисен җиткерү өчен мул файдалана. «Ядрә» шигырендә, мәсәлән, һавадагы үрдәкне атып төшергән ядрә телгә килә һәм сөйли.

Р. Харис сурәтлелек тудыруда, аның эчке мәгънәви мәйданын киңәйтүдә шигырь эчендәге бәйләнешләрне һәм мөмкинлекләрне генә түгел, шигырьдән тыш — шигырьләр арасындагы бәйләнешләрне дә файдалана. «Дәрдмәнд» бәйләме бу юлда беренче тәҗрибә булды. Әмма биредә әле шигырьләрнең үзара бәйләнешләре йомшак, берсен-берсе тирәнәйтергә булышмыйлар. Дәрдмәндтән алынган шигъри сүзләрне — цитатаны яңача кулланулары белән генә бер-берсенә берләшәләр. «Синең йөрәгең тибә» циклы бу юлда — бәйләнешләрне ныгытуда алга бер адым булды. Әмма арада иң уңышлысы итеп мин «Яралар» һәм «Бизәк» бәйләмнәрен санар идем. Тирән фикер һәм заман сулышы белән сугарылган, сурәтлелеге яңача ачылган бу цикллар шагыйрьнең генә түгел, хәзерге татар поэзиясенең уңышы санала иде.

Сурәтлелекне яңартуда һәм баетуда Р. Харис күп төрле алымнардан, чаралардан һәм мөмкинлекләрдән файдалана. Ул шигырь строфасын да, интонациясен дә фикер-хискә яраштырып, һәр шигырьнең үзенә генә хас үзенчәлекле интонацион-ритмик рәсемен табарга тырыша, шул юнәлештә дә актив эзләнә. Шигырь гармониясен үзенчә тудырудагы эзләнүләре дә хуплауга лаек, бу өлкәдә дә аның уңышлы һәм гыйбрәтле табышлары бар.

Шагыйрь стилендә 70 нче елларда яңарак тенденцияләр күренә башлавын да әйтмичә ярамастыр. Берсе аның — кайчандыр үзе үк каршы чыккан тасвирый хикәяләүгә нигезләнгән озын әсәрләр — шигырьләр, хикәяләр, ораторияләр. Баштарак «Сабантуй» язылa — биредә матур гына тотып алынган күренешләр, шигъри детальләр бар барын, бәйрәм аһәңе дә сизелә. Әмма әсәрнең без нйләшкән һәм көткән икенче катламы — тирәнрәк яткан фикер-хис катламы йомшак. Хикәятләрендә дә шул як әле үзен нык сиздертә.

Р. Харис иҗатындагы икенче бер парадоксаль тенденция — ул шулай ук үз вакытында — 60 нчы елларда үзе каршы чыккан декларативлыкка һәм риторикага урын бирә башлавы. Тасвирый хикәяләүне хуш күрүе — анысы аңлашыла һәм табигый, зарури үсү күренеше буларак кабул ителә. Ә менә соңгысы — шигырь, җыр төрләренә декларативлыкны хуҗа итеп кертеп утыртуы — аңлашылып бетми. Бу аеруча аның музыка белән бәйле әсәрләрендә — «КамАЗдашлар», «Ил улы — Ямашев» кебек җырларында, ораторияләрендә, кантаталарында күзгә ташлана. Җырда политик сулышлы олы темага килеп кергәч, шагыйрьнең без белгән гадәттәге образлы теле кәрмәкләнеп кала, ул үзенчә түгел, кемгәдер ияреп киткәндәй була, гомумирәк сүзләр сөйли башлый, сүзнең җегәрлеге югала. Оратория кебек катлаулы жанрда бәлкем, риториканың азмы-күпме урын алуы табигыйдер дә, ә менә җырда һәм шигырьләрдә декларатив сөйләшүнең чамасы турында шагыйрь ныклабрак уйланырга тиеш.

Лирик парчалардан, җырлардан соң Р. Харис шигъри циклларны, оратория либреттоларын үзләштерде. Шигъри фикерне нигезләбрәк һәм тулырак ачарга, чорны һәм тарихи шәхесләрне калкурак күрсәтергә омтылу аны табигый рәвештә поэма жанрына мөрәҗәгать итәргә этәрде. Татар поэзиясендә беренчеләрдән булып ул гражданнар сугышы геройлары Мулланур Вахитов һәм Камил Якуб турында поэмалар иҗат итте («Мулланур», «Камил Якуб»). Икесе дә бер үк тарихи чорга һәм тарихи шәхесләргә багышланган булсалар да, алар үзләренең шигъри фикерләре — пафослары, сюжет корылышлары, тасвирлау алымнары буенча бер-берсеннән бик нык аерылып торалар. «Мулланур»да сүз революционерның дошманнар тарафыннан үтерелсә дә, җаны халык күңелендә яшәве — үлемсезлеге турында бара. Бу — әсәрнең төп пафосы:

... Җанын җилгә биргән сулыш үлеме!
Без бит җирдә җилләр сулап киләбез.
... Җанын җиргә биргән ал кан череме!
Каннан икмәк шытканга бит торебез.

Шагыйрь сюжетта шартлылыкны мул файдалана. Һәртөрле хыялый күренешләргә киң урын бирә. Анда аркан монологы да бар, су да телгә килә. Кырык палачның Мулланур йөрәген эзләп таба алмау күренеше дә бар... Гомумиләштерүдә шартлылыкка таянуның, әлбәттә, отышлы булуы шөбһәсез. Әмма әлеге поэма шушы шартлылык белән артыграк мавыгу нәтиҗәсендә тарихи конкретлыкның йомшаграк бирелүен, Мулланур образының реаль сызык-бизәкләрдә ачылуын әйтергә кирәк.

«Камил Якуб» поэмасы чынбарлыкны тормышка охшаш рәвешендә, реалистик дәреслектә сурәтләве белән шагыйрьнең тасвирый хикәяләү юнәлешендә иҗат иткән уңышлы адымы булды. Биредә вакыйгаларны һәм драматизмны шагыйрь «Мулланур»дагыча уйлап чыгармый, ә тормышның үзеннән ала, шул чорның сикәлтәле юлларында туган агышыннан эзли. Әсәренең шигъри фикере дә уйландыра торган: нәтиҗәнең нигезне чайкавы, үзе тудырганның үзен үтерүе мәсьәләсе. Шушы фикер Камил Якуб үзе оештырган җиде меңле батальонның һәр төрле коткыларга бирелеп фетнә кузгатуын һәм фетнә вакытында Камилнең үтерелүен драматик киеренкелек белән сурәтләгәндә тәэсирле итеп ачыла.

«Җитмеш икенче елның икмәге» — Р. Харисның чираттагы поэмасы булды. Икмәк өчен табигать каршылыклары белән көрәш темасына язылган хәзерге заман турындагы әлеге әсәреннән соң ул «Рәссам» поэмасында кабат тарихка мөрәҗәгать итте.

Поэма Казанның атаклы художнигы, рус рәсем сәнгате тарихында тирән эз калдырган Н. И. Фешин истәлегенә багышланган. Әсәрдә сүз аның «Гүзәл тән», «Сугым сарае», «Яңгыр боткасы» исемле картиналарының язылу процессы турында бара. Поэманың рәсем исемнәре белән аталган өч бүлеге — әлеге өч рәсемнең язылу-туу тарихы турында сөйли, шул рәсемнәргә бәйләп XX гасыр башында яшәгән художникның катлаулы эчке дөньясына алып керә. Бу поэма — шагыйрьнең тасвирый хикәяләү юлындагы әсәрләренең иң уңышлысы. Биредә шагыйрьнең сүз белән рәсемләү буенча да, аерым күренеш-детальләрнең эчке фәлсәфи мәгънәләрен ача алуы ягыннан да осталыгы тагы да камилләшә төшүе ачык күренә. Образны социаль тип буларак кына түгел, ә характер — билгеле бер профессия вәкиле итеп ачу ягыннан да шагыйрь уңышка ирешә алган. Әмма ул конкрет тарихи шәхес образын иҗат итүгә караганда иҗат кешесенең — рәссамның гомумиләштерелгән образын тудырырга, художникның конкрет әсәрләренә яшеренгән гомумкешелек тойгыларын ачарга, XX гасыр башы шартларында туган әсәрләренең бүгенге заманга бәйле мәгънәви — фәлсәфи эчтәлеген һәм кешелек тойгыларының уртаклыгын, даимилеген, дәвамлылыгын күрсәтергә омтыла. Рәссам, сәнгать, чынбарлык мөнәсәбәтләренең гаять тә каршылыклы чагылышы өч рәсемнең иҗат ителү процессы аша ачыла.

Поэманың «Гүзәл тән» бүлегендә курсистка кызның ялангач тәнен рәсемгә төшерүгә бәйләп рәссамның күңелендә туган уйлары, кичерешләре — иҗат психологиясе тирән ачылуын әйтергә кирәк. Художник бөтенләе белән бирелеп, хыял дөньясында гизеп рәсем ясый. Ул — чын иҗатчы. Менә ул киндеренә беренче буяуларын сала — маңгай, битләр, коңгырт чәчләр пайда була:

һәм пумала адаштырды
үз хуҗасын шул чәчләрдә...
Шул чәчләрдә... чәчәкләрдә... аланнарда...

Рәссам үзе тудырган сихри дөньяда әнә шулай шатлана-шатлана адашып йөри. Икенче яктан, шагыйрь Рәссам иҗатын дөньяның могҗизалы күренеше буларак күрсәтә. Төсләр, буяулар белән аның кулы могҗиза тудыруын — тормыштагы матурлыкны тередән дә тере итеп гәүдәләндерүен ул сүзләр белән тәэсирле итеп сурәтли алган. Монысы инде шагыйрь осталыгы.

**Сызды рәссам алсу җәя. Уксыз җәя.**
**Утлы җәя — өске иреннәр.**
**Тыгыз, сутлы, йомшак кереш —**
**асгы иреннәр.**
**Уксыз — угы очкан. Утлы, татлы.**

Әмма иҗатчы белән чынбарлык мөнәсәбәте гаять тә катлаулы булып чыга. Өндәге матур кыз тәненнән ул илаһи пакьлек символы булырлык образ тудырса, шул образның реаль өлгесе — курсистка кыз икенче төнне үк аның үзен «гөнаһка» этәрә. Гөнаһлы төннән соң — «үзенең шашып-шашып үпкән сурәтен рәссам елый-елый тураклап ата». Әлеге фаҗигале хәлне рәссам ни өчен эшли соң? Кызга ачуланыпмы? Алай дисәк, кыз бит үзе сәнгатьтәге матурлык алдында югалып, рәссам кодрәте янында көчсез булып кала, рәссам янына үзе килә. Минемчә, сүз кызның «гөнаһысы» турында баруга караганда, рәссамның «гөнаһысы» турында бара булса кирәк. Үзе тудырган матурлыкның, илаһи пакьлекнең, идеалының шул рәсем янында ук юкка чыгуы, идеалындагы илаһи пакьлеккә үзенең кер төшерүе аны фаҗигагә этәрә. Идеаль дөнья реаль дөньяда шунда ук юкка чыга — бу хәлне рәссам үзгәртә алмаса да, үзенең протестын белгертмичә кала алмый. Әмма бу протест аңарда әле бу дәвердә бик тә наив һәм акылсызрак рәвештә (үзе ясаган рәсемне тураклау) чагыла.

Ә бит рәссамның протест белгертү өчен гаять тә көчле коралы бар — ул төсләр, буяулар аша матурлык дөньясын гына түгел, шул матурлыкны юкка чыгарган кырыс, вәхши чынбарлыкны да шыксыз итеп сурәтли ала, үзенең хисләрен белгертә ала. «Сугым сарае» рәсемендә ул әнә шулай эшли дә. Бу рәсем — сугышка, сугыш тудырган вәхшәткә, чынбарлыкның аяусыз чынлыгына протест.

**Алмашынгач кеше аңы ерткыч аңы белән**
**Кушылды сугымчы каны үгез каны белән,**
**Кеше каны хайван каны белән...**
**... Аның остаханәсе бу!**
**Әллә сугым сараемы!**
**Әллә сугым серемено баткан,**
**Канын агызып яткан Европамы!**

Картинадагы вәхши күренеш — сугымчыларның канлы куллары, үгез суйган чалгы пычаклары, тиресе туналган, бу бөркегән дымлы түшләр, тутыгып беткән тимер чөйгә эленгән баһадир үгез йөрәге — болар барысы да туры мәгънәсендә генә түгел, икенче планда — символик планда да — «сугышлы Европа» буларак та кабул ителәләр. «Сугым сарае» беренче империалистик сугышны хәтерләткән күренеш булып кына түгел, ә гомумән Җирдәге вәхшилекне, кешесезлекне, кансызлыкны гәүдәләндергән символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Никадәрле күңелләрдәге пычракларны, канга сусауларны юасы бар әле! Җирнең тәнендә әле дә «сугым сарайлары» аз мени? — Шигъри фикернең логикасын табигый рәвештә шагыйрь әнә шулай хәзерге заманнарга да бора. Бу ягын, әлбәттә, бүгенге көнгә бәйләп көчәйтә төшкәндә дә әйбәт булыр иде.

Рәссамның өченче рәсеме — «Яңгыр боткасы». Шуның язылу тарихын һәм символик мәгънәсен поэманың өченче бүлегендә ачыла.

Рәссам «Сугым сарае» рәсемен ясаганнан соң, мунчада юынып, күңелендә утырган авыр юшкыннан бераз котылгандай була. Әмма бит әле халык язмышы бар.— Җир өч ел буе сугым сарае булып килә.

**Сәясәтләр бугазында канлы төер —**
**Йотып җибәрергә йотым су кирәк!**

Тормышның бүгенгесеннән тую, аның үзгәрәсен көтү һәм теләү Җирне күңелдә булса да бәхетле итеп күрү теләге уята. Шушы омтылыш рәссамны шифалы яңгыр сюжетына алып килә. Дөньяны, җирне ул үзе теләгәнчә, барлык кешеләр теләгәнчә

чиста, пакь итеп ясый. Яңгыр дары мичкәләрен җебетә-җебетә, сүздән — яман сүзне, җаннан — кара җанны юа-юа коя... Хыялдагы сулар рәсемне бөтенләй үзгәртә:

**Менә ул бәхетле, пакь, чиста дөнья!**
**Менә, менә!..**
**Кулы нәрсәгәдер килеп бәрелде...**
**Остаханә генә икән ләбаса бу, киндер генә...**

Хыял белән реаль тормышның, художник белән чынбарлыкның каршылыгы дәвам итә. Шушы каршылык рәссамның күңелен «утлы күз яшьләренә коендыра». Шул ук вакытта шагыйрь «якын офыкларда, илләр, тәхетләр өстендә яшенле яңгыр» җыелуын әйтеп, Октябрь революциясе якынлашуына ишарәләп куя.

Р. Харисның поэмалар иҗат итү тәҗрибәсе аның бу өлкәдә дә уңышлы иҗат итә алуын раслый. Күрәсең, шигърият өчен вакыты белән һәм урыны белән хикәяләп, озынрак язу да кирәк икән. Шундый фикергә ышануы Р. Харисны киләчәктә эпик колачлы драматик рухлы, тирән фәлсәфәле масштаблы әсәрләр язуга китерүе дә бик ихтимал.

Р. Харисның хәзер энергиясе ташып торган, дәүләт хезмәтендә һәм иҗатта җигелеп эшләгән җегәрле чагы. Иҗатына гомуми күз ташлау шуны күрсәтә: ул поэзиянең төп юлыннан атлый, халык һәм ил сулышы белән яшәргә, заман адымыннан һәм ритмыннан артка калмаска омтыла. Шигырьгә дә ул дәүләт хезмәте кебек җаваплылык белән карый, «кеше кешегә кояш булсын» дигән изге теләктән чыгып эш итә. Ул поэзиянең тематикасын, жанр чикләрен, алымнарын төрләндерү буенча туктаусыз эзләнә һәм тормышның агышы турында уйлана. «Яшим дисәң» шигырендә лирик герой шундый бер эксперимент ясап караган иде — күкрәгеннән үз йөрәген ала да ул Мәҗнүн йөрәген куя. Ни хикмәт: шуннан соң күзе дә — Мәҗнүнчә! — тик кызларның матур иреннәрен генә күрә башлый, куллары да нечкә бил генә эзли. Ә тормыш гаять катлаулы булып чыга. Шагыйрь кабат Мәҗнүн йөрәген үз йөрәге белән алыштырырга мәҗбүр була һәм, безнеңчә дә, дөрес эшли. Тормышны тирән итеп аңлау һәм киңрәк иңләү өчен Мәҗнүн йөрәге генә җитми. Р. Харисның шигырьләрендә дә аның үз йөрәге типсен, үз акылы үзенчә фикер йөртсен, куллары нечкә билләрен дә кочсын, колачы җир шарын да иңләсен, киеме дә үз киеме, тавышы да үзенеке булсын. Безгә үз йөрәге типкән Ренат Харис кирәк, безгә шул шагыйрь кадерле.

# ҖЫР ХӘЗИНӘБЕЗ

Халык арасында киң таралган җырларны әледән-әле махсус җыентыклар итеп бастырып чыгару — Татарстан китап нәшриятында күптәннән килә торган матур традицияләрнең берсе. Башта алар «Халык җырлый» дигән исем белән дөнья күреп килделәр. Ә 1972 елда, шушы сериянең дәвамы төсендә, 100 мең данә белән «Җырлар китабы» басылып чыкты. Һәм бик тиз арада таралып бетте. Соңгы елларда йөзләрчә яңа җырлар туып, алар рухи дөньябызның күркәм бер казанышына әйләнде. Шуларны да үз эченә алган яңа җыентыкны укучылар инде байтактан көтәләр иде. Ниһаять, «Җырлыйк әле» дигән самими генә исемле шундый китап (төзүчесе Илбарис Надиров) 1980 елда чыкты. Анда барысы 550 җыр тексты бирелгән. Әлбәттә, аларның зур өлеше — 1972 елгы җыентыкта басылган һәм вакыт сынавын уңышлы үткән әсәрләр. Әмма соңгы вакытларда иҗат ителгән җырларны туплауга да зур әһәмият бирелгәнлеге куандыра.

Җырлар ике зур тематик төркемгә туплап бирелгәннәр. Башта шуларның «Иҗтимагый-лирик җырлар» дип исемләнгән беренче бүлегенә күз салыйк.

Яхшы хәтерлисездер, Л. И. Брежневнең «Кече җир» китабында җырның кешеләргә искиткеч зур тәэсир көчен күрсәтә торган гыйбрәтле бер эпизод тасвирлана. «Рица» сейнеры Цемес бухтасында минага эләгә. Көчле шартлау сугышчыларны салкын диңгезгә алып ташлый. Аларны зур кыенлыклар белән десант мотоботына күтәрәләр «һәм шушындый фаҗигале шартларда, шушы атыш һәм гарасат эчендә кинәт җыр башланды...— дип яза автор.— Бу җыр Кече җирдә чыгарылган иде, анда менә хәзер шушы боттагылар кебек корыч ихтыярлы һәм көчле рухлы сугышчылар турында әйтелә. Мин ул җырны электән үк белә идем, хәзер исә беренче тапкыр аны шунда ишеткәнмендер кебек тоела...

Әкренләп кешеләр башларын күтәрә башлады, ятканнар торып утырды, утырганнар аягүрә басты, кайсыдыр инде җырга да кушылды. Әле яңа гына кичерелгән тетрәнүләргә карамастан, алар үзләрендә ышаныч тойдылар, сугышчан формага килделәр».

Әйе, канлы көрәш кырындамы, зур төзелеш мәйданындамы — кайда гына булмасын, җыр кешеләргә һәрвакыт какшамас ныклык бирә, аларны якты идеаллар белән канатландыра. Җәмгыятебезнең рухи тормышында, коммунизм төзүчеләрнең дөньяга карашын, югары әхлакый сыйфатларын формалаштыруда җыр сәнгате гаять тәэсирле чара ул. Китапта тирән патриотизм һәм гражданлык хисе белән сугарылган иҗтимагый-лирик эчтәлекле әсәрләргә зур урын бирелүе чын күңелдән хуплауга лаек. Беренче чиратта, болар — партия һәм Ленин, туган ил, туган як турындагы җырлар. Биредә музыкаль Ленинианабызның беренче карлыгачы булган «Ай, дуслар!» исемле халык җыры да, инде күптәннән киң танылган, җыр хәзинәбезнең алтын фондына кергән «Күңелем Ленин белән сөйләшә» (С. Хәким, Х. Вәлиуллин), «Гасырлар кешесе» (М. Мазунов, Б. Мулюков), «Туган җирем — Татарстан» (Г. Зәйнашева, А. Ключарев), «Казан» (Х. Вахит, М. Мозаффаров) кебек җырлар да бар. Соңгы елларда иҗат ителгән уңышлы әсәрләрнең бүгенге репертуарда шулай ук ныклы урын яулауларын билгеләп үтәргә кирәк.

Иҗтимагый-лирик җырларыбызның икенче төркемчәсе революцион көрәш, Ватанны саклау, тынычлык темасына багышланган. Бу тема безгә беренче башлап халыкара һәм рус революцион поэзиясенең күренекле әсәрләрен тәрҗемә итү аша килеп керде. «Казан мөхбире» газетасында

язылганча, әле 1905 елда ук Алафузов заводы эшчеләре үзләренең митингларында большевиклардан «Марсельеза»ны татарчага тәрҗемә иттерүне сорап чыгалар. Аннары «Марсельеза», «Варшавянка», «Смело, товарищи, в ногу» кебек җырлар безнең халык иҗатында да революцион көрәш темасының ныклап тамыр җәюе өчен әйбәт җирлек булып хезмәт итә. Моны бигрәк тә солдат җырлары мисалында ачык күрергә мөмкин. Рус-япон һәм Беренче бөтендөнья сугышлары чорында туган «Порт-Артур», «Герман сугышы», «Газиз башым» кебек җырларда патшага һәм яшәп килгән стройга каршы протест торган саен ачыграк ишетелә. Ниһаять, шушы чорда халкыбызның атаклы революцион җырларыннан берсе «Бетсен патша, ясын тәхет, безгә сугыш кирәкми» дигән ялкынлы юллар халык массаларының самодержавиене бәреп төшерү һәм ирекле, тыныч тормыш яулау өчен көрәш девизы булып яңгырый. Китапта бу бүлекчә хаклы рәвештә нәкъ шушы «Күзге ачы җилләрдә», «Ком бураны» кебек халык җырлары белән ачыла. Революция һәм гражданнар сугышы чоры героикасын гәүдәләндергән җырлардан исә «Комсомолка Гөлсара» (Ә. Ерикәй, Җ. Фәйзи), «Ак каен» (Х. Туфан, М. Вәлиев), «Татбригада сугышчылары җыры» (М. Ногман, Р. Яхин), «Мулланур» (С. Хәким, Җ. Фәйзи) һ. б. әсәрләр бирелгән.

Революцион көрәш темасына табигый рәвештә Ватанны саклау, тынычлык өчен көрәш темасы килеп ялгана. Совет халкының Бөек Ватан сугышы чорындагы тиңдәшсез батырлыгын данлаучы әйбәт җырлар бик күп бездә. Һәм аларның яңаданяңалары иҗат ителеп тора. Композиторларыбызның (бигрәк тә Р. Яхинның) Муса Җәлилнең Моабит дәфтәрләрендәге шигырьләренә күп кенә яңа көйләр язуы бик шатлыклы күренеш.

Беренче бүлектә яңа бер мөһим тематик төркем бар. Анда — тыныч тормыш һәм иҗади хезмәткә, яшәү бәхетен, яшьлек ямен җырлауга багышланган әсәрләр. Бу җырларда заман сулышы, чор ритмы көчле яңгыраш тапкан. Иң беренче итеп бирелгән «Без кабызган утлар» (К. Тинчурин, С. Сәйдәшев) җыры, гүя, бөтен бүлекчәнең лейтмотивын билгели. Тормышка һәм хезмәткә мәхәббәт, яшәү мәгънәсен халык, ил бәхетендә күрү, киләчәккә нык ышаныч белән карау кебек сыйфатлар тәрбияләүдә мондый җырларның роле бик зур.

Ниһаять, беренче бүлектәге шаян җырлар турында бер-ике сүз. Анда без һәркайсыбызга күптәннән таныш булган «Өф-өф итеп» (Г. Афзал, Р. Еникеев), «Улым үземә охшаган» (Ә. Фәйзи, Ш. Мәҗитов), «Шалт, Мөхәммәтҗан» (Ш. Галиев, И. Хисамов), «Үрдәкләрем-дүдәкләрем» (Н. Арсланов, И. Хисамов) шикелле җырларны укып тагын бер елмаябыз. Әмма китапка юмористик эчтәлекле яңа әсәрләрнең бөтенләй диярлек өстәлмәве күңелдә ризасызлык хисе калдыра. Икенче бүлекнең дә шаян җырлар бүлекчәсендә шул ук хәл күзәтелә.

Кеше күңеленең иң саф һәм иң нечкә хис-тойгыларын чагылдыручы әсәрләр булганга, табигый ки, җырларның бик күбесе мәхәббәт темасына карыйлар. Китапның да яртысыннан күбрәк өлешен шундыйлар алып тора. «Мәхәббәт җырлары» дип аталган икенче бүлек, хронологик тәртип буенча килеп, халкыбызның ярату-сөюгә багышланган борынгы һәм яңа әсәрләре белән башлана. Халык иҗатындагы күркәм традицияләрне дәвам иттереп, тагын да баетып һәм үстереп, шагыйрьләр һәм композиторлар йөзләгән лирик җыр иҗат иттеләр. Үзәктә — Х. Туфан, Ә. Ерикәй, С. Хәким, Ш. Маннур, З. Нури, М. Ногман, Н. Арсланов, М. Хөсәен һ. б. сүзләренә язылган җырлар... Бу рухи хәзинә һаман байый, тулылана бара. Монда урта һәм яшь буын шагыйрьләрнең дә өлеше зур.

«Җырлыйк әле» җыентыгы белән танышканда, җыр репертуарыбызның тематикасы бай, идея-эстетик дәрәҗәсе югары булуы күренә. Бик куанычлы хәл: җыр өлкәсендә хәзер бездә шагыйрьләрнең зур армиясе эшләп килә. Әйтик, китаптагы җыр текстларын язуда барлыгы йөздән артык автор катнашкан. Җыр сүзләрен иҗат итүгә үзенчәлекле, сәләтле шагыйрьләрнең җәлеп ителүе, һичшиксез, җырларыбызда хис-фикер тирәнәюгә, аларның шигъри эшләнеш дәрәҗәсе күтәрелүгә китерде. Җыр хәзинәбездә үзенә хас моңы, стиле, аһәңе белән хәтердә калучы әсәрләр саны арта бара.

Китап уңышлы әсәрләрдән генә тормый. Аның битләрендә тема актуальлеге яисә көенең матурлыгы аркасында гына эләккән текстлар да очрап куйгалый. Атап әйткәндә, КамАЗга багышланган кайбер әсәрләр шундый тәэсир калдыра. Чорыбызның

бу бөек төзелешен халык һәм ил тормышы белән бәйләп, киң колачлы итеп, конкрет детальләр һәм шигъри образлар аша чагылдыру җитешми.

**Утлар уйный безнең яшь кулларда**
**Мәхәббәттән күңел очына.**
**Туа бәхет, хыял чынга аша,**
**Язмыш белән язмыш кушыла.**

Бу өзек җыр сәнгатебезне үстерүгә лаеклы өлеш керткән, дистәләгән матур җырлар иҗат итүдә катнашкан шагыйрь М. Хөсәеннең «Ак кала» дигән әсәреннән алынды. М. Газарның «Чаллыдан хат» җырында да сүзнең нинди төзелеш хакында барганлыгын «Чаллы», «КамАЗ» дигән исемнәрдән генә белә алабыз.

Шаблонга ияру, бер үк тема, фикер һәм сурәтләрнең кабатлануы җыр поэзиябездә шактый нык тамыр җибәргән кимчелекләрнең берсе. Берничә еллар элек ул аерым районнарга һәм авылларга атап чыгарылган җырларда үзен нык кына сиздереп алган иде. «Инкубатордан чыккан чебешләрне» хәтерләтүче бу җырларда «барлык районнарның да кызлары, егетләре бер-берләренә ике тамчы су кебек охшашлар — бер үк эпитетлар, чагыштырулар, сыйфатламалар... Кайбер җырлар өчен эпитетлар гына түгел, шигырь юллары да уртак. Мәсәлән, «Саба» җырындагы:

**Диңгез кебек дулкынланып**
**Кырда чайкала иген, —**

тезмәсе «Ямьле безнең Минзәләбез» җырында:

**Диңгез кебек дулкынлана**
**Киң басуларда иген,—**

дип бирелгән». Бу бик хаклы тәнкыйть сүзләрен без И. Надировның үз мәкаләсеннән алдык («Ил яшәве — җыр белән», «Казан утлары» журналы, 1976, 1 сан). Яңа җыр җыентыгы төзегәндә ул чыннан да андый җырларның санын бермә-бер киметкән. Ләкин иләкнең тагын да нечкәрәген алганда да ярыйсы булган икән. Юкса «Саба» һәм «Ямьле безнең Минзәләбез» җырларының китапка кабат килеп керүләре аңлашылып бетми. Өстәвенә башка төрле кабатланулар да күренә. Анда, мәсәлән, соңарган мәхәббәт турындагы җырлар күпкәрәк киткән шикелле. Г. Зәйнашева: «Моңарчы соң кайда йөрдең син?..» Н. Дәүли: «Син кайда идең, кайларда йөрдең?..» И. Ганиева: «Соңлап кына килдең син каян?» Шушы ук мотив яшь шагыйрь Ф. Сафинның нигездә оригиналь сурәтләр белән, җылы, хисле итеп язылган «Бир кулыңны» җырына да килеп кергән: «Моңа кадәр, сылу, кайда булдың?..»

Әлбәттә, йөзләгән текст белән эш иткәндә, кабатлану, кайбер җырларның авторлары буталу кебек аерым кимчелекләрдән бөтенләй котылу мөмкин дә түгелдер. Ләкин шуны әйтергә кирәк: җыентыкта, бер мәртәбә газета-журнал битендә басылганнан соң, хәзергә концерт залларында яки радио-телевидение аша актив яңгырый алмаган җырлар да бар. Әгәр төзүче бу әсәрләрне киләчәктә халык арасында популярлаштыру максатын күздә тоткан булса, моңа ирешү өчен, бәлки аларның ноталарын да урнаштырырга кирәк булгандыр.

Ә гомумән алганда, И. Надиров җыентык өчен җырлар сайлауга, аларны тәртипкә салуга шактый зур көч куйган, халыкны идея-эстетик тәрбияләүдә җыр жанрының бурычларын һәм җыр сөючеләрнең зәвык-ихтыяҗларын тирәнтен аңлап эш иткән. Нәтиҗәдә «Җырлыйк әле» китабы бүгенге җыр хәзинәбезне шактый тулы итеп һәм әйбәт сыйфатлары белән күрсәтә торган җыентык булып чыккан.

**ХУҖИ МӘХМҮТОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# МИФТАХЕТДИН АКМУЛЛАНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Миркасыйм Госманов

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ИҖАТЫ ҺӘМ МИРАСЫ

*Жаткан җирдән ходай кичәр диган — хурлык,*
*Сәбәп эзләп, тѳз җул менән җѳгер диган!..*

*Залимнарга хәзерләнгән җәһәннәм бар,*
*Ходаем бу дѳньяда ормайды икән?!*

Шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың (1831—1895) иҗаты, тормыш юлы татар, башкорт һәм казакъ әдәбиятлары тарихында шактый өйрәнелгән. Безнең әдәбият белемендә шагыйрь мирасы белән якыннан кызыксыну Октябрь революциясенә кадәр үк аның әсәрләрен эченә алган өч китабы басылып чыгудан башланып китә, аннары ул кызыксыну Р. Фәхретдинев, Х. Гали, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, М. Гали, М. Гайнуллин хезмәтләрендә дәвам итә. Казакъ әдәбияты тарихында Акмулла иҗатын өйрәнүгә С. Сәйфуллин, Д. Качкынбаев, В. Кинҗәбаев, Б. Исхаков һәм башкалар шактый өлеш кертсәләр, башкорт әдипләреннән С. Кудаш, К. Мәргән, Ә. Харисов һәм Ә. Вильдановлар шагыйрь иҗаты буенча материаллар туплау, аны актив пропагандалау юлында зур тырышлык күрсәттеләр. Һәм бу бер дә очраклы түгел, чөнки бөтен иҗаты мәгърифәтчелек рухы, социаль гаделлек, актив гуманизм идеяләре белән сугарылган ялкынлы демократ, хикмәтле сүз остасы Акмулланың нәсел нәсәбе, авыр тормышы әлеге өч халыкның охшаш язмышына, якын туганлыгына символ булган кебек, аның бай эчтәлекле, катлаулы әдәби мирасы да хаклы рәвештә аларның уртак байлыгын тәшкил итә.

Ләкин, кызганычка каршы, бу кабатланмас зур талант иясенең барлык әсәрләре дә безнең көннәргә хәтле тәгәл килеп җитмәгән кебек, аның катлаулы тормышы турында да безнең мәгълүматыбыз тулы түгел әле. Күп кенә мөһим мәсьәләләрнең һаман да хәл кылынып бетмәве, вакыт-вакыт каршылыклы, хәтта ялгыш фикерләрнең яңгыравы әнә шуның нәтиҗәсе. Шуңа күрә, олы шагыйрьнең туууына 150 ел тулу бәйрәмен билгеләгән чакта, аның тормышын, иҗат үзенчәлеген чагылдырган материалларга тагын бер кат мөраҗәгать итү, моңарчы мәгълүм фактларны янә бер мәртәбә тикшереп, өйрәнелеп җитмәгән материалларны җентекләп карау һәм тәкъдир ителә торган шәхеснең кешелек сыйфатларын, индивидуаль иҗат йөзен билгеләргә омтылу таләп ителә. Бары шулай эшләгәндә генә шагыйрь иҗатының әһәмиятен яңа югарылыктан бәяләп, шул бай, катлаулы мирасны өйрәнү юлында алда торган актуаль мәсьәләләрне дөрес билгели алачакбыз. Чөнки Акмулланың тормыш юлын чагылдырган материалларның иң ышанычлы булып күренгәннәре дә каршылыктан, хәтта бер кадәре «серлелектән» азат түгелләр.

## Соңгы истәлек

Шундый материалларның әһәмиятлеләреннән берсе сыйфатында революциягә хәтле бик актив эшләгән тарихчы, журналист Риза Фәхретдиневнең «Асарь» дип аталган монументаль био-библиографик җыелмасының кульязма килеш сакланып калган өченче һәм дүртенче томнарын күрсәтергә мөмкин (беренче һәм икенче томнар 1900—1911 елларда аерым-аерым кисәкләр булып басылган). Менә шул кульязма хезмәтнең соңгы томында (11—20 битләр) Акмулла хакында зур күләмле биографик материал — аның турындагы истәлек белән бергә шагыйрьнең соңгы елларга хәтле билгеле булмаган берничә яңа шигыре, бер хаты, һәм тагын башка документлар теркәлгән [1].

Материаллардан күренгәнчә, Р. Фәхретдинев мәгърифәт җырчысы Мифтахетдин Акмулла иҗаты белән күптән кызыксынган, беренчеләрдән булып аны өйрәнә башлаган, шул эшне гомер буена дәвам иткән икән. һәм бу игътибар аңлаешлы: алар икесе дә атаклы философ һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани идеяләре белән сугарылып формалашкан акыл ияләре, фикердәшләр.

Биография, «Асарь»да кулланылган стильгә хас рәвештә, болай башланып китә: «Акмулла дип мәшһүр бу шагыйрь (мең) өч йөз унөченче (1313/1895) ел җөмади-елуля — үктәбер аенда залимнәр тарафыннан шәһид вә Миасс заводы каберлегенә китерелеп дәфен кылынды». Моннан соң автор, шагыйрь кабере өстенә кем таш куйдыруын, үтерүчеләрнең кемнәр икәнлеген әйткәч, аның кайчан, кайда тууы, яшьли ятим калуы, үксезлек, үгилек күрүе, ачлы-туклы яшәп, төрле мәдрәсәләрдә укуы, җөмләдән шагыйрь Шәмсетдин Зәкидән дә сабаклар алуы, ниһаять бәхет эзләп, казакъ якларына чыгып китүе хакында сөйли.

Р. Фәхретдинев стиленә һәрвакытта диярлек документальлек хас. Монда да шулай: иң элек ул Акмулланың төрмәдән язган бер хатын, шул хат белән Хафиз исемле хәлфәгә җибәрелгән ике шигырен күчерә һәм мәгълүм фольклорчы, педагог Хәсән Гали тарафыннан шагыйрь хакында тупланган материалларны китерә; катлаулы, бәхәсле мәсьәләләргә аңлатмалар бирә. Хезмәтенең икенче өлешендә исә шагыйрь хакындагы үз истәлекләрен яза. Чөнки алар 1894 елның сентябрендә Уфада очрашып, якыннан танышкан булалар...

«...Уфа шәһәренә килде. Күрештек,— дип яза автор.— Бу вакытта бу кешенең Мәрҗани хакында басылган мәрсиясене [2] күргән вә шул васита [3] берлә үзене ерактан торып, беркадәре генә булса да, белгән идем. Моны казакъ акыннарының берәрсе булыр дип йөридер, ләкин мәзкүр мәрсия эчендә үземезнең шивәмезчә тәртип ителгән шигырьләр булганлыктан, бу гөманымның тугъры булуына шөбһә берлә карыйдыр идем».

Р. Фәхретдинев Акмулла белән әдәби-гыйльми мәсьәләләр буенча озак-озак әңгәмәләшә һәм якыннан аралашу нәтиҗәсендә шагыйрь турында кызыклы гына күзәтүләр ясый. Акмулланың эзлекле тәгълим-тәрбия, системалы тирән белем ярдәмендә җитлеккән профессиональ шагыйрь түгел, бәлки табигый сәләт белән гадәти шартларда үскән олы талант иясе — чын халык җырчысы булуы галимгә ачык күренә: «Мәдрәсәдәге иптәшләре вә замандашлары хәбәрләренә күрә, Акмулла зирәк вә үткен табигатьле һәм дә игътибарлы булса да, һәрбер зирәк кешеләрдә була торган хәлгә муафикъ, дәрес тугърысында тырыш булмаган вә артык ватылмаган, өзәләнеп укымаган. Тавышы яхшы гына моңлы булып, җырлауга оста булган. Йортыннан азык барып тормаганлык вә атасы да моның хәленә артык игътибар итмәгәнлек сәбәбендән, мәдрәсәдәге гомере ачлы-туклы үткән».

Белемлелек критерие итеп классик мөселман культурасын белүне алга сөрүче Р. Фәхретдинев, үзе дә сизмичә, «сахра улы» Акмулланың да тиешле югарылыкта бу-

[1] Галим архивы хакында әтрафлырак мәгълүматны махсус укырга мөмкин: «Казан утлары», 1966 ел, 7 сан.
[2] Элегия.
[3] Юл, чара.

луын күрсәтә торган бер факт китерә. Әңгәмәләрнең берсендә шагыйрь мондый үпкә белдерә:

— «Асарь»да күп кешеләрнең тәрҗемәи хәлләре языладыр, исемләре матбугатка кереп каладыр, ләкин казакълардан мәшһүр затлар язылмыйлар яки бик аз язылалар; хәлбуки анларда да исемләре матбугатка керергә лаек булган галимнәр вә мөгътәбәр затлар бар; шунлар да язылсыннар иде!» — ди шагыйрь. Димәк, әллә кайлардагы, әллә кайчангы гарәпләрне җентекләп белә алмаган Акмулла яшәгән конкрет мохиттан яхшы ук хәбәрдар булган икән.

Шагыйрьнең ни өчен казакъ дөньясын яхшы белүен һәм бу мәсьәләдә аның үзенә авторитет булуын истәлек авторы болай аңлата: «Егерме биш яшендә вакытында үзенең ватаныны калдырып чыгып киткән вә казакъ арасына барып кергән (...), вә казакъ угылы казакъдан аерып алмаслык бер дәрәҗәгә ирешкән. Үзендә шигырь сөйләүгә истигъдад[1] барлыгыны вә шуңар әһәмият биреп, шуның берлә шөгыльләнүне ошбу көндән башланган булуы занн ителәдер»[2].

«Асарь»дәге материалларның әһәмияте болар белән генә чикләнми. Мәсәлән, моңарчы Акмулланың этник яктан кем булуы мәсьәләсе төрле фаразларга урын калдыра килә. Р. Фәхретдиневта бу сорауга да өлешчә җавап бар: «Үземездән элек аның дөньядан күчүене хәтеремә китермәгәнем, һәрвакыт үз гомерем кыска булуын уйлаганым сәбәбендән («Асарь»да үлгән, ягъни тормыш һәм эшчәнлеге тәгәлләнгән шәхесләрнең генә биографияләре язылган — М. Г.), бу адәмнең тәрҗемәи хәленә мөнәсәбәтле мәгълүмат хакында бернәрсә дә сорашмадым вә язмадым. Мәгәр дә үзе сүз арасында ата-анасыннан берсе Казан кешесе булганы хәлдә, икенчесе халис башкорт икәнлекне сөйләгән иде: шул нәрсә хәтеремдә калган».

Бу мәгълүматны «өлешчә җавап» дип билгеләүнең сәбәбе шунда ки, күп кенә документларга караганда, Акмулланың тудырган атасы Мөхәммәдьяр асылда Сырдәрья якларыннан килгән казакъ кешесе булып, яшьли татар һәм башкорт арасында торган, татар мәдрәсәсендә укыган, башкорт җирендә татар кызы Бибигөлсем Сәлим кызына өйләнгән. 1831 елның 14 декабрендә, Туксанбай авылында (Р. Фәхретдинев буенча — Дүсән авылында) аларның улы — булачак шагыйрь Мифтахетдин туган. Мөхәммәдьяр яшьли үлеп киткәч, анасы Камалетдин Ишмөхәммәд угылы исемле башкортка кияүгә чыга. Моны шагыйрьнең үз сүзләре үк раслый:

**Акмулла алты яшьдә ятим калган,**
**Әкәсе үлеп, чичәсен истәк алган...**

Казакъча «әкә» — безнеңчә әтигә, «чичә» әнигә туры килсә, «истәк» дигән тарихи атаманың элек башкортларны аңлатуы күптән мәгълүм.

Мифтахетдиннең чын атасы кем булу мәсьәләсен аның кабере өстенә куелган таштагы язу хәл кыла. 1980 ел җәендәге археографик экспедиция вакытында Миасс шәһәренә кереп, моңарчы тексты тәгәл басылмаган әлеге ташны яңадан тикшереп укып чыктык[3].

Гарәпчә язу болай яңгырый:

Къәтле шәһидән
сәнәти 1313 фи сәманийәти
җөмади-ел-үля фи ләйләти-л-җомга
мелла Мифтахетдин әлмәгъруф
би Акмулла ибне Мөхәммәдьяр хәлфә
нәсәбән вә ибне мелла Кәмалетдин
тәрбиятән. Тәммә, тәммә.

Татарча мәгънәсе: «Шәһидләрчә үтерелгән, 1313 (һиҗри) елда сигезенче җөмадиел — үляда, җомга көнне кичен»[4] Акмулла исеме белән билгеле мелла Мифтахетдин, нәсел буенча атасы Мөхәммәдьяр хәлфә, тәрбия буенча атасы мелла Кәмалетдин. Тәмам, бетте».

---

[1] Сәләт, куәт.
[2] Уйлау, фикерләү.
[3] Таш шәһәр белән тимер юл арасында «кысылып» калган татар зиратында саклана, иңе — 42, җир өстендәге буе — 70, калынлыгы — 10 см. Текст нәхтә почерк белән башкарылган җиде юлдан гыйбарәт.
[4] Миладн буенча 1895 елның 27 октябренә каршы төнгә туры килә.

Шагыйрь үз анасының кем булуы хакында да шактый ачык әйтә, мәсәлән, казакъ укучыларына мөрәҗәгать итеп, үзенең ата нәселе буенча казакъ икәнлеген расларга теләгән бер шигырендә ул болай ди: «... агалар, хәуф итәмен: анасы нугай кызы димәсәңез». Нугай дип, киң мәгълүм булганча, казакълар татарларны атыйлар.

Әмма булачак шагыйрьгә үз анасыннан да яшьли аерылырга туры килә:

Үгәй ана кулында йәтим калдым,
Андан да бик эрәтем китеп калдым,

— ди ул соңрак күрсенеп.

Шулай итеп, шагыйрьнең моңарчы тиешле дәрәҗәдә җәлеп ителмәгән үз сүзләре аның тудырган атасы буенча «чала» казакъ, тәрбияләгән әтисе һәм, ихтимал, үги әнисе ягыннан — өлешчә башкорт, туган, сөт имезгән анасы тарафыннан исә ярты татар булуын раслый икән.

Булачак шагыйрьнең мәктәп-мәдрәсәдә алган тәгълим-тәрбия якларына игътибар итсәк тә, шундый ук нәтиҗәгә килер идек.

Әлбәттә, гыйльми әдәбиятта, бигрәк тә икенче кул чыганакларга (истәлекләргә) таянып язылган кайбер соңгы дәвер хезмәтләрендә, шагыйрьнең чыгышын икенчерәк рәвештә сурәтләргә омтылулар да бар. Ләкин, безнеңчә, андый бәхәсле истәлекләр нигезендә ясалган фаразлар түгел, бәлки шагыйрьнең үз сүзләре биргән документаль нәтиҗәләр күпкә ышанычлырак.

Акмулланың теле турындагы хәбәр дә игътибарга лаек: «үзе... ,— дип дәвам итә Р. Фәхретдинев,— яхшы гына казакълашкан булса да, сүзендә артык казакълашмый: бөрҗан вә үсәргән башкортларыннан аермасыз рәвештә сөйләшер иде». Әгәр моңа өстәп, Мәрҗанигә багышланган Акмулла әсәрләренең нигездә әдәби татарча, ә башка кайбер шигырьләренең шактый казакъча язылган булуын игътибарга алсак, шагыйрьнең аңсыз рәвештә әллә нинди катнаш телдә түгел, бәлки төрле аудитория өчен махсус тел-стильдә язарга омтылганлыгын аңларбыз.

Р. Фәхретдинев Акмулла иҗатының кыйммәтен тар этник проблемаларны хәл кылуга кайтарып калдырмый. Бу мәсьәләдә ул шактый дөрес позициядә тора. Акмулла, чыннан да, классик төрки-татар әдәби традицияләреннән тыш, казакъ халык поэзиясе белән сугарылып, дала поэтик мәктәбендә дә тәрбияләнгән, шул ике башлангычны бергә кушкан кабатланмас шагыйрь. Безнең көннәргә хәтле килеп җиткән шигырьләренең иҗтимагый яктан иң тирәннәре Шиһабетдин Мәрҗани эшчәнлегенә бәйләнгән булуын, шулай ук башка әсәрләрендә дә Болгар—Казан тематикасы күтәрелүен, «казакъча яздым» дигән әсәрләренең зур өлеше татарча яңгыравын исәпкә алганда, Акмулланың татар поэзиясе чишмәсеннән мул һәм даими дым алганлыгы бәхәссез.

Җыеп әйткәндә, Мифтахетдин Акмулла, кайсы гына яктан карасаң да, кардәш халыкларыбызның уртак улы булып күз алдына баса. Яңа материаллар моны тулысы белән раслый. Р. Фәхретдинев тә мәкаләсенең буеннан буена шул фикерне куәтләп уздыра.

Ниһаять, Р. Фәхретдинев язмаларында Мифтахетдиннең кешелек сыйфатларын күрсәтә торган мәгълүматлар да шактый: Үзеннән киткән хатынын дини суд ярдәмендә кайтару максаты белән Уфага килгән, әмма бу мәсьәләдә Риза казыйның булышлыгына ирешә алмаган Мифтахетдиннең күңеле төшә. Фәхретдинев тә уңайсыз хәлдә кала, шулай да ул хөкемен үзгәртми: «вөҗданым кушканча эш итәргә мәҗбүр идем»,— ди. Ләкин шагыйрьнең калган хәтерен, сынган күңелен икенчерәк юллар белән юатырга, күтәрергә омтыла ул: ерак сахраларга кайткач, Акмуллага горурланып сөйләрлек бер вакыйга булсын дип, аны мөфтидән махсус кунак итеп мәҗлескә чакырттыра. Шагыйрь хөрмәтенә оештырылган әлеге зиягфәттә башкорт мәгърифәтчесе Мөхәммәдсәлим Өметбаев та була. Р. Фәхретдинов «Труйский муллаларының мәҗлесендән башкаларны» күрмәгән сахралы «садә вә гасаби» Мифтахетдиннең зур руханилар, эре аксөякләр, патша чиновниклары белән якыннан аралашкан М. Өметбаев янында югалып калуыннан курка. Ләкин Акмулла үзен дәрәҗәле тота, аңгәмәгә актив катнашып, төрле шигырьләр укып, «үзенең урыныны, мәртәбәсене саклап кала...»

Мәҗлес күтелмәгәнчә җанлы, күңелле уза, чөнки аңа ике шагыйрь — Акмулла һәм Өметбаев — рух бирә, алар мәҗлесне үзләре бизәп җибәрәләр. «Акмулла, — ди истәлек авторы,— үзенең шигырьләрене моңлы тавыш берлә, бер кадәре кабзыйәт[1] вә гайрәт берлә сөйләде, вә яхшы гына тәэсир бирде. Моның туктавы берлә, һич көтмәгән бер вакытта, Мөхәммәдсәлим әфәнде, санагатенчә[2] бер кеше берлә очрашуы сәбәпле булса кирәк, күңеле ачылып, мөсабәкать кылырга[3] кереште. Вакыйгандә[4] монлар бер-берене белмәгәнләр иде. Аның тукталуына — Акмулла, Акмулла тукталуына Мөхәммәдсәлим иртиҗалән[5] шигырьләрене сөйләделәр. Үзләренең яшь вакытларыны хәтерләренә төшереп, бу көнге вакытларыны һәм дә нинди мәҗлестә булуларыны онытып җибәрделәр!»

Сүз бәйгесенә кергән ике шагыйрь генә түгел, истәлек авторы язмаларына караганда, мәҗлестә катнашкан башка кешеләр дә үзләренең кайда утыруын тәмам оныталар. Р. Фәхретдинев исә нәтиҗә чыгарып: «Шушы сәгатьдән соң үзем дә мондый бер күңелле мәҗлескә очрамадым. Мондый вакыйгаларның кадерләре беленмәгән!..» — ди инде кырык елдан соң көрсенеп...

Әмма Уфадагы бу очрашу Акмулланың соңгы истәлеге була: күп тә узмый аны Миасс шәһәре тирәсендәге юлда Гафиятулла Байморат улы һәм Дәүләтша Надиршаһ улы дигән кешеләр үтереп китә...

## Бәхәсләр һәм бурычлар

Акмулла хакында Ризаэтдин Фәхретдинев, Хәсән Гали һәм Дусмаил Качкынбаевлар туплаган материалларда, шагыйрьнең тормыш юлын, шәхси сыйфатларын ачыклый торган бәхәссез мәгълүматлардан тыш, мәсьәләне шактый катлауландырып, хәтта бераз бутап җибәрә торган хәбәрләр дә бар.

Мәсәлән, Р. Фәхретдиневтә шагыйрьнең туган елы дип «1248/1832, күрсәтелә. һиҗри исәп белән 1248 ел милади, ягъни хәзергечә календарь буенча 1832 елның 31 маеннан 1838 елның 21 апреленә кадәрге вакытка туры килә. Димәк, «Асарь»да «төгәл» аталган 1248 ел һиҗрине кабул итсәк, Акмулла 1832 елда туган була.

Р. Фәхретдинев үзе үк милади буенча күрсәткән 1832 һәм 1895 еллардан чыгып исәп йөртсәк, шагыйрь 63 яшендә үтерелгән була. һиҗричә исәпләгәндә (1248 һәм 1313), шагыйрь гомеренә 65 ел туры килә. һәм бу аңлаешлы: һәр һиҗри елның озынлыгы миладидан якынча 11 көнгә кыскарак. Шулай да шагыйрь кайсы елны туган соң, ягъни әдип Фатих Кәрими бастырган метрикага нигезләнгән элекке традицион 1831 елның 27 декабрендәме[6], яки «яңа табылган» 1832 елдамы? Минемчә, элекке мәгълүмат дөрес. Чөнки Уфага килгән чакта (1894 елның сентябрендә), Акмуллага чыннан да 63 яшь була һәм моны хәтердә тоткан Р. Фәхретдинев соңрак 1895 тән әлеге 63 не алып ташлап, 1832 милади елны һәм аннан 1248 һиҗрине исәпләп чыгарганга охшый.

Димәк, «Асарь»да китерелгән мәгълүматларның барысына да тәнкыйтьсез карарга ярамый икән. Шулай да, әлеге метрика һәм кабер ташындагы мәгълүматларга нигезләнеп, Мифтахетдин Акмулланың гомере 1831 елның 14 (26) декабре һәм 1895 елның 15 (27) октябре белән чикләнә дип ышанычлы рәвештә әйтә алабыз.

Мифтахетдиннең кайсы авылда туган булуы да төгәл хәл ителмәгән әле. Хәзерге Уфа галимнәре элекле рәвештә Туксанбай дигән башкорт авылын атасалар, «Асарь»да Дусән исемле авыл күрсәтелә. Ләкин Р. Фәхретдинев Туксанбай авылын да яхшы белгән: бер урында шагыйрьнең «Әхмәди исемендә энесе Туксанбай авылында гадәти кешеләрдән» булуын әйтсә, икенче җирдә, Мифтахетдин һәлак булгач, аннан калган әйберләрне әлеге Туксанбайда торучы Әхмәдинең алып китүен, шагыйрь кул-

---

[1] Каушау.
[2] Һөнәр.
[3] Ярышу.
[4] Дөреслектә, чынлыкта.
[5] Кинәт илһамланып.
[6] Карагыз: «Безнең юл» журналы, 1928, 6—7 саннар, 32 бит.

5

язмаларын исә — Тамьян авылына илтеп куюын хәбәр итә. Безнеңчә, бу ике төрле хәбәр Мөхәммәдьяр һәм Камалетдиннәргә барып тоташа шикелле: ике төрле версия әлеге ике шәхеснең ике авылда торуы белән аңлашылса кирәк. Әлбәттә, бу мәсьәлә киләчәктә махсус тикшерүне сорый.

Шагыйрьнең тормыш юлын барлау, ачыклау, үз нәүбәтендә, аннан калган бай һәм катлаулы мирасны җентекләп өйрәнү, гыйльми нигездә дөрес үзләштерү белән бәйле. Кызганычка каршы, бу өлкәдә дә хәзергә мактанырлык зур эшләребез юк. Акмулладан калган шигырьләрнең һаман тупланып җитмәве, аңар нисбәт ителә торган әсәрләрнең дә тәнкыйть иләге аша уздырылмавы шуны раслый. Фикерне дәлилләр өчен тагын бер мәсьәләгә тукталыйк.

Югарыда әйтелгәнчә, «Асарь»дә Хәсән Галинең Акмулла иҗатына багышланган, 1912 елда язылган бер озын хаты, шул хат эчендә шагыйрьнең ике-өч зур әсәре һәм күп кенә шигъри өзекләре китерелә. Хат башында Х. Гали шагыйрьнең үги анасы әле дә Туксанбай авылында исән булуын, шагыйрь үзе тере чакта утырып йөри торган өч бүлек әрҗәле арбасының энесендә һаман сакланып калуын хәбәр иткәч, түбәндәгеләрне яза: «Акмулла үзенең моңлы вә әсәрле шигырьләрене киң далаларда уйлап чыгарадыр да, шушы арбасына утырып кәгазьгә язадыр иде диләр. Себер ханларындан Чыңгызхан бине Вәлиханга (Ч. Ч. Вәлихановның этисе — М. Г.) иштикя юллы[1] язган мәктүбендә ошбу шигыре бар:

**Алмагач ашъян[2] тоткан сез бер шаһбаз[3],**
**Шаһбаздан ит дәм җиткән без дә бер таз;**
**Асыл затым сорасаңыз, мин бичара:**
**Дәрдеманд Хөббихуҗа ибне Нияз;**
**Аргы атам Әбуталиб Ширьяздан,**
**Бер мулда таптан чыккан[4] моны язган;**
**Сездәрдән изге нәзар[5] өмид итеп,**
**Акмулла без фәкыйрең, илдән язган.»**

Р. Фәхретдинев раслау белән килешеп җитми: «Бу шигырьне без сөйли торган Акмуллага нисбәт итүендә Хәсән Гали әфәнде яңлыша торгандыр. Шуны сөйләүче үзе үз исемене «Хөббихуҗа ибне Нияз» дип бәян итә. Шуның өчен моны Мифтахетдингә нисбәт итүгә вәҗһ булмас[6]. Казакъларда Акмулла дип мәшһүр башка бер шагыйрь булса кирәк. Шигырь шул затныкы булыр. Мәрҗанинең бер мәҗмагында үз каләме берлә: «безгә Акмулла килгән, ләкин мин өйдә булмаганмын»,— дип язылган язуны үзем күрдем. Хәлбуки, Мифтахетдин Казан шәһәренә бара алмаганлыгыны үземә үзе сөйләгән иде».

Чыннан да «Асарь»нең дүртенче томында китерелгән Мәрҗани язмалары арасында мондый сүзләр бар: «Казакъ диярындан[7] «Акмулла» дип мәгъруф[8] булган Хөббихуҗа бине Нияз 1292 дә рәҗәб урталарында (1876 ел, август — М. Г.) Казан шәһәренә килеп киткән, мин аны күрә алмадым. Атасы Болгар татарларындан булып, анасы казакъ икән. Сахибе фазыйль[9] диделәр, Харәзем вә Бохара вә башка урыннарда йөргән, «Назурә»[10] хакында мөгътәкыйд вә хөсне-с-сәна, вә җәмил әззикр[11], диделәр. Труйски әтрафында, вә мөраббисе[12] дә Эстәрлебаш карьясендә[13], диделәр».

---

[1] Зарлану рәвешендә.
[2] Кош оясы.
[3] Лачын, шоңкар.
[4] Сословиедән чыккан.
[5] Мөнәсәбәт, караш.
[6] Туры килмәү.
[7] Өлкә, ил.
[8] Билгеле.
[9] Гыйлем иясе.
[10] «Назурә» — Ш. Мәрҗани әсәре.
[11] Ышанычлы яхшы фикердә һәм матур сүзләрдә.
[12] Тәрбияче.
[13] Авыл.

Р. Фәхретдинев бу сүзләргә карата түбәндәге аңлатманы бирә: «Монда сөйләнгән тәгърифләрнең[1] беркадәресе без белә торган вә гасырымызда булган шагыйрь Акмулла (Мифтахетдин — Р. Ф.) га тугъры киләдер. Беркадәресе тугъры килми. Моны Мәрҗани күрмәгән, бәлки кешеләрдән ишетеп язган. Мәрҗанигә сөйләүчеләр үзләре ике Акмулланы бергә катнаштырып вә беренең тәгърифене икенчесенә күчереп сөйләгән булулары куәтлегә кыйлә»...

Бәлкем Р. Фәхретдинев ялгышадыр дигән шикнең булуы да ихтимал. Әмма икенче бер дәлилләр дә бар, мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗанигә багышланган «Мәрсия»нең кереш өлеше ахырында «Аh, дәрига! Баралмадым катына аның»,— дип үкенеч белдерсә, галим үлгәч өстәлгән бүлегендә Казанда булмавын тагын да ачыграк яза:

Гыйнайәт кылса ни, йа рабб,
Үзем байгыш, атым арык:
Казан шәһренә бер барып
Күрә алмадым ,дәрига, аh!

Атының «арык», үзенең «байгыш» ягъни ярлы булуы турында сөйләү шигырьне ике төрле аңларга урын калдырмас шикелле.

Шуңа да игътибар итәргә кирәк: әгәр Х. Гали китергән шигырьнең авторы үз исемен Хөббихуҗа дип, атасын исә — Нияз, ә бабасын Әбуталип Ширьяздан дип күрсәтеп, аннан соң үзен «Акмулла» дип танытса (Мәрҗанине эзләп килүче кеше дә үзен нәкъ шулай атаган!), Мифтахетдиннең атасы, югарыда күргәнебезчә, — Мөхәммәдьяр яисә Камалетдин. «Хөббихуҗаны» Акмулланың өстәмә псевдонимы дип уйларга да урын юк, чөнки алай булганда, шәҗәрә мәгънәсен югалта: «ибне» һәм «аргы атам», ягъни бабам дигән махсус генеалогик күрсәткечләргә урын калмый. Ниһаять, югарыда Х. Гали китергән өзекне төрле җирдә төрлечәрәк йөрүе дә•аңа шикләнеп карарга нигез бирә.

Шулай итеп, бер-берсенә туры мөнәсәбәттә булмаган, үзара мөстәкыйль дүрт-биш документ Мифтахетдиннән башка тагы бер шагыйрь булуы, аның да халыкта Акмулла дип йөртелүе файдасына сөйли икән.

«Хөббихуҗа» исеменә беренчеләрдән булып игътибар иткән Г. Әс-Сәнди аңар мондыйрак аңлатма бирә: Мифтахетдингә үчеккән казакъ байлары аны казакъ түгел, бәлки гаскәри хезмәттән качып йөрүче татар (яисә башкорт) дип игълан итәләр һәм донос язалар;[2] төрмәгә эләккән Акмулла исә үзенең чыгышын хуҗалар (сәетләр) нәселеннән итеп күрсәтергә теләгән...[3] Ләкин мондый аңлатманың очы очка ялганмый. Беренчедән, бу очракта, Х. Гали хатындагы өзекнең икенче строфасы кабул ителә алса да, аның «Хөббихуҗа ибне Нияз» дигән алдагы өлеше кабул ителми: Мифтахетдин сыйфатында хөкемгә җәлеп ителгән кеше Хөббихуҗага әверелеп кенә җәзадан котыла алмас иде. Икенчедән, бөтен иҗаты, аңлы әдәби эшчәнлеге «тугрылыкка», дөрес сөйләүгә багышланган шагыйрьнең тупас мистификация белән шөгыльләнүе — үз исемен Мифтахетдиннән Хөббихуҗага үзгәртүе акылга сыеп бетми...

«Асарь»дәге мәкаләсен тәмамлап, Р. Фәхретдинев болай яза: «Нинди сәбәп берлә Мифтахетдин үзенә «Акмулла» дигән гонванны[4] алган? Бәлки, моның сәбәбен үзе сөйләгән булыр, ләкин хәзер хәтеремдә юк. Бәлки, казакъларда булган мәшһүр Акмулла гонванлы икенче бер шагыйрь вафат булгандан соң, казакълар шуның гонванныны моңа биргәнлəрдер дигән фикер куәтлемә киләдер». Бу сүзләр яхшылап тикшерүгә мохтаҗ, чөнки галим үзе дә, кистереп әйтмичә, уйланырга урын калдырган.

Без дә фикер алышу максаты белән башкорт халык шагыйре Сәйфи ага Кудашка мөрәҗәгать иткән идек. Аның җавап хатында мондый сүзләр бар: «1961 елның 18 августында без казакъ язучысы академик Сабит Моканов белән, халык шагыйре Омар Шипинның хәлен белер өчен, Кустанай өлкәсе, Убаган районындагы Маяковский исе-

[1] Сыйфат.
[2] Казакълар һәм башка Урта Азия халыклары патша Россиясендә гаскәри хезмәттән азат ителгән булалар.
[3] Акмолла әфәндинең иншад итдеке мәнзуматиле башка бер көч мөншадатыны вә кәндесенең тәрҗемәи хәлен мөштәмил мәҗмугадер. Казан, 1904, 8 һәм 17 битләр (искәрмәдә).
[4] Дәрәҗәле исем. Бу урында: псевдоним.

мендәге совхозга бардык. Аның белән әңгәмәләшеп утырган чагында мин Акмулла турында сүз кузгаттым... Менә шул вакыт акын теге мәгълүм Мифтахетдин Акмулладан башка, казакъта янә бер Акмулла исемле акын булганлыгын һәм шуның халык арасында сөйләнелеп йөртелә торган берничә үләңен язып алып, Алматыга—Казакъстан Фәннәр Академиясенә җибәрелгәнлеген әйтә. Ләкин мин, үземне кызыксындырган мәсьәлә булмагач, бу хакта төпченеп сорашмадым».

Димәк, төрле документлар да чынлыкта бер-берсенә мөнәсәбәтсез ике Акмулланың бер заманнарда һәм бер тирәләрдә яшәве файдасына сөйлиләр. Ниһаять, шуңа да игътибар итәргә кирәк: әгәр Ш. Мәрҗани язмаларын авторның үзеннән соң беренче булып укучы бары Р. Фәхретдинев икәнлеген онытмасак (ул язмалар беркайда да басылмаган әле), Х. Гали китергән шигырь дә, казакъ поэтикасы һәм гомумән төрки шигырь күзлегеннән караганда, төгәл һәм камил әсәр. Аны фальшивка дип әйтергә нигез юк. Мәрҗани язмаларындагы фактларны да мистификация җимеше дип әйтә алмыйбыз. Ә Омар Шипин исә тагы да икенче дәлилләргә нигезләнеп фикер йөрткән...

Бәс, ничә Акмулла булган соң? Әгәр бер Мифтахетдин Акмулла гына булса, аның тормыш юлын, бөтен иҗатын яхшы беләбез дип әйтә алабызмы?!.

Бу сорауларга өзеп бер җавап биргәнче, күп эзләнәсе, күп тир түгәсе булыр әле. Эзләнүне дәвам итү исә төрле яклап файдалы. Әгәр «юл уңып», бер Акмуллабыз икегә — Мифтахетдин һәм Хөббихуҗага аерелсә,— әдәбиятларыбыз тагын бер кызыклы күренешкә баер, шуның белән кайбер буталчыклыклар да җуелыр иде. Киресенчә килеп чыкканда да юлыбыз уңачак: ышанычыбыз нык, белемебез тулы булып, шөбһәләрдән арынырбыз.

Мәсьәләнең шушы якларын күздә тотып, бәхәсле фактларга киңрәк тукталу, сорауны да «кабыргасы белән кую» кирәк табылды.

## Уртаклыкның бер тамыры

Акмулла мирасын өйрәнүчеләрнең һәммәсе дә диярлек аның татар, казакъ һәм башкорт әдәбиятлары өчен уртак шагыйрь икәнлеген икърар итмичә уза алмыйлар. Һәм бу аңлаешлы: аның чыгышы, тәгълим-тәрбиясе, үзләштерелгән традицияләре, тудырган һәм үстергән шигъри мәктәбе — һәммәсе бергә моңа бик ачык дәлил.

Уртаклыкның бер чыганагы иң әүвәл, әлбәттә, телгә барып тоташа. Татар һәм башкорт телләренең үзара бик аңлаешлылыгы хакында махсус сөйләп торуның хаҗәте булмаган шикелле, татар һәм казакъ телләре арасындагы якынлык та исбатлап торуны таләп итми. Әгәр Акмулла араларында гомер кичергән Көньяк Себер һәм Көнбатыш Казагыстан казакъларының объектив сәбәпләр нәтиҗәсендә татар әдәби теле тәэсирен элек-электән үк татып килүен, шул төбәкләрдәге тел үзенчәлекләрен фәндә беренчеләрдән булып тикшергән Хөсәен Фәезханов әйткәнчә, аларның язма телдә беркадәр «нугайлашып» (татарлашып) өлгерүләрен игътибарга алсак, бу фикер тагын да куәтләнә төшә. Әлеге төбәкләрдә яшәгән татарлар һәм башкортлар да образлы сүзләргә, экспрессив чараларга бай җанлы казакъ теленнән күп итеп өлеш алганнар, аны яратып кулланганнар. Мондый ихтыяҗны тормыш үзе — көндәлек аралашу, Габдулла Тукай әйтмешли, даими «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашу» тәэмин иткән. Шуңа күрә XVIII—XIX йөзләрдә татарча һәм казакъча «катнаш» яки «катнашрак» телдә язучы әдипләр — шагыйрьләр, акыннар барлыкка килә. Бу традиция XX гасырның башына да күчә. Мисалга XIX йөздә күп санлы поэма-кыйссалар язып калдырган Мәүләкәй Юмачиков, Әхмәт Уразаев-Кормашиларны, традицияне XX гасырда дәвам иткән «чала татар» Әкрам Галимов (казакъча «Айкап» журналының секретаре) белән тюрколог-фольклорчы һәм педагог «чала нугай» Хәсән Галиләрне күрсәтү дә җитә.

Акмулла иҗаты — менә шушы гаять үзенчәлекле этнолингвистик «кушылма» әдәби күренешнең бер һәм иң характерлы нәтиҗәсе. Ул үзе тәрбияләнеп үскән этник катнаш даирәдәге телләрне — әнисе бишектә тирбәткән татар телен, тәрбиягә алган әтисе сөйләшкән башкортчаны бер тигез дәрәҗәдә белеп, мәктәп-мәдрәсәләрдә шу-

ларны өйрәнеп үскән, аннары, сахра мохитына чумып, чәчән акыннар белән әйтеш бәйгесенә керерлек дәрәҗәләрдә мөкәммәл рәвештә җанлы казакъ телен дә үзләштергән. Шуңа күрә Акмулла кирәк икән — татарча, кирәк икән — башкортча, хаҗәте килгәндә саф казакъча сөйли алган, яза алган; ихтыяҗ булса, аларның өчесен берга кушкан.

Күп очракта мондый кушылу стихияле рәвештә дә килеп чыккан, әлбәттә. «Җүкәне майлау менән кайыс булмас» дигән бер генә юлны алып карагыз. «Менән» теркәгече башкорт һәм казакъ телләренә хас булып, татарча нормага сыймаса, ә «кайыс» (каеш) бары казакъ ягына тартса, утрак тормыш һәм урманчылык традициясенә бәйләнгән «җүкә» сүзенең килеп керүе бары татар теле стихиясенең генә тәэсире. Мондый мисалларны Акмулла теленнән дистәләп-дистәләп китерергә мөмкин.

Шул ук вакытта Акмулла хакында бары стихияле рәвештә «катнаш» телдә язучы шагыйрь сыйфатында хөкем йөртергә дә ярамый. Төрле телләрне кызык итеп куша алган кебек, ул аларны, кирәген тапса, эзлекле рәвештә аера да белгән. Шуңа күрә аның бер төркем әсәрләре саф иске татар әдәби телендә, икенчеләре бөтенләй диярлек казакъча язылган. Хәтта бер әсәренең эчендә дә аның аерым өлешләре арасында шундый үзгәлекләр күзәтелә. Бу — андый әсәрләрнең элек төрле этник аудиториягә адресланган аерым-аерым парчалар рәвешендә язылып, соңрак тематик җирлектә кушылуының нәтиҗәсе булырга тиеш.

Хәзерге көн милли укучылар өчен аңлаешлылык җәһәтеннән билгеле дәрәҗәдә кыенлык тудыра торган мондый «тел чуарлыгын» ничек бәяләргә соң? Мәсьәләгә конкрет һәм тарихи якын килгәндә бу — шагыйрьнең конкрет аудиториягә аңлаешлы телдә язарга омтылуының нәтиҗәсе. Икенчерәк итеп әйткәндә, бу хәл иске татар әдәби теленең демократлашу процессындагы үзенчәлекле бер күренеш. Чуарлыкны югарыда күрсәтелгән даирәнең этник төрлелеге, катнашлыгы барлыкка китергән. Чөнки Акмулла, трибун шагыйрь, прогрессив идеяләр пропагандисты буларак, шигырьне — китап өчен, китапны киштә өчен генә язмаган, бәлки аны үзе яшәгән җирләрдәге катнаш телле җанлы кешеләргә адреслаган (әйтик, шул «стилистик мәктәпне» өлешчә дәвам иткән Дәрдменд тә җирле сөйләшкә таянып язган).

Мифтахетдиннең тел мәсьәләсендәге позициясе аның хәлфәләргә сабакның «мәгънәсен үз теленчә төшендерсен», «үзеңезнең телеңезчә анык кылып, баласы мөселманның андагандай» итеп дәрес бирсен!

Шагыйрьнең үз телендәге гарәп-фарсы элементларының шактый күп булуыннан чыгып, берьяклы ашыгыч нәтиҗә ясарга да ярамый. Беренчедән, мондый күренеш ул чорда хөкем сөргән иске әдәби телнең лексик арсеналы һәм мәдрәсәләрдә тел укытуның торышы белән аңлатыла. Икенчедән, моны тел-форма яссылыгында гына түгел, бәлки эчтәлек-проблема планында да карарга кирәк. Мәсәлән, бүгенге көндә, биология кануннары буенча зур, принципиаль полемика алып барганда, йөзләгән латинча махсус атамалардан баш тарту дөрес түгел икән, XIX йөздәге мөселман дөньясында фәлсәфәгә караган проблемаларга кагылган чакта, гарәпчә терминнардан, катлаулы һәм төгәл төшенчәләрдән башка бер адым да ясавы мөмкин булмаган; өченчедән, күрәшче шагыйрь үз әсәрләрен гади халыкка гына түгел, бәлки искелекне яклап ятучы консерватив, хәтта клерикаль руханиларга да күндергән, ягъни алар белән аларның үзләренчә сөйләшү зарурлыгын аңлаган.

Акмулла теле әдәбиятыбызның демократлашу юлындагы алга таба бер адым булуын аңлар өчен, аның җанлы сөйләм теленә якынаерга омтылуына да игътибар итәргә кирәк. Дөрес, бу юнәлештә дә ул эзлекле түгел һәм, объектив сәбәпләр аркасында, алай була да алмаган. Әмма «башындан, башындин» кебек традицион рәвештә язасы урынга шактый еш «башыннан, колагыннан» дип бирү — соңрак гамәлгә кергән «ишеткәнчә язу» принципларына якынаюның бер билгесе.

Акмулланың тел мәсьәләсендәге реалистлыгы аның русча сүзләргә карата мөнәсәбәтендә дә яхшы чагыла. Әгәр XIX йөздәге күп кенә иске язучыларыбыз солдат һәм губернатор кебек көндәлек кулланылыштагы сүзләрне әсәрләренә кертүдән баш тартсалар, Мифтахетдин аларны үз теленә үреп бирә:

Нисбәт берлән форма төзеп, сурәт сатмай...
Кирәк солтан булсын, кирәк — император...

Болардан тыш аның телендә солдат, чинауник, эфисәр, кантон, наград, паруд (порода — нәсел), бырат — (брат — туган) бизмән һ. б. очрый. Кайчакларын шагыйрь шундый алынма сүзләр ярдәмендә отышлы шигъри фигуралар да тудыра:

**Күз алдында карманнан кармагандай!..**

Җыеп әйткәндә, Мифтахетдинев Акмулланың тел үзенчәлеге, бер яктан, аның тугандаш халыклар арасындагы уртаклык сыйфатын ачык итеп характерласа, икенче яктан, аның иҗатындагы, дөньяга карашындагы халыкчанлык тенденцияләренең дә калку гәүдәләнеше ул. Менә шуларның һәммәсен дә исәпкә алганда, без шагыйрьнең теле белән сак кыланырга, аның тарихи-документальлек сыйфатларын бозмаска тиешбез.

## Икенче тамыр

Бу мөһим башлангыч XIX йөзнең уртасы һәм икенче яртысында тарихыбызда йөз биргән, Россиядәге изелгән халыкларның күпчелеге өчен хас мәгърифәтчелек һәм азатлык өчен көрәш хәрәкәтенә, шушы күренешләрнең эчке бердәмлегенә кайтып кала. Акмулланың, үзенә идеал итеп туң схоластикага, догматизмга каршы баш күтәргән, кешегә рухи ирек, аң-белемгә хокук даулап чыккан мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанине сайлап алуы һич тә очраклы түгел.

Сүз уңаенда шуны да әйтеп китик, Акмулла татарлардагы мәгърифәтчелек идеяләрен бер Мәрҗанигә генә кайтарып калдырмый. Мәсәлән, шагыйрьнең:

**Курса хәзрәт алардан борын булган,**
**Мәдехка ул бер лаек урын булган,**

— дигән сүзләре аның Габденнасыйр Курсави эшчәнлеген дә яхшы белгәнлеген күрсәтә. Мәрҗани исә, мәгълүм булганча, шул Курсави күтәреп чыккан мәсьәләләрне үстереп җибәргән, системага салган, төзек тәгълимат югарылыгына күтәргән фикер иясе.

Әйе, Мәрҗани — бездә мәгърифәтчелек идеологиясен формалаштырып, шул идеяне алга сөргән, аның өчен көрәшкән, аң-белем, фикри хөрлек өчен башкаларны да актив көрәшкә чакырган җәмәгать эшлеклесе. Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Тукайлар аның эшчәнлегендәге нәкъ менә шул хосусиятне беренче чиратта атап, шунысы өчен аны олылыйлар. Әмма бөек мәгърифәтченең әдәби образын гәүдәләндерүчеләр, әдәбиятта аның фикерләрен яклаучыларның төүгеләреннән берсе Мифтахетдин Акмулла булды дисәк, әлләни ялгышмабыз. Чөнки Тукайга хәтле Мәрҗанигә багышланган әсәрләрнең күпчелеге Акмулла шигырьләре төсле халыкка таралмаган иде. Өстәвенә, шагыйрь традицион мәдхия язу белән генә чикләнми, бәлки Мәрҗани фикерләре өчен актив рәвештә көрәш алып бара, аның тарихи урынын билгеләргә омтыла:

**Бәрадәр, сезгә үтенәм сәлам язып,**
**Күзең сал, Мәрҗани ул — Тимер казык!**
**Булмаса, кыйбла тапмай адашырсың,**
**Караңгыда җүн белмәй юлдан язып!**

Мәрҗани эшчәнлегенә очраклы рәвештә болай киң тукталынмый. Чөнки ул күтәреп чыккан азатлык, фикердә хөрлек мәсьәләләре XIX йөзнең икенче яртысында Россиядәге күпләгән мөселман халыклары өчен дә актуаль, шунысы белән уртак проблемаларның берсе була. Шуңа күрә дә Акмулла, мәгърифәтчелек идеяләрен пропагандалап, киң казакъ сахраларында казакъча гыйбарәләр белән «үләң әйтсә», башкорт арасында «башкортның наград алган кантоныдай» кәпәренгән карагруһ муллаларга, «чинауник — түрәләргә» һөҗүм ясый. Мәрҗани эшчәнлеген ул үз җирендәге,

үз илендәге, үз халкындагы зур казаныш, прогресс сыйфатында бәяли, «бездән» дип, басым ясап әйтә:

Хәмде лиллаһ, бу диярда бездән чыкты
Мәрҗани Шиһабетдин ахунд хәзрәт!

Ләкин Мәрҗанине ул шәхси дуслык, яисә кан кардәшлеге хакына түгел, бәлки аның идеясе, фикере, эшләгән хезмәтләре өчен яклый:

Батырны «батыр» диләр — көчен күргәч,
Останы «оста» диләр — эшен күргәч,
Ул минем атам имәз, остаз имәз,—
Хаклыкны тәсъдикъ зарур эшен күргәч!

Мәгърифәтчелек идеяләренең милли чикләргә сыймыйча, бер үк дәвердә төрле халыклар өчен дә уртак булуын өстәмә фактлар ярдәмендә расларга мөмкин. Мәсәлән, шул ук Мәрҗанинең мәсләктәше һәм дусты Х. Фәезхановның, бер яктан, казакъ мәгърифәтчеләре Чукан Вәлиханов, Ибрай Алтынсарылар белән дуслык мөнәсәбәтендә торуын, икенче тарафтан, аларның һәммәсе дә прогрессив карашлы рус ориенталистлары һәм алдынгы рус җәмәгатьчелеге вәкилләре белән уртак тел табуларын искә төшерик. Һәм бу бик табигый, чөнки мәгърифәтчелек иң беренче планга кешенең рухи хөрлеген, мәгънәви тигезлеген, аң-белемгә хокуклылыгын куя. Бары уку, аң-белем, гыйлем — фәннәр генә, мәгърифәтчеләр, шул җөмләдән Акмулла да уйлавынча, кешене төгәл камиллеккә, бәхет-сәгадәткә ирештерә.
Ләкин уку-белемнең нәтиҗәлелеге өчен рухи пакьлек шарт:

Аһ, дәрига! Эч тазарсын, эч тазарсын,
Булмаса файда бирмәс коры белем...

Прогресска мондый карашны без бүген тарихи чикләнгәнлек дип атыйбыз. Әмма аның тарихи зарурилык — узылырга тиеш бер зарури этап икәнлеге дә бәхәссез. Чөнки социаль тигезлек өчен эзлекле көрәшнең — сыйнфый көрәшнең котылгысыз булуын аңлар өчен дә кешенең гомумән иреккә, хөрлеккә, тигезлеккә хокуклы икәнлеген танырга кирәк. Шуның өчен дә шагыйрьнең үз иҗатында гаделсезлеккә һәрвакыт каршы чыгуы күп очракта идея протесты, наданлыкка каршы протест булып гәүдәләнә — социаль изүне рухи изү «алмаштыра».

Гавам халкы башларын без каңгырттык...

Ә бу «без», төпченә башласаң, конкрет сыйныф вәкилләренә әверелә:

Көче бар мирзаларга ярамсынып,
Шәригатьне күңел өчен борып салган!..

Шагыйрьнең социаль гаделсезлектән туган ялагайлыкка шулай каршы чыгуы, алдакчыларның битлеген ертып, кимсетелгәннәр мәнфәгатен яклавы, наданлыкны кире кагып, гыйлемлекне мактавы, ниһаять, сүздә генә түгел, гамәлдә дә турыдан яруы өчен җәмәгатьчелек аны «Акмулла», ягъни «ак күңелле белем иясе» дип олылаган:

Нәтиҗәдә Акмулла дип исем алдым,
Бу исем бүләк булмыш тугрылыкка...

Дөрес, Акмулла иҗатында, аның дөньяга мөнәсәбәтендә, хәзерге югарылыктан торып караганда, бөтенесе дә бертигез дәрәҗәдә түгел. Үз вакытында Г. Тукай дөрес билгеләп үткәнчә, аның шигырьләрендә тәгассыб — дингә бирелгәнлек тә чагылыш таба. Әйтик, кешеләр арасындагы социаль-иҗтимагый тигезсезлекне күргән, шуның өчен көенгән шагыйрь бу хәлдән ничек котылу юлын белми. Руханиларның халыкны

изү максатыннан чыгып алдап килүен яхшы белгән акыл иясе, алардан арыну фикерен алга сөрәсе урынга, үзе үк дин өйрәтүне камилләштерү мәсьәләсен пропагандалый, шунысы белән әлеге эксплуататор руханиларның позициясен ныгытуга хезмәт итә...

Бүгенге күзлектән караганда, бу, һичшиксез шулай. Әмма шагыйрь яшәгән чорны, шул вакытта хөкем сөргән иҗтимагый һәм идеологик атмосфераны искә төшерик! Акмулла күтәреп чыккан тар һәм каршылыклы лозунгларда да зур кыюлык, яңалык шактый. Ул, мәсәлән, «иң әүвәл кирәк нәрсә иман» дип, бер карауга аллага булган игътикад-ышаныч мәсьәләсен алгы планга куйса да, тора бара шул иманны күңел, гакыл, әдәп, сабыр кебек гадәти һәм дөньяви әхлак-этика категорияләренә кушып, хәтта аларга буйсындырып бирә. Әйтик, имансыз (дөресрәге: гомумән инанусыз!) кешедән яшәү хокукын тартып алырга җыенмаган автор:

**Бозыкка җир өстеннән асты артык,**
**Булмаса күңел таза — күмел дигән!**

— дип, нәфесе, холкы, гамәле бозыкларны үлемгә хөкем итә. Аны ил эчендә азгынлык, әдәпсезлек, гыйффәтсезлек таралу борчый, җәмгыятьнең киләчәген уйлап, яшьләрнең язмышын кайгырта:

**Кагынган бу заманда буз балалар,**
**Хәрамлык ягына тиз кузгалалар,—**
**Тыюсыз бит алдына йөреп үскән,**
**Аман торса ярар иде кыз балалар!**

Ул нәфесе, җаны бозыкларның, изүчеләрнең «теге дөньяда җәза алачагына гына канәгатьләнми, аларның бу дөньяда ук тиешле хөкемгә тартылмыйча калуларына көчле ризасызлык белдерә, шунысы белән әлеге иман-игътикад мәсьәләсенә чын дөньяви мәгънә бирә:

**Залимнәргә хәзерләнгән җәһәннәм бар,—**
**Ходаем бу дөньяда ормайды икән!!.**

Бер урында «хода кичәр дигән менән эш бетмәйде» дип, тәмаме белән алла ихтыярына бирелү идеясен кире какса, чак кына алга таба узып:

**Җаткан җирдән ходай кичәр дигән — хурлык,—**
**Сәбәб эзләп, төз җул менән җөгер дигән!**

— дип, ул чорда хөкем сөргән «тәрке дөньялык» (дөньядан кул селтәү) фәлсәфәсеннән кискен рәвештә баш тарта.

Гомумән, Акмулла уртага куйган иман мәсьәләсе дә, гадәти дини таләпләрдән узып китеп, үзенең тамырлары белән Шиһаб Мәрҗани күтәреп чыккан «акылга — хөрлек, фикергә — ирек, кеше шәхесенә — ихтирам!» дигән таләпләргә барып тоташа.

Шул ук вакытта Акмуллага Ш. Мәрҗани идеяләрен гадәти пропагандалаучы сыйфатында гына чикләп карарга да ярамый. Кайбер моментларда ул үз остазының аерым фикерләрен кискенләштереп, үстереп җибәрә. Әйтик, бездә 1905 елдан соң киң популярлык казанган кайбер лозунглар беренче булып Мифтахетдин шигырьләрендә яңгыраш тапты:

**Хәл килсә, төрле фәнне күргән яхшы,**
**Кямилләр катарына кергән яхшы;**
**Урысча укып кына түгел белмәк —**
**Хәл килсә, французча белгән яхшы!**

Иҗтимагый мәсьәләләрне хәл кылган чакта милли чикләрдән чыгуга болай омтылу икенче юнәлештә дә гәүдәләнә. Әйтик, патша хөкүмәтенең колониаль политикасы

нәтиҗәләрен казакъ чынбарлыгында ачыграк күргән һәм үз җилкәсендә дә татыган шагыйрь гомум милли азатлык проблемасын, гәрчә шактый берьяклы булса да, халыкара масштабта карарга тырыша. Мәсәлән, XIX гасыр ахырында Һиндстандагы колониализмга каршы көчле хәрәкәтне күздә тотып, Россия империясендә икеләтә изелгән халыкларның килачәге турында да уйлана. Мәгърифәт, аң-белем кирәклеге хакында әйткән сүзләре белән генә түгел, бәлки шушындый антиколониаль фикерләре буенча да Акмулла үз замандашлары күңелләренә юл сала. Чөнки шагыйрь яшәгән һәм иҗат иткән елларда кеше-шәхес иреге һәм гомумән милли азатлык идеяләре Идел буенда да, Урал якларында да, Казагыстан далаларында да, шул төбәкләрдә яшәгән халыклар — татар, башкорт һәм казакълар өчен дә бер дәрәҗәдә диярлек актуаль, уртак һәм газиз була.

## Мирасның урыны

Акыл-хикмәт иясе, мәгърифәт идеяләренең ялыкмас пропагандисты, изелгән-кыерсытылганнарның сердәше, моңдашы булу белән бергә, Акмулла шәрә фикерләр өләшеп йөрүче коры вәгазьче, дидактик әдип кенә түгел, ул — чын мәгънәсендәге талантлы, нечкә хисле шагыйрь һәм көчле сүз остасы. Аның әсәрләрен салкын кан белән укуы мөмкин түгел. Афористик җыйнак, фикри тирән юллар сине уйланырга мәҗбүр итә, көтелмәгән уңышлы борылышлар, тапкыр табышлар сокландыра, мавыктыра. Акмулла әсәрләре кат-кат укуны сорый, укыган саен яңа хисләр, яңа фикерләр уята. Хәтта элек башка әсәрләрендә бер тапкыр очраган, монысында янә бер кабатланган аерым юллар яки строфалар да яңа контекстта мөстәкыйль һәм яңа тормыш белән яши башлыйлар. Шуңа да махсус басым ясап әйтергә кирәк, мондый вариантларның барлыкка килүе шагыйрьнең гадәти кабатлануы, яисә «фикер кытлыгы» нәтиҗәсендә түгел. Дошманның күкрәгенә кадалган сөңгесен суырып алып, икенчесенә ыргыткан батыр шикелле, Акмулла да үткен әйтелгән фикерләрен, отышлы шигъри юлларын, туры бәрә торган ачы телле образлы строфаларын кабат-кабат «обоймага теза». Үзен профессиональ дип, иҗатының колачы оригиналь шигырьләренең саны белән үлчәнә торган кабинет шагыйре итеп сизмәгән, бәлки мәгърифәт идеяләренең оранчысы, димәк, көрәшче итеп тойган автор мондый юлга аңлы рәвештә баскан. Чөнки аның өчен аерым әсәрләрнең үзара текстуаль мөстәкыйльлеге, тәгәлләнгәнлеге кыйбат түгел, бәлки мөһим фикерләрнең, турыдан яра торган образларының максатка ирешүе, нәтиҗә бирүе кирәк.

Шулай ук Акмулланы йомры гыйбарәләр, образлы сүзләр, тапкыр җөмләләр сиптерүче, эчтәлеккә генә басым ясап, формага артык игътибар итмәүче, сәнгатьчелек җәһәтеннән «талымсызрак» шагыйрь икән дип уйларга да урын юк. Мифтахетдин кирәген тапкан чакта, форма белән эчтәлекне сәнгатьчә югарылыкта куша алу, бөтенчә итеп әйткәндә, гадәти материаллардан да әр-яңа «эретмә»ләр тудыра алу кодрәтенә ия шагыйрь. Мисал итеп аның кайбер газәлләрен атарга мөмкин. Шулар арасында бигрәк тә «Хәтимә» исемле шигыре аерылып тора. Бу гаҗәеп газәл үзенең фикер тыгызлыгы, хөкем гаделлеге, иман-бурыч мәсьәләләрен чишүдә гуманистик универсальлеккә ирешкәнлеге белән генә түгел, бәлки шигъри форма, ягъни эчке һәм тышкы рифмалар системасын, вәзен-үлчәү, кафия-ритм һәм гомум аһәң җәһәтләреннән дә, сирәк осталар тудырган уникаль бәллүр ваза шикелле, кабатланмас бер әсәр ул.

Дөрес, Акмулланың күпчелек әсәрләре классик шәрык поэзиясендәге жанрларда түгел, бәлки казакъларда ныграк сакланып калган унбер иҗекле саф төрки халык шигыре үлчәмендә язылган. Мондый дүртьюллык шигырь, гадәттә «ааба» рифма системасына корылып, аерым строфалар уртак рифмалыкны таләп итми. Халык шигыре техникасыннан оста файдаланган Мифтахетдин бу вәзенне дә иҗади куллана, аңа сарын, чобыртма дигән, рифмалары күп юлларга уртак булуы нәтиҗәсендә үзенчәлекле тезмә барлыкка килә торган фольклор элементларын актив кертә. Шуңа күрә шигырь аерым фикерләрне бер рәткә тезгән строфалар төркеменнән түгел, бәлки

барган саен бер фикерне куәтләп, үстереп бирә торган бербөтен строфалар ташкынын тудыра. Бу хәл исә фикерне — сугышчан әзлекле, хисне көчле экспрессив итә. Нәтиҗәдә шагыйрь әйтергә теләгән фикерләр укучы (дусты яки дошманы) өстенә бер-бер артлы тәгәрәгән дулкын кебек ябырыла, яки ургып-ургып яуган яшенле яңгыр төсле ишелеп-ишелеп төшә.

Менә шушы сыйфатларның барысы да Акмулла иҗатына форма ягыннан да, эчтәлек җәһәтеннән дә кабатланмас эзлеклелек, системалылык һәм төгәлләнгәнлек хасияте бирә. Мәсьәләгә шушы күзлектән караганда да шагыйрьнең мирасы Г. Тукайга кадәрге поэзиябездә иң зур казанышларның берсен тәшкил итә.

Әлбәттә, шагыйрь мирасындагы афористик җыйнак, фикри тирән, үткен һәм образлы шигъри элементларның да кыйммәте бик зур. Аларның кайберләре язма әдәбиятта аерым әсәрләргә баш, эпиграф булырлык, җанлы сөйләмдә исә мәкаль, әйтем рәвешендә яңгырарлык дәрәҗәдә камилләр. Мисалга берничә генә үрнәк китерик:

**Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән...**

**Түрә димә, кара димә — фигълен кара...**

**Әдәб диган — мәхәббәткә сәбәб диган...**

**Хода кичәр диган менән эш бетмәйде...**

**Саф алтынны нәҗескә буяу илән**
**Нәҗес китәр, алтынның заты китмәс!..**

**Яманны түрә кылсаң — йортың бозар,**
**Гакылсызны үстерсәң — ботын сузар...**

**Алманы карамадан карамыйлар...**

**Дәүләткә адәм бармы котырмаган!..**
**Йорты Болгар улса улсын, йортны болгар улмасын...**

Акмулла фикерләренең кайберләре татар әдәбиятының тирән тамырларына, үзәк программаларына барып тоташа. Мәсәлән, аның:

**Дөньяда тулып яткан газизләр бар,**
**Телләрен, сандугачтай, акча кискән!**

— диган сүзләре XVI йөздә иҗат иткән гуманист Мөхәммәдьярның,

**Нәчәләр (кем) сүзләмәен сүз гөлене кистеләр,**
**Сүзләгәнне күрә белмәй, тән тишеп кан эчтеләр,**

— диган ачынуына авазлаш. Акмулла бу социаль эчтәлекле ачынышны яңа шартларда кискенрәк яңгырата.

Акмулланың Эстәрлебаш мәдрәсәсендә чакта тирән белемле, зур поэтик талантлы татар шагыйре Шәмсетдин Зәкидән дәресләр тыңлавы әдәбият тарихыбызда мәгълүм факт. Яңа табылган кайбер мәгълүматларга караганда, яшь Мифтахетдин үз хәлфәсе белән күп вакытлар әңгәмәдәш булган. Димәк, Акмулладагы эчке мәгънәгә, рельефлы образларга, тапкыр һәм хикмәтле сүзләргә, төгәл формага булган мәхәббәт тә беркадәр шул Шәмсетдин Зәкидән килә.

Әгәр дә Габделҗаббар Кандалый үзенең беренче әсәрләреннән булган «Рисаләйел-иршад» диган поэмасында кешеләрнең байларга, ярлыларга бүленүенә, шул рәвешчә үзара каршы куелуларына:

**Гаҗәб хәйрәт [1], гаҗәб вәйа,**
**Нәзар [2] кылсаң бу дөньяйә:**
**Фәкыйрә игътибар һич юк,**
**Идәрләр гыйззәти байә [3],**

— дип, протест белдергән булса, Акмулла ул мотивны үстереп җибәрә:

**Гаҗәб: һәркем гани [4] булса,**
**аңа хөсне [5] дидар әйләр;**
**Фәкыйрь мескенгә пәрва [6] юк,**
**мөзалләт [7] берлә зар әйләр...**

Яңа чор татар поэзиясенә Акмулла ясаган тәэсир бик зур. Дөрес, монда береэ бәхәсләшеп ала торган моментлар да юк түгел. Мәсәлән, Акмулланың этник чыгышын яки башкорт, янсә татар, яки казакъ кына дип хәл кылуны беренче планга куйган, мәсьәләне шулай тар аспектта чишүне төрлечә уздырырга омтылган Ә. Харисов Г. Тукайның кайбер фикерләрен «үзенчәрәк» аңлата. Ул бөек шагыйрьнең Акмулла «шигырьләреннән тик казакъ исе, күчмә халык исе чыгып торадыр» [7] дигән сүзләрен генә йолып алып, ачык әйтмәсә дә, аның Акмулла әсәрләренең «безнең татар рухына, татар халкына бер дә тәэсире юктыр» дигән [8] ашыгыч һәм ялгыш фикерен куәтләргә омтыла [9]. Ләкин, әзлекле булсак, Г. Тукайның шунда ук үзенә каршы килеп әйткән икенче сүзләрен дә игътибарсыз калдыра алмыйбыз. Мәсәлән, ул, 1905 елгы революцияне, 17 октябрь Манифестын күздә тотып, шуннан «соң мәйданга чыккан ике бөек шагыйрьләребез (Мәҗит Гафури белән Нәҗип Думави күздә тотыла — М. Г.) үрнәкне шул мәрхүм Акмелладан алганнар булырга кирәк, чөнки шигырьләрен галибән [10] шул казакъ бәхре [11] илә язалар» дип, үзе үк уртаклык һәм тәэсир булу фактын икърар итә. Төпченә торсак, яңа дәвер татар поэзиясенә Акмулла тәэсире М. Гафури, Дәрдмәнд, Н. Думави иҗатлары белән генә чикләнми, бәлки Г. Тукайның үзендә дә шактый нык сизелә. Мәсәлән, Акмулланың:

**Инсафдан бер мыскал юк эшемездә,**
**Кинә, хәсәд, фәсад тулган эчемезгә,**

— дип, күңелгә дә, гамәлгә дә үчлек, көнчелек (хәсәд), бозыклык (фәсад) тулуыннан нәфрәтләнүен Габдулла Тукайның:

**Мәлганәт, пычрак вә ялган берлә тулган безнең эч...**

— дигән сүзләрендә дәвам табуын, үстерелүен күрәбез.

Һәр ике шагыйрь өчен дә вөҗданны һәм шуның аша бөтен тормышны пакьләү мотивы уртак. Әгәр бу фикер Акмуллада:

**Иң әүвәл пакьләү кирәк эчнең керене**
**Эчтә тулып җатмасын сасык эрен;**
**Аһ, дәригa! Эч тазарсын, эч тазарсын,**
**Булмаса, файда бирмәс коры белем!**
**Тыш таһарәт алу белән эш бетмәйде,**
**Булмаса чын таһарәт әүвәл эчтән...**

---

[1] Хәйран калу, аптырау.
[2] Карау, күз салу.
[3] Байга.
[4] Бай.
[5] Якты чырай.
[6] Ярдәм, кайгырту.
[7] Г. Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. 3 том, Казан, 1976, 225 бит.
[8] Шунда ук.
[9] А. И. Харисов. Литературное наследие башкирского народа. Уфа, 1978, стр. 278 (цитата Г. Тукай әсәрләренең 1956 елда чыккан 3 томы буенча бирелә).
[10] Күбрәк.
[11] Үлчәү.

— дигән хәлдә иске төшенчәләр һәм образлар ярдәмендә үткәрелсә, Тукайда — наив мәгърифәтчелек стадиясеннән узып, революцион-демократик аң югарылыгына менгән трибун шагыйрьдә — ул бөтенләй икенче юнәлештә үстерелеп, бик нык гомумиләштерелеп, яңа рух белән сугарыла, кискенләшә:

Ни сәбәбдән җир йөзендә
Тәңгә мунча, җанга — юк!!

Акмулла белән тирән фикер уртаклыгы, иҗади бәйләнешне күрер өчен Тукайның «Шиһаб хәзрәт» исемле мәгълүм мәдхиясенә мөрәҗәгать итү дә җитә. Мәсәлән, Акмулланың:

Хәмде лиллаһ, бу диярда бездән чыкды
Мәрҗани Шиһабетдин ахунд хәзрәт.
Караңгыда фанусны[1] кабызган ул...
Ашкан бер галим чыкса, яманлаймыз,
Мәҗлесне гайбәт илә тәмамлаймыз...
Котырган эт һава карап өргән менән
Асманда[2] торган айның нуры китмәс...

— дигән сүзләрен Тукай юллары белән чагыштырып карарга мөмкин:

Чыкты ахыр бездән дә бер бөтен кеше,
Яхшы аңлап, тәкъдир итү читен кеше;
Татарда да гыйрфан уты кабынганны
Күрсәтергә күтәрелгән төтен кеше...
Чыкты, әлбәт, бу даһигә сәфил дошман;
Чыккан дошман мәгълүб булып чыкты эштән.
Олуглыкта, өстенлектә Шиһаб хәзрәт
Этләр буе җиталмаслык җиргә кичкән...

Мондый эзлекле охшашлыкларны, рухи берлекне гадәти очраклык кына, яисә бербersеннән механик рәвештә күчерү нәтиҗәсе генә дип аңлатып булмый, әлбәттә[3]. Монда, фикер якынлыгыннан тыш, әдәби мәктәп һәм гомум язмыш уртаклыгы булуы да бәхәссез. Ниһаять, соңгы факт Г. Тукайның Акмулла әсәрләрен яттан белүен, аңына сеңдерүен, үз призмасы аша уздыруын раслый.

Җыеп әйткәндә, татар әдәбиятының Мөхәммәдьярдан алып Тукайга кадәр булган үсү тарихында Мифтахетдин Акмулланың үз урыны бар. Һәм ул урын — шагыйрь иҗатының иҗтимагый актуальлеген, көчен, мәгънәви тирәнлеген, сәнгатьчә оригинальлеген исәпкә алганда — күп гасырлы поэзиябез үрләренең зурларыннан берсе дияргә була. Чөнки поэзиянең сугышчан иҗтимагыятьлеге җәһәтеннән әлеге ике арадагы шагыйрьләрнең бик сирәкләре генә Мифтахетдин Акмулла белән ярыша ала иде. Шушы күзлектән карaганда, Тукай үзе — Акмулланың туры варисы, аның иҗтимагыятен яңа баскычка, бүтән биек үрләргә менгерүче.

Шулай ук иҗтимагый тарихыбыз күгендә Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйрилар кабызган зур йолдызлар арасында аның да үз йолдызы — якты йолдызы балкып яна.

Әгәр Курсави эшчәнлеге «Бохараи шәриф»тә иске мөселманлыкның катып калган «фикри оясын» бер тузгытып алу белән башланып киткән булса, Мәрҗани — Фәезханов фикерләре, татар дөньясы кысаларыннан чыгып, бөтен Россия мөселманнарында мәгърифәтчелек хәрәкәте тернәкләнүгә һәм үсеп китүгә зур өлеш кертте. Моның шу-

---

[1] Факел, фонарь.
[2] Күк йөзе.
[3] Г. Тукайның яңа чор татар әдәбиятына Акмулла тәэсирен кечерәйтеп күрсәтергә омтылуын аның Мифтахетдин мирасына гомумән күз йомарга теләве дип түгел, бәлки 1905 елдан соңгы татар әдәби теле үсешендә бөтенләй башка тенденция көчәюе һәм шул тенденция башында үзе торуы, яңа перспективага йөз бирүе нәтиҗәсе дип аңларга кирәк.

лай икәнлеген хәзер Урта Азия һәм Казагыстан тарихчыларының барысы да диярлек таный. Күп халыкларның мәгърифәтчеләренә яңа дәреслекләр, уку китаплары төзүдә Каюм Насыйри хезмәтләре тәҗрибә чыганагы була. Шул ук вакытта Курсави һәм Мәрҗани, Фәезханов һәм Насыйриларның формалашуларын, бәрәкәтле эшчәнлеген Шәрык халыклары, шул җөмләдән Урта Азия һәм Казагыстан, алай гына түгел, хәтта бөтен Россия халыкларының әдәби һәм мәдәни, гыйльми һәм фәлсәфи хәзинәсеннән, ниһаять, азатлык өчен алып барган көрәшләреннән аерып каравы мөмкин түгел. Мифтахетдин Акмулла иҗатына килсәк, ул да шушы тирән тарихи уртаклыкның, язмыш һәм максат берлегенең якты гәүдәләнешеннән гыйбарәт. Аның дөньяга килүе белән тәгълим — тәрбиясе дә, шәхси язмышы белән иҗтимагый тормышы да, ниһаять, телстиле, поэтикасы, әсәрләренең кайда яңгыравына карамастан, һәрчак, һәр җирдә үз итеп кабул кылынган гомум гуманистик рухы — барысы да моңа яхшы дәлил.

* * *

Дамир Гарифуллин

# ТЕЛДӘН ТЕЛГӘ, КУЛДАН КУЛГА

Шигырьләренең кайбер юллары мәкальләргә, әйтемнәргә әверелеп халыклашкан шагыйрьләр күп түгел. Мифтахетдин Акмулла да әнә шундый бәхетле язмыш ияләреннән берсе. «Вә ләкин, һәр кош очып лачын булмый», «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән», «Сәгатьне алга борып көн төн булмый», «Яман сүзнең күңелдән заты китмәс», «Фетнәнең күбе чыгар телебездән» кебек әйтемнәр нигезендә аның сүзләре ята. Нәкый Исәнбәт төзегән мәгълүм китапларына Акмулланың «Әфлисун арасында син бер кишер», «Кара чебен сау җиргә күзен салмас», «Дошманга пәйгамбәр дә ярамаган» дигән сүзләре мәкальләр яки әйтемнәр булып теркәлгән.

«Галим һәм укытучы, шагыйрь һәм балта остасы Акмулла һәрвакыт, үзенең бердәнбер мөлкәте булган ялгыз атын китап һәм столярлык кораллары төягән арбасына җигеп алган да, Шиһап Мәрҗани күтәргән яңалыкларны яклап һәм мактап, фанатик муллалар белән сугыша-сугыша, авылдан-авылга, каладан-калага мәгърифәтчелекне пропагандалап йөргән». Сәйфи Кудашның «Яшьлек эзләре буйлап» дигән истәлекләр китабындагы бу сүзләр тугандаш татар, башкорт, казакъ халыкларының уртак шагыйре Мифтахетдин Акмулла хакында шәхес буларак та, шигъриятенең төп эчтәлеген ачыклау юнәлешендә дә тәгәл билгеләмә була ала.

Истәлекләргә караганда, илгизәр шагыйрь башкорт җәйләүләрендә, татар авылларында, казакъ йортларында күп йөргән. Аның чәчәннәр белән ярышып шигырь сөйләвен, акыннар белән «әйтес»тә катнашуын, авылларда җыру сибүләрен күп кеше күргән, күңелләрне нурландыручы канатлы сүзләрен хәтергә сеңдергән. Әтисенә язган сәлам-хатларын кулдан-кулга йөртеп укыганнар.

Ил агалары борынгы бәетләр, җырлар белән бергә, кызыклы истәлекләр, хәтта тарихи реликвияләрне кадерләп тоталар. Шулай бервакыт миңа «Акмулла урындыгы» саклануы турында әйттеләр.

Аны Кәшшафетдин Шаһмәрдән углы әл-Минзәләви әс-Сәләки әллә 1892, әллә 1893 нче елда казакъ ягыннан алып кайткан булган.

Кем соң ул Кәшшафетдин?

Казакъ совет энциклопедиясенең бишенче томында (314 бит) аның турында кыскача гына белешмә бар. Анда «Кәшшафетдин Шаһмәрдән углы — казакъ акыны. Яшь чагыннан мөселманча язу танып, шәрык әдәбиятын күп укыды. Шәрык әдәбия-


тындагы сюжетларны казакъчалап кыйсса-дастаннар язды»,— диелгән һәм егермеләп әсәренең исеме китерелгән, шунда ук үз галимнәреннән Ибрай Алтынсарин, Абай әсәрләрен дә халыкка аңлатуы әйтелгән.

Шиһап Мәрҗанидан тугыз ел белем алып, Кәшшафетдин 1892 елда Уфага барып Диния назаратында имтихан тота һәм мөдәррислеккә указ ала. 1892 елның 13 августында аларның кызы туа. Ул чакта казакъта метрикә дәфтәре тотыру гамәлдә булмаганга, ул кызын теркәү өчен туган авылына — Минзәлә өязенең Сөлек авылына кайта.

Хәзер Алма-Ата шәһәрендә йөзьяшәр Харрас абый Ризатдинов истәлекләренә караганда, Кәшшафетдин бер сәфәрендә әлеге урындыкны алып кайткан, казакълашып бетә язган шагыйрь Акмулланы очратуы турында сөйләгән.

Кәшшафетдин бу урындыкны яңа тормыш корып җибәргән сеңелесе Бибисалиха белән кияве Шәймөхәммәткә бүләк итеп калдырган. Урындык соңыннан кияүнең атасы Рәхмәтуллада сакланган. Рәхмәтулланың малае Хәбибулладан улы Габделәхәткә күчкән һәм бер төрле тарихи истәлек булып хәзерге көннәргәчә сакланган.

Ул алты аралы булган. Еллар узган саен урындык искерә барган һәм бала-чагалар аның һәр яктан берәр аратасын сындырганнар. Бер генә кадак та сукмыйча ясалган әлеге урындык Акмулланың балта эшенә дә бик маһир булуы турында сөйли. Аңа карап шагыйрьне күз алдына китерәсең...



Әнә, уйчан гына бер карт, авыз эченнән я казакъ, я татар, я башкорт телендә нидер көйли-көйли, ат җигә. Арбаның бер бүлемендә балта, чүкеч, пычкы, борау, ышкы кебек әйберләр, икенчесендә китаплар. Алгы өлешкә үзе менеп утыруга, аты кузгала. Ерак җирләр узалар. Халык белән очрашканда Акмулла арбадан әкрен генә төшә, атының башына солы салынган капчык кидереп куя, аннары җыелмалы урындыгын таратып утыра да, үз тирәсенә җыелып өлгергән кешеләргә шигырьләрен көйләп укый башлый... Беренче ишетүгә үк җанга җылы сала торган акыллы шигырьләре белән ул аларны үзенә җәлеп итә.

**Алтыга берне кушып, сан ун булмый,**
**Сәгатьне алга борып, төн көн булмый.**
**Белемлелек — арысланнан көчле батыр,**
**Шуңа атланмый, синең төшең һич көн булмый.**

Үзе әйткәнчә, Акмулладан сүз хикмәт белән чыккан. Шигырьләренең күңелдән-күңелгә, кулдан-кулга күчеп саклануының сәбәбе дә әнә шундадыр. Сарман районының Яхшыбай авылыннан Рәсиха Сафиуллинада сакланган язмалар арасында 32 юлдан торган «Гыйлемгә эстәү турында» дигән шигырь бар. 1910 елда Казанда чыгарылган бер китап тышлыгының эчке битләренә карандаш белән язылган, ахырына «1918 ел, 3 ноябрьдә шимбә көн» дип куелган. Димәк, бу шигырь шагыйрь үлгәннән соң 23 ел үткәч язып куелган. Күчерүче, әлбәттә, Акмулланың үлгәнен ишеткән, һәрхәлдә аның вафат булуы яки үтерелүе хакында хәбәрдар булган. Шигырь кырына язылган «Инна лиллаһи вә инна лиллаһи рәҗүгун» дигән сүзләр әнә шул хакта сөйли. Беренче биттә шагыйрьнең исеме Мифтахетдин бине Кәмалетдин бине Мөхәммәдьяр рәвешендә язылган. Күрәсең, биредә Мифтахетдиннең үз атасы белән үги атасы бергә буталгандыр.

Чыннан да, кайбер басма һәм кульязма чыганакларга карaганда, шагыйрьнең атасы Сыр-Дәрья буендагы Акмәчет (хәзерге Кызыл Урда шәһәре) тирәсеннән Стәрлебашка килгән Мөхәммәдьяр исемле казакъ булган. Ул биредә мәдрәсә мөдәррисе Нигъмәтулла Тукаев асраулыкка алган ятимә кызга никахланган. Менә шул никахтан Мифтахетдин туган, әмма ул бала чагында ук Мөхәммәдьяр вафат булган һәм тол калган Бибигөлсем Туксанбай авылының Кәмалетдин исемле мулласына хәләл җефет була. Кәмалетдин Мифтахетдинны үз улы итеп яздыра.

Халыкта Акмулланың үлеменә карата чыгарылган бәет тә яши:

**Акмулланың арбасын**
**Ике күк ат тартадыр.**
**Акмулланың газиз башы**
**Су буенда ятадыр.**

**... Акмулланы үтергәннәр**
**Тегермән аръягында...**

Билгеле булганча, шагыйрьнең гомере фаҗигале рәвештә өзелә. Миасс имамы Сәлахетдин Сәхипзадин аңа җеназа укый, әдип Миасс зиратына җирләнә. Күпмедер вакыттан соң Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәсе хуҗасы Зәйнулла Рәсүлев аның каберенә таш яздырып куйдыра.

Тынгысыз шагыйрьнең асыл сөякләре Европа белән Азия кул бирешкән җирдә ята. Аның каберенә эз өзелми. Шигырьләре исә элеккедән дә көчле яңгыраш ала. «Акмулла бәете»ндә шундый юллар бар:

**Акмулланың китаплары**
**Торып калган Казанда...**

Бу, мөгаен, шагыйрьнең 1892 елда Казанда басылып чыккан «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» дигән китабына ишарәдер. Ул шәһәрнең мәшһүр китап магазиннарында сатылган. Башка урыннарга бик таралмаган. 1904 һәм 1907 елларда аның Казанда тагын ике китабы чыга. Халык арасында популярлык казанган бу китапларда аның тормадә язган шигырьләре һәм югарыда телгә алынган мәрсиясе урын ала. Акмулла әсәрләре телдән телгә, кулдан кулга да күчерелеп тарала.

Инде китап тышлыгында сакланган әлеге «Гыйлем эстәү турында» дигән шигырь хакында берничә сүз.

Җитмешенче елларда Галиев Җиһанша бабайдан:

**Башында акылы барга ләббәй-ләббәй**
**Баш ора кирәк Идел, кирәк Урал,**

— дигән юлларны еш ишеткәнем бар. Ул үзе революциягә кадәр казакъта мөгаллим булган, совет чорында гомере буе балалар укыткан кеше. Акмулла шигырьләрен көйли-көйли сөйли иде. Хәтерендә булган Акмулла шигырьләрен, мөнәҗәтләрен язып бирергә вәгъдә итеп йөргән көннәрдә вафат булды. Табылдык шигырьдәге «алла колы» дигән гыйбарә Акмулланың яратып әйтә торган сүзе түгелме икән? «Сүз чыгар

шагыйрьләрдән хикмәт берләң» дип башланган шигырендә дә шул ук гыйбарә бар бит. Акмуллага хас тапкырлык, образлылык әлеге кульязмада да байтак. Әсәрнең эчтәлеге шагыйрьнең тоткан мәсләгенә — мәгърифәткә өндәүгә, томаналыкка каршы чыгуга туры килә. Шигырь, бик аз сандагы гарәп һәм фарсы сүзләрен искә алмаганда, саф татарча язылган. Акмулла иҗатын өйрәнүчеләр бик хаклы рәвештә күрсәткәнчә, шагыйрь казакъ, татар, башкорт халыклары арасында аларның үз телләрендә сөйләшкән. Шигырьнең 1918 ел ахырында гына күчерелүен дә исәпкә алырга кирәктер. Яттан сөйләнә-сөйләнә ул инде шактый «татарлашкан» булырга мөмкин. Бу әсәр Мифтахетдин Акмулланың революциягә кадәр басылган китапларында да, аның 1935 елда Алма-Атада чыгарылган шигырьләр җыентыгында да юк.

Әдип иҗатына, тормышына кагылышлы һәр истәлек безгә бик кадерле. Әлеге кульязма, авторын ачыклау мөмкин булмаган тәкъдирдә дә, Акмуллага нисбәт ителүе белән, шагыйрьгә халык хөрмәтенең бер чагылышы лабаса! Шунлыктан «Гыйлем эстәү турында» Акмулла нәсихәте әдәбият сөючеләрдә әлбәттә зур кызыксыну тудыра. Биредә аның бездә билгеле текстын китерү урынлы булыр дип уйлыйм.

### Гыйлем эстәү турында

Дөньяда кайда барсаң гыйлем эстә,
Һәр заман әһле гыйлем [1] чыкар өскә.
Наданлар җарамыйдыр һич бер эшкә,
Ушбу сүзне һәр даим төшер искә.

Галимләр бу дөньяга баш булмакда,
Халыкның күз өстендә каш булмакда.
Йөрмәгел табиг улып [2] вәхшилеккә,
Наданлар ни эшләсә фаш булмакда.

Гыйлем-һөнәр адәмгә кирәк корал,
Ауганда таянырга терәк корал.
Башында гакълы барга ләббәй-ләббәй [3]
Баш ора кирәк Идел, кирәк Урал.

Гыйлем-һөнәр адәмне адашдырмай,
Юлында кыйбласыңдан [4] саташдырмай.
Наданлар дүрт аяклы ишәк кеби
Җәфа чигә уң-сулны карашдырмай.

Галим кеше тырышыр көн-төн димәс,
Җитәр инде өс-башым бөтен димәс.
Мәйданда җалган-алдау хәким чакда
Кәефләнеп җатуны һич дә сөймәс.

Ир кеше гыйлем эстәр, сабак алыр,
Ир кеше үзе үләр, даны калыр.
Ир кешенең тырышуы аркасында
Ничә җанлар рәхәтләнеп сулыш алыр.

Галимләр җәһаләткә [5] бер дә түзмәс,
Ходаның рәхмәтеңдән өмид өзмәс.
Җук гаеп казаларга түзәй-түзәй,
Ил гизә гыйлем эстәп, бәхет эзләй.

Адәмгә гыйлем, һөнәр пар канатдыр,
Дөньяда гыйлем кеше асыл затдыр.
Наданлар, беләсез бит, алла колы,
Җактыны күрәлмәгән җарканатдыр [6].

* * *

[1] Әһле гыйлем — гыйлем иясе, укымышлы кеше.
[2] Табиг улып — буйсынып.
[3] Ләббәй — «менә мин синең алдыңда» мәгънәсендә (Мәккәдә хаҗ вакытында әйтелә торган сүз). Бу урында Идел дә, Урал да укыган кешеләргә хезмәт итәргә әзер дигән дигәнне аңлата.
[4] Кыйбласы — бу урында йөз тоткан юлны, максатны белдерә.
[5] Җәһаләт — наданлык, аң-белемсезлек.
[6] Шигырь тексты гарәп хәрефләре белән язылган төп нөсхәдәгечә бирелде.

# КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ. «БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК».** Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

Соңгы елларда балалар әдәбиятында аеруча активлык сизелә. Күптән түгел генә Татарстан китап нәшриятының нәниләргә атап чыгарган шигъри «күчтәнәчләре» — Р. Фәйзуллинның «Паласны кем кагар?», Р. Миңнуллинның «Җиде абый тай җигә», М. Фәйзуллинаның «Болытсыз яңгыр», Ә. Рәшитовның «Кояш иле — бәхет иле», Җ. Дәрзамановның «Төнге мажара», Х. Халиковның «Уйныйсың киләме?» исемле җыентыклары моңа ачык дәлил.

**...Бөреләр үрли кояшка,**
**Балалар йөгерә уйнап.**
**Күчә-күчә илдән илгә**
**Май килә дөнья буйлап.**
**Даһилар кебек гади ул,**
**Гадиләр кебек тыйнак...**
**Май килә дөнья буйлап.**

Бу шигырь — әлеге «Без, без, без идек» исемле җыентыктан.

М. Әгъләмов әдәбият сөючеләргә «Учак урыннары» һәм «Исәнме, йөрәк» исемле шигырь җыентыклары белән таныш. Ул балалар матбугатында да сирәк кенә булса да матур-матур шигырьләре белән катнашып килә иде. Менә аның нәниләргә багышланган беренче китабы дөнья күрде.

Җыентык «Безнең матур дөньябыз», «Матурлык безнең белән...», «Без — табигать баласы» дип исемләнгән өч бүлектән тора. Һәр бүлек үзенең кызыклы булуы, серлелеге, матурлыгы белән, шаян һәм шул ук вакытта бераз гына мактанчык та, бераз гына хәйләкәр дә булган малайлары белән күңелне үзенә җәлеп итә.

Шагыйрь «Без», «Безнең авыл», «Без хәзер зур көч булдык», «Клубта», «Өй саклаганда» исемле шигырьләрендә балалар психологиясенең кызыклы якларын оста күрсәтә.

Алдыбызда — шагыйрь хыялында туган нәниләр дөньясы, малайлар дөньясы.

**Бабайлар көткән дөньяны**
**Күтәрлек кадәр генә.**
**Алар хыялланган илгә**
**Җитәрлек кадәр генә**

булган малайлар дисенме («Без»), авылыгызда

**— Һәммәсе бар, тик сездә**
**Космонавт юк бит,**
— диючеләргә:
**— Ә мин әйтәм: ул кадәр**
**Ашыкмагыз, дусларым,**
**Без үсәбез, сез әле**
**Онытмагыз без барын,**

— дип җавап кайтарган малайлар дисеңме, космоска очуны «бик тә җиңел мәсьәлә» дип беркатлы гына уйлаган, әмма укытучы апасы өйгә биргән мәсьәләне дә чишә алмаган Гариф дисеңме («Гариф диген бер малай»),— кыскасы, кем генә юк монда! Ул шигырьләрне үзеңнең инде күптән балалар яшеннән чыккан булуыңны да онытып укыйсың.

Китапның «Матурлык безнең белән» дип исемләнгән икенче бүлегендәге шигырьләр туган илгә, аның гүзәл табигатенә («Яшәү», «Яфрак җыры», «Инешнең илгә кайтуы», «Кечкенә легенда») шул табигатьнең назларын, иркәләүләрен тоеп үскән батырларга дан җырлый. Ул батырлар арасында Воронеж егете Ершов («Арча кыры»), Герой-шагыйрь Муса Җәлил) «(Ышаныч»), безнең көннәрдә Газинур батырлыгын кабатлаган Рифкать Миргазизов («Батырлыкның башы») кебек курку белмәс кыю ир-егетләр бар.

**Чыпчыкларга кыек — оя,**
**Бөркетләргә — биек кыя.**
**Киңлекләргә сыймый бөркет,**
**Җырга сыя...**

Шагыйрь дөньяны, табигатьне, мохитны балалар күзе белән күреп һәм аңлаешлы, йөгерек тел белән язып, безнең күз алдыбызга җанлы образларда, сурәт-картиналарда китереп бастыра белә. Менә аның «Билгесез солдат» исемле шигыре:

**Без киләбез сиңа кояшлы**
**көннәрдә,**
**Бөек нәселнең дәвамын**
**раслап.**
**Син безнең абый, син**
**безнең әти,**
**Син безнең бабай, билгесез**
**солдат.**

Тынычлык өчен көрәшеп зур яуда башларын салган батыр ватандашларыбызны онытмаска, аларның исемнәрен мәңгеләштерү йөзеннән куелган һәйкәл-обелискларны һәрвакыт кадерләп тотарга, аңа илтүче юлларне беркайчан да суытмаска шулай өнди ул.

**Җил булып истең,**
**Гөл булып үстең,**
**Син безгә күчтең, билгесез**
**солдат.**

«Без, без, без идек» — шагыйрьнең балаларга атап чыгарылган тәүге китабы. Ул нәниләр дөньясын тагын да кызыклырак, мавыктыргычрак итеп ачкан, балаларга гына хас шаянлык һәм җылы лиризм белән сугарылган шигъри күчтәнәчләре белән тагын да куандырсын иде.

**Ленарис ЛЕРОНОВ,**
Казан дәүләт университеты студенты

**Клара БУЛАТОВА. «ГЕЛ КОЯШКА КАРАП».** Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981

Нечкә күңел, табигый моң борын-борыннан хатын-кызны шагыйрә иткән. Әбиләребезнең бишек җырлары һәм бәетләре, уен көйләре һәм такмаклары-такмазалары әле дә безнең күңелләргә килеп кагыла. Бу мирас безне кешелекле итеп тәрбияли. Шатлык һәм хәсрәтләрен, өмет һәм хыялларын шигырь итеп ак кәгазь битенә күчергән шагыйрьләребез иҗаты — чорлар, заманнар кичкән шул моңның дәвамы сыман. Клара Булатова шигърияте дә әнә шундый хисле, моңлы, хыялый дөнья. Аның яңа җыентыгы белән танышу бу тәэсирне тагын көчәйтә. Мәхәббәт һәм наз, бәхет һәм сагыш, өмет һәм хыял күп бу шигырьләрдә!

**Дуслар белән бергә көлеп була,**
**Бәйрәмнең, дип, яме китмәсен.**
**Җанда тетрәнүне җиңеп була,**
**Ә йөрәк соң, йөрәк нишләсен?**

Җыентыкның бер бүлеге шушы шигырь исеме белән — «Ә йөрәк соң, йөрәк?» дип исемләнгән. Тирән кичерешле, күңелне сискәндерерлек, уйландырырлык шигырьләр байтак бу бүлектә. Шагыйрә мәхәббәт дигән серле дөньяны хатын-кызларга гына хас күңел сизгерлеге һәм җылы хис белән, үз нуры, үз балкышы белән яктыртып үтә.

«Кешегә мәдхия» дип аталган икенче бүлектә урнаштырылган шигырьләр күтәренке пафослы, оптимистик рухлы булулары белән аерылып торалар. Шагыйрә үзен уйландырган, борчыган проблемалар турында язганда, әле бөтен тавышына ук булмаса да, шактый җитди һәм кызыклы фикерләр әйтә:

**Син, табигать, безсез —**
**Гелсез, төссез.**
**Синдә аккан сулар салган эз,**
**Синдә үскән урман,**
**Төшкән томан**
**Нигә кирәк булсын Кешесез?**

Күбрәк хис кочагында онытылырга яратучы шагыйрә күңелендә фәлсәфи уйланулы, фикерле-гамьле шигырь юлларының да тууын белеп, аның өчен сөенеп куясың. Инде шәхес буларак та, шагыйрә буларак та өлгереп килүче Клара Булатованың көчлерәк, публицистик рухлырак авазын да ишетәсе килә. Кызганычка каршы, җыентыкта инде күп тапкырлар кабатлаудан төссезләнгән шигъри юллар да шактый урын алган.

**Син бер якта, мин бер якта,**
**Бергә чаклар еракта...**
яки:
**Беребез анда, беребез монда,**
**Җырдагы кебек кенә...**

— шикелле юлларның ачышы юк. Алар ничек җиңел укылсалар, шулай тиз онытылалар да.

Каен — күп шагыйрьләрнең, шул исәптән Клара Булатованың да, яратып куллана торган символы. «Каен кызы сары толымкай»лар турында инде ул күп матур шигырьләр язган иде. Шулардан соң каен турында менә тагы бер яңа шигырь:

**Сер салган тәлгәш — төен ул,**
**Ачылмый бөре сыман.**
**Кан булып эчкә урнашкан**
**Кыз-хатын сере сыман.**

Әллә нинди урынсыз һәм ямьсез чагыштыру бит бу...

Ләкин шагыйрәнең иң уңышсыз, иң йомшак шигырьләре, минемчә, «Ана җыры» дип исемләнгән бүлеккә урнаштырылган. Коры санап китү, такмаклау, төче соклану бу циклга кергән күп шигырьләргә хас.

**Ал тирәктер, гөл тирәктер,**
**Чәчәкләрдер, гөлләрдер,**
**Сандугачтыр, карлыгачтыр,**
**Тагы әллә кемнәрдер.**

Катлаулы һәм хәвефле заманда, һәр яңа туган бала башына дистәләгән үлем коралы туры килгән гасырда, ай-һай, ана кеше йөрәгендә мондый төче соклanулар гына тантана итәме икән?! Һәм шунысы кызганыч — бу очраклы рәвештә генә язылган шигырь түгел. Хисләрне ваклау, фикерне өстән-өстән генә, информация өчен генә, мәгънәсенә төшенми генә әйтеп үтү, сүзнең кадерен, кыйммәтен җую шигырьдән-шигырьгә күчеп, тулы бер бүлекне (бәлки, шагыйрә иҗатының бер тармагын?) биләп ала. Ана буларак, шагыйрә һәм гражданин буларак та дөнья турында, бала язмышы турында фикер йөртү кайда? Мондый шигырьләр укучыны уйландыра, тетрәндерә, сагайта алмыйлар...

Бәлки шагыйрәгә дөньяны танып-белү чикләрен географик яктан да бераз киңәйтеп, ил-җирне зуррак масштабта күрергә, өйрәнергә кирәктер? Әнә бит ул үзе дә бер шигырендә:

**Бирегез канатлар,**
**Биеклеккә ашыйм,**
**Яңа йолдыз ачыйм,**
**Яңа дөнья ясыйм!**

— дип рухланып-илһамланып дәшә, әле хыялында гына күзаллаган зур дөнья, үзе өчен яңа дөнья ачарга омтыла.

Шагыйрәләребезнең карашын, тар стеналар белән чикләнмичә, зуррак биеклектә, киңрәк офыклы итеп күрәсе килә. Дөнья күләмендә танылган Нәдирә һәм Зөлфияләр, Марина Цветаева һәм Сильва Капутикяннар иҗатын нәкъ менә мөһим фикер һәм тансык хис канатлары күтәрә бит!..

**Фәүзия БӘЙРӘМОВА.**

●

**Хәкимҗан ХАЛИКОВ. «УЙНЫЙСЫҢ КИЛӘМЕ?»** Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

Ничектер шулай гадәткә кергән: балалар әдәбияты турында сөйләшкәндә без, гадәттә, проза һәм поэзия өлкәсендәге уңышларны гына санап китүчәнбез. Драматургия жанры бөтенләй читтә кала. Хәер, балалар өчен сәхнә әсәре аз языла яки бөтенләй язылмый икән, әлеге дәшми калуны аңларга да мөмкин.

Әмма бүген — балалар драматургиясе сүрелә төшкән заманда — дөресен әйтергә кирәк, дәшмәвебез мактанырлык хәл түгел. Мәктәп укучыларының сәхнәдә кую өчен язылган яңа китапларны «чыра яндырып» эзләүләре һәркемне борчырга тиештер.

Х. Халиковның «Уйныйсың киләме?» дип исемләнгән китабы иң әүвәл әнә шул хакта уйландыра. Сәхнә уеннарын берләштергән бу китап яшь укучылар өчен кирәкле һәм файдалы бүләк булган. Безнең карашыбызча, балалар әдәбиятының чикләрен, офыкларын киңәйтүдә автор күркәм эш башкарган. Китапның үзенчәлеге нәрсәдә соң? Әдәбиятка һәм сабыйлар дөньясына ул нинди яңалык алып килә? Инде хәзер шушы сорауларга җавап табарга тырышып карыйк.

Иң элек уен турында берничә сүз. Билгеле булганча, уен ул — дөньяны, тормышны, тирә-юньне өйрәнү һәм танып-белүнең үтемле бер чарасы. Уенның тарихы ерак гасырларга китә. Борынгы йола биюләрен генә искә төшерик: никадәрле уен элементлары анда! Заманында философлар уен беренчелме, әллә хезмәт беренчелме дип юкка гына бәхәсләшмәгәннәр, күрәсең. Уен кешелекнең сабый чагыннан ук билгеле. Бүгенге балалар да аннсыз яши алмый. Бу урында сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның «Эш беткәч, уйнарга ярый» дигән хикмәтле сүзләре ирексездән искә төшә. Х. Халиков бүгенге көн балаларына «Уйныйсың киләме?» дип мөрәҗәгать итә икән, бу да бик табигый янгырый.

Алдан ук әйтеп китик, китапка кертелгән әсәрләр сәхнәдә уйнар өчен дә, автор тәкъдим иткәнчә, «су буенда, урманда, ачык урында уйнар өчен» дә бик кулай. Рәссам Рәис Шакирҗанов исә кайсы герой ничек киенергә тиешлекне китапта төсле рәсемнәр белән шактый отышлы итеп күрсәтеп биргән.

Табигать — тормышыбызның аерылгысыз бер өлеше. Ул — байлык һәм матурлык чыганагы. Аны сакларга яратырга кирәк. Бу җәһәттән «Чәчәк җыйганда» һәм «Нинди кош?» уеннарының тәрбияви әһәмияте шунда: алар нәкъ менә табигатькә карата шәфкатьле, рәхимле булырга өйрәтәләр. Болындагы чәчәкләрне кемдер өзеп бетерә икән, дөньяның ни яме калыр? Шуңа күрә дә андый усалларның кулын бал корты чага, аларга «җәза» бирә:

**Кирәксезгә чәчәк өзеп**
**Йөрмәссезме моннан соң?**
**Берсен генә өзсәгез дә**
**Үпкәләштән булмасын!**

Шунысы куанычлы, китапны укыган саен сагындырган, инде онытыла башлаган тукранбаш, күкчәчәк, карабодай кебек үсемлекләр һәм күке, тартар, бытбылдык, шәүләгән, ярканат, көртлек кебек кошлар дөньясына килеп керәсең. Табигатькә сусау арта, урмандагы кошлар хоры күңелеңә күчә. Шушы хисләрне кичергәннән соң табигатьне яратмый кара син! Әнә бит, «аучылар» да кошларга ни диләр:

**Усал малай икән бу дип**
**Уйлый күрмәгез, яме.**
**Безнең янда беркайчан да**
**Куркып йөрмәгез, яме!**

Юлга чыксаң, иптәшең үзеңнән әйбәтрәк булсын, ди халык мәкале. Әлеге сүзләрне «Юлчы бабай юлдаш эзли», дигән әсәргә, эпиграф итеп куярга мөмкиндер. Юлчы бабай — тәҗрибәле, дөнья күргән кеше, ул үзенә юлдаш итеп теләсә кемне алмый. Аңа Кыю, Зирәк, Көләч, Тугры, Тыйнаклар гына иш була ала. Уенда Әләкче, Куркак, Ялагай, Астыртын һәм ялкауларның чын йөзе фаш ителә. Шулай итеп, автор кешедәге яхшы сыйфатларны сәнгатьчә зурлый һәм пропагандалый, тискәре күренешләрне тәнкыйть уты белән көйдерә. Бәхеткә каршы, кайбер очракларны искә алмаганда, язучы бу фикерләрен үгет-нәсихәт тәлинкәсенә салып бирми, яшь укучы нәтиҗәне үзе чыгарсынга урын калдыра. Гомумән, яшь буында дөреслек һәм гаделлек хисе тәрбияләү китапның кешелекле омтылышын, төп идея-эстетик юнәлешен билгели.

Балалар өчен язылган әсәрләр, кем әйтмешли, «җырлап» торырга тиеш. Бу җәһәттән караганда китапка тел-теш тидерерлек түгел. Шигырьләрнең музыкаль һәм сыгылмалы тел белән язылган булуы укуны җиңеләйтә, балаларның сөйләм осталыгын үстерүгә булышлык итә.

Китап уйландыра, көлдерә, җирдә әле «Әйдә Ярар» дигән ваемсыз һәм хәйләкәр зат барлыгын да искә төшерә. Әлеге зат күп кенә октябрятларны төп башына утыртмакчы, үз ягына аудармакчы була, әмма юкка тырыша. Инде аптырагач, Әйдә Ярар залдагыларга мөрәҗәгать итә:

**Арагызда минем дуслар,—**
**Ваемсызлар юкмы соң?**

Менә шулчак тамашачыларның: «...Дусларыңны бүтән җирдән эзлә»,— дип әйтүе, әсәрнең шушы пассив тон белән тәмамлануы гына күңелдә канәгатьсезлек хисе калдыра, инде никадәрле яхшылыкка өйрәтеп өлгергән язучының абруена күләгә төшерә. Педагогик чикләнгәнлек әсәрнең кыйммәтен киметкән, әлбәттә.

Сүзнең ахырында тагын кайбер теләкләр белән дә уртаклашасы килә. Күп кенә уеннарның (мәсәлән, «Кем тизрәк таба?») артык гади һәм гадәти вакыйгаларга корылган булуы, аларның тәэсир көчен кимetә, сәнгатьчелек дәрәҗәсенә зыян китерә. Әсәрләрнең күбесе, балалар табигатьне танып белсен һәм яратып үссен, дигән изге ният белән язылган. Шул сәбәпле булса кирәк, автор җиргә, тормыш фактларына «ябышып» ята. Ә бит бүгенге көн баласы өчен фантазия дә, көтелмәгән вакыйгалар, кискен борылышлар да бик кирәк! «Уен дәвам итә». Китаптагы әсәрләрнең күбесе әнә шул сүзләр белән тәмамлана. Әйе, уен гына түгел, иҗат та, әдәби осталык серләренә төшенү процессы да дәвам итә. Димәк, балалар әдәбиятын үстерүдә инде ничә еллар актив эшләп килүче Х. Халиковтан киләчәктә тагын да кызыклырак, тагын да яхшырак әсәрләр көтәргә нигез бар.

Шат БӘДИГОВ.

# Г. НИЯЗБАЕВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Драматург Габдерәүф Ниязбаев 1881 елның 3 декабрендә Оренбург өлкәсенең Сәет бистәсендә (Оренбург Каргаласында) Хәкимбай исемле крестьян гаиләсендә туа. Авыл мәктәбендә берничә ел укыганнан соң, Казанга килеп Татарская учительская школага керә. Габдерәүф бу мәктәпнең алдынгы укучылары белән бергә, революцион хәрәкәттә актив катнаша, күренекле большевик Хөсәен Ямашев белән якыннан таныш була.

Беренче рус революциясе бастырылганнан соң, Г. Ниязбаев Урта Азиягә китә. Ләкин анда кулга алына һәм өч ел буе тикшерүсез-нисез төрмәдә утыра. Бездә Г. Ниязбаевның 1911 елның 11 сентябрендә Ташкент төрмәсеннән әнисенә язган хаты саклана. Анда ул төрмәдәге хәлен аңлата, туганнарының ешрак хат язуын үтенә.

«Хөрмәтле газиз әнкәем! Рамазан шәриф илән тәбрик итәмен,— дип яза Габдерәүф. — Үзем, әлхәмделилла, бик сәламәтмен. Бүген миңа игълан кылдылар: 9 сентябрьдән башлап минем эшем Туркестанский военный окружной судка күчте, диң. Хәзергә обвинительный акт алганым юк әле. Судның кайчан булачагын анык белмәсәм дә, эш судка күчкәч, тиздән булыр дип уйлыйм. Ни булса да шушы бер-ике ай эчендә булып калыр инде...».

Күрәсең, хәрби суд аны коткармаган, сәяси эштә гаепләп, берничә елга хөкем иткән булса кирәк. Чөнки яңа революцион күтәрелеш елларында да, соңыннан да Ниязбаевның исеме матбугатта телгә алынмый.

Драматургның иҗат биографиясен ачыкларга ярдәм итүче тагын бер кызыклы документ — Беренче революцион армиянең политик бүлеге белән төзелгән килешү табылды.

Гражданнар сугышы елларында революцион үзгәрешләр белән рухланган Г. Ниязбаев ике-өч ел эчендә «Беренче таң», «Борадәран Галимевләр» («Көчле вә көчсезләр»), «Кызыл истигъбаль өчен көрәш», «Кара көннәр» һәм «Гөлбостан» исемле биш пьеса яза. «Кызыл истигъбаль өчен көрәш» драмасы 1919—1920 елларда Оренбургта яшәгән артистка Н. П. Анненкова-Бернар тарафыннан русчага тәрҗемә ителә. «Борадәран Галимевләр» драмасын сәхнәгә беренче кат 1918 елның маенда Г. Кариев идарәсендәге татар театры куя. Аның белдерүендә: «Татар сәхнәсендә беренче мәртәбә яңа әсәр. Үз тормышыбыздан. «Борадәран Галимевләр». Драма дүрт пәрдәдә. Рәүф Ниязбаев әсәре. 4 нче пәрдәдә Борадәран Галимевләр утарында эшчеләр бәйрәмендә яхшы җырчылар авыл җырларын һәм яхшы биючеләр тарафыннан авыл биюләре иҗерә ителәчәк»,— дип языла. Бу исә әлеге постановкада музыкаль номерлар байтак булган дигән сүз.

1918 елның беренче яртысында «Сәйяр» труппасы Ф. Бурнашның «Таһир һәм Зөһрә», М. Фәйзинең «Галиябану», Г. Ниязбаевның «Борадәран Галимевләр» музыкаль драмаларын куя. Ягъни, музыкаль драмаларны кую башлана. Дөрес, соңгысын чын музыкаль драма дип әйтүе читенрәк әле, чөнки белдерүгә карап кына, музыкаль номерларның пьесага табигый рәвештә керәме, юкмы икәнлеген ачыклап булмый. Һәрхәлдә, эшчеләр бәйрәмендә җырлап-биеп күңел ачу күренеше драматик пьеса кысаларын киңәйтә төшә һәм төрләндерә.

Мәгариф эшчеләре бик кирәк вакытта авылга китеп, Г. Ниязбаев җиң сызганып эшкә керешә. Кызганычка каршы, татар халкының талантлы улы озын гомерле булмый. 1920 елның 18 апрелендә Ямансар авылында тиф авыруыннан үлеп китә. «Мәгариф эшләре» журналы 1920 елгы 5—6 саннарында: «Мәшһүр драматургларыбыздан Габдерәүф иптәш Ниязбаев тиф авыруы белән үлде. Җәсады Каргалы шәһәренә күчерелеп, 21 апрельдә тантаналы сурәттә дәфен кылынды», — дип яза.

ХӘСӘН ГОБӘЙДУЛЛИН.

# ЯРЛЫ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

„Шагыйрь Ярлы Кәрим. Гражданнар сугышы чорында исеме шактый таралган шагыйрьләрнең берсе. Халык үзе дә ярлы, шагыйре дә ярлы...» — дип язган иде Сибгат Хәким үзенең бер мәкаләсендә.

Ярлы Кәрим — илдә Совет власте урнаштыру өчен көрәш барган, гражданнар сугышы ялкыны дөрләгән чорда әдәбият мәйданына килеп, бөтен тормышы һәм иҗаты белән революцион яңарыш хәрәкәтен яклашкан шагыйрь.

Ул җырларда җырланган ямьле Дим буйларында, элекке Бәләбәй өязенең Ает авылында туган. Җыр-шигырь яраткан гаиләдә, шигъри күңелле кешеләр арасында тәрбияләнгән. Тома сукыр әтиләре Әхмәтвәли агай үзе өчен генә чыгарган шигырьләрен укыштыргалаган, әниләре Мәрьям апа да башкалардан ишереп кенә күңелендәге уйларны, Дим буе табигатен тасвирлап шигырь язган. Шуңа күрәдер инде бу гаиләдә янә бер шагыйрь — «Үлем турында уйлама, илең турында уйла» дип, ут эченә кергән солдат-шагыйрь Фатих Кәрим дә үсә.

Ярлы Кәрим (Габдулла Кәримов) кече яшьтән үк зирәк акыллы, укуга һәвәс була. Башта ул мәхәллә мәктәбендә, аннары Оренбургтагы Хөсәения мәдрәсәсендә белем ала. Ләкин хөр күңелле үсмер егет бу тормышны изге китаплардан гына өйрәнеп булмасын яхшы аңлый. Октябрь революциясенең беренче көннәреннән үк мәдрәсәне калдырып, ул Совет властен ныгыту өчен көрәш мәйданына юл ала. 1919 елда Коммунистлар партиясенә керә. Кызылармиячеләр арасында политик тәрбия һәм агитация-пропаганда эшләре алып бара. Петроградны акгвардиячe юлбасарлардан саклауда катнаша һәм каты яралана.

Ярлы Кәрим үзенең көрәшкә чакыру авазы булып яңгыраган шигырьләрен хәрби частьләрдә яза, кызылармиячеләр алдында укый, беренче әсәрләрен Төркестан фронтында чыга торган хәрби газета битләрендә бастыра. Шул чорда ул иң актив журналист һәм популяр шагыйрь булып таныла.

Армиядән соң Ярлы Кәрим газета редакциясендә эшли, Мәскәүдә Көнчыгыш хезмәт ияләренең Коммунистик университетында укый, әдәби иҗат белән шөгыльләнүен дәвам итә. Әмма мәкерле дошман белән көрәштә алган яралар шагыйрьгә тынычлык бирмиләр: аның гомер юлы яшьли, иҗаты чәчәк аткан чорда өзелә.

Ярлы Кәрим — энесе Фатих Кәрим кебек үк, үлем турында уйламыйча, җаны-тәне белән ил язмышын кайгыртышкан, иҗаты белән үлемсезлек яулаган шагыйрь. Татар һәм башкорт халыкларының уртак рухи хәзинәсенә кергән бу шигъри мирас хәзерге заман укучысына легендар елларның революцион көрәш аһәңен җиткерә.

# АЛЬБЕРТ ЯХИНГА 50 ЯШЬ

Кеше дөньяда яшәү серен гомер буе кешеләрдән өйрәнә. Бу мәгълүм хакыйкатьне мин дусларым, иптәшләрем, танышларым турында сөйләгәндә кабат-кабат исемә төшерәм. Күңелем тупасланып китеп кемнедер урынсызга рәнҗетәм икән, йомшак күңелле дустым тәнкыйтьләп, оялтып, ялгышымны төзәтергә ярдәм итә, зирәк акыллы өлкән дустымнан сабырлыкка, төптән уйлап эшләү серләренә өйрәнәм, туктаусыз янып торган тынгысыз дустым үзенең мисалында ялкаулыктан, үшәнлектән арынырга булыша.

Альберт Яхинны белә белгәннән бирле мин аның турылыгына сокланып яшим. «Турылык» төшенчәсенең мәгънәсе бик киң һәм ул төрле очракта төрле сыйфатта ачыла. Турылыкның бөтен сыйфатлары да Альберт характерында ачык күренә дисәм, аны яхшы белгәннәр минем белән килешерләр дип уйлыйм. Юлдаш икән — ул чын мәгънәсендә юлдаш: бар авырлыкны үз өстенә алыр. Дус икән — инде чын дус, саф дус, дуслык белән ашналыкне беркайчан да бутамый торган кеше. Дус булып күренергә генә теләүчеләрне тиз танып алыр.

Вәгъдәсенә Альберт һәрвакыт турылыклы. Вакытын, тынычлыгын, тормыш уңайлыкларын корбан итеп булса да, биргән сүзендә тора. Шунысы да бар, гаҗәеп ярдәмчел кеше булуына карамастан, ул теләсә кайчан теләсә нинди вәгъдә бирергә ашыкмый. Үтенеч бары тик гадел үтенеч булырга тиеш. Чөнки Альберт Яхин һәртөрле гаделсезлекнең явыз дошманы. Гаделсезлекне ул эрегә, вакка булми һәм ул мәсьәләдә бернинди компромисска бармый. Дөресен әйтик, гаделлекне яклау, аның өчен көрәшү мәсьәләсендә артык принципиаль кешеләрне кайберәүләр өнәп ук бетермиләр. «Яши белеп» яшәүчеләр тормышның катлаулылыгын, кешеләрнең әулия түгеллеген сылтау итеп, андыйлар хакында мыскыллабрак сөйлиләр, җае килгәндә алар аның бәләкәй генә ялгышын да җинаять дәрәҗәсенә күтәрәләр. Бәхеткә каршы, безнең җәмгыятьнең тормыш принциплары гаделлекне яклауга корылган, һәм, табигый, Альберт Яхин кебек кешеләр җитди «кыйналулардан» сакланып киләләр. Өстәвенә, гаделлек өчен көрәшүчеләр үзләре дә оптимист булалар...

Галим һәм язучы турында аның кешелек сыйфатларына болай киң тукталу биредә юкка түгел. Чөнки чын язучы үзенең күңелендә язылганнарны гына кәгазьгә күчереп бара.

Әгәр дә Альберт Яхинның кандидатлык диссертациясе Шамил Усманов һәм аның иҗаты хакында икән, моны һич тә очраклы тема дип әйтеп булмый. Фәннәр кандидаты дигән исем алу өчен генә язылмаган ул диссертация. Гражданнар сугышы каһарманы, 19 яшеннән полк комиссары, ялкынлы публицист, көчле рухлы коммунист, гомеренең соңгы минутына чаклы Ватанга, халыкка, партиягә турылыклы булып калган Шамил Усманов турында сокланып сөйләү яшь аспирантның рухи ихтыяҗы булган. Соңрак әлеге героик образ Альберт Яхинның Аяз Гыйләҗев белән бергә язган драмада Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә күтәрелде. Озак вакыт зур уңыш белән барды ул спектакль. Шамил Усманов кебек шәхесләр турында пьеса язу җиңел түгел. Монда төрле уен-көлке, буш мәзәкләр белән тамашачының игътибарын җәлеп итәм дисәң, герой үзе дә вакланып кала. Сәхнәдән герой дип әйткәнгә генә тамашачының исе китми. Геройның геройлыгын тормыш детальләре аша, характер сыйфатлары белән ышандырып күрсәтергә кирәк. «Шамил Усманов» спектакле безне ышандырды, дулкынландырды. Драманы иҗат итүчеләрнең күңелләрендәге хис сәхнәдәге образ аша безнең күңелләргә күчте, рухыбызны баетты.

Альберт Яхин — алты дистәдән артык сатирик хикәя авторы. Иҗатын тулысы белән сатира жанрына багышлаган башка язучы бездә юк диярлек. Ул юклыкның төрлетөрле сәбәпләрен санап тормыйча, сатира жанрының шактый ук четерекле жанр икәнен кабатлап әйтү дә җитә. Күрер күзгә кыска булып күренгән хикәягә үткен, төгәл фикер салу өчен аерым бер осталык һәм мәгълүм дәрәҗәдә егетлек тә кирәк, көлә белеп көлү өчен күңелеңнең саф булуы кирәк. Урынсызга көлеп гөнаһсыз кешеләрне рәнҗетүең бар. А. Яхин гөнаһлары булган кешеләрдән генә көлә, усал итеп көлә, мәгънәле итеп көлә. Шуңа күрә аның хикәяләре кешелекле хикәяләр. Кешеләрне безнең җәмгыятебезнең гуманистик рухында тәрбияләүче хикәяләр.

Язучы тормышны өйрәнергә тиеш дип кат-кат сөйлибез. һәм ул шулай да. Фараз кылып кына бәлки ни дә булса язып буладыр. Әмма андый «әсәр»ләрнең кемгә кирәге бар? Автор фантазиягә ничаклы гына бай булса да, язганының төбендә тормыш дөреслеге ятмаса, фантазия җимеше пешмәгән, өлгермәгән була. Альберт Яхин «Чаян» журналында уналты ел буе (баштa җаваплы секретарь, аннары баш редактор булып) эшләү чорында журналга әдәби әсәр китерүче фантазер авторларга шул хакыйкатьне кабатлап торды. Ул үзе тормышны тирәннән белә һәм аңлый торган кеше. Колхозда комбайнчы булып эшләгәндә, мәктәптә укытканда тормышның үзәгендә булган кеше. Баш редактор буларак бүтәннәр язган фельетоннарга кул куеп кына утырмады, командировкага йөрде, геройлары белән күзгә-күз очрашты. Йөздән артык фельетонында безгә намус белән яшәргә комачаулаучылардан фельетон теле белән көлде. Фельетоннарда конкрет кешеләрнең конкрет гаепләре тәнкыйтьләнсә, Альбертның хикәяләрендәге әдәби образлар аша без гомумиләштерелгән социаль типлар белән очрашабыз, аларны танып белергә, яхшыны яманнан аерырга һәм начарга каршы көрәшергә өйрәнәбез.

«РСФСРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем дә аңа сатира жанрында актив һәм нәтиҗәле эшләгәне өчен, ягъни гаделлекне көрәшеп яклаган өчен бирелде.

Шунысы кызганыч, соңгы елларда Альберт хикәяләр язмый башлады. Аның җитди сәбәбе дә бар — ул гыйльми хезмәт язу белән мәшгуль. Хезмәтенең ни турында икәнен әйтсәм, юбиляр ачуланмас дип уйлыйм. Кыскасы, болай: дөньяда фольклор дип атала торган әдәбият бар. Гасырлар буенча исеме билгеле булмаган авторлар иҗат иткән бу әдәбиятны меңләгән галимнәр тикшереп, өйрәнеп киләләр. Менә шул гаҗәеп бай әдәбиятны өйрәнгәндә күп кенә очракта фәнни дәлилләү җитешми. Кем ничек булдыра ала шулай аңлата. Ә бит һәр фәннең беркем дә боза алмый торган закончалыклары була. Альберт Яхин фольклорның да эчке закончалыклары бар дип саный һәм аны фәнни методлар белән өйрәнә. Моның өчен халык авыз иҗатын яхшы белү генә җитми, социология, философия, психология, логика дигән фәннәрне, хәтта математиканы белү дә зарур. Катлаулы хезмәт. Хәер, Альберт Яхин җиңел эшкә алынмый инде ул. Мин аңа уңышлар телим. Бәхет телим. Аны хөрмәт иткән кешеләрнең тагын да күбрәк булуын телим.

**ТУФАН МИҢНУЛЛИН.**

# МӘРЬЯМ РАХМАНКУЛОВАГА 80 ЯШЬ

Мәскәү. 1957 ел, 19 май. Казан вокзалы. Татар әдәбияты һәм сәнгате ункөнлегендә катнашучыларны башкалабызның танылган сәнгать эшлеклеләре каршы ала. Очрашу митингысында мәскәүлеләрне сәламләү, аларга җавап сүзен әйтү Мәрьям Рахманкуловага тапшырыла. Бу хәл һич тә очраклы түгел, чөнки Мәрьям Рахманкулованың тормышы һәм иҗаты татар совет профессиональ музыкасының үсешеннән аерылгысыз. Ул — профессиональ музыка сәнгатебезгә нигез салучыларның берсе.

Кем булырга? Тормышта үз юлыңны ничек табарга? Аның алдында бу сораулар тормаган. Табигать Мәрьям Рахманкуловага матур тавыш, моң, талант кына түгел, ә шуларга өстәп, тырышлык һәм хезмәт сөючәнлекне дә юмарт бүләк иткән.

Татар әдәбиятының күренекле эшлеклеләре аны бик иртә күреп алып, олы сәнгать кыйбласына юнәлдергәннәр. Ундүрт яшьлек Мәрьям Рахманкулованың җырлавын Фатыйх Әмирхан тыңлаган, шул хакта язып чыккан. Габдулла Тукай нәни Мәрьямнең абыйсы — әдип, җырчы Солтан Рахманкулый белән дус булган. Рахманкуловлар өендәге иҗади атмосфераны күз алдына китерүе кыен түгел. Бөек шагыйрь килде исә, өйдә җыр, музыка хөкем сөрә. Солтан мандолинада уйнап җырлый. Ара-тирә җырга Мәрьям дә кушыла. Аннан өлкәннәр җыр, музыка, халык иҗаты турында озак-озак сөйләшәләр. Болар барысы да булачак артистканың сизгер күңелендә тирән эз калдырган. Сәнгатьне бирелеп ярату, үз хезмәтең белән кешеләрне гүзәллек дөньясына алып керү эстафетасын Рахманкулова халкыбызның хөрмәтле шагыйре Габдулла Тукайдан, шагыйрьнең замандашлары һәм дуслары — алдынгы карашлы яшьләрдән кабул итә. 1916 елдан башлап — Мәрьям Рахманкулова сәхнәдә. Башта ул халык көйләрен оста башкаруы белән танылә. Моңа ирешүдә, әлбәттә, балачакта авылда еш булуы, авыл гармунчыларын, авыл җырчыларын бирелеп тыңлавы, халык моңнарын йөрәгенә сеңдереп үсүе сәбәпче булгандыр. Ул балачактан ук үзе ишеткән җырларның сүзләрен җыя килә. Үсә төшкәч Габдулла Тукай шигырьләрен көйгә салып җырлый. Гомере буена халык талантларының үзенчәлекле моңына колак сала.

«Республикабыз районнарына чыгып, халык җырчыларын тыңлаганда, моңарчы миңа таныш булмаган гүзәл үзенчәлекләрне, җырлауның яңа алымнарын ишетәм. Халык иҗатының һаман тудылана баруына, халык фантазиясенең чиксез бай булуына таң калам. Һәр очрашу мине рухландыра һәм алдыма зур җаваплылык куя»,— ди Рахманкулова. Ул 1946 нчы елда композитор Заһид Хәбибуллин, Александр Ключарев белән

бергә музыкаль фольклор җыю экспедициясенә чыгып әлегәчә ишетелмәгән байтак кына көйләр алып кайта, аларны җырчыларга тәкъдим итә, үзе дә җырлый. Аның һәр көйнең үзенчәлеген таба, җырлавында халыкның күңел көрлеген ача белгән оста җырчы булуына өстәп, хөрмәткә лаеклы тагын бер үзенчәлеген әйтеп үтәсе килә. Мәрьям Рахманкулова көйләргә тиң тирән эчтәлекле матур сүзләр таба белә.

Аның бу тәҗрибәсен 1920—1980 елларда үзе белән бергә радиода җырлаган Гөлсем Сөләйманова, Мөхәммәт Сафин да хуплап кабул итте: һәр көйнең исеменә, яңгырашына әһәмият биреп, куплетларның бер-берсе белән бәйләнештә булуына омтылдылар. Еллар үтү белән бу хәл җырларда сюжетлылыкны тудырды.

Халык арасында киң таралган «Алмагачлары» көенә нинди генә сүзләр җырланмый. Әлеге «таушалган», «урам» көенә Рахманкулова үзенә күрә сюжетлы, көйнең исеменә бәйләнешле сүзләр сайлый. Ул сүзләр белән көйне яшь күңелнең беренче мәхәббәте итеп кабул итәсең. Шул ук вакыта җырдагы юмор да елмайдыра.

**Алмагачның агачыннан**
**Кашык юнды ул миңа;**
**Нарасый бала чакта ук**
**Гашыйк булды ул миңа.**

«Алмагачлары» көенә Мәрьям яңа саф сулыш өрде. Үзенчәлекле көйгә ул матур, эчтәлекле сүзләр тапкан. Шундый матур, зәвыклы итеп җырлый да. Мәрьямнән соң «Алмагачлар»ны җырларга минем батырлыгым җитми. Аның кебек өздереп җырлый алмам шикелле»,— ди Гөлсем Сөләйманова.

Еллар үткән саен М. Рахманкулованың иҗат колачы киңәя. Репертуарына сәнгать мәйданына чыга барган яңа татар композиторларының әсәрләре өстәлә. Махсус музыкаль белем алган беренче татар профессиональ җырчыларыннан берсе Мәрьям Рахманкулова Бетховен, Шуберт, Чайковский романсларын татар телендә җырлый. Рус, француз революцион җырлары, рус һәм башка милләт совет композиторларының яңа җырлары аның башкаруында яңа тормышка өндәү булып яңгырыйлар.

1927—1933 нче еллар — Мәрьям Рахманкулованың радиода гаҗәп бер иҗади ялкынлану белән эшләү чоры. Ул елларда радиода артистлар турыдан-туры микрофон алдында җырлыйлар иде. Мәрьям Рахманкулова бүген, әйтик, татар, башкорт көйләрен җырлый, ә икенче көнне сүзләрен үзе үк тәрҗемә итеп Европа һәм рус классиклары әсәрләрен башкара, үзбәк көйләре белән таныштыра. Ә киләсе концертта яшьтәшләре Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаровның яңа җырларын өйрәтә. Радиодан җыр өйрәтүне Рахманкулова башлап җибәрә.

Яшь артистка үзен интернациональ рухлы, бай репертуарлы җырчы итеп тә таныта. Аның программалары, тыңлаучылары музыкаль зәвыгын камилләштерү, гомуми культурасын киңәйтүне күздә тотып, һаман байый килә.

Җырчы тавышы — даими тәрбиягә мохтаҗ, үтә саклык һәм игътибар белән эш итүне таләп итүчән музыка коралы. Җырчы — әнә шул назлы музыка коралының серләренә төшенгән, тавыштан файдалану техникасын яхшы үзләштергән, тавышны саклый белгән, аны көндәм итеп тәрбияләгән сәнгать остасы. М. Рахманкулованың меццо-сопрано тавышы югарыга иркен күтәрелә, түбән регистрда хәтфәдәй йомшак, куе, тигез агыла. Ә кайбер әсәрләрдә ул тавыш бик җитез агыла һәм житезлеге, җиңеллеге белән оста чигелгән нәфис бизәкләрне хәтерләтә. Аның әле хәзер дә көр, тигез булуына сокланасың.

Үзенең иҗат бәйрәмен каршылаган көннәрдә Рахманкулова «Борынгы татар халык көйләре» җыентыгын матбугат өчен хәзерләде. Анда әле моңарчы ишетелмәгән 20 дән артык көйнең ноталары, сүзләре, көйләргә аңлатмалары тупланган.

Мәрьям Рахманкулова — татар опера сәнгатенә нигез салучыларның берсе. Опера театрыбыз ачылган көннән алып, ул 20 ел эчендә татар, рус һәм Европа композиторларының опералары буенча куелган спектакльләрдә 21 образ иҗат итә.

РСФСРның һәм Татарстанның халык артисткасы Мәрьям Рахманкулованың 65 еллык иҗаты — татар совет музыка сәнгате үсешендә якты бер сәхифә ул.

**ЗӘЙНӘП ХӘЙРУЛЛИНА.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## КАЗАНДА КИНО СӘНГАТЕ БӘЙРӘМЕ

XII Мәскәү халыкара кинофестивалендә катнашучы бер төркем чит ил кунаклары Казанга килде. Аларны аэропортта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, партиянең шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова, ТАССРның кинофикация дәүләт комитеты председателе В. Н. Макаров, ТАССР Кинематографистлар союзының беренче секретаре И. Н. Алексеев, республикабыз башкаласының җәмәгать оешмалары, производство һәм иҗат коллективлары вәкилләре каршылады.

Шул ук көнне «Татарстан» кинотеатрында фестиваль фильмнары күрсәтелә башлады. Тантананы халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты секретаре Л. Г. Космылина ачты. «Совинтерфест» вәкиле Тамара Белецкая залдагы тамашачыларны фестиваль кунаклары белән таныштырып чыкты, Болгариядән, Палестинаны азат итү оешмасыннан, Бөекбританиядән, Венесуэладан, Көнбатыш Берлиннан килгән кино сәнгате эшлеклеләренең иҗатлары турында сөйләде. Кунаклар исеменнән Болгария вәкиле, кинотәнкыйтьчесе Вера Найденова чыгыш ясады. Ул Татарстан башкаласында үзләрен җылы каршылаулары өчен рәхмәт әйтте, бу фестивальнең тынычлыкны, халыклар арасында дуслыкны ныгытуда матур бер өлеш булачагына ышаныч белдерде. Кичәнең икенче өлешендә Болгария кинемотаграфистлары иҗат иткән «Тырново шаһинәсе» һәм Япониядә эшләнгән «Кабахәтләр» исемле нәфис фильмнар күрсәтелде.

Икенче көнне фестиваль кунаклары Казан белән таныштылар. Иң элек аларны Казан шәһәр Советы башкарма комитетында кабул иттеләр. Башкарма комитет председателе А. И. Бондаренко кунакларга шәһәрнең узганы һәм бүгенгесе, аның үсеш юллары турында сөйләде. Аннары кунаклар В. И. Ленинның музей-йортында, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында һәм Казанның башка истәлекле урыннарында булдылар.

Казанлылар «Родина», «Татарстан», «Комсомолец» һәм «Идел» кинотеатрларында XII Мәскәү халыкара кинофестивале фильмнары белән таныштылар. Алар Болгария, Испания, АКШ, Франция, Япония, ГФР, Һиндстан кинемотаграфистлары төшергән нәфис фильмнарны яратып карадылар, кунаклар белән очраштылар.

## БҮЛӘКЛӘР ТАПШЫРЫЛДЫ

Билгеле булганча, быел апрель аенда, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карары белән, язучы Атилла Расихка — «Язгы авазлар», «Ике буйдак», «Сынау» трилогиясе һәм «Ямашев» романы өчен; РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты Е. А. Кузинга һәм ТАССРның халык артисты Ю. С. Федотовка — В. И. Качалов исемендәге Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан дәүләт Зур рус драма театрында «Большевиклар», «Изгеләрнең изгесе» һәм «Астория» кунакханәсе» спектакльләрендә башкарган рольләре өчен; архитекторлар группасы җитәкчесе Г. А. Бакулинга, инженер-төзүчеләр Ә. З. Зәкиевкә, И. П. Парамоновка, бизәү эшләре мастерлары Ә. Н. Фәйзуллинга, С. Ш. Хисаметдиноватга — Казан шәһәрендә ТАССР Художниклар союзының күргәзмә залы бинасын проектлау һәм төзү өчен Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре бирелгән иде. ТАССР Министрлар Советында 1981 елгы лауреатларга дипломнар һәм значклар тапшырылды. Республикабызның бу югары бүләкләрен ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары, Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты председателе М. Х. Хәсәнов тапшырды. Ул яңа лауреатларны кайнар котлады, аларны совет халкының героик казанышларын талантлы сурәтләгән әсәрләр иҗат итәргә, замандашларыбыз образларын калку гәүдәләндерергә, чорга лаек архитектура чишелешләрен тормышка ашырырга һәм, гомумән, республиканың әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә тагын да зуррак өлеш кертергә чакырды.

Бүләкләнүчеләр иҗат кешеләренә карата даими кайгыртучанлык күрсәтүләре өчен партия һәм хөкүмәтебезгә чын күңелдән рәхмәт белдерделәр, киләчәктә дә күп милләтле совет культурасын үстерү хакына нәтиҗәле эшләячәкләренә ышандырдылар.

Премияләр тапшыру тантанасында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында ачык партия җыелышы уздырылды. Җыелыш Татарстанда Каракалпакстан АССР әдәбияты һәм сәнгате көннәре йомгаклары, урак өстендә язучылар алдында торган бурычлар, Татарстан язучыларының ГДРда булып кайтулары турындагы мәсьәләләрне карады. Докладлар белән Гариф Ахунов, Фәрваз Миңнуллин, Рафаэль Мостафин иптәшләр чыкты. Фикер алышуларда Сибгат Хәким, Рәйсә Ишморатова, Габдулла Шәрәфетдинов, Роберт Миңнуллин һәм Харрас Әюпов катнашты.

Җыелышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин булды һәм чыгыш ясады.

## ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ — УКУЧЫЛАРГА

Татарстан китап нәшрияты 1982 елда да укучыларны яңа китаплар белән куандырачак. Аларның күпчелеген матур әдәбият китаплары алып торачак. Замандашларыбызның матур эшләрен, бәхетле тормышларын, якты киләчәкләрен чагылдыручы китаплар арасында проза, поэзия, әдәби тәнкыйть, очерк һәм публицистика укучыларның игътибарын аеруча җәлеп итәр дип уйлыйбыз. Нәшрият балалар әдәбиятына да зур урын бирә. Без түбәндә шул китапларның кайберләре белән укучыларны таныштырырга булдык.

Проза һәм пьеса китаплары:

Мирсәй Әмир. **Хатирәләр урманы.** Күренекле язучының автобиографик повесте.

Диас Вәлиев. **Язмышның чарасы бер генә.** Җыентыкка драматургның театрларда уйналган билгеле пьесалары тупланган.

Әхәт Гаффар. **Язлар моңы.** Бүгенге авыл тормышына багышланган драмалар һәм бер пәрдәле пьесалар.

Аяз Гыйләҗев. **Җомга көн кич белән.** Китапка язучының соңгы елларда авыл кешеләренә багышлап язган яңа повестьлары кертелгән.

Марсель Зарипов. **Үзеңнеке — үзәктә.** Татарстан нефтьчеләре турындагы повесть.

Риза Ишморат. **Сайрасын тургайлар.** Колхозчыларның бүгенге матур тормышларын тасвирлаган документаль повесть.

Мәдинә Маликова. **Узма, гомер!** Китапта язучының замандашларыбыз хакындагы хикәяләре урын алган.

Туфан Миңнуллин. **Кырларым, туйгаларым.** Илебезнең бик күп театрларында уңыш белән барган пьесалар тупланмасы.

Кояш Тимбикова. **Тәңкәле тау.** Повестьлар китабы.

Ризван Хәмид. **Кайтыр идем.** Пьесалар.

Фәнис Яруллин. **Һәркемнең үз сукмагы.** Лирик һәм юмористик хикәяләр китабы.

Гадел Кутуй. **Илһам.** Повестьлар һәм хикәяләр.

Разил Вәлиев. **Яшисе килә.** Рифкать Миргазизовның батырлыгы турында повесть.

Гариф Галиев. **Без — авылныкылар.** Хикәяләр җыентыгы.

Хисам Камалов. **Бердәнбер ул.** Батыр танкистка, аның иптәшләренә багышланган повесть һәм Бөек Ватан сугышы турындагы хикәяләр җыентыгы.

Рәфкать Кәрами. **Ашкыну.** Химкомбинат тезүче яшьләр тормышыннан алып язылган повесть.

Шамил Рәкыйпов. **Аяз күктә карлыгачлар.** Яңа документаль-драматик повестьлар һәм очерклар китабы.

Лирон Хәмидуллин. **Онытылмас сукмак.** Повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы.

Кави Латыйпов. **Нәни Чапай.** Гражданнар сугышының легендар герое В. И. Чапаевның балачагы һәм яшьлек еллары турында повесть.

Зәки Нури. **Үлгәннәр дә үч ала.** Партизан хикәяләре.

Фаил Шафигуллин. **Бәхет йолдызы астында.** Повестьлар һәм хикәяләр.

Поэзия китаплары:

Гәрәй Рәхим. **Мәхәббәтем турында җыр.**

Гөлшат Зәйнәшева. **Җырчы миләш.**

Әхмәт Рәшитов. **Киек каз юлы.**

Марс Шәбаев. **Ак тынлык.**

Лена Шакирҗанова. **Мөлдерәмә күңел.**

Рәфыйк Юнысов. **Вакыт чылбыры.**

Нури Арсланов. **Иделем — илем.**

Әхмәй Ерикәй. **Ике йөз җыр.**

Рөстәм Мингалим. **Шигырьләр, поэмалар.**

**Без яшибез совет илендә.** Коллектив.

Илдар Юзеев. **Мәхәббәт китабы.**

Рәдиф Гатауллин. **Йөрәк сойли.**

Хәйдәр Гайнетдинов. **Ут теле.**

Әхмәт Гадел. **Көмеш кыңгы җыры.**

Галимҗан Латыйп. **Җир җыры.**

Фәннур Сафин. **Тынлык.**

Әдәби тәнкыйть китаплары:

Мансур Вәлиев. **Табарга һәм югалтмаска!**

Тәлгат Галиуллин. **Безнең заман — үзе җыр.**

Рәис Даутов, Нәзәһәт Нуруллина. **Совет Татарстаны язучылары.**

Ринат Мөхәммәдиев. **Татар әдәби тәнкыйтенең формалашу проблемалары.**

Хатип Госман. **Олы юлга чыкканда.**

Суфиян Поварисов. **Тел — күңел байлыгы.**

Балалар өчен китаплар:

Шәүкәт Галиев. **Канатлы малай.** Шигырьләр.

Роберт Миңнуллин. **Айга очтык!** Шигырьләр.

Газиз Мөхәмматшин. **Без әле җирдә яшибез.** Повестьлар.

Афзал Нигъмәтуллин. **Кояш нигә кызара!** Шигырьләр.

Клара Булатова. **Марс китабы.** Шигырьләр.

Габделхәй Сабитов. **Айбаш.** Хикәя.

Саҗидә Сөләйманова. **Кем уяткан Ләйләне!** Шигырьләр.


Болардан тыш тагын Җәлил турында Рафаэль Мостафинның «Өзелгән җыр эзеннән», Шәмси Хамматовның «Муса Җәлил — партия солдаты», Исхак Зәбировның «Җәлил һәм җәлилчеләр» исемле китаплары, Самат Шакирның «Исемнәре мәрмәрдә» дигән очерклар җыентыгы, «Советлар Союзы Геройлары» исемле китапның беренче кисәге, «Татар халык иҗаты» сериясеннән «Бәетләр» китабы, «Идел» альманахының чираттагы саны, «Күңелле сәхнә» җыентыгы, Чаллы язучыларының проза китабы, татар язучыларының рус теленә тәрҗемә ителгән яңа китаплары дөнья күрәчәк. Гариф Ахуновның (дүрттомлык) икенче томы, Гомәр Бәшировның (дүрттомлык) икенче томы, Мәҗит Гафуриның (дүрттомлык) өченче томы, Кави Нәҗминең (дүрттомлык) икенче томы, Һади Такташның (өчтомлык) өченче томы, Рафаэль Төхфәтуллинның (икетомлык) беренче томы укучылар кулына барып ирешәчәк.

Укучылар, шулай ук мәктәпләр, китапханәләр үзләренең заказларын турыдантуры «Книга-почтой» кибетенә җибәрә алалар. Кибетнең адресы: г. Казань, ул. Октябрьская, дом 18, магазин № 14, «Книга-почтой».

# Туган якта һәр тал җырлый

ӘГЪЗАМ ФӘТТАХ музыкасы

СИБГАТ ХӘКИМ шигыре




Туган якта һәр тал җырлый,
2 Җырлый таллар таңгача.
Җырлый таллар, яна йөрәк,
Нигә йөрәк, янмаса?

Туган якта һәр тал җырлый,
3 Җырлый һәр тал үзенчә.
Җырлый таллар, нишләр ярлар,
Бер көн җырлар өзелсә?!

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!**

Озак та үтмәс, сезнең кулга журналның быел басылачак соңгы 12 нче саны килеп керер. Нинди яңа әсәрләр белән шатландырыр, әдәбият өчен мөһим нинди мәгълүматлар бирер ул?

Алдан ук әйтеп куйыйк, декабрь ае күренекле язучыларыбызның туган көннәренә бик бай: К. Нәҗминең тууына — 80 ел, Г. Әпсәләмовның тууына — 70 ел, С. Хәкимгә — 70 яшь, З. Нурига — 60 яшь, Ю. Әминовка 60 яшь тула. Бу уңайдан журналда фәнни мәкаләләр дә, истәлекләр дә, әдипләрнең үз иҗатларыннан үрнәкләр дә күп басылачак.

Проза бүлеге укучыларга язучы Вакыйф Нуруллинның «Һәлакәт» исемле яңа повестен тәкъдим итә. Әсәр кайбер замандашларыбызның үз-үзләрен тотуда җибәргән аяныч хаталары өчен борчылып, яман юлга аяк басуның нидән килеп чыгуын аңлатырга тырышып, шул хәлләрне мавыктыргыч вакыйгалар һәм образлар аша тасвирлап язылган. Автор гүя укучыны, чорга лаек буласың килсә, тормышыңны үкенмәслек итеп кичәргә теләсәң, повестьтагы төп образ сыман яман юлга баса күрмә, дип кисәтеп куя.

Шигырь сөючеләр бу санда С. Хәким, Ш. Галиев, С. Гәрәева, Л. Зөлкарнәев кебек шагыйрьләребезнең яңа әсәрләре белән танышачаклар.

Очерклар һәм публицистика рубрикасында М. Рафиковның «Язмышлар», Т. Әйдинең «Аталар һәм уллар» исемле язмалары урнаштырылган.

Тәнкыйть бүлегенә кергән мәкаләләрнең күбесе алда телгә алынган юбилярлар иҗатын анализлауга багышланган.

Моннан тыш «Китап күзәтү», «Төрлесеннән», «Укучы сүзе», «Елмаеп та, көлеп тә...», «1981 елда журналда басылган әсәрләр», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» рубрикаларына кертелгән язмалар да укучыны кызыксындырыр дип ышанабыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210